ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2007



# МӘҢГЕЛЕК ШӘҺӘРЕБЕЗ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН



*Бауман урамында нәшрият йорты.*
*30нчы еллар.*



*Кәҗә дамбасында (хәзерге Ленин дамбасы) төзелеш эшләре.*
*50нче еллар.*

*XX гасырда алынган фотосурәтләр.*
*Абдулла Дубин коллекциясеннән.*

# Казан утлары
# Qazan utları

*2007*

# 12
(1022)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рәшат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әхсән БАЯН. Без күрмәс еракларга... *Шигырьләр.* ........ 5
Нурихан ФӘТТАХ. Аклан. *Хыялый роман.* ........ 9
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Соңгы еллар дәфтәреннән. *Шигырьләр.* ........ 42
Альберт ХӘСӘНОВ. Кызлар күрсәм... *Хикәя.* ........ 48
Зиннур ХӨСНИЯР. Дисбе җебе өзелгәчтен. *Шигырьләр.* ........ 61
Әхәт САФИУЛЛИН. Көтелмәгән очрашу. *Хикәя.* ........ 64

**ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ ЯШӘҮЧЕ КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ**

Ринат БАТТАЛОВ. Көтү. *Шигырьләр.* ........ 69
Ибраһим БИЕКТАУЛЫ. Мизгелләр. *Шигырьләр.* ........ 70
Гөлфия ИСХАКОВА. Кабат язлар килә. *Шигырьләр.* ........ 72
Зөһрә ВӘЛИ. Урланган төн. *Хикәя.* ........ 73
Эльмира НИГЪМӘТҖАН. Дусларыма. *Шигырьләр.* ........ 76
Гыймран САФИН. Нәсел агачы. *Шигырьләр.* ........ 77

**ПУБЛИЦИСТИКА**

I Бөтендөнья татар галимнәре форумы. ........ 78
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Гасырлар чатында... ........ 79
Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Мөһаҗирлектәге татар әдәбияты. ........ 84
Ирек САБИРОВ. Фикер бөртекләре. ........ 120

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рифат СВЕРИГИН. Тормыш чоңгыллары һәм тарих төпкелләре аша... ........ 90
Фәрит БӘШИР. Ачыдыр хакыйкать юлы... ........ 97
Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Аның сукмагы. ........ 114

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ........ 132
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ........ 137

**ХӘТЕР**

Тәлгат НӘҖМИЕВ. Биш очрашу. ........ 144
Ростәм АКЪЕГЕТ. Күңелендә яшерен гамь бар иде. ........ 150

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рашат НИЗАМИ. Яшәү тамыры... тирәндә. ........ 157

**ЮМОР-САТИРА**

Ростәм ЗАРИПОВ. Тукай күчтәнәче. ........ 170
Ринат МӘННАН. Шигырьләр. ........ 174
Ростәм ГАЛИУЛЛИН. *Шаян хикәяләр.* ........ 176

Берлекнең яңа әгъзалары. ........ 178
2007 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге. ........ 180
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Н. ФАТТАХА «Аклан» (продолжение); рассказы А. ХАСАНОВА, А. САФИУЛЛИНА; стихи А. БАЯНА, Р. ФАЙЗУЛЛИНА, З. ХУСНИЯРА.
«Творчество татарских поэтов и писателей Удмуртии»: стихи Р. БАТТАЛА, И. БИЕКТАУЛЫ, Г. ИСХАКОВОЙ, Э. НИГЪМАТУЛЛИНОЙ, Г. САФИНА, рассказ З. ВАЛИ.
«Публицистика»: «I Всемирный форум татарских ученых»; статья Т. ГАЛИУЛЛИНА «На рубеже веков»; статья Х. МИННЕГУЛОВА «Татарская литература Зарубежья»; И. САБИРОВ. «Мысли вслух»
«Литературная критика»: статья Р. СВЕРИГИНА к 80-летию писателя М. Хабибуллина; статья Ф. БАШИРА к 70-летию Ф. Яруллина, статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА к 80-летию М. Хасанова.
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение); Ф. ГАРИПОВА «История наших деревень» (продолжение).
«Память»: Т. НАЗМИЕВ. «Пять встреч»; статья Руст. ФАЙЗУЛЛИНА к 70-летию З. Насыбуллина.
«Книжное обозрение»: рецензия Р. НИЗАМИ на книгу Н. Гамбара «Корень жизни».
«Юмор-сатира»: рассказы Р. ЗАРИПОВА, Р. ГАЛИУЛЛИНА, стихи и эпиграммы Р. МАННАН.
В номере отмечается 80-летие С. Шакурова, 90-летие С. Урайского.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2007 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зимний лес»; поэт Рамис АЙМЕТ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by N. FATTAH «Aklan» (continuation); stories by A. HASANOV, A. SAFIULLIN; verses by A. BAYAN, R. FAYZULLIN, Z. HUSNIYAR.
«Creativity of Tatar poets and writers from Udmurtia»: verses by R. BATTAL, I. BIEKTAULY, G. ISHAKOVA, E. NIGMATULLINA, G. SAFIN, story by Z. VALI.
«Publicism»: «1st World forum of Tatar scientists»; article by T. GALIULLIN «On boundary of centuries»; article by H. MINNEGULOV «Tatar literature of abroad»; I. SABIROV. «Think aloud»
«Literary criticism»: article by R. SVERIGIN to 80th anniversary of writer M. Habibullin; article by F. BASHIR to 70th anniversary of F. Yarullin, article by F. GALIMULLIN to 80th anniversary of M. Hasanov.
«Science»: A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation» (continuation); F. GARIPOVA «History of our villages» (continuation).
«Memory»: T. NAZMIEV. «Five meetings»; article by Rust. FAYZULLIN to 70th anniversary of Z. Nasybullin.
«Book review": review by R. NIZAMI on book by N.Gambar «Root of life».
«Humour-satire»: stories by R. ZARIPOV, R. GALIULLIN, verses and epigrams by R. MANNAN.
In issue is celebrated 80th anniversary of S.Shakurov, 90th anniversary of S.Uraysky.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.11.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С–1499 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2007 ел.

Şigriət
Шигърият

Әхсән Баян



# БЕЗ КҮРМӘС ЕРАКЛАРГА...

## Бурыч

Дөнья минем теләк белән
Бармаганга үртәлеп:
Шөкер, димен, уйлый алам,
Елый алам бит әле.
Теләкләрнең чиге җитте.
Гомер шулай үтә дип.
Тынычландырам димәгез,
Алар түгел бетәрлек...

«Экологик, алкоголик
Хәл»дән корый теңкә бик,
Оныкның да оныклары
Бездән ярдәм көтә бит.

Бурычларны үтәмичә,
Китикмени иртә үк?
Калсын җирдә шундый саф су—
Уйламыйча эчәрлек.

Калсын бездән шундый һава,
Суларлык шикләнмичә.
Дөньядан шунда китәрбез,
Ишекләр бикләмичә.
Беләм, бик тә сез beләсез,
Яшәү түгел шикәр үк.
Тозсыз булсаң, йөрисе юк,
Кеше исеме күтәреп.

## Тузган дөнья

Кала—шатлыкка ашырды
Күпме кешенең зарын:
Җимереп тузган торакларын,
Төзеде яңаларын...

Ә зур дөнья калды җимерек,
Сырхау ул... Ахры, шуңа,
Килми ашыгып барасым
Раббыбыз каршысына.

Җирдә кешелек йортының
Түшәме, кирпечләре,
Төшеп өскә, калсак күмелеп,
Коткарырлык көч бармы?

Калтыравык бу бинаның
Түбәсе күптән кыйшык.
Эче тулы канлы төтен,
Сулый адәм ут йотып.

Төзәтсен дөнья ярасын,
Дауларны тыя алсын.
Явызлык шунда иячәк
Үч, мәкер тулы башын.

Шул көнне килә күрәсем,
Тезләнеп сорыйм даим:
—Тузган дөньяны сипләргә
Бирче дәрман, Ходаем!

## Шагыйрь язмышы

*(Мостай Кәримне укыганда туган уй)*

Ул күп йөрде дөнья буйлап,
Җир шарын чыккандыр айкап.
Бәллүеннән киткәч ерак,
Җир дә тар булгандыр кайчак.

Сыеп бетте шагыйрь гомере
Киштәләрнең тынлыгына.
Илне иңләп йөри хәзер
Җәрәхәтле җыры гына.

***

Зәңгәр балкышлар астында
Яшел чыршы чайкала.
Җил белән бергә җилпенеп,
Очмакчыдыр кай таба.

«Әйдә, китик!»—ди, өстеннән
Карларны кага-кага:
«Чал төсләрне син дә шулай
Төшер коеп, тап чара».

«Китсәк, кичке шәфәкъ алда
Тоташыр алсу таңга.
Сагышлар калыр кичләрдә,
Шул булыр җанга дәва»

Имин еллар теләп калам
Чыршыга, наратларга.
Уйлар китә узганнарга—
Көлгән, сөйгән чакларга.

Ымнарны авазга сала
Кычкырып ала карга.
Төсен саклап, ул да бара
Без күрмәс еракларга.

## Җил

Ай көнләшердәй иде кыз,
Үзе дә шуны белде.
Буй җиткәч, патша егете
Килер әле, дип йөрде.

Актылар, һай, күпме сулар,
Җилләр сөеп уздылар.
Кершәннәр инде, буяулар
Ярдәм итмәс булдылар.

Чырайдагы сары төсләр
Теләкләрне үзгәртте.
Аңлады кыз, дөньядан без
Көтәбез шул күбрәкне.

Ул көткән патша егете
Җирдә булмаган икән.
Кыз бер көн, бөтен өметен
Җуеп, шулай хәл иткән:

«Өйгә кем керсә беренче,
Юлдаш итәм шуны мин».
Ишетеп, ачык ишектән,
Кергән килеп... шомлы җил.

Ә шомлы җил һич тә таныш
Түгел—килгән чит җирдән:
Ул икән ерак океанда
Кораблар батырып йөргән!

## Таш

Рәссамны бит сез беләсез,
Ул, әйтерсең, сихерче.
Ясый адәмнәр сурәтен,
Соклана күргән кеше.

Үз илендә, үз җирендә,
Юып дәрья суында,
Чуер ташлар өеп куйса,
Тере төсле тоела.

Булды шулай, булды чын, әй,
Таш сынга ул җан өрде.
Ышан, кара, синең алда—
Таш түгел, кеше инде.

Җанлы ташка әйтте рәссам
Шатланырлык сүз инде:
—Мин ни тойсам, син тоярсың,
Мин—ул хәзер син инде.

Ә таш кеше?... Яшьләр түкте,
Шашкан заманга карап:
—Илаһым, сорыйм, тезләнәм,
Син таш ит мине кабат!!.

***

Минем алда, зинһар, еламагыз,
Авыр булса да бик кайгыгыз.
Күз яшьләре күрсәм, мин дә елыйм,
Зинһар, шуны искә алыгыз.

Ярдәм итәр идең, килми кулдан,
Аяклардан мине шул ега.
Булмас кебек моңардан да авыр,
Моңардан да ачы фаҗига.

## Юк булды

Танышулар, табышулар күп булды,
Үпкәннәрем, кочканнарым юк булды.
Җилләр белән очканнары рас, диде,
Әйтте тормыш, инде табылмас, диде.

Еллар әллә чоңгылларда йотылды,
Ай шикелле, Кояш төсле тотылды?..
Бергә үскән яшь сылулар?... Юк булды.
Калды бары уйлар гына моң тулы.

Әй, дөнья, дим, сөйгәннәргә сереңәйт,
Шулай гына була әллә мәхәббәт?
Ургый чишмә, ә бит мәңге мул сулы!
Яшәү, гомер дигәнебез—ул чынмы?!

Әллә төтен, әллә инде ут булды,
Юк булды...

***

Ташладың да киттең, бәгырь,
Җаным мәңге тилмерер.
Авыр сүз дә әйткәнмендер,
Ишеткән ким түгелдер.

Төрлесе булгандыр, бәгырь.
Хаталардыр күбесе.
Уртак иде бөтенесе—
Яратулар билгесе.

Яхшымы, әллә яманмы—
Сәбәпче бит мәхәббәт.
Хәзер нәрсә ишетсәм дә,
Әйтер идем мең рәхмәт.

Син кире кайт бу дөньяга,—
Яшәмәдек туешып:
Ялгыз ничек кичим? Алда—
Инеш түгел, тормыш бит.

## Аккош мәхәббәте

Гомер буе аккош мәхәббәтен
Бөек максат диеп сакладым.
Ә ул калды җырда, моңнарымда,
Ә тормышта үзен тапмадым.

Ә тормышта аккош мәхәббәте,
Һава ярып, кайчан яңгырар?
Тавышлары китеп адаштылар,
Кайтмаскамы китеп бардылар?

Соңгы аккош җыры туар әле,
Гомер хакы торган яр булса,
Биек ярдан ташка ташланырлык
Мәхәббәтнең тиңе табылса.

## Манара

«Сөембикә» ава диләр,
Авып ил башын тишсә?
Манарабыз ава дисәң,
Төшә инкыйраз искә.

Ауса авар инде диеп,
Күтәбезме авасын?
Кирпечләрен җыя-җыя,
Кемнәр салыр яңасын?

Кем коткарыр манараны?—
Кем булсын бездән бүтән?!
Манарада милләт төсе,—
Тоташкан алар күптән.

Безнең өмет төсле ае
Югала да яңара.
Кояш чыгуын чиркәү аша
Үрелеп карый манара.

Мин халкымны уйлап, озак
Карап торам аңарга.
Болытлар буйлап ул бара
Кайларгадыр... Кайларга?!

*2006—2007*

**Редакциядән:**

***Бу айда Татарстанның халык шагыйре, журналыбызда дистә еллар җаваплы сәркатип, баш редактор урынбасары вазифаларын башкарган элекке хезмәттәшебез, даими авторыбыз Әхсән Баянга 80 яшь тулды. «Казан утлары»ның күпсанлы укучылары исеменнән әдипне ихлас котлап, аңа сәламәтлек, яңа иҗади уңышлар телибез.***

Нурихан
Фәттах

# АКЛАН

ХЫЯЛЫЙ РОМАН

* * *

Борынгылар ташка язып калдырган кануннардан читләшү кайчан башлангандыр—төгәлен генә беркем дә белми. Кайберәүләр әйтә, элекке заманда борынгылар сүзеннән чыгу булмаган, читләшү ул әлерәк кенә башланган ди. Мондый чакта гадәттә мака сар Карунга төртеп күрсәтәләр, мака сар Карунның тетмәсен тетәләр. Мака сар Карунның тетмәсен тетми дә булмый. Аклан иленә Карун сар китергән зыянны, талауны, кыланышны берни белән дә чагыштырып булырлык түгел. Тигез таш җәелгән туры юллар салдырып, әле анда, әле монда алтынланган биек сарайлар, манаралар утыртып, туктаусыз зур-зур кәмәләр, сугыш кораллары ясатып Карун бөтен илнен җелегән корытты. Үз кешеләре белән, үз алтыны-көмеше белән ясатса, билгеле, беркем аңа бер сүз әйтмәс иде, рәхмәт әйтеп читтән генә карап торыр иде. Юк шул! Мака сар Карун бөтен илне аякка бастырды, көлле кешенең амбарына кулын тыкты, байлыгына кул сузды, иң яманы аның шул булды. Шуна күрә дә Карун эшләгән барлык эшләр бик күпләргә беренче мәртәбә борынгылар сүзеннән читкә чыгу булып тоелды. Әллә кырык, әллә утыз ел буена ул туктаусыз җир асты сарайлары, амбарлар салдырган. Салым түләү, ясак җыю исәбенә җыелган, казып алынган, талап алынган, урлап алынган бар байлыгын менә шул җир асты сарайларын, амбарларын бизәүгә тотып барган. Сарайлар, амбарлар бизәлгәч исә, калган барлык алтын-көмешне, энҗе-мәрҗәнне, кием-салымнарны шунда тутыра башлаган. Карун, имеш, шул дәрәҗәдә саран, катмыш булган—мака сар булса да үзе көтүчеләр, каралар кебек көн дә сыра эчкән, арпа боткасы ашаган, әче алма кимергән һәм биленә таушалып беткән алъяпкыч бәйләгән, шәрә йөргән. Юк, кулында, имеш, алтын башлы шома таягы да булган. Сарлык билгесе. Үзе, имеш, агачтан салынган кечкенә йортта яшәгән, көн дә, имеш, бакчада казынган. Хатыны да, имеш, бер генә, балалары күп булган. Янында бернинди кораллы сакчысы булмаган, кая теле шунда тәпи-тәпи җәяү йөргән.

Чынында ничек булгандыр, ансын инде беркем белми. Шулай да, тилемилерәк булса да, Карунны гел хурлап, гаепләп тә булмый. Борынгылар ташка язып калдырган кануннар арасында «алтын җыймаска», «җир астына сарайлар салмаска» дигән бернинди сүз юк. Ул язулы ташларны да, башка борынгы язуларны да Тажит ага кат-кат укып карады, ләкин аларда мака сарнын эшләгән эшләрен юкка чыгарырдай берни тапмады. Эшләрен алай җинел генә юкка да чыгарып булырлык түгел, чөнки Карунның җир асты сарайларының, алтын-көмеш тутырылган амбарларның кайда икәнлеген беркем белми.

*Ахыры. Башы 10 санда.*

Каруннан соң аның урынына килеп киткән мака сарлар да, угры-караклар да әз тырышмаганнар ул җир асты байлыкларының эзенә төшәргә. Акланның, тураның казып каралмаган, актарып каралмаган бер төшен калдырмаганнар, борынгы сарайлар астына, коймалар астына төшкәннәр, кеше күп җыела торган теләсә кайда ишетелә торган һәр яна имеш-мимешкә колак салганнар, иске йорт урыннарын тикшереп чыкканнар.

Дөрес, изге тауда ниләр эшләнүен күпләр белеп тә житкерми. Изге тауда— сарай өстендә сарай, таш амбар өстендә таш амбар дигәндәй. Анда җирнең һәр карышы—изге. Шуңа күрә анда тора салып казый да алмыйсың, кирәкмәгәнгә нинди дә булса яңа корылма да кора алмыйсың. Шулай да анда да туктаусыз эш бара. Тура халкына сиздермәскә тырышып әле анда, әле монда тирән-тирән коелар казып карыйлар. Җир асты юллары салалар. Карун байлыгы турындагы имеш-мимешкә ышанмаучылар да булган. Алар әле дә бар. Кайбер сарлар Карун исемен ишетергә дә теләмәгәннәр һәм, буш хыял белән шөгыльләнмичә, ничек тә үзләре нинди дә булса зур эшләр башкарырга һәм шул рәвешчә үз исемнәрен мәңгеләштерергә тырышканнар.

Тажит ата яхшы белгән мака сар Карман да Карун байлыгына кызыкмады, үзең белгән мал кадерлерәк дип исәпләде. Егерме биш ел буена Тажит ата Карман сарның иң ышанычлы яраны булды, егерме биш ел буена аңа турылыклы хезмәт итте. Мака сарның теләгенә туры китереп ул яңа сарайлар, корылмалар салдырды, сугыш көмәләре ясатты, елгалар, тар үзәннәр аша күперләр күтәреп, тау-ташларны кистереп, туры юллар салдырды. Аклан иленең, Аклан утравының көньягыннан төньягына сузылган, чакрым саен таш багана утыртылган туры юлны да Тажит төзүче салдырды. Бу аның да, мака сар Карманның да үз гомерләрендә соңгы зур эшләре булды. Аклан утравын көньяктан төньякка таба урталай ярып үтәргә тиешле туры юл Актауга житеп беркадәр җир киткәч тә, төгәлләнмичә тукталып калды. Моннан тугыз ел элек тә, нәкъ бүгенге сыман ул көнне Турадан көтмәгәндә чапкын килеп төште һәм «Мака сар Карман күчте» дигән күңелсез хәбәр әйтте.

Ил башлыгы мака сар күчкән көннән башлап бөтен илдә өч көнгә эш туктатыла, кырык көнгә һәртөрле уен-көлке, күңел ачу тыела иде. Монда да кинәт бөтен нәрсә тынып калды. Урман кисүчеләр урманнан чыктылар, таш кисүчеләр тау арасыннан чыктылар. Таш түшәүчеләр, түшәлмәгән ташларын, коралларын калдырып шулай ук читкәрәк киттеләр, ачыктан-ачык сөенә башладылар. Иртә таннан кичкә кадәр баш күтәрми бил бөккән коллар, каралар гына түгел, кораллы сакчылар, күзәтчеләр дә күңелсез хәбәрдән соң ничектер туарылып, бушанып калгандай булдылар. Күпчелек шулай исенә-акылына килә алмаганда, кайбер усалраклар, яшьрәкләр тизрәк моннан ычкыну ягын карадылар. Соныннан, тикшереп карагач, утызлап кешенең качып киткәнлеге билгеле булды.

Юл төзүдәге каралар да, сакчылар да тулысынча Тажит атага буйсыналар иде. Ул үзе турыдан-туры мака сар Карманга гына буйсына иде. Менә хәзер ул юк. Ул инде ерак юлга чыккан. Аны куып житү, аның белән сөйләшү-аңлашу мөмкин түгел. Моңарчы ул үзенең сөекле яранын теләсә кемнән, теләсә нинди көтелмәгән хәлдән яклап-саклап килде. Кояш артык кыздырганда ул аның өчен җиләс күләгә булдырды, өстән яңгыр койганда ышанычлы түбә булды. Ачыкканда ул аның тамагын туйдырды, сусаганда су бирде. Инде аны хәзер кем яклар да, кем саклар?

Чапкын авызыннан күңелсез хәбәр ишеткәч тә, Тажит ата иң элек үзе турында, үзенең Турадагы ике катлы таш йорты, анда калган җәмәгате, кызлары, балалары, коллары турында уйлады. Аннан да бигрәк ул шул турыда борчылды: Карман сар урынына кемне сайлап куярлар мака сар итеп? Ул, билгеле, бу турыда да белмәде түгел—белде. Моны бөтен ил халкы белеп

торды. Аклан иленен башы булып Карманнан кечерәк, ләкин калган өч туган арасында өлкәнрәк булган Аланча сака гына кала ала иде. Ләкин бозыклыгы, җинел акыллылыгы белән бөтен илгә, бөтен тирә-якка даны таралган Аланчаны һич тә Акланның мака сары итеп күрәсе килми иде.

Мака сар Карман илнең көньягыннан төньягына туры таш юлны тикмәгә генә салдырмады, билгеле. Аклан утравының иң төньяк төбәгендә, кәмәләр туктап тору өчен җайлы, яр буе булган Саба авылы янында ул монарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән эшләр башлап җибәрергә исәпләде. Саба авылы янында ул кимендә ике-өч мең кешелек яңа тура корырга, шунда ук яр буендагы кыяларны кисеп, сугыш кәмәләре өчен иркен куыш ясатырга булды. Алай-болай диңгез юлбасарлары яисә анда ерактагы күршеләр көтмәгәндә килеп басмасыннар өчен, төньяктагы яр буйларында җитәрлек каләр көч тотарга кирәк иде. Монарчы бер-ике мәртәбә төньяктан акайлар, шул ук Саба янында төшеп, яр буен талап киткәннәр иде инде. Мака сар Карманның юл салдыруын күпчелек игенчеләр, терлекчеләр якламаса да, аның кирәклеген аксөякләр аңламый булдыра алмадылар. Илне саклау өчен сугыш кәмәләре дә, тауга уеп ясалган тау куышлары да, яңа тура да, туры юл да—барысы да, әлбәттә, кирәк иде. Ләкин икенче төрле фикер йөртүчеләр дә бар иде. Шулай фикер йөртүчеләр арасында Акланның дин башлыгы пир ата Мәнзүм дә бар иде. Ул, билгеле, мака сар теләгенә дә каршы килә алмады, ул шулай ук Аклан илендә туры юллар салуга да каршы түгел иде. Ул бары туры юлның Актау капкасына тия язып, якыннан гына узып китүенә каршы иде. Тигез юл салынса бөтен илдән монда ярлы-ябагай агылыр. Актау тормышында кирәкмәгән борчулар башланыр дип курыкты ул. Аның исә соңгы көннәрен тыныч кына зекер әйтеп, келәү әйтеп, һәр туар көнне алкышлап тыныч кына уздырасы килә иде. Таҗит төзүче Мәнзүм атаның борчуларын, куркуларын бик яхшы аңлады. Шуна күрә ул аның үзе белән сөйләшеп карамакчы, юлның ил өчен бик кирәк булуын аңлатмакчы булды. Ләкин ул чакта аның белән бернинди яхшылап сөйләшү була алмады. Пир ата Мәнзүм аны, мака сарның ышанычлы яранын, куштанын, колын тыңларга да теләмәде. Шулай да әйтте:

—Ил кайгысын мин генә кайгыртам икән дип ялгыша күрмә—Ил кайгысын без дә кайгыртабыз. Төнне Кара кыяда янган утны күрәсеңме? Күрсән, шул—ул ут безнең Акланның сере. Аның серен белергә, аны сүндерергә, кыяны җимерергә тырышып каручылар әз булмаган. Туры юлыгызны диңгез ярына илтеп чыгарсагыз, диңгез ягыннан да тагын ут белән кызыксынучылар килеп чыкмас дип кем әйтә ала?

—Анда, диңгез буенда көчле сак булачак, изге ата,—диде ул чакта төзүче Таҗит пир ата Мәнзүмгә.—Угрыдан куркып юллар салдырмыйча да булмый, изге ата,—дип тә өстәде ул.

Ул чакта алар арасындагы сөйләшү шуның белән тукталып калды. Икенче мәртәбә Таҗит төзүче пир ата Мәнзүм белән башкачарак шартларда сөйләште. Чапкын турадан күнелсез хәбәр алып килгәч, ул кинәшергә дип туры Мәнзүм ата янына юнәлде. Бу дөньяда хәзер аның үзеннән һәм Мәнзүм атадан башка кинәшерлек беркеме юк иде. Кеше үлеменә сөенергә ярамаганлыгын белсә дә, яңа хәбәрне әйткәч Мәнзүм атаның йөзендә сөенеч сыман бер нәрсә чагылып калды. Ул хәтта ишетелерлек итеп җинел сулап куйды һәм тиз арада кыяфәтен үзгәртеп, кайгырган булып:

—Барыбыз да шунда барачакбыз,—диде.—Мака сар Карманның илгә-көнгә бик күп изгелеге тиде… Изге җаны авырлыксыз күккә ашсын, Атабыз катына барып ирешсен, төмән еллар йолдыз булып адашканнарга юл күрсәтеп балкып торсын,—диде.

Капка төбенә килеп җиткән юл эшенең тукталып калуына ул чын күнелдән

сөенеч белдерде. Соңыннан башын иебрәк, нидер әйтергә әзерләнеп торган Таҗиткә күтәрелеп карады да, ничектер көтмәгәндә әйтеп куйды:

—Синең эшләр шәптән түгел, улым—диде.

—Ник?—диде Таҗит төзүче, бик авырлык белән.

—Ник икәнен син үзең дә беләсең,—диде пир ата Мәнзүм.—Белмәгән булсаң, минем янга килеп тормас идең.

—Мин бәлки саубуллашырга килгәнмендер,—диде Таҗит, туры сүздән читләшергә тырышып.

—Юк, сиңа саубуллашырга ярамый, сиңа монда келәүлектә калырга кирәк,—диде пир ата.—Анда кайтсаң сине...

—Минем бер языгым да юк!—диде Таҗит, үз-үзен яклагандай итеп.

—Синең языклы булуың кирәкми дә,—диде пир ата. Аланча сака мака сар булса, Карман сака яклы һәркемне йә илдән сөрәчәк, яисә базар уртасында башын чаптырачак. Син аны да беләсең.

—Беләм! Ләкин минем анда йортым, җәмәгатем, балаларым. Мин аларны күрергә тиеш.

Пир ата Мәнзүм башка сүз озайтып тормады. Ул аны капкага кадәр озата килде.

—Алай-болай... Кайчан килсәң дә синең өчен капка ачык булыр,—диде ул.

Туктатылган эшне, туктаган, туарылган караларны һәм сакчыларны үзенең булышчысы карамагына калдырып Таҗит төзүче турага кайтып китте. Өендә аны дүрт күз белән көтеп торганнар. Бик нык кайгырып, борчылып көтеп торганнар. Ул кайтып кергәч, барысының да йөзе ачылып китте. Җәмәгате җылый-җылый муенына килеп сарылды, чыр-чу килеп, әти-әти! дип балалары урап алды, күрше бүлмәдән кызлар, асраулар, каралар йөгерешеп чыкты. Исән икән әле! Исән икән!—диде җәмәгате бер үк сүзне кабатлап.—Хәзер инде үлсәк тә, калсак та бергә,—диде. Әйе, ул кайткан көнне өйдә чын-чынлап бәйрәм булды—тәмлерәк, ятрак ашлар пеште, кешеләрнең сөйләшүендә, үзара мөнәсәбәтендә көн дә булмый торган бер күтәренкелек хөкем сөрде. Шул ук вакытта алар кайгы көненең бетеп житмәвен дә тоймый, анламый булдыра алмадылар—ул көннәрдә урамнарда кычкырып көлгән, сөйләшкән тавышлар ишетелмәде. Турада, бистәдә бары ниндидер тотып, аерып булмый торган чүелдек кенә тирбәнеп торды да, дингез ягында су кошларының чыелдык, кыска тавышлары гына ишетелеп-ишетелеп китте.

Ул көннәр Таҗит атаның хәтерендә шулайрак уелып калган. Аннан соң шунысы да истә: үз йортында, үзенең икенче катында, аулак бүлмәсендә берне куну белән, икенче көнне яңа хәбәр килеп житте: мака сар итеп Аланча саканы билгеләгәннәр!

—Уяндыгызмы? Торыгыз, тор!—дип кычкырды әниләре инәлеп яшь аралаш, бар көченә сөякчел куллары белән бүлмә ишеген шакылдатып.

Беренче булып урыныннан Нәфисә сикереп торды, аны-моны аңлашмыйча, өстенә дә киенмичә, ишеккә ташланды.

—Ни булган, әни, ни булган, ут чыкканмы әллә?!—диде йокылы тавыш белән куркып та, ачуланып та.

—Оятсызлар! Шул гомер йоклап яталармы?!—диде карт ана, күрәсең килененең шәрәлеген өнәмичә. Ачудан ул хәтта төкереп куйды.

Таҗит ул көнне юри эндәшми ятты. Эндәшмәсә дә, күз кырые белән генә ярым ачык ишек төбендәге тамашаны күзәтмичә булдыра алмады. Нәфисәнең озын кара чәчләре полтыранган, бер өлеше алдына, бер өлеше артына салынып төшкән, үзе чытырдатып бер кулы белән ишекнең жиз тоткасына тотынган, икенче кулы белән ишек яңагына тотынган. Арттан ул шундый сылу, күркәм. Бар жире түгәл, йомры. Нишләп алар затын алла шулай йомры да, тулы да, нәфис тә итеп яраткандыр, нишләп ир кеше генә

тупас та каты гынадыр. Яшьрәк чагында Тажит гел шул турыда уйлана иде. Үзе төзегән, салган сарайларга, манараларга, койма-капкаларга да ул һәрвакыт хатын-кызга хас күркәмлек, төгәллек бирергә тырыша һәм шул чагында һәрвакыт үзенең җәмәгатен, үзенең яна буй житкереп килгән Лиясен күз алдына китерә торган иде. Әнисенең тупаслыгын, әрсезлеген исә ул беркайчан анлый алмады. Менә шушылай таң тишегеннән улының, килененең ятак бүлмәсенә бәреп керүен гомумән күрәлмады. Ләкин ул көнне, ул иртәдә Тажит бернигә кысылмыйча тавыш-тынсыз һаман ята бирде—шул кадәр сагынып яратышудан соң, дөньяда инде барлык ямьсез нәрсәләр беткәндер сыман тоела иде.

Ләкин алай ук булмаган икән шул. Жебегән, булдыксыз улының әле һаман тыныч ятуына үч иткән сыман, карт ана, килененең яшь тәнен этеп-төртеп жибәреп, чәреллә бүлмәгә үк басып керде һәм бар нәрсәнең ямен, тәмен жибәреп:

—Аланча мака сар булган!—дип кычкырып жибәрде.

Шуннан соң бөтен нәрсә баш-аяк килде. Бәхетле ирнең күз аллары томаланып калды, жылы, татлы ятагы-ние белән, жиз тоткалы ишекләре, шәрә Нәфисәсе һәм карга тавышыдай ямьсез, бозык тавышлы анасы белән мәтәлеп, буталып ул каядыр упкынга ыргытылгандай булды.

—Алар килеп алып китканче, төялергә, китәргә кирәк!—диде әнисе.

—Кая? Ник?—диде Тажит, ниһаять урыныннан торып.

—Кая булсын—ил читенә!—дип кычкырды карт ана.—Кая булса да барыбер түгелмени?! Кәмәче белән сөйләштем, ул риза, кирәк булса ун кәмә дә бирә алам, диде.

—Чынлап сөйлисеңме син, әни?—диде Тажит, нәрсә турында сүз барганын яна төшенә башлап.—Көпә-көндезме, хәзер үкме? Кем чыгарсын безне турадан? Бүген, кайгы көнендәме?!

—Көн булмаса, төн бар!—диде әнисе.

—Уйлап карармын,—диде Тажит, әнисенең тизрәк бүлмәдән чыгып китүен теләп.

Ул чыннан да уйлады, теләр-теләмәс кенә уйлады. Ул иртәдә ана нишләптер бернинди кайгырыр нәрсә юк сыманрак тоелды. Йокыдан торгач, аның тизрәк балаларын, асрауларын, караларын күрәсе, өйараны чыгып карыйсы, кайбер нәрсәләрне карап беләсе килә иде. Шулай иренеп кенә таш сукмактан урам як капкага таба китеп барганда тышта, урамда якыннан гына узып китеп баручы арба тавышы ишетелде. Пар ат жигелгән жинел арба туп-туры аларның капкасы янында туктап калды һәм Тажит төзүче эчке яктан капкага килеп житкәндә, тышкы яктан да кемдер килеп житте һәм түземсезләнеп, бар көченә шакылдатырга тотынды. Хужа кеше, аны-моны уйларга өлгермичә, ашыгып барып капканы ачты һәм каршысында сарай йомышчысы Бабулны күреп аптырап китте. Ул чакта да Бабул кыскарак буйлы һәм таза, карап торышка житез, тынгысыз бер кеше иде. Өстенә ул сугышчы ирләрнеке кебек бизәкле, кыска һәм жиңсез күн күкрәкчә кигән, аягында шулай ук кызыл күннән тегелгән жинел башмак. Уң кулында кыска саплы жиз сөнге, билендә—хәнҗәр. Озын, кара чәчләре тулымлап үрелгән, майланган—елкылдап тора.

Хәзер дә ул әнә чәчләрен матурлап үргән, майлаган. Ләкин чәчләре инде сирәкләнә төшкән, төсе дә карга канатыдай чем-кара түгел, арада чал кергән бөртекләр күренгәли. Шулай да төсе-кыяфәте, әйтерсең тамчы да үзгәрмәгән—үз-үзеннән канәгать, үз-үзенә ышанган, үзен батыр да, кыю да итеп күрсәтергә тырыша. Хәер, җентекләбрәк карасаң, хәзер инде анда арыганлык, таушалганлык та күренә. Күз төпләре шешенке, бит тиресе сәлперәйгәнрәк. Күрәсең, күп эчә, рәтләп йокламый...

Әйе, теге көнне Бабул хәзергегә караганда да кыюрак, батыррак иде бугай.

Шулай булмыйча! Моннан тугыз ел элек кем генә шулай булмады икән?! Масаюы да, тәкәбберлеге дә баштан ашкан иде бугай.

Ярым ачык капкада күзгә-күз очрашкач, Бабул кычкырып:

—Бу йортта Тажит төзүче торамы?—диде. Бабул аның Тажит икәнлеген дә, бу йортта торганлыгын да бик яхшы белергә тиеш иде, чөнки алар бер-берсен ишетеп тә, күреп тә беләләр, еш кына очрашып бер-ике сүз сөйләшеп тә алалар иде.

—Мин ул... Тажит... әллә танымадын?—диде Тажит, аптырагандай итеп.

Бабул хужа кешене этеп-төртеп дигәндәй ачык капкадан эчкәрәк үтте һәм һәрбер сүзен ап-ачык итеп:

—Сине мака сар Аланча үз катына чакыра. Әйдә, киттек!—диде.

—Хәзер үкме?!—диде Тажит каушап.

—Хәзер үк!—диде Бабул, кистереп.

—Ни... ыы... мин әле ашамаган-эчмәгән, юынмаган да,—диде Тажит карышкандай итеп, ни әйтергә дә белмичә.

—Ашарсың да, эчәрсең дә... баргач!—диде Бабул, кырт кисеп.

—Туктале, нишләп болай кисәк кенә?—диде Тажит.—Мака сар катына болай бару килешми ич—киемнәремне алыштырыйм.

—Бар, тиз бул,—диде түземсез Бабул, ләкин Тажит борылып китә башлаган иде, шундук аның артыннан иярде.

Тажит өйгә кереп тиз генә киемнәрен алыштырды, үзен чорнап алган, мыс-мыс җылаша, кайгырыша башлаган хатын-кызларга, балаларына юатып бер-ике сүз әйтеп-әйтеп алды. Шул чакны ул буй җитеп килгән Лиясен күреп алды. Күңеленнән генә «Нинди чибәр булып килә! Яшь чактагы Нәфисә—суйган да каплаган» дип уйларга да өлгерде, яратып ул кызының аркасыннан сөйде. Лиянең күзләрендә яшь бөртеге күренеп китте.

Каяндыр биш яшьлек улы килеп чыкты, «Эти!» дип шундук аягына сарылды. Улын кулына күтәрергә туры килде. Ул чактагы улы нәкъ бүгенге Бәләкәч сыман иде. Улын капкага кадәр күтәреп барырга туры килде—муенныннан ул ике куллап шундый нык итеп тоткан иде, җылатмыйча, күңелен кырмыйча аны һич аерырлык түгел иде. Капкадан чыкканда улын көчкә Нәфисәгә бирә алды. Шулай итеп аерылды ул... улыннан, Нәфисәдән, Лиядән—барлык якын, кадерле кешеләреннән, йортыннан-жиреннән. Шуннан соңмы? Шуннан соң тиз арада алтын манаралары, биек таш корылмалары белән ерактан ук күзнең явын алып, берәүләрдә сөенеч, берәүләрдә көенеч тойгысы өстәп торган Изге тауга, мака сарлар һәм аларның якыннары гына яши торган сарайларга алып бардылар. Кайгы көне әле яна башланса да, кайгы көнендә нинди дә булса эш эшләү язык саналса да, тәхеткә утыруының беренче көнендә үк күптән килгән изге тәртипләрне бозып, мака сар Аланча аның белән эш турында, бары эш турында гына сөйләште.

Таш коймалар, сулы бәжралар белән әйләндереп алынган түгәрәк тураның уртасындагы изге турага алар булдыра алган кадәр турыдан бардылар, булдыра алган кадәр тизрәк бардылар. Кичләрен, көндезләрен җәяүлеләр, атлылар өзлексез йөреп торган таш урамнарда урам себерүче каралардан башка, җирән ишәккә атланып каяндыр кайтып килүче чурадан һәм биек таш капкалар, таш күперләр янындагы кораллы торгаклардан башка беркем очрамады. Таш урамнар, таш күперләр кызу чапкан ат-арбалар тавышыннан гүләп торды. Соңгы берничә аен башкаладан читтә урман-таулар арасында уздырганга Тажит туган йортын, җәмәгатен, балаларын гына түгел, туган турасын да сагынган иде. Биек таш күперләргә, куе яшел агачлар арасында күмелеп утырган матур таш йортлар, сарайларга, яр буйлары ташка төрелгән су өстенә—бөтен тирә-якка ул беренче мәртәбә күргән сыман, тансыклап карап барды. Шул ук вакытта ана ул боларны соңгы кат күрә сыман да тоелды. Шуна

күрә ул аеруча матур тоелган күренешләргә, таш, агач һәм җиз-бакыр катнашкан корылмаларга аеруча җентекләп һәм сокланып карады. Анын билгеле «соңгы кат» дигән фикергә ышанасы килмәде. Ләкин тук, симез атларнын туктаусыз чабуына, тәгәрмәчләрнен туктаусыз дөбердәвенә һәм күз алдындагы күренешләрнен туктаусыз үзгәреп торуына ышанмаска мөмкин булмаган кебек, бүген менә хәзер тиздән, озакламый язмышта кинәт ниндидер үзгәреш булу мөмкинлегенә дә ышанмыйча булмый иде.

Юл буена аны билгесезлек һәм шомлану тойгысы газаплады. Ник алып баралар аны изге тауга? Нишләп шулай ашыгыч рәвештә? Мәрхүм Карманны җирләүдә, төрбәгә урнаштыруда берәр төрле кинәш-табыш кирәк булганмы, әллә бөтенләй башка нәрсәме? Карман җирләнеләчәк төрбә күптән әзер—эчке-тышкы бизәкләре ясалган, алтын-көмеш саркатибы шулай ук күптән әзер. Аны инде төзәтеп тә, яхшыртып та, баетып та булмый. Әллә соң яна мака сар мәрхүмнен гәүдәсен үзе төзеткән төрбәгә куймыйча, тиз арада яна төрбә, яна саркатип ясатырга ниятләнә микән? Булмас димә. Әллә нинди көтелмәгән нәрсәләр уйлап табарга мөмкин ул.

Изге тауга алар шау-шу куптармыйча, тавыш чыгармыйча, атларын атлатып кына менделәр. Аларга күп санлы алтын-көмеш бизәкле биек, авыр капкалар җинел генә ике якка ачыла торды, ябыла торды. Шомартылган таш аралаш шакмаклап җиз-бакыр җәелгән юлларнын ике ягына тезелгән эре сөякле таза, тук сакчылар тавыш-тынсыз озатып калдылар. Болдырда, ишек катында, биек баскычлар янында аларны шулай ук тавыш-тынсыз һәм бераз гына йокылары ачылып җитмәгән тук, чибәр ирләр, : лтын-кызлар каршы алып, озатып калдылар. Анда ишек төбе бүлмәләрендә, аралыкларда, баскыч төпләрендә—һәркайда муллык, байлык һәм изгелек бөркелеп тора. Анда ниндидер ят җинел исләр килә, идәндә, түшәмдә, эстинәдә бизәкле, затлы ташлар, алтын-көмешләр ялт-йолт килә. Анда кызлар, асраулар барысы да яшь, барысы да күзнен явын алырлык чибәр. Алар ягымлы һәм алар матур итеп көлә, елмая беләләр. Хәтта бөтен илдә кайгы көне булганда да көлә-елмая беләләр. Бәлки алар шуна да ул көнне ныграк көлгән-елмайганнардыр әле.

Аланча саканын эчәргә, күнел ачарга, яшьләр белән төрле тамашалар корырга яратуын белмәгән кеше юк. Төне буе шау-шу килеп, утлар яндырып, җырлап-көлеп изге тау тирәли кәмәләрдә йөрү дисенме, гимнас өйләрендә таза яшьләрнен үзара көрәшләрен, ат чабышлары, йодрык сугышлары оештыру дисенме—аннан берни калмый, бернидән тайчынмый. Үзе йөри, үзе оештыра һәм үзе катнаша. Яшьрәк чагында ул хәтта җырлаган-биегән һәм ким кызлар кебек әргәндә уйнаган дип сөйлиләр. Аннан сон анын турында шунысын да сөйлиләр: төне буе күнел ача, төшкә кадәр йоклый диләр.

Сакадан кинәт мака сарга—ил башына әверелгәч кенә Аланча көндәлек гадәтләрен тиз генә үзгәртә алмаган, азрысы. Ак, кызыл, кара ташларны матур итеп аралаштырып төзелгән, тышкы ягыннан да, эчке ягыннан да алтын-көмеш һәм фил сөякләре белән араландырып бизәлгән кечерәк бер бүлмәгә җиткәч, пышылдап кына сөйләшә торган асраулар ана бераз көтеп торырга куштылар. Ул күрсәтелгән урында туктап калды, көтә башлады. Ана шактый көтәргә туры килде. Карлыкканрак тавышы белән, пышылдабрак сөйләшә торган, күз төпләре салыныбрак торган «кара» узып барышлый гына сөйләнгән кебек «торды!» диде дә, китеп тә барды. Анысы күздән югалырга өлгермәде, икенчесе килеп: «коена!»диде. Икенче хезмәтче китеп бераз торгач, якындагы биек терәкләр арасындагы аралыктан өченче хезмәтче килеп чыкты. Монысы яшьрәк, житезрәк иде, ләкин монысынын да йөзе йокылы-уяулырак иде.

—Мака сар сине үз янына чакыра,—диде яшьрәк, житезрәк хезмәтче һәм үз артыннан барырга ишарәләп, баш какты.

Тажит төзүче хезмәтче артыннан иярде. Мака сарның коену бүлмәсенең ишеге ачык килеш калган иде. Коену бүлмәсеннән үтә нәфис һәм хуш исле май исе килеп бәрелде. Мондый ят исле майны да, үсемлекләрне дә бик ерактан, җир читеннән, коньяк-көнчыгыш яктагы дингез буендагы Дарцин иленнән китертәләр. Мондый хуш исле майларда бары тик мака сарлар да, аның хатыннары гына коена ала. Коену бүлмәсеннән шакмаклы таш идәнгә майлы аяк эзе чыккан һәм тоташ ак, кара ташлардан аралаштырып салынган баскыч буйлап, югарыга, икенче катка менеп киткән иде. Ярым шәрә берике ир, кулларына чүпрәк тотып, майлы тапларны сөртеп азапланалар иде. Яшь, житез хезмәтче белән Тажит, идән сөртүче ирләргә дә, майлы аяк эзләренә дә якын килмәскә тырышып, читтәнрәк бардылар. Киң баскычтан югары менгәч, Тажитнең борынына җинел, тәмле аш исләре килеп бәрелде. Хезмәтче туры аны мака сарның аш бүлмәсенә алып керде. Бай җиһазланган биек, иркен бүлмәдә ашаучылар күп түгел иде. Ләкин ашаучыларның барысы да ирләр һәм барысы да Аланчаның иң якын кешеләре иде. Ике көнлек мака сар төзүче Тажитне ерактан ук күреп алды, каршылау өчен урыныннан торды һәм ягымлы итеп:

—Килденме? Әйдә, утыр, безнең белән тамак ялгап алырсың,—диде.

Мондый ягымлылык күреп Тажитнең күнеленнән авыр таш кинәт юкка чыкты. Ана җинел һәм иркен булып китте. «Юкка бетеренгәнмен. Бу мине үзенә якынайтырга исәпли ахрысы» дип уйлап алды ул яна ил башы турында. Тартынмыйча, каушамыйча күрсәтелгән урынга утырды һәм артык комсызланмыйча, әдәпсезләнмичә, үз өендәге кебек, башкалар кебек алдындагы азыкларны ашарга тотынды. Ашаганда беркем берни сөйләшмәде, бары мака сар, табын хуҗасы буларак күршеләренә яисә аш ташучыларга берәр сүз әйткәләп, тамагын кыргалап, кикергәләп алды. Тажит яхшы белгән Аланча сака бераз гына симерә башлаган, киң күкрәкле һәм көр тавышлы алып ир иде. Кычкырып сөйләшә, кычкырып көлә, кемнең кем булуына карамастан, теләсә кемнең сүзен бүлдереп, бары үз сүзен генә өстен чыгарырга тырыша. Еш кына ул юмарт һәм киң күнелле була ала, ләкин бер киреләнсә, аны инде берни белән урыныннан кузгатып булмый.

Ул көнне табын янында башка вакыттагы кебек алай кычкырып та көлмәде, кем белән дә булса сүз дә көрәштермәде. Тажиткә бу баштарак гаҗәп тоелды, ләкин әле һаман кайгы көне икәнлеген исенә төшергәч, монда бер дә гаҗәпләнерлек нәрсә юклыгы беленде.

Гаҗәп нәрсә соңыннан, ашап туйгач булды. Ашап туйгач, табын янындагы ирләр таралышкач, Аланча аны сарайның өченче катына алып менеп китте. Монда яктырак та, иркенрәк тә иде. Ачык тәрәзәдән талгын гына булып саф һава агылып тора, еракта башкала йортлары, бакчалар, түгәрәк коймалар һәм арыклар шәйләнә, колак төбендә өзлексез гүелдек булып, беркайчан тына белми торган тура шау-шуы ишетелеп тора.

—Беләсенме, ник чакырдым мин сине?—диде мака сар Аланча беренче сүзе итеп.

Ул моны йомшак, ягымлы итеп әйтәм дип уйлады ахрысы, ләкин аның тавышы тупасрак һәм күтәренкерәк булып чыкты.

—Юк, әлегә белмим, мака сар,—диде Тажит мөмкин кадәр буйсынучан итеп.

—Мака сар! Миңа әле беркемнең дә «мака сар» дип олылап эндәшкәне юк,—диде кинәт Аланча, куанычтан елмайгандай итеп.—Рәхмәт. Изге атам-анам белән ант итеп әйтәм, килешә алсак, гел түремдә утырырсың, уң кулым булырсың, төзүче Тажит.

Тажит инде җинелчә кармакка каба торган кеше түгел иде, шулай да, кармакка капканда да, нинди кармакка кабуыңны белеп, алдынны-артынны

уйлап эшләргә кирәк иде. Сүзнен кай таба баруын чамалый алмыйча озак кына эндәшми утырды.

—Ил башлыгы мака сар белән килешмәү язык булыр иде,—диде ул ашыкмыйча гына,—ләкин ин элек нәрсә турында килешү кирәклеген белү кирәкми микән?

—Шунын өчен чакырдым да мин сине,—диде Аланча сар.

Никадәр туры сүзле тупас кеше булса да, шулай да ул да чак-чак кына каушый һәм икеләнә иде бугай. Ул да, тиешле сүз әйтә алмыйча, беравык тынып, як-ягына карангалап утырды.

—Сине, Тажит, Акланда белмәгән кеше юк. Агам мәрхүм Карманнын барлык төзү-кору эшләрен син башкардын. Анын төрбәсен, сарайларын син салдырдын, юллар төзеттен. Бар байлыгын агам мәрхүм үзенен шул төрбәсенә, сарайларына, күперләренә тотып бетерде. Син аны беләсен…

—Беләм,—диде Тажит теләр-теләмәс кенә.

—Мина ул коры таяктан башка берни калдырмады. Амбарлар буш, сандыклар буш, чүлмәкләр буш. Жир асты базларында, ашлык чокырларында тычканнар гына чабышып йөри. Кораллы ирләргә, сакчыларга, торгакларга, алыпларга түләргә түгел, аларнын тамагын туйдырырга да берни юк. Үзен беләсен, мәрхүм агамнын күп эшен илнен аксөякләре дә, каралар да… беркем яратмады. Ил-көннен күнелен күрү өчен, Акландагы һәркем үзен бәхетле итеп тойсын, үзенчә яшәсен өчен, минемчә, салымнарны, түләүләрне бетерергә кирәк булачак. Ләкин, салымнарны, түләүләрне бетерсәк, илне саклаучы кораллы ирләргә, чиргүгә, сакчыларга, торгакларга… акчаны каян алырга?

Анлашылды. Барысы да анлашылды. Акча мәрхүм Карманга да кирәк иде, яна сар Аланчага да кирәк икән. Аланча сар сүзләрен уйлап, сайлап сөйләде, бераз гына үртәлеп, бераз гына мескенләнеп сөйләде. Акча кирәк, акча! Ләкин акча, байлык, алтын-көмеш һәм көч-куәт Тажиттә түгел, киресенчә, мака сар Аланчанын үзендә бит! Кичәдән башлап барысы да анда, анын кулында. Нишләп төзүче Тажиттән акча өмет итә әле бу?

Аланча сака булса, яки анда сугышчымы, кәмәчеме булса, Тажит, билгеле, ана шулайрак дип жавап кайтарган булыр иде, ләкин бу юлы Тажит тыелып калды һәм беркадәр вакыттан сон:

—Мин әлегә берни анламадым, мака сар,—диде. Мака сар Аланча аскы азау тешенә кысылган ит кисәген тартып чыгарды да, тел очына куеп читкә төкергәч, зур, авыр гәүдәсе белән жайлабрак Тажит ягына якынрак килде һәм пышылдыйм дип уйлап:

—Сине… теге… Карунның яшерелгән хәзинәсен белә диләр. Мина шул байлык кирәк!—дип кычкырды.

Мондый сүз ишетеп Тажит катты да калды. Монда килгәндә ул үзе өчен, йорты-иле өчен әллә нинди үлем төрләре уйлап табып газапланган иде, ләкин һич тә мондый төр үлем күнеленә килмәгән иде. Карун байлыгы. Кем әйткән аны? Үз гомерендә беркемгә анын Карун байлыгы турында сүз әйткәне юк. Монарчы аннан андый байлык турында сорашучы да булмады. Байлыкны аны башка юл белән таптылар, эшләп, сату-алу итеп, көч түгеп.

—Мин… андый байлыкнын кайдалыгын белмим, мака сар,—диде ул Аланчаның симерә башлаган майлы, тупас һәм әшәке йөзенә туры карап.—Илдә Карун байлыгы турында төрле имеш-мимеш сөйләнә—ансын ишеткәнем бар. Бик күпләр аны эзләп тә караганнар, ансын да ишеткәнем бар.

—Изгеләр тавында, турада син күп эшләр эшләттен, базлар, жир асты юллары казыттын…—диде Аланча түземсезләнеп.

—Барысы да булды, мака сар—базлар да, жир асты юллары да казыттым,—диде Тажит.—Шул чагында минем Карун байлыгына тап булуымны күргән кеше булса, хәзер ул минә килсен дә, әйтсен анын кайдалыгын! Мин бәлки

күрми киткәнмендер. Икәүләшеп, өчәүләшеп янадан эзләп карарбыз.

Шул чакны Аланчаның йөзе караңгыланып калды. Атаклы төзүченең түгел, үзенең кармакка кабуын күреп ул озак кына иренен чәйнәп утырды.

—Алайса, белмисең?—диде ул шуннан соң.

Бу юлы, аның тавышы коры һәм ямьсез ишетелде.

—Белмим, мака сар,—диде Тажит.—Белсәм шундук йөгереп килеп әйтермен.

—Бар, кайтып тор—кирәк булсаң чакыртырмын,—диде мака сар.

Ул көнне алар арасында шундыйрак сөйләшү булды. Өенә кадәр аны ат арбада Бабул кайтарып куйды. Кайтып житәрәк, аның күңеленә бер уй килде: мака сар белән икәүдән-икәү генә сөйләшүдән файдаланып аңа бер сүз әйтергә кирәк булган. «Чын хәзинә Карун байлыгы түгел, чын хәзинә менә шул!» дип әйтәсе калган. Менә шушы сөйләшүдән соң ул гел шул турыда уйлады. Ни өчен изге таудагы сарлар өчен чын хәзинәнең ниндидер имеш-мимеш Карун байлыгы түгел, аллалар сүзе икәнлеген әйтә алмавына ул гомере буе үкенү кичерде.

Ике көннән кумү булды. Якын илләрдән, утраулардан бик күп кунаклар—карлар, кәмиләр, мислар, ширданнар, туршалар, киликалар, сабалылар һәм башкалар килде. Арыклар, яр буйлары дингез култыклары ул көннәрдә кәмәләр, каеклар, бораннар белән тулды, кешеләр белән тулды. Изгеләр тавының көнбатыш ярындагы Авалаш утравында, иртәннән башлап кичкә кадәр мәрхүм мака сарга багышланган уеннар, ярышлар һәм кан коюлар булды. Яшьләр көч сынаштылар—йөгерделәр, ук аттылар, атта чабыштылар, ярсу үгез белән сөзештеләр—көрәштеләр. Иң ахырда коллар сугышты. Ике төркемгә бүленгән йөзәр-йөзәр кеше, анадан тума шәрә килеш, кыяктай үткер жиз кылычлар белән, ярсып-ярсып бер-берсен тураклыдылар. Кумү уеннарының иң куркынычы, иң тәэсирлесе шушы иде. Меңләгән, ун меңләгән таза, исән ирләр, чибәр кызлар, хатыннарның күз алдында очлы хәнҗәр котырынган җырткыч сыман, тере тәнне ботарлады. Меңләгән, ун меңләгән күзләр алдында куллар, башлар киселеп төште, күкрәкләр, корсаклар тишелеп, эчәгеләр акты. Кайгы дип, дәһшәттән шашынган тере кеше белән тулы болын уртасында, түгәрәктә елга булып кызыл кан акты. Төрле тавышлар белән кычкырган, шыңшыган, ыңгырашкан, гаргылдаган авазлар яңгырап торды. Шул авазлар арсында, шакы-шокы килеп, чыкы-чыкы килеп жиз хәнжәрләр чәкәшкәне ишетелеп-ишетелеп китте. Коллар башта кумәкләшеп, бер зур төркем булып сугыштылар, соңыннан олы төркем кечерәк төркемнәргә бүленде. Бераздан кечерәк төркемнәр дә юкка чыга башлады һәм иң ахырда мәетләр арасында чабышып-куышып йөргән өч-дүрт кеше генә калды. Аларның кайберләре, яклау эзләп, якындагы лелекләр—таза, яшь, иркле кешеләр ягына омтылды, кайберләре мәетләр арасында качып калмакчы булды. Болынны әйләндереп алган кораллы сакчылар куалап аларны кире уртага керттеләр, кемнәрдер ерактан таш ыргытты. Бернинди котылу чарасы юклыгын күреп, коллар янә уртага ташландылар, бер-берсе артыннан куыша башладылар. Ләкин шул чакны сакчылар божрасы кысыла төште, куышучы коллар беравык тын алып торгандай иттеләр дә, бушрак, тигезрәк урынга чыгып янә бер-берсенә якын килделәр. Уртада ике, аннан соң бер генә кеше калганчы шактый вакыт узды. Ун меңләгән кеше әле давыл кебек, дингез кебек гүләп, шаулап алды, әле шул ук дингез кебек кинәт тынып-тынып калды. Аксыл чәчле житез акай колы иң ахырда үзенең иң соңгы дошманын калап үтерде дә, жинүче буларак, коралын югары күтәрде һәм шашкан кебек мәетләр өстеннән сикерә-сикерә, түгәрәк әйләнеп йөгерә башлады. Жыелган халык, күк күкрәтеп, аңа алкышлар яудырды. Ләкин шулай да акай колы түгәрәкне әйләнеп чыга алмады. Ул инде берничә жирдән яраланган иде,

анын кулы, боты, кукрәге, бөтен жире кызыл канга буялып, тапланып беткән иде. Соңгы дошманын үтергән жиргә килеп житәрәк ул нәрсәгәдер абынып йөз түбән капланды һәм шуннан соң инде кузгала алмады. Мәетләрне жыеп якындагы таш күпердән, ташлы ярларына бәрелеп, ашкынып аккан елгага ташладылар. Тиз арада уртага таудай итеп коры-сары утын-агач өелде, өем өстенә мәрхүм мака сарның кабыгы куелды. Утынга утны кичке якта төрттеләр. Таудай коры-сары утын агач янып беткәнче Авалаштан халык таралмады. Мәрхүм мака сарның көлен, янган сөякләрен жыеп алтын савытка салдылар да, әзер төрбәсенә алып киттеләр.

Тажит турыдан-туры күмүдә катнашмады. Ләкин ул сарайга якынрак кешеләрдән булганга, калкурак урында, аксөякләр янындарак булды һәм уртада, түгәрәктә булган бар нәрсәне үз күзе белән карап-күреп торды. Монарчы әле анын мондый тамашаны күргәне юк иде. Ул көнне, ул төнне бик күпләр кайгыдан маңгайларын, битләрен, колакларын җәрәхәтләп, кан чыгардылар, башкаларга ияреп кычкырып-кычкырып жыладылар. Кайбер чибәр кызлар тәэсиргә бирелеп, чәчләрен кистеләр, икенче берәүләр исә битләренә корым үкәделәр.

Кайгы кырык көнгә сузылды. Ул көннәрдә урамнарда, ишек алларында, бакчаларда, койма башларында әледән-әле үкереп -үкереп жылаган тавышлар ишетелде, көпә-көндез урам уртасыннан чәче-башы полтыраган, тәне җәрәхәтле яисә бите карага буялган шәрә ирләрнен, хатыннарның йөгереп узып киткәннәре күренеп калды. Кайбер өйләргә, капка баганаларына ак киндерләр чыгарып элделәр. Үзе исән чагында усал булып тоелган мака сар өчен бу кадәр кайгы белдерү бик үк аңлашылмый сыман иде. Ләкин Тажит тә, башкалар да моны бик яхшы аңладылар—бетмәс-төкәнмәс бу жылау, сыкрау, үкерүләр, ямьсез итеп кычкырулар, үз-үзенне камчылау, яисә, үз-үзенне җәрәхәтләп, ямьсезләп йөрүләр, үлгән мака сар өчен кайгырудан бигрәк, исән, тере мака сарга каршы юнәлдерелгән иде, әлбәттә. Моның шулай икәнлеген беркем дә яшереп азапланырга тырышмый да иде, ахрысы. Шул ук урамнарда, базарларда, чит ил кәмәләре, дингезчеләре күп жыела торган яр буйларында, тамгалыкларда—һәркайда мака сар Аланчаны тозлап-борычлап сүккән сүзләр, ана карата чыгарылган табышмаклар ишетелде. Кайгы көннәрендә авыз күтәреп жырлау, такмак әйтү тыелган булса да, ул көннәрдә беркем беркемне тыймады. Анда-монда ялт-йолт каранып, андышып, колак салып шымчылар йөрсә дә, әүвәлгечә базарларда, урамнарда, яр буйларында, капкаларда төнге торгаклар, сакчылар, каравыллар торса да, беркемгә бер кыек сүз әйтмәделәр, беркемне тотып кулга алмадылар. Ул көннәрдә изгеләр тавы ягыннан сөрәнчеләр дә килмәде, йомышчылар да йөрмәде. Мака сар Карман үлү белән изгеләр тавында, турада, бөтен илдә, әйтерсен, тормыш туктап калды.

Мака сар Карманны жирләп, жиде көн үткәч, сигезенче көнне Тажит төзүчене алырга дип турадан тагын сар йомышчысы Бабул килде. Алар мака сар Аланча сараена барып житкәндә төш вакыты якынлашып килә иде. Мака сар Аланча исә әлерәк кенә йокыдан торган, кайнар суда коенган, тәненә хуш исле майлар үкәгән, чәчләрен тараткан, үрдергән. Сабый балалардай мәмрәп, кайгысыз һәм канәгать бер кыяфәттә, ашарга килгәнен көтеп утыра иде. Тажит төзүчене туп-туры сарның табыны янына алып керделәр, табын янына ашарга-эчәргә утырттылар. Шунда ук ике арада ачыктан-ачык сөйләшү булды. Мака сар Аланча Тажит төзүче белән үз итеп, якын итеп сөйләште.

Сөйләшә торгач, шул нәрсә ачыкланды: мака сар Аланча бүгеннән үк сөекле хатыны Нурлы бикәнең алтын сынын ясатмакчы икән. Нурлы бикәнең алтын сыны алтын койма эчендәге барлык сыннардан биегрәк тә, күркәмрәк тә

булырга тиеш икән. Аннан соң Нурлы бикәнең алтын сыны туранып кайсы төшеннән карасаң да, ерактан ук балкып, нурлар сибеп торырга тиеш икән.

Яна мака сар йомшак күнелле, сүз тыңлаучан һәм сабыйларча теләсә нәрсәгә, теләсә кемгә ышанучан беркатлырак кеше иде. Тажит төзүче анын холкын шактый яхшы белә, ләкин ул әле аның мака сар булгач башка кешегә әйләнү ихтималын гына чамалап җиткерми иде. Тиз ышанучан, тиз ризалашучан булганга күрә дә тәхеткә утыруының беренче адымыннан ук менә шундый нәрсәгә риза булгандыр да инде ул. Нурлы бикә гел чибәр күренергә тырышучы, холыксыз урта яшьләрдәге хатын иде. Алтын сын, имеш! Ана таш сын да күбрәк булмас микән?

Тажит төзүче үз алдына шулайрак дип уйлады, ләкин бу турыда кычкырып әйтүдән тыелып калды.

—Алтын сыннарны элекке мака сарлар иң элек үзләренекен ясатканнар,—диде ул шулай ук бераздан сүзгә башлап.

—Мин Нурлы бикәнекен ясатырга булдым,—диде мака сар.

—Мин әле аңлап җитмәдем: ни өчен мин?—диде Тажит төзүче, сорауны турыдан-туры куеп.—Бездә атаклы сынчылар, коючылар да бар бит.

—Син алардан да атаклырак, Тажит,—диде Аланча мактау һәм... боеру белән. Тажит төзүче тынып калды. Ләкин ул барыбер «риза» сүзен әйтергә ашыкмады. Аның әле ачыклыйсы нәрсәләре бар иде.

—Болай булгач, юлны нишләтербез икән соң?—диде ул.

—Мин сиңа ышанам, Тажит,—диде Аланча, ягымлы елмаеп, ап-ак йомшак чүпрәк белән авыз читен сөрткәләп.—Син юлны да, сынны да—икесен дә башкара алырсың.

—Синең теләк минем өчен—изге,—диде Тажит килешеп.

—Шуны да бел, Тажит. Нурлы бикәнең дә теләге бу!—диде мака сар Аланча җитди итеп.

—Синең теләккә, Нурлы бикә теләгенә мин бик теләп риза,—диде Тажит, баштагы сүзен төзәтеп.—Нурлы бикәнең алтын сыны монарчы куелган барлык сыннардан зуррак, биегрәк, күркәмрәк булыр. Бөтен сарайда, бөтен Акланда Нурлы бикә—иң чибәр, иң акыллы хатын.

—Мака сар Аланча хатыны Нурлы бикәнең алтын сынына киләчәк буын кешеләре дә таң калырлык булсын!—диде Аланча, шактый тантаналы итеп.

Ашап туйгач, төз гәүдәле, чем кара чәчле, кара кашлы чибәр Аланча, аталарча Тажитнең аркасына кулын куеп, атаклы төзүчене табын бүлмәсенең ишегенә кадәр озата куйды. Аны ишектән чыгарып җибәргәндә ул аеруча якын һәм ягымлы булып тоелды. Иң кирәкле серен әйткән кебек ул Тажит төзүченең колагына иелә төште һәм тавышын әкренәйтеп:

—Барысы турында да моннан соң Нурлы бикә белән киңәшерсең,—диде.

—Киңәшермен,—диде Тажит.

Шуннан соң ул туры Нурлы бикә бүлмәсенә юнәлде. Ана бераз гына көтеп торырга куштылар—бикә, күрәсең йокыдан торгач киенеп, ясанып, төзәнеп бетмәгән иде. «Бераз гына» дигәне озак кына булып чыкты. Илнең иң гүзәл, иң акыллы хатынының Тажит төзүчегә ямьсез булып күренәсе килми иде ахрысы.

Югарыдан, түшәмнән төшкән яктылыкта каршыдагы киң, биек ишекнең көмешле, бизәкле яңаклары аеруча матур булып, балкып күренде. Ишекнең ике ягында да таш савытларда яшел яфраклы ал, кызыл чәчкәле гөлләр балкып утырды. Фил сөягеннән кырып, сырлап һәм шакмак-шакмак бүлгәләнгән биек түшәмне тотырып торучы кызыл терәкләр артында, почмактарак, алтын читлектә, каяндыр чит илләрдән китерелгән кечкенә кошлар сайрады. Кызыл күн белән тышланган һәм аяклары арыслан аягы сыман итеп эшләнгән йомшак кәнәфидә утырып торучы Тажит янынннан,

алтын белән аралаштырып көмеш калайлар түшәлгән тигез идәннән йомшак кына атлап, бикәнең асраулары—кара тәнле, калын иренле, йә булмаса, киресенчә, ап-ак тәнле, житен сыман аксыл чәчле йончыган кыяфәтле кызлар узып китте. Тажитнең янында гына диярлек, тышкы ишеккә якын жирдә, йокымсырап әзмәвердәй зур гәүдәле, сакал-мыексыз печмән сакчы басып торды. Тик торудан арып, авызын ачып, иснәп-иснәп алды, аякларын, кулларын бер урыннан икенче урынга алыштырды, үтеп-сүтеп йөргән асрауларга ахмакларча елмаеп калган булды. Ике ягында кызыл терәкләр тезелгән, киңлеге биш-алты адым булган якты аралык ун якта каядыр ары сузылды. Аннан кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшкәне, табак-савыт шылтыраганы ишетелде. Асрау кызлар шул яктан килеп, сулга борылдылар да, киң, иркен баскычтан югарыгы катка менеп киттеләр. Икесе ике яктан килүче ике асрау бер мәртәбә туп-туры бер берсенә килеп бәрелделәр дә, чак-чак кына куркып, жинелчә кычкырып жибәрделәр, аннан соң көлешеп, бер-ике сүз әйтешеп, аерылып киттеләр. Икенче мәртәбә капма-каршы килгән кара тәнле белән ак тәнле кыз баскычның аскы басмасы янында бер-берсенә юл бирә алмый азапландылар.

Тажит төзүче урыныннан кымшанмыйча, як-якка күзләрен йөртеп, тыныч кына юк-бар нәрсә күзәткәләп утырды. Бер ярты сәгать чамасы үткәч, сул яктагы баскычтан кара чәчләре күпереп торган, нечкә билле, ачык муенлы, киң озын итәкле аллы-гөлле күлмәге жилфердәп торган чибәр кыз ашыгып түбән төште, елмаеп Тажит янына килде дә, хуш исле нәфис бармаклары белән Тажит төзүченең кулына кагылды.

—Бикә чакыра,—диде ул күгәрчендәй гөрләп.

—Бигрәк ягымлы икәнсең. Исемең ничек?—дигән булды Тажит түгәрәк битле, кара кашлы чибәр кызга сүз кушып.

—Әлфия булабыз!—диде кыз ярым шаяртып, ярым житди итеп.—Әйдә тизрәк, бикә сине күптән көтә. Ашагач гимнас эйенә барасыбыз бар. Бүген анда—ярыш!

—Бикә түгел, мин көтәм,—диде Тажит, жавапсыз каласы килмичә генә.

Чыннан да Нурлы бикә каядыр китәргә ашыга иде бугай. Ул инде тиешенчә төзәнгән, бизәнгән, ясанган һәм яхшылап таралган, майланган, күпертелгән чәчләрен бозарга, аяк очына чаклы төшеп торган озын итәкле күлмәген борчырга, жыерчыкландырырга теләмәгәндәй, калку урында таш сындай тын гына көтеп утыра иде.

Тажит килеп керү белән ул матур ак тешләрен күрсәтеп, ясалма елмаеп, аңа якынрак килергә кушты. Шуннан соң, Тажит якынрак килеп, түбәнчелек белән баш игәч һәм өч-дүрт адым чамасы аның каршында туктап калгач, беренче булып сүзгә башлады.

—Мака сар Аланча минем алтын сынымны ясатырга булды,—диде ул көлемсерәп һәм сөрмәле матур күзләрен уйнатып.—Минем алтын сыным монарчы Түгәрәк тауда булган барлык сыннардан зуррак, шәбрәк булырга тиеш. Акланның кай төшеннән карасаң да, ул еракта ук күренеп торырга тиеш. Чит илдән килгән теләсә кем аны күреп шаккатарга тиеш. Аннан соң... ул минем үзем кебек... булырга тиеш!—диде Нурлы бикә һәм үзенең тапкыр сүзеннән үзе үк көлеп куйды.

Ана ияреп Тажит тә көлде.

—Теләгең үтәлер, бикә,—диде ул, баш иеп.

—Ярар, үтәрсең, Тажит төзүче,—диде бикә мәрхәмәтле елмаеп һәм сүзенең тәмам икәнлеген аңлатып урыныннан торды.

—Минем сиңа бер-ике сүзем бар, бикә,—диде Тажит ашыгып.

—Әйт,—диде Нурлы бикә ясалма елмаеп.

—Синең алтын сының барлык сыннардан зуррак буласы булгач, аны

ачыграк, калкурак җиргә утыртырга кирәк булыр иде,—диде Таҗит.—Ләкин Түгәрәк тауда андый җир юк—сарай өстендә сарай дигәндәй. Син кая кинәш итәрсен икән?

—Мин инде уйладым аны,—диде бикә, күзләрен кыса төшеп.—Түгәрәк тауның дингез ягында, көнчыгышында бушрак урын бар...

—Тишек чүлмәк дип йөртелә торган ташландык җирме?!—диде Таҗит коты алынып.

—Шулай дисәң дә була,—диде Нурлы бикә теләр-теләмәс кенә.—Анда тегe Дикә дигән уйнашчы хатын күмелгән диләр.

—Дикә?!—диде Таҗит үзе дә сизмәстән.

—Дикә инде, Дикә!—диде Нурлы бикә яратмыйча.—Шундагы буш урынны төбеннән алып ташларга да, коймадан, таудан биегрәк итеп таш багана утыртырга. Шуның өстендә—минем сын! Мин аны шулайрак күз алдына китерәм, Таҗит төзүче.

—Анлашылды,—диде Таҗит, уйланып һәм тора таштай катып тик торды.

—Мин ашыгам,—диде бикә түземсезләнеп.—Уйла, кара, тикшер. Бер-ике атнадан килерсен.

—Килермен,—диде Таҗит төзүче төштәге сыман, артына чигенеп.

Нурлы бикә янынннан чыгу белән ул туры төпсез чүлмәк чүплегенә юнәлде. Күзенә ак-кара күренмичә, ашыгып китеп барганда, тигез таш җәелгән, ике ягында да хуш исле куе куаклар үсеп утырган тар сукмакта ул сынчы Әүфил белән очрашты. Чынчы Әүфил дә ашыгып каядыр китеп бара иде. Сынчы Әүфил Таҗитнең Түгәрәк таудагы иң якын танышларыннан берсе иде. Нурлы бикәнең бөтен дөньяны таң калдырырга тиешле алтын сыны турында сүз чыккач та ул иң элек менә шушы Әүфилне исенә төшерде. Әүфил, бөтен Акланда иң остасы саналмаса да, аның башкаларда булмаган яхшы яклары бар иде. Ул кешенең бигрәк тә бит төзелешен, күз карашын җанлы итеп бирә ала иде. Дөрес, тәнне, аяк-кулларны, күкрәкләрне ул бик үк төгәл итеп бирә алмый, аның гәүдә сыннары җансызрак, килешсезрәк була. Аннан соң ул бераз ашыгучанрак та, шапшаграк та. Ул ясаган сыннарның эшләнеп беткәч тә төгәлләнмәгән, онытып калдырган, күрмичә калдырылган берәр кимчелеге табыла. Кайчан карама, аның кулы, беләге ак балчыкка, кызыл балчыкка буялган булыр яисә битендә, муенында берәр төрле майлы тап ялтырап торыр. Билендә исә таушалып, иләнеп пычранып һәм утлы куз төшеп көеп, тишкәләнеп беткән күн алъяпкыч булыр. Хәзер ул иске алъяпкычын салып, яңасын, кыскарагын кигән, битен-кулын да яхшылап юган сыман. Шулай да сул як терсәгендә майлы ак балчык табы торып калган.

Тар сукмактагы бу көтелмәгән очрашудан Таҗит белән Әүфил аптырап киттеләр, көлеп җибәрделәр һәм бер-берсенә юл биреп, читкә тайпылдылар. Икесе дә берьюлы диярлек бер-берсенә:

—Кая киттең болай?—диделәр.

—Нурлы бикә чакыра!—диде Әүфил бик зур сер әйткән кебек, күз кысып.

Ун кулының кыска, юан бармагы белән Таҗитнен күкрәгенә дусларча төртеп алды да, үз сүзеннән үзе кызык табып көлгәндәй итеп алды. Сынчы Әүфил эчәргә ярата һәм шапшак, гамьсез кеше буларак, теләсә нәрсә ашый, теләсә кайда ятып йоклый иде. Шунда тамагына әллә балык кылчыгы, әллә икмәк кибәге кадалып калган, әллә салкын җил өргән—инде ничә ел менә кешечә ачык итеп түгел, ничектер гыжылдап сөйләшә. Шуңа күрә аның көлүе дә кыска-кыска бер гыжылдавык кына булып чыкты.

—Көпә-көндезме?!—дигән булды Таҗит тә, Әүфилнең тупас шаяруына ярарга тырышып.

—Ишетмәдеңмени әле—үзенең сынын ясатмакчы була!—диде ташчы тишек авыз Әүфил, чишелеп.

—Ишетмәгәнием шул,—дигән булды Тажит.—Син соң ишеттенме әле: ту анабыз Диканең чишмәсе Төпсез чүлмәк чүплеге астында икән бит!

Әүфилнең шат, гамьсез йөзе үзгәреп китте. Гаҗәпләнеп, коты алынып ул хәтта артына чигенгәндәй итеп куйды.

—Каян белдең?—диде ул, очлы күз карашы белән Тажитнең йөзен тишәрдәй булып.

—Нурлы бикә әйтте!—диде Тажит, пышылдап, үзе дә сизмәстән.

—Син дә анда булдыңмени?—диде Әүфил, Дикә турындагы хәбәрне ишеткәндәгегә караганда да гаҗәпләнебрәк.

—Булдым,—диде Тажит.—Мака сар Аланча янында да булдым. Төпсез чүлмәк чүплеген алып ташлап, шунда биек таш багана утыртып, башына Нурлы бикәнең сынын…

—Мина да әйтте ул аны!—диде Әүфил, ашыгып, Тажитнең сүзен бүлдереп.

—Нурлы бикәме?—диде Тажит.

—Нурлы бикә,—диде Әүфил, күзен читкә борып.

Аның хәзер тизрәк аерылып китәсе килә иде ахрысы. Шулай да үзеннән өлкәнрәк һәм үзеннән атаклырак Тажит янының ул беренче булып кузгалып китә алмый иде. Бу, билгеле, әдәпсезлек булачак иде. Ул чакта Тажит Әүфилдәге эчке үзгәрешне сизмичәрәк калды. Бөтен игътибарын аның Дикә турындагы хәбәр биләп алган иде. Ул әле аны аңлап-төшенеп тә житмәгән иде бугай, шуңа күрә аның бу хакта Әүфил белән фикер дә алышасы, эчен дә бушатасы килә иде бугай.

—Анда ниндидер чокырмы, тау куышымы бар дип сөйлиләр—караганың юкмы?—диде ул сүзне һаман Төпсез чүлмәк чүплегенә бормакчы булып.

—Кайда, нинди чокыр?—диде Әүфил, берни аңламыйча.

—Төпсез чүлмәк чүплегендә инде!—диде Тажит.

—Нишләп мин чүплектә актарыныйм?!—диде Әүфил, хәтере калгансыман, борынын жыерып.—Минем эш болай да муеннан. Әле менә Әлфи сака кызының сынын ясап бетереп килем. Тагын менә монысы, Нурлы бикә…

—Нишләп алай соң әле ул?—диде Тажит, аптырабрак, Төпсез чүлмәк чүплеген беразга исеннән чыгарып.—Мака сар да, Нурлы бикә дә иң элек минем белән сөйләштеләр. Бөтен эшне башкарып чыгуны мина йөкләделәр. Мин шулай аңладым.

—Мин әлегә берни аңламадым,—диде сынчы Әүфил ясалма көлеп.—Кулым эштән курыкмый. Күзем яхшы күрә. Ни кушсалар, шуны эшлим.—Миннән каршылык юк. Менә тагын чакырганнар. Барып килим инде, соңыннан иркенләп сөйләшербез.

Китәргә рөхсәт сораган сыман ул шулай ашык-пошык кына сөйләнде дә, кузгалып китте. Тажит ана каршы килмәде.

—Мин шунда булырмын—чүплек тирәсендә,—диде ул аерылышканда.

Ашыгып ул Төпсез чүлмәк чүплеге ягына китеп барды. Түгәрәк тауда төрле эш белән, йомыш белән еш булырга туры килсә дә, Түгәрәк таудагы, бигрәк тә алтын коймa эчендәге, үзәктәге биек, бай сарайларны, каравыл өйләрен, матур биналарны һәм берсеннән-берсе матуррак, гүзәлрәк бакчаларны биш бармагы кебек белсә дә, Тажит төзүченең беркайчан Төпсез чүлмәк чүплеге янында булганы юк иде. Ул якка барса шул чүп-чар түгүче каралар, коллар йөри дә, Түгәрәк таудагы су, бакча, урам караучылары һәм эше төшкән кайбер багалар барып чыга.

Таш җәелгән тар сукмак куе куаклар арасыннан барды-барды да, көтмәгәндә түгәрәк ачыклыкка барып чыкты. Як-ягында гөлләр, хуш исле куаклар үсеп утырган түгәрәк болында кояштан янган таза битле ярым шәрә малайлар чыркылдап, уйнап, тыз-быз йөгереп йөри иде. Түгәрәк болыннан соң сукмак сулга каерылды һәм үр менә башлады. Монда инде аяк астына берниндн таш

җәелмәгән, шулай да сукмак күп йөргәнлектән шомарып, тапталып беткән иде. Биек, куе агачлар арасыннан чыккач, Таҗит нindider таш корылмалар янына килеп җитте. Бу мал-туар, кош-корт ябып куя торган каралты-кураларның арткы ягы булып чыкты. Якында гына этләр өрде, әтәчләр кычкырды. Абзарлар ягыннан бик үк тәмле булмаган төрле әче-төче исләр килеп китте.

Кәҗә сукмагы бераз җир текә яр буйлап барды да, бераздан иркенрәк төшкә барып чыкты.

Таҗит туктап калды. Тау монда сөзәк кенә булып түбән таба төшә дә итәгендәге түгәрәк таш коймага төртелеп кала. Тау өстендә берән-сәрән вак куаклардан башка якында бернинди агач-фәлән үсми. Сулда, тау өстендә, үзәктәге алтын коймага таба, куе булып, биек булып мәңге яшел урман калкып утыра. Еракта, коймалар һәм астагы, үзәндәге төрле корылмалар, агачлар артында, зәңгәрләнеп диңгез күренә. Диңгез ягыннан талгын гына җил исә. Ләкин диңгез җиле белән бергә, таудан астагы чүплек өеменнән бозык, тәмсез исләр килеп-килеп китә. Чүплектә бер-ике эт иснәнеп йөри.

Таҗит, чүплек ягыннан килгән исләргә игътибар итмәскә тырышып, сулгарак, ачыграк җиргә чыкты. Биек агачлар янына барып якын тирәне, диңгез, тура якларын карады. Аннан соң нindider сукмактан сакланып кына аска таба төшә башлады. Аяк астыннан түбәнгә вак ташлар ычкынып төшеп китте, кояшта кызынып яткан кәлтәләр куркып читкә тайпылдылар. Ул тау астына төшеп җиткәндә, нindider үләксә белән туенып яткан козгыннар, ямьсез каркылдап, дәррәү кузгалып киттеләр. Этләр дә, кеше килүен күреп, теләр-теләмәс кенә читкә тайпылып китеп бардылар.

Таҗит төзүче, тау буендагы чүп-чар өеменә, чүп-чар өеме астыннан төртелеп чыгып торган нindider таш кисәкләренә карый-карый, түбән төште һәм чүплекне бар яктан да тикшермәкче булып, койма буенча уңга борылды. Ләкин коймага якын килү белән ул мондый уеннан кире кайтырга булды. Монда нидер аңа барысы да чирканыч тоелды. Еллар буена төрле чүп-чар түгүдәнме, башка сәбәптәнме, аяк асты монда сазлы җирдәге кебек селкенеп һәм лычкылдап тора иде. Димәк, чыннан да монда кайдадыр чишмә чыгып ята булса кирәк. Әллә соң җир астыннан берәр төрле юынтык сулары төшә микән? Хәер, монда бит коры чүп-чар гына ташламыйлар, пычрак юынты суларын да китереп каплыйлар.

Ул төшкән җиреннән кире менде дә, чүплекнең икенче ягына чыкты һәм янә тау астына төште. Монда да шул ук хәл иде—таш койма янына якынаю белән, аяк асты шикле рәвештә тирбәнә, селкенә, бата башлады, аяк баткан төштән исә лычкылдап пычрак су килеп чыкты. Чүплек астыннан бернинди тау куышына яисә баз авызына охшаган нәрсә күренмәде. Бөтен нәрсәне чүп-чар, иске-москы каплап киткән. Монда бөтен нәрсә бар: агач, таш, чүлмәк калдыклары да, вак ташлар да, тукыма, чыпта, салам һәм иске-москы тире, күн калдыклары да, коелган иске яфраклар да, балчык, сөяк-санаклар һәм төрле үләксәләр дә...

Карана торгач, Таҗит шуна да игътибар итте: Түгәрәк тауны астан әйләндереп алган һәм тигез җирдән сузыла торган түгәрәк койма кайчандыр элеккерәк заманнарда хәзерге чүплек өеменең урта бер җиреннән узган ахрысы. Чөнки чүплекнең ике ягында да, тау итәгеннән чак кына өстәрәк, әле дә иске койма нигезе аермачык булып беленеп тора. Әле дә анда, аяк астында эре-эре таш кисәкләре, яндырылган кирпеч ватыклары аунап ята. Аннан соң, койманың иске өлеше белән яңа өлеше килеп тоташкан төшләре дә ерактан ук күренеп тора. Димәк, хәзерге чүплек астындагы җирнең яртысы элегрәк койма тышында булган. Шул койма тышындагы калкурак урыннан күрәсең, изгеләр чишмәсе агып яткан, ту анабыз Дикәнең сыны да, күрәсең,

менә шунда булган. Шулаймы? Бик мөмкин. Ләкин моның чынында шулаймы-түгелме икәнлеген белү өчен ин элек жиз койманың эчке ягына кереп тагын тикшереп карарга кирәк, аннан да бигрәк, бу чүплекне юк итеп, чистартып аның астында ниләр барын үз күзен белән күрергә кирәк. Әгәр чыннан да шунда изгеләр чишмәсе, ту анабыз Дикәнең изге сыны табылса, нинди бәхет, нинди зур куаныч булыр иде бу! Тажитнең үзе өчен генә түгел, бөтен тура өчен, Аклан иле өчен бу искиткеч шатлык булыр иде! Изгелек кире кайту дигән сүз булыр иде. Шатлык кынамы соң? Бу янадан бөтен илдә тәртип, имენлек урнашу, янадан аллалар сүзенең өстен чыгуы, бозыклыкның, җәбер-золымның, кайгы-хәсрәтнең юкка чыгуы булыр иде.

Туктале, Аланча да, Нурлы бикә дә түгел, аллалар чуалтты микән соң бу эшне? Кем генә булмасын, чуалды эш, чуалттылар. Бөтен нәрсә баш-аяк килде. Очлы кыя башындагы утка гына берни булмаган. Ул һаман яна да яна. Ул—мәңгелек, аның белән чагыштырганда, кеше гомере—күз ачып йомган ара.

Тик менә Нурлы бикәнең ту анабыз Дикә турында ямьсез итеп сөйләнүе генә эчне пошыра. Белеп сөйләнәме ул, белмичәме? Ни генә булмасын ана да, аларга да яхшылап аңлатсаң, аңламый калмаслар. Бит алар үзләре ин элек шул аллалар нәселеннән! Шушы төшкә биек багана утыртып, алтын сынын багана башына бастырып кую турында хыяллана икән, ана да каршы килеп булмый. Монда хәтта Нурлы бикәнең үзенә әйтмичә генә хәйлә корырга да була. Синең сының—ин югарыда, изге анабыз Дикәнең сыны, чишмәсе синең аяк астында кала дияргә була. Масаеп, кукраеп тик йөрсен. Жиз койманы исә янадан элекке эзенә күчереп, чишмәне янадан тышкы якка калдырасын. Ерактан караганда Алтын бикәнең аягы астында нәрсә барлыгы күренмәячәк тә. Биек койма янындагы чишмәгә исә элеккечә халык агылачак, келәү әйтеп, зекер әйтеп, изге аталарыбызны, аналарыбызны искә төшерәчәк. Янадан халыкның күзе ачылачак, аңы ачылачак. Ин кирәге бүген шул түгелмени?!

Үз алдына хыялланып Тажит кире мака сар Аланча сарае ягына юнәлде. Бик кыска гына вакыт эчендә дә бөтенесен аерым ачык итеп күз алдына китерде—сигез кырлы таш бағананы да, аның өстендә балкып торачак алтын сынны да һәм аннан астарак, читтәрәк янадан челтерәп ага башлаячак изгеләр чишмәсен дә—барысын да аерым ачык итеп күз алдына китерде. Күңеленнән ул бу чүплек башын Түгәрәк тауның үзенә әйләндерде. Жиз койма тышында ул төрле яктан килгән каралар өчен яшел болыннар ясады, болыннарга гөлләр, вак куаклар утыртып чыкты. Шунда ук читтән килүчеләр өчен бик борынгы заманнардагыча куышлар утыртып куйды, аксөякләр өчен ак, кара, кызыл ташлардан җыйнак кына матур-матур йортлар салырга да онытмады. Яшел болында сыерлар, сарыклар утлап йөрде. Таякларына таянып гамьсез генә көтүчеләр басып торды.

Өч катлы биек сарайга якынлашканда ул беркадәр сүрелә төште. Усал чынбарлык күңел күзенә капланган алдаугыч элпәне искәрмәстән төртеп тишкән кебек булды. «Бернинди чишмә дә юктыр әле анда» диде ул үз алдына, ямьсез, сасы чүплекне күз алдына китереп. Юк, шулай да койманың теге ягына чыгып караганда начар булмас иде. Ниндирәк җир ул? Йортлар, каралтылар, бакчалар ниндирәк, суы койма аша чыгамы, әллә шунда гына җыелып ятамы? Ләкин хәзер генә ничек итеп анда барасын? Турыдан, койма өстеннән чыгып булмый, әйләнгеч юл ерак. Аннан соң бит әле ул бүген үзенең Карлы тау ягындагы эшчеләре янына да өлгерергә тиеш.

Кайту ягына борылгач, Тажит, өч катлы биек сарай яныннан үткәндә, кояшлы, ачык ишегалдына кермәс өчен, юри читләтеп күләгәле куаклар арасыннан китмәкче булды. Ләкин сарай турысыннан барганда Тажит шулай да ул якка карамыйча булдыра алмады. Шул чакны ул ишектән сынчы

Әүфилнең чыгып килүен күреп калды. Ул да, ахрысы, аны күрде—Таҗиткә шулай тоелды. Ул, күләгәдән чыгып, сынчыны көтеп торырга мәҗбүр булды. Алар янадан очраштылар. Сынчы Әүфилнең йөзе бик шат күренде.

—Ни булды? Ник чакырган?—диде Таҗит беренче сүзе итеп.

—Сорама да. Булды инде,—диде бәхетле сынчы кул селтәп һәм туктап торасы килмәгәнлеген сиздереп ашыгып китеп барды.

—Эш күп. Ашыгам,—дигән булды соңлап булса да.

Шул чагында Таҗиткә Әүфил сынчының сүзе дә, йөзе-кыяфәте дә Төпсез чүлмәк чүплегендәге селкенчәк җир кебек, бик-бик шикле һәм ышанычсыз тоелды.

Аның ни өчен шикле булуы соныннан, бик соңлап аңлашылды.

Ләкин бу билгесезлек, аңлаешсыз, хәтта шомлы тынлык кырык көн генә сузылды. Карманның кырыгы үткәрелгәч, урамнар, базарлар, яр буйлары янадан халык белән, ыгы-зыгы һәм яшьләр, балалар чыр-чуы белән күмелде. Шул ук вакытта изгеләр тавында да әкренләп хәрәкәткә килделәр. Хәрәкәткә килүнең икенче көнендә үк диярлек чүлмәкче бистәсенә ике ат җигелгән биек кәрәндәсенә утырып Аланчаның йомышчысы Бабул килеп җитте.

Капка шакыган тавышка Таҗит үзе чыкты. Ярым ачык капкада ул тагын түгәрәк йөзле, симерә башлаган, ләкин тынгысыз кыяфәтле Бабул белән күзгә-күз очрашты.

—Бу йортта Таҗит төзүче торамы?—диде Бабул тагын кычкырып.

—Мин ул Таҗит төзүче,—диде Таҗит тыелып кына.

—Сине мака сар Аланча үз янына чакыра, әйдә, киттек,—диде Бабул көр тавыш белән.

—Хәзер үкме?!—диде Таҗит янә.

—Хәзер үк!—диде Бабул.

Бу юлы аны көтеп тә торгыздырмадылар, ашарга да чакырмадылар. Бу юлы аны туры мака сар Аланча янына алып керделәр. Бу юлы каралар да, мака сар үзе дә ягымлы, йомшак күңелле булып күренмәде. Килеп керүгә, күзен күтәреп Таҗитнең йөзенә карау белән, мака сар аның маңгаендагы яна төзәлеп килә торган ярасына игътибар итте һәм чыраен сыткандай итеп:

—Мәрхүм Карман өчен син дә бик кайгыргансың икән,—дип куйды. Аланчаның нәрсәгә ишарәләвен Таҗит төзүче, билгеле, аңламый булдыра алмады. Тик ул аның ни өчен моны шелтә белән әйтүен генә аңлый алмады.

—Гомерем буена мин мәрхүм Карманның колы булдым, мака сар,—диде төзүче Таҗит, бер агарып, бер кызарып.—Карманга турылыклы булган кебек, мин сиңа да турылыклы, мака сар!

—Шулай микән?..—диде Аланча коры гына, яратмыйча гына.

—Шулай, мака сар!—диде төзүче Таҗит.—Актауда бүленгән эшем көтеп тора. Миңа хәзер үк шунда китәргә боерсаң иде.

—Китәрсен,—диде мака сар Аланча, уйланып.—Тик син миңа әйтмәден: Карун хәзинәсе кайда?

Шулай диде дә, күзләрен акайтып, ашардай булып каршысындагы кешегә күтәрелеп карады. Таҗит коелды да төште. Аның әле беркайчан мондый куркыныч кыяфәтне күргәне юк иде бугай. Ул шундук йөзтүбән идәнгә егылды. Бөтен өй эче кинәт тып-тын булып калды. Колакта бары кан шаулады да, колак төбендә дәһшәтле кешенең мыш-мыш тын алганы ишетелде.

—Миңа житкерделәр... син—беләсен!—диде Аланча, усал чыжылдап.

—Белгән булсам, бик сөенеп әйтер идем,—диде Таҗит, башын калкыткандай итеп.

—Белмәсән, бел! Эзлә, тап!—диде мака сар Аланча, йомшагандай итеп.

Ул ана торырга кушты. Таҗит торып басты һәм ни әйтергә белмичә, беравык эндәшмичә торды. Ул, билгеле, «эзләрмен»дип җиңел генә сүз биреп,

чыгып та китә алган булыр иде, ләкин сүз биргәч бит әле аны үтисе дә бар! Сүзендә тора алмасаң, соныннан ни дип җавап бирерсең? Моның ташы кызган, моның түзәр әмәле калмаган, мона хәзер үк Карун малы кирәк!

—Мин барысын да аңлыйм, мака сар,—диде Тажит, исен җыя башлап.—Амбарлар бушап калган, чокырлар бушап калган. Илнең иминлеген, көч-куәтен саклап калу өчен сиңа тиз арада бик күп акча кирәк. Тик шулай да илнең иминлеге, көче-куәте байлыкта гына түгел.

—Тагын нидә?—диде мака сар Аланча, сагаеп.

—Ата-ананы олылауда, мака сар!—диде Тажит шешенке йөзле мака сарның йөзенә туры карап.

—Беренче мәртәбә ишетәм!—диде мака сар Аланча, күрәләтә мыскыл белән. Тажит аның мыскыллы сүзләрен игътибарсыз калдырды һәм бар батырлыгын җыеп:

—Минем сиңа бер сүзем бар, мака сар!—диде.

—Әйтеп кара,—диде Аланча теләр-теләмәс кенә, симез ияк астын кашыштырып.

—Булмаган Карун хәзинәсен эзләгәнче, безгә иң элек анабыз Дикәнең югалган сынын, югалган чишмәсен эзләп табарга, йөгәнсезләнгән караларны туры юлга өндәргә, илдәге бозыклыкны бетерергә кирәк.

—Кирәк!.. Бигрәк күп «кирәк». Әле мин тәхеткә утырырга да өлгермәдем—кирәк тә кирәк…—диде мака сар, чыраен сытып, үчекләгән сыман сөйләшеп.

«Юкка әйттем!» дип уйлады Тажит үз алдына, эче пошып.

Күренеп тора, тыңламый, аңламый. Кирәге юк.

Шуннан соң ул чыгып китте. Чыкканда шулай да сорады:

—Юл салуны нишләтергә?—Актауга китсәм каршылык булмасмы?—диде.

—Кайтып тор, кирәк булсаң, чакырырмын,—диде мака сар, ачык кына җавап бирмичә.

Бер-ике көннән иртән иртүк мака сар йомышчысы Бабул тагын килеп җитте. Тагын ана Тажит капка ачты, тагын алар капка төбендә кычкырып үзара сөйләшеп-аңлашып алдылар һәм иң ахырда Бабул кәрәндәскә үз янындагы буш урынга ымлап: «Әйдә, киттек!» диде. Аны тагын ярым йокылы урамнардан, ярым буш күперләрдән, куе күләгәле биек агачлар арасыннан тураның уртасына—алтын-көмеш манаралары, биек ак сарайлары балкып торган Изгеләр тавына алып киттеләр. Алар тагын бизәлгән, җиз белән тышланган биек капкаларга керделәр һәм ике ягында да тигез булып, яшел куаклар үскән, яфрагы саен нәфис кошлар сайраган сихри юллардан каядыр ары бардылар, ләкин бу юлы аны мака сар сараена түгел, каядыр ярым караңгы җир асты базына алып керделәр. Аяк табаннары ашап, шомарып беткән ташлы юлның кайсы якка борылуын күргәч, ул шундук барысын да аңлап алды. Бу юлы аны мака сар янына түгел, хөкемчеләр янына алып бардылар. Өч көн буе аннан сорау алдылар. Кайчы туе көнендә мака сар Аланчаны сүктеңме, үзегезнең урамда такмаклап аны мыскыллап җырулар әйттеңме?—диделәр. Кирәкле җавапны ала алмагач, башка яктан кыса башладылар. Карунның яшерелгән хәзинәсен беләсең икән, ник әйтмисең? Карун байлыгы—сарлар байлыгы ул, Аланча мака сарга тиешле байлыкны йомып калмакчы буласыңмыни, диделәр.

Өченче көнне хөкем чыгардылар. Хөкем бик кыска булды: мака сарга каршы баш күтәргән өчен башын чаптырырга, кулларын-аякларын кисәргә, диделәр. Хөкем карары мака сарга җиткерелде. Изгеләр тавындагы язулы ташта: «Аксөякләрнең каны чыгарылмаска тиеш» дигән сүзләр бар иде. Мака сар Аланча хөкем карарын мәңгелек сөргенгә алыштырды. Мәңгелек сөргенгә озатылган кеше, үзенең барлык караларын, малын-туарын алып, турадан, Акланнан читкә китәргә, җир ачарга һәм яңа җирдә мәңге төпләнеп калырга тиеш иде.

Жыеныргa, күченергә аңа ун көн вакыт бирелде. Иң элек аңа кешеләрен, мал-туарын, азык-төлеген, барлык кирәк-ярагын төяп юлга чыгу өчен унлап кәмә табарга кирәк иде. Турада күренекле кеше булганлыктан, аның кәмәчеләр, балтачылар арасында да, сатучылар һәм башкалар арасында да таныш-белешләре шактый күп иде. Уйлана торгач, ул иң элек Әүхәт белән сөйләшеп карарга булды. Бөтен турада сатучыларның иң бае, көчлесе, иң булдыклысы шул Әүхәт иде. Аның кәмәләре дә күп, кешеләре дә күп. Аның йөрмәгән җире, күрмәгән иле калмагандыр. Ул инде кайнар комлы Кәми якларында да, җир чите Тартөш якларында да, кыш көнендә җиргә күктән ак мамык ява торган салкын якларда да булган. Яшь чакларында аны диңгез юлбасары булган, чит җирләрдә, сагалап торып, үтеп-сүтеп йөргән кәмәләрне талаган, яр буйларындагы авыл-туралapга басып кереп, кем туры килә шуны коллап алып китә торган булган һәм әсирләрен соңыннан олы базарларда кол итеп сата торган булган дип, шундый юллар белән баеп киткән дип сөйлиләр. Дөрес, бу инде күптән булган, хәзер ул—тураның иң атаклы уңган сатучысы.

Ни генә булмасын, кайсы якка китәргә, кайда төпләнергә кирәклеген ул яхшырак белергә тиеш.

Әүхәтнең җимеш агачлары арасында күмелеп утырган ике катлы таш йорты олы арык буена, диңгез капкасына якын җиргә, тышкы зур койма янынарак урнашкан иде. Моннан бер ай элек кенә Әүхәт көнчыгыштагы Дарчин иле якларыннан кайтып төшкән һәм хәзер, аннан кайткан хуш исле ят кабыкларын, майларын, җимешләрен сатып бетергәч, монда, үз йортында эшләрен җайга салу белән мәшгуль иде.

Таҗитнең ни өчен килүен ул әйтмичә дә чамалап алды. Таҗитне үлемгә хөкем иткәннәр икән дә, үлем җәзасын мәңге сөргенгә алыштырганнар икән дигән имеш-мимеш инде бөтен турага таралып өлгергән иде. Зур башлы, зур куллы һәм төртелеп торган зур корсаклы Әүхәт килүчене ачык йөз белән каршылады. Ишегалдында артык сүз озайтып тормыйча ул икәүдән-икәү генә сөйләшү өчен ике катлы йортның аскы катындагы аулаграк, карангырак һәм җиләсрәк бүлмәсенә алып керде. Киң, иркен бүлмәнең ишек төбеннән алып түренә кадәр—әле унда, әле сулда, әле бер почмакта, әле икенче почмакта төрле зурлыктагы төргәкләр, коелган җиз-бакыр, тимер кисәкләре аунап ята. Һавада ниндидер ят, җинел һәм ачы-төче исләр килә иде.

Әүхәт чүлмәкләр, капчыклар арасыннан боргаланып, түргә узды, идән уртасындагы ачыграк урында туктады да, артына борылды.

—Әйдә, утырыйк шушында,—диде, тәбәнәк өстәл янындагы йомшак, калку урынга күрсәтеп.

Беренче булып ул үзе утырды, Таҗит тә утыргач, кулын сузып якыннан гына нечкә муенлы чүлмәкне эләктереп алды һәм өстәл өстендәге берДән-бер көмеш кәсәгә борла агызды.

—Сүзне иң элек шуннан башлыйк,—диде ул борла тулы кәсәне авызына якын китереп.

Бераз тынып утыргач, Әүхәт янә үзенең кунагына күтәрелеп карады.

—Әйтеп кара, ни йомыш?—диде.

Таҗит бер-ике сүз белән үзенең йомышын әйтте.

—Кайчан, кайсы якка китәргә?—диде Әүхәт, бик үк аңлап җитмичә.

—Андый сүз булмады,—диде Таҗит, авыр сулап.—Мин, бәлки ишетмәгәнмендер. Башыма суккандай булды. Сөргенгә, мәңгегә! Мин аңа әзер түгел. Минем бер кая китәсем килми.

—Мин ник кирәк сиңа?—диде Әүхәт гөрелдәп, сорауны турыдан-туры куеп.

—Кәмә кирәк, кәмә.—диде Таҗит эчке бер газап белән.—Вакытында китеп

өлгермәсәм, алар мине көчләп бирәр жиргә озатырга мөмкиннәр. Аңлыйсыңмы?

—Аңлавын аңлыйм да,—диде Әүхәт теләр-теләмәс кенә.—Шулай да син бик үк аңлата алмадың әле.—Кайчан, кайсы якка китәргә?

—Мина хәзер барыбер,—диде Тажит, әле һаман туры гына жавап бирмичә.—Мина хәзер кайда да бер кояш...

—Юк, кайда да бер кояш түгел,—диде Әүхәт. Жырда гына шулай—кайда да бер кояш. Кояш ул төрле жирдә төрлечә. Бер жирдә ул сина көлеп карый, икенче жирдә чыраен сытып карый, өченче жирдә ул сине күрми дә.

—Бармы син йөргән жирләрдә мина елмаеп карый торган кояш?—диде Тажит.

—Бар!—диде Әүхәт.—Минем булмаган жирем, күрмәгән илем юк. Сина яраклы кояш та... төн ягында.

—Төн ягында? Анда бик салкын диләр бит,—диде Тажит.

—Салкын диләр... Куркытыр өчен шулай диләр аны,—диде Әүхәт.—Төньяк—иксез-чиксез. Анда буш жирләр, тау-ташлар, урман-сулар—барысы да бар. Ярты ай чамасы барасың да күл сыман бер дингезгә килеп керәсең. Без аны мәрмәр дингезе дип йөртәбез. Тар бугазны үткәч, икенче дингезгә барып чыгасың. Суы зәп-зәңгәр. Жаның кая тели—шунда туктыйсың. Култыклар, куеннар күп. Туктау өчен, тупләнү өчен жайлы урыннар күп.

—Кыргыйлар да күпме?—диде Тажит.

—Кыргый булмаган жир юк,—диде Әүхәт.—Алардан куркып торасы юк. Алар көтү кебек. Иген икмиләр, жимеш үстермиләр. Урманда, аяк астында нәрсә табалар, нәрсә аулап алалар—шуның белән туенып торалар. Таурлар иле дип атала.

—Безнекеләр, лелегләр беркем дә юкмы ул якларда?—диде Тажит.

—Нишләп булмасын!—диде Әүхәт.—Тау башларында, су буйларында кечерәк кенә таш туралар, авыллар бар. Заманында Карун энесе Типкә бине шунда сөргән булган. Ул анда тура салдырып, таулардан бакыр чыгарттырып, Карунны баетып яткан, дип сөйлиләр. Иген игәләр, мал асрыйлар. Аралары ерак, шулай да бер-берсенә барышып-килешеп йөриләрдер. Яр буйларында кәмәләр күренә.

—Сугышалар да микән?—диде Тажит.

—Ишеткәнем булмады,—диде Әүхәт.—Мин алар ягына өч мәртәбә бардым. Ул төньяк дингезнең яр буйларына аяк басмаган жирем юк.

—Кояш кыздырган якларга никтер күнелем тартмый,—диде Тажит.—Күрәсең, шунда... төньякка юл тотарбыз ахрысы.

—Кайчан?—диде Әүхәт, кунагының күзенә туры карап.—Бер ун көннән Әвер жиле исә башлаячак. Шуңа кадәр кузгалып өлгерергә кирәк.

—Шулай ук азмыни?—диде Тажит ыңгырашып.—Ул йортны-жирне, каралты-кураны, бакчаларны, иген кырларын... нишләтермен соң мин аны? Ах! Ул арада ничек итеп сатып өлгермәк кирәк.

—Әмже бистәсендәге йортыңны да, койма буендагы өйләреңне дә, барысын да үзем алырмын,—диде Әүхәт.

—Син?!—диде Тажит, аптырап. Ул монда килгәндә никтер бу сәүдәгәрне бары кәмәләр белән чит жирләргә генә йөри дип уйлый иде.

—Мондагы йортың—шәп. Нык, таза.

—Аерым-аерым торырсың микәнни?—диде Тажит беркатлы гажәпләнү белән.

Әүхәт көлеп куйды.

—Бер көнне синекендә, бер көнне үземнекендә торырмын... килешсәк,—диде Әүхәт.

—Килешсәк,—диде Тажит үз алдына. Калын иренле, зур йодрыклы һәм

зур корсаклы Әухәтнең шулай күз алдында аның йортына баш булып, инде хәзер үк анда үзенең улын башкаландырып чыгарырга исәп тотуы Таҗитне ничектер өшетеп җибәрде. Беренче мәртәбә ана үзенең ирегә түгел, монда калачак йорты-җире, күнегелгән шундый өйләре, бүлмәләре, бакчалары бик-бик кызганыч булып тоелды. Башын иеп ул озак кына эндәшми утырды.

—Без әле килешмәдек,—диде Әухәт гөрелдәп, аны күнелсез уйларыннан бүлдереп.

—Килешмәдек шул,—диде Таҗит, күндәм генә.—Син мине төньяк дингез буендагы берәр җиргә илтеп куймакчы булдың...

—Мин әле алай димәдем. Мин бары сина әйтеп кенә күрсәттем,—диде Әухәт.—Беләсеңме, безгә иң элек синең мондагы йортың-җирең турында килешергә кирәк. Килешсәк, мин сина барлык кешеләреңне, малың-туарыңны, азык-төлегеңне күчерергә җитәрлек кәмә бирермен, ишкәкчеләр бирермен.

—Башта минем йорт-җир турында килешәбез, соныннан кәмә турындамени,—диде Таҗит, Әухәтнең сөйләшүне каядыр читкә боруын чамалап.

—Кайсысыннан башласак та ярый,—диде шундук Әухәт күндәмлек белән.—Алайса кәмә турында сөйләшик. Мин сина кәмә бирәм. Күпме кирәк, шул кадәр. Йөгең күпме булса, бәясе дә шулча булыр.

—Булды. Килештек,—диде Таҗит.

—Йорт-җир бәясен кәмә өчен суктырырбыз,—диде Әухәт ипләп кенә.

—Тулысынчамы?!—диде Таҗит, ашыгыбрак.

—Нишләп тулысынча булсын?—диде Әухәт күндәмлек белән.—Кәмә өчен—аерым, йорт-җир өчен аерым килешәбез.

—Булды, килештек,—диде Таҗит һәм үзе дә сизмәстән өстәлдәге кәсәгә үрелде.

Әухәт тиз арада кәсәгә борла агызды һәм алар ике арадагы килешүне беркетеп янә ант эчтеләр.

—Үзең илтеп куячаксыңмы яңа җиргә, Таурга?—диде Таҗит иң ахырда.

—Мин үзем бара алмам. Бу арада бик авыртынам,—диде Әухәт.

Таҗит өчен монсы бөтенләй көтелмәгәнчәрәк булды. Әухәтнең оста кәмәче, дингезче булуын турада белмәгән кеше юк.

—Син бармагач, кем генә алып барыр икән соң безне ул Таурга?—диде Таҗит аптырап.

—Өлкән улым Мизан алып барыр,—диде Әухәт.—Кая барырга, ничек барырга—барысын да белә. Ун яшеннән минем белән йөрде.

Әухәт шулай диде. Ахырда, күрәсең, үзе дә сизмәстән өстәп куйды:

—Синең йорт-җирең аңа булачак... килешкәч. Башкаландырам. Бәясен дә үзе түләсен.

Шул ук көнне кичке якта Әухәт Таҗитларга килде. Атасына ияреп малае Мизан да килгән иде. Малае кәрәндәс җиккән, атасын коллар күтәргән. Атаклы дингезченең күтәрәмгә утырып йөрүе гаҗәбрәк иде, әлбәттә. Дингезче Әухәт үзе дә шулайрак дип уйлады микән, аягына басу белән, акланган сыман, җинелчә генә ыңгырашып алды.

—Кәрәндәстә эчне селкетә. Эчәкләрем актарылгандай була.—диде.

Таҗит эндәшмәде, шулай да күнеленнән уйлап куйды, »юри кылана, мина үзенең авырганлыгын күрсәтмәкче була» диде. Әухәтләрдә сөйләшкәннән соң аның күнеленә инде шикле бер уй килеп өлгергән иде. Моңарчы таза булган һәм бер җире дә авыртынмаган Әухәтнең аңа ерак юлга чыгарга кирәк булгач кына авыртына башлавы сәеррәк тоелган иде. Аннан да бигрәк аның бит бөтен җаваплылыкны малае Мизанга ышанып тапшырырга ниятләве күнелне тырнап тора иде. Малае Мизанның яхшы дингезче булуына, яшь һәм кыю, батыр булуына Таҗит әз генә дә шикләнмәде. Ләкин никтер менә

хәзер Тажитне бөтен иле-көне, малы-туары белән тиешле жиргә алып барып житкерә алмас шикелле тоелды. Аннан сон, Тажитнен йортын-жирен, каралтыларын юл исәбенә суктырып, малае Мизанны яна йортта баш итеп калдырырга исәпләве дә Әүхәтнен бары үз кайгысын, ягъни малаен башкаландыру өчен генә эшләнгән эш булып тоелды.

Ни булса булды, Әүхәтне дә, малаен да ул якты йөз белән каршылады, икесен дә капкадан уздырып жибәрде. Бергәләп алар ин элек ишек алдын, бакча якларын карап чыктылар, абзарга, каралты-курага күз ташладылар, бакча уртасында челтерәп аккан кайнар сулы, салкын сулы жиз көпшәләр янында туктап карап тордылар. Тажитнен йорты изгеләр тавыннан ерак түгел, шунлыктан аннан килә торган кайнар һәм салкын суы да тулыбрак, көчлерәк булып ага. Чүлмәкчеләр бистәсендә, Әүхәт өендә чишмә суы теләр-теләмәс кенә ага. Тажит мона шундук игътибар иткән иде. «Һи, боларнын чишмәсе үләр-үлмәс кенә ага икән» дип уйлаган иде үз алдына. Тажит ишегалдындагы чишмәләргә Әүхәт белән малае да игътибар иттеләр. Соклануларын яшермичә, туктап, чишмә тавышына колак салып тордылар. Малае түзмәде, хәтта салкын суны учына алып эчеп тә карады. «Монда тәмлерәк—диде.—Безнен суда нииндидер ят тәм бар»—диде.

Шуннан Тажит аларны ике катлы таш өенә алып керде, бүлмәләрне күрсәтеп йөрде. Алар килгәндә инде бөтен өйнен, бөтен ишегалдынын асты өскә килгән иде. Анда-монда әржәләр, савыт-сабалар, чүлмәкләр тезеп куелган, ашыгып, ары-бире килеп каралар, эшчеләр йөренә—әле бер нәрсәне, әле икенче нәрсәне урыныннан күчерәләр. Капчыкларга, чүлмәкләргә ашлык, киптерелгән жимеш, орлык тутыралар. Икенче берәүләр май тулы чүлмәкләрнен авызларын балавызлап-томалап булашалар. Каралты-кура ягында кешеләрнен, атларнын, мал-туарнын тавышлары ишетелеп-ишетелеп китә.

Кунакларны Тажит үзенен өске каттагы иркен, якты бүлмәсенә алып керде. Ачык тәрәзә аша дугаланып борылган кин арык ягына, ерактан күренгән биек таш йортларга, манараларга карап, хозурланып торгач алар, идән уртасына, йомшак калку урынга утырып түгәрәк өстәлдәге көмеш савыттан шәрәп ант эчеп, эш турында сөйләштеләр.

Шунда йорт-жирнен дә, кәмәнен дә бәясен килештеләр, кайчан, каян кузгалып китү турында да килештеләр.

Ул көнне сүз күп булды. Борласы да күп эчелде. Кунаклар карангы төшә башлаганда гына аякларына бастылар һәм китәргә жыендылар. Шул чакны алар арасында бөтенләй уйламаган, күз алдына китерелмәгән сүз ялганып китте. Өлкәннәр эш турында, бәяләр турында сөйләшкәндә Әүхәтнен малае Мизан сүзгә катышмыйча күбрәк тынлап кына утырды. Үзен каядыр чит жиргә, күз күрмәгән, колак ишетмәгән жиргә алып барачак яшь дингезчегә Тажит әледән-әле сынап карап-карап алды. Атасы кебек эре сөякле, буйчан һәм зур куллы иде ул сәүдәгәр малае Мизан. Күкрәк кин, беләкләр таза, муен нык, дингездә үскәне, бик иртәләй ишкәк ишә башлаганы әллә каян күренеп тора. Чем кара чәчләре озын, алты үремгә үрелгән. Йөзе ачык, ягымлы, күз карашы дәртле. Борыны туры, матур. Тик менә ирене генә бераз калынрак сыман. Анысы атасыныкына охшаганрак. Аннан сон ир кеше өчен тешләре ваграк сыман.

Лия белән алар капкадан кереп ишегалды карап йөргәндә очраштылар. Үз өендә булганга Лия өстенә жинелчә генә киенгән иде. Яшь муены, яшь беләкләре ачык, өстенә кигән бизәксез генә күлмәге дә артык озын түгел иде бугай.

Үзе яраткан кызыллы-каралы чүлмәге белән ул чишмәгә суга чыккан иде. Алар шунда, чишмә янындарак очраштылар. Күзгә-күз очраштылар. Мизан

каршысында сихри гүзәл чибәр кыз күреп, искәрмәстән кинәт туктап калды. Лия, үз каршысында ят кешеләр, ят ир кешеләр күреп җинелчә генә «аһ» итеп җибәрде. Сөрмәле күзләре белән бер күтәрелеп карады да, оялуыннан кыпкызыл булды, оялуын яшермәкче булып көлеп җибәрде һәм тиз генә читкә борылып, китеп тә барды. Әүхәтнең малае туктаган җиреннән кузгала алмыйча, аның артыннан борылып карап калды. Аның да йөзе тынычсыз иде.

Боларның барысы да аталары күз алдында булды. Яшьләрнең шундый көтелмәгән очрашуларына, оялуларына өлкәннәр дә татлы бер тынычсызлану кичерделәр һәм елмайгандай итеп, мәгънәле генә бер-берсенә карашып алдылар. Ике арада бу хакта бер сүз булмады—барысы да күз карашы белән аңлашылды.

Барысы турында да килешеп, кайтып китәр алдыннан Әүхәт сакланып кына әйтеп куйды:

—Тел очында бер сүз калды, әйтсәм, үпкәләмәссенме?—диде.

Тажит аның нәрсә әйтәчәген сизенеп алды, шундук аның күз карашы яшь җегетнең йөзенә төште. Яшь җегет тә тынып, сагаеп хуҗаның сүзен көтте.

—Шулай аяк өсте генә әйтә торган сүзмени?—диде Тажит.

—Юк, юк,—диде Әүхәт.

—Алайса, әйдәгез, өйгә керик,—диде хуҗа, кунакларны өенә чакырып.

—Бер кузгалгач, кире борылсак, юлыбыз унмас,—диде Әүхәт икеле-микеле итеп.

—Алайса, иртәгә килегез,—диде Тажит.

—Әти, иртәгә килерсең,—диде шул чакны яшь җегет тә түземсезләнеп.

Икенче көнне Әүхәт үзе генә килде һәм кичәгенәк әйтелми калган сүзне әйтте.

Аның нинди сүз булырга тиешлеген белсә дә, Тажит ул төнне рәтләп йоклый алмады—үзенчә төрлечә чамалап, уйланып чыкты. Лия аның ин яраткан кызы иде. Барлык туганнары, барлык апалары-сеңелләре арасында Лия иң чибәре, иң күркәме һәм иң ягымлысы иде. Аннан соң, ул инде кечкенәдән үк сарайдагы Һабил улы Юныска ярәшелгән иде. Үзенең язмышы кинәт кире якка борылгач, ата кеше күбрәк менә шул Һабил Юнысы турында уйлый иде. Сөргенгә озатылган ата кешенең кызына өйләнергә теләрме Һабилнең Юнысы, әллә соң аннан баш тартырмы? Өйләнсә дә, өйләнмәсә дә, шушы арада, шушы көннәрдә Һабилнең Юнысы аңа хәбәр бирергә тиеш иде кебек. Тажит шулай дип уйлады. Шулай булуын теләде. Чөнки мондый чакта аның тәртибе шундый иде. Ләкин Һабил Юнысыннан әлегә бернинди хәбәр алынмады. «Күрәсең, үземә барырга туры килер. Ялынып, йөземне җыртып, түбәнсенеп»—дип уйлады ул еш кына эче пошып. Бәлки, барып та торырга кирәкмидер. Килми, димәк баш тарта. Килмәде, килмәс тә.

Әүхәткә ул, билгеле, мондый нәрсәләр турында берни әйтмәде.

—Кызыма ундүрт тулмаган,—диде ул Әүхәткә уйчан гына. Чынлап минем белән туганлашырга теләсәң, җарингәгә улың килеп алыр... Таур иле дигән яна җирдән.

Әүхәтнең йөзе үзгәреп китте. Күрәсең, ул мондый сүз ишетермен дип уйламаган иде.

—Ундүрт тулмаган, имеш!.. Тулмасын. Кем аны тикшереп тора? Икәү килешсәк, җитмәгәнмени?—диде ул аптырап.

—Мин синең белән туганлашырга каршы түгел, Әүхәт,—диде Тажит, нык итеп.—Лиянең ундүрт яше тулганмы, юкмы икәнен беркем тикшермәс, бәлки. Ләкин ана әле ундүрт юклыгын әнисе белә, күрше-күлән белә, Изге анабыз Дикә белеп тора. Ничек итеп мин изгеләргә, Анабыз Дикәгә каршы килеп, бозык юлга аяк басыйм? Андый эшне эшләсәк, сиңа да, миңа да күктән рәхмәт яумас.

—Шулай шул,—диде Әүхәт, көрсенеп.—Син мина караганда динлерәк. Ярар, синенчә булсын. Шулай да айык эчәбезме, калым турында сөйләшәбезме сон?

—Анысына каршылык юк,—диде Тажит.

Моннан тугыз ел элек бөтен Акланда атаклы дингезче Әүхәт белән менә шушындыйрак сөйләшү булды. Айык эчелде, калым турында сүз булды. Түрәгә барып сату-алу турында килешү төзеделәр. Ашык-пошык әзерләнделәр, ашык-пошык төялделәр дә, яр буенда беркадәр көтеп тордылар да, иртәгә унынчы көн була дигәндә, кузгалып киттеләр. Кырыйдан дингез өсте шактый тигез иде. Айга якын эшсез ятып, хәл жыйган ишкәкчеләр яшьләр, тазалар иде. Көчсез жилгә ишкәкләр дә булышкач, жиз кагылган калку борынлы авыр кәмәләр, вак дулкыннарны ярып, су өстеннән шактый жинел йөгерделәр.

Акланнан кузгалып бер тәүлек тулып килгәндә караеп Тирәү утравы күренде. Кояш су өстеннән аерылып, күктә асылынып торганда, Тирәү утравын үнда калдырып, узып киттеләр. Кичкә чаклы тагын унда, сулда таулы утраулар күренде, каршыга йөзгән берничә мал-туар кәмәсе күренеп калды. Караңгы төшкәнче алар бардылар да, бардылар, әледән-әле алга, якякка карандылар, шул ук вакытта артны да онытмадылар. Акланнын биек таулары, таулардан да биегрәк булып утырган сарайлары, алтынланган манаралары, коймалары балкып, нурлар сибеп бик озак аларны озатып барды.

Кичкә таба жил тынып калырга тиеш сыман иде, ләкин көтмәгәндә ул көчәя башлады, һәм каршыдан, төн ягыннан исә башлады. Ишкәкчеләр арасында «Әвер!« дигән шомлы сүз ишетелеп китте. Алар инде арыган, ачыккан булсалар да, тагын да ныграк көч куеп, тырышып-тырышып ишәргә тотындылар. Тик кәмәләр генә кызулый алмадылар. Кәмәдәгеләрнең эчена курку йөгерде. Кешеләр изге аталарын, аналарын, изгеияләрне исләренә төшерделәр, кычкырып-кычкырып келәүләрен әйттеләр. Шул чакны Тажит тә, юлга чыккач беренче мәртәбә, атабыз Минне, анабыз Дикәне исенә төшерде һәм шундук эче жу итеп китте. Юлга чыгу алдыннан ыгы-зыгыда ул су ияләренә, Атабыз Мингә багышлап корбан бирергә оныткан иде!

Шул турыда яшь дингезчегә әйткәч, егет кычкырып көлде генә. Юлга чыккач яшь дингезченен үз-үзен тотышы да, өзек-өзек сүзләре дә Тажиткә бөтенләй ошамады. Ул үзен кирәгеннән артык хужа итеп, бар нәрсәдән өстен итеп тотты. Билгеле, кәмәдәге һәркем берсүзсез ана буйсынырга, анын гына сүзен тыңларга тиеш иде—Тажит инде монысын гына белә. Ләкин корбан турында әйткән сүздән сон дингезченең, булачак киявенең шулай кычкырып көлүе бөтенләй ошамады Тажиткә. Шулай да ул бу турыда әйтеп тормады. Тиз генә түбәнгә төшеп китте һәм ит өчен дип алынган бер кара бәрәннен тиз-тиз генә аякларын бәйләде дә, кычкыртып аны югарыга алып менде, багышлау сүзләре әйтте, тынычсыз чайкалган караңгыда дингезгә ташлады.

Анын бу эшен барысы да күреп тордылар. Беркем берни эндәшмәде. Бары яшь капитан гына көлеп куйды һәм:

—Соң инде, сон!—диде.

—Нәрсә «соң»?—диде Тажит, капитан янына килеп, ачу белән.

—Корбанны аны яхшылап, йоласын туры китереп бирергә кирәк,—диде капитан, аңлатырга кирәк табып. Моннан өченче елны да без шундый хәлгә тарыдык. Бу әле Әвер жиле түгел. Бер-ике сәгатьтән Корыкыя утравына барып житәрбез, шунда төн кунарбыз.

Тажитне ул шулай дип тынычландырырга тырышты, ләкин анын мондый аңлатуыннан соң да, озакламый туктап ярга чыгу, ял итү турындагы сүзләреннән соң да Тажит әз генә дә тынычланмады.

Ул арада жил көчәйгәннән көчәйде, кәмәләр бик авырлык белән генә

шуыштылар. Кайчагында аларның алга баралармы, әллә бер урында торалармы икәнлеген дә аерырлык түгел иде—колак төбендә бары тик шомлы итеп жил шаулаганы ишетелде дә, шыгыр-шыгыр килеп, шап-шоп килеп ишкәкләр ишкәне генә ишетелде. Бер заман ачы чыелдап сыек караңгылыктан акчарлаклар килеп чыкты. Кычкырышып, кәмәләр тирәсендә очып йөрделәр-йөрделәр дә, каядыр юкка чыктылар һәм бераз вакыттан, артка төшеп, чи-чи килеп, кәмәләрне озатып килә башладылар.

—Әнә, акчарлаклар каршыларга килгән. Ярга житәбез!—диде яшь капитан кешеләрнең күңелен күтәреп.

Бераздан еракта, бик еракта кара судан да каракарак булып, биек булып күтәрелгән Корыкыя утравы күренде. Кешеләрнең эченә жылы йөгерде. Барысы да, каршы искән жилдән сакланырга тырышып, төньяктагы Корыкыя утравына карап бара башладылар.

Ләкин аларга Корыкыя утравына барып житәргә насыйп булмады. Каршы жил көчәйгәннән көчәйде һәм бер заман тирә-яктагы караңгылыкны ярып, ялт-йолт килеп, яшькелт яшен яшьнәде, дөбер-шатыр килеп күк күкрәде. Каршы искән жил белән яңгыр сибәли башлады. Куркып кычкырган тавышлар ишетелде. Кешеләр янгырдан, жилдән качып киндер түбә астына керергә тырыштылар. Кайберәүләр куркып тар баскычтан түбән төшеп китте.

Көн яктысында кәмәләр бер-берсеннән ерагаймыйча, су өстендә йөзгән казлар кебек, әле бер-бер артлы тезелеп, әле төркемләшеп бардылар. Яшь дингезче утырган кәмә юл күрсәтүче буларак, барысыннан алда барды. Жил көчәеп, күк күкрәп, яшен яшьни башлагач, тәртип бозылды, якын-тирәдәге кәмәләрнең барысын да берьюлы күрерлек булмый башлады. Ыгы-зыгы вакытында якында гына кинәт күк күкрәвенә охшамаган шакылдау, сыну һәм кот алынып кычкыру тавышлары ишетелеп китте. Сул якта койрыкларын тиешенчә тота алмаган ике кәмә бер-берсенә килеп бәрелгән иде. Ул якта кычкырыш, елаш аеруча көчле булып ишетелде. Кәмәләргә зыян килгәнме-юкмы, әлегә белерлек түгел иде, ләкин бәрелешкән ике кәмәнең дә күпмедер ишкәкләре сынган булырга тиеш иде.

Монысы әле аның баласы гына булган. Анасы соңыннанрак булды. Беренче күк күкрәүдән соң икенче күк күкрәү булды. Бөтен күкне, суны икегә ярып, коточкыч тавыш чыгарып чатнады да, бөтен дөньяны яктыртып яшен яшьнәде. Күп тә үтмәде, коеп яңгыр яварга тотынды. Тажит утырган кәмәне дә бер заман икенче бер кәмәгә китереп бәрде. Нидер шартлап сынды, ватылды.

Кемнәрдер кычкырды, кемнәрдер аллага ялварды. Бөтен нәрсә кинәт баш-аяк килде. Яшь дингезче Мизан янында, борындагы сикедә карап барган Тажит, ниндидер көчкә буйсынып искәрмәстән упкынга ыргытылганда, нәрсәгәдер тотынып калды. Ул бик таныш тоелган нәрсә шома да, каты да һәм жансыз да иде. Бер-ике мәртәбә суга чумып, текә дулкын өстенә килеп чыккач, ул әлеге каты һәм жансыз нәрсәнең кәмә борыны икәнлеген аңлап алды. Кәмәнең каз муены сыман алгарак чыгып торган борыны ат башы кебек итеп ясалган, «баш»ның маңгай тирәсе ныклык өчен жиз калай белән тышланган иде. Юан имән агачыннан ясалганга һәм һәрвакыт суда, су өстендә булганга ул инде муртайган, авырайган иде. Шунлыктан ул үзен ике куллап тотып алган ир кешене бик авырлык белән генә күтәрде. Ат башы белән бергәләп Тажит әле суга чумды, әле калкып чыкты. Су өстенә чыгу белән, аякларын селтәп, каядыр йөзәргә дә тырышып карады, ләкин болай тыпырчынып аның бары хәле генә бетте. Ул йөзәргә азаплануыннан туктап калырга мәжбүр булды. Шаулап, гүләп, үкереп торган дингез аны каядыр агызып алып китте.

Үзенең хәле шәптән булмаса да ул тирә-якка күз ташларга да онытмады. Бер мәлне ул як-ягында дулкыннар белән көрәшкән кәмә сыман кара-моралар

күрде. «Ярый әле алар исән икән» дип уйлады ул үз алдына. Беркадәр вакыттан соң янадан дингез өстенә күз төшерде, кара-моралар юкка чыккан, тирә-якта берни аерырлык түгел иде. Шул чакны, аның күнелен сызлатып, ачыттырып, чиксез бер әрнү тойгысы өтеп алды. «Барысы да... су төбенә китте микәнни?« дип уйлады.

Күпмедер вакыттан соң дингез аны ниндидер яр буена китереп чыгарды. Җил тынган, көн яктырган, дулкыннар юашланып калган. Аяк астында, якында, тирә-якта... каты җир. Су буенда комлырак, судан читтә вак таш, тагын да арырак тәбәнәк калкулык, калкулыкта куе куаклар. Аннан да арырак, бөтен күкне каплап, тоташ бер карангылык булып, текә таулар, кыялар калкып утыра. Берни селкенми, берни чайкалмый. Дөнья яратылганда ничек куелган булса, кымшанмыйча, баш-аяк килмичә шул көенчә утырып торалар. Нинди рәхәт, нинди тыныч! Ләкин нинди җир, нинди утрау икән соң бу?

Артык пошынмыйча, кайгырмыйча Тажит шул турыда уйлады һәм мәкерле куркыныч судан, дингездән ничек тә ераграк булырга тырышып, каршыдагы куаклар ягына китеп барды. Барып җитә алмады—аягында тәкатьсезлек тоеп, тигез җирдә сөрлегеп китте, егылды һәм кулларын-аякларын як-якка ташлап, егылган җирдә тынып калды.

Ул комлы, ташлы яр буена килеп чыкканда вакыт кич иде ахрысы. Карангыда, төн урталарында ул уянып китте, күзләрен ачты. Уяну белән иң элек ачлык тойгысы баш калкытты. Ачлык тойгысыннан соң туну, салкынлык тойгысы барлыкка килде. Ул үзенең соңгы мәртәбә кайчан, нәрсә ашаганын да хәтерли алмады. Ана хәзер үк нәрсәдер табарга, нидер капкалап алырга, һичьюгы чишмәгә ятып су эчәргә кирәк иде. Ләкин кая барырга, кемне күрергә—ул моны аерымачык кына күз алдына китерә алмады. Күз алдында, анда, зиһендә бары бер генә нәрсә торып калган иде—ул да булса дингез, яшен, күк күкрәү һәм кәмәдәге ыгы-зыгы. Аннан соң имән агачыннан юнып эшләнгән ат башы. Ләкин боларның барысы да чын түгел иде. Боларны ул төштә генә күргән иде бугай. Җил-давыл, дингез турында олылар төрле куркыныч нәрсәләр турында сөйләгәч, бала чагында ул шулай йокыдан саташып, коты алынып уянып китә торган иде.

Бәлки, хәзер дә ул шулай куркыныч төш кенә күргәндер? Өндә шундый нәрсә булырга мөмкин түгел. Барлык йортын-иенең белән төялеп чыгып кит тә, искәрмәстән җил-давылга юлык та!.. Кинәт, тора салып бөтенесе су төбенә китсен, имеш! Юк-юк, булырга мөмкин түгел! Изге Мин атам, изге Дикә анам! Мөмкинме шундый нәрсә? Мин—исән. Димәк, алар да исән булырга тиеш. Җәмәгатем, балаларым, караларым. Кайда икән алар. Дингез, әйтче яшермичә...

Аның шулай дип әйтәсе килде, аның кычкырасы, бөтен җирне-күкне дер селкетеп аһ орасы килде.

Ул кычкыра алмады. Яр буенда ул ниндидер кара нәрсә күреп алды. Бу ана дингез чыгарып ташлаган кешедер сыман тоелды. Ашыгып ул әлеге үзе кебек үк үлемнән котылган кеше янына килде. Аның кеше дигәне юеш комда ятып торып калган ат башы булып чыкты. Ул шундук айнып китте. Бөтен нәрсә ап-ачык булып янадан күз алдына килде. Шул ук мәлдә диярлек ул бөтен күкне каплап, дингезгә үк терәлеп торган биек таулар, кыялар ягында кайдадыр бик югарыда өзлексез янып торган, каядыр галәмгә ашарга тырышкан сыман туктаусыз ыргылып, бәргәләнеп янган җанлы, тере ут күреп алды.

Шулай итеп, барысы да аңлашылды. Дулкын аны Акланга, изге утрауга китереп ташлаган. Нәкъ Саба авылы янына диярлек. Анда аның танышлары бар. Анда аның хәтта төн уртасында барып капкасын кагарлык якын кешесе дә бар. Ерак түгел. Шушы килеш, хәлсез килеш алпан-тилпән барганда да,

таң атуга барып җитәргә, таныш капканы кагарга булачак. Чынлап та ул кузгалып китте. Ләкин Саба ягына түгел, биектә, югарыда туктаусыз бәргәләнеп, өндәп, чакырып янган ут ягына таба китте. Ул мондагы тауларны, таулардагы сукмакларны белә иде. Белмәскә, турадан килә торган туры юлны ул диңгез буена кадәр нәкъ шушы төштән уздырырга тиеш иде ләбаса. Текә таулар арасыннан ул аны диңгез ярына сөзәк итеп, шул ук вакытта туры итеп төшерергә тиеш иде. Моның өчен берничә җирдән калкулык сыртларын кисеп алырга, берничә җирдән тирән аралыкларга таш-балчык өяргә, озын бер күпер салырга кирәк булачак иде. Аннан соң ул сугыш кәмәләре туктап тору өчен иркен куен ясарга, яр буенда исә ныгытылган таш кала салырга тиеш иде.

Ләкин менә булмады. Аның да, мәрхүм Карманның да хыялы тормышка ашмады. Белексез, булдыксыз мака сар бөтен эшне чуалтты да ташлады. Туктале, әллә соң мака сар Аланча түгел, аллалар чуалты микән соң бу эшне?

Кем генә булмасын, чуалды эш. Чуалттылар, баш-аяк китерделәр. Очлы кыя башындагы серле утка әнә берни булмаган. Ул һаман да яна да яна.

Тажит туры утка таба карап барды һәм таң алдыннан таныш капканың җиз дүңгәләгенә барып тотынды. Эчке якта башта кыңгырау шылтыраган тавыш ишетелде, аннан соң йокылы каравылчының нидер мыгырданганы ишетелде. Аягында көчкә басып торган, берничә көн эчендә танымаслык булып ябыккан, суырылган, яңакларын, ияк очларын сакал-мыек төкләре каплап киткән Тажит тын алырга да куркып капка ачылуын көтте. Аның өчен бу тормыштагы барлык газаплардан, кайгы-борчулардан котылу капкасы иде. Яр буенда, тауда, урманда тотып алсалар, аны янадан көчләп читкә озатачаклар яисә хәтта кол итеп сатачаклар иде. Аны менә тотып алмадылар. Исән-имин ул менә бу капка янына килеп җитте. Ләкин, капкадан кереп, биек таш койма белән әйләндереп алынган шушы изге җиргә аяк бастымы, ул инде беркайчан да моннан кире чыга алмаячак иде. Үзе теләп, үзен-үзе ул монда төрмәгә ябып куячак иде. Ләкин бу дөньяда аның өчен хәзер бердән-бер котылу урыны—шушы төрмә иде.

Капканы ачарга бик үк ашыкмадылар. Башта сорадылар: кем син, нишләп йөрисең? диделәр. Белеп килдеңме, белми килдеңме? диделәр. Коралың юкмы, юлдашларың юкмы? диделәр. Сорауларга кыска-кыска итеп ул җавап бирде. Кайбер җавапларны ишетеп житкермәделәр, ахрысы, кат-кат сорадылар. Шул ук вакытта кемдер югарыдан, капка баганасы биеклегендә эшләнгән биек басмадан аны күзәтеп торды сыман. Тажит башын күтәреп карамады—ул аны бөтен күңеле белән сизеп-тоеп торды.

Күпмедер көттереп торгач, капканы ачтылар. Тажит, уң аягын атлап, изге җиргә, тыелган җиргә басты. Кергәч, ул кыска гына итеп яңадан үзенең һәлакәткә юлыгуын, күпмедер диңгездә булуын сөйләп бирде. Ул бары аларга үзенең кемлеген әйтмәде дә, исемен генә әйтмәде. Капка сакчылары аңа үзләренең кичтән калган каты-коты икмәкләрен бирделәр, эчәренә су бирделәр. Шуннан соң тар, кысан куыш идәнендәге изелеп, әвәләнеп беткән саламга күрсәтеп, кояш чыкканчы йоклап, ял итеп алырга куштылар. Ул шундук сузылып ятты да йокыга китте.

Нәкъ менә мака сар йомышчысы Бабул кебек, аякларын, кулларын як-якка ташлап, дөньясын онытып йоклады.

Икенче көнне аны Мәнзүм ата белән очраштырдылар. Никадәр танымаслык булмасын, Мәнзүм ата аны таныды һәм озак кына исенә-акылына килә алмый утырды. Мәнзүм атага Тажит барысын да сөйләп бирде. Үзен бирелеп, теләктәшлек белдереп тыңлаучыга аның күңелендәге иң зур кайгысын да әйтәсе килде.

—Җәмәгатем, балаларым... оныта алмыйм.—Алар алдында үземне гаепле

саныйм,—диде ул, күз яшен күрсәтмәс өчен битен каплап.

—Менә алла аларны корбан итеп алган,—диде Мәнзүм ата дәртсез бер салкынлык белән.

—Барысын да микәнни?!—диде Тажит, коты алынып.—Инде беркайчан да мин аларны күрә алмам микәнни?

—Монда аяк баскач... күрә алмассың,—диде Мәнзүм ата.

—Исән булсалар дамы?!—диде Тажит, ышанасы килмичә.

Мәнзүм ата җавап кайтармады.

—Син, Тажит, тау-ташны кисеп туры юл салмакчы булдың. Инде аңладыңмы—туры юл анда түгел, монда,—диде Мәнзүм ата.—Мин сиңа әйтеп карадым—тыңламадың. Ул вакытта мин сине ярата алмадым. Хәзер син минем... алмашым булырсың. Сизеп торам—озакламый тыным киселәчәк. Сине миңа алла үзе җибәргән. Исемеңне алыштырырсың... Заманында Сабир ата миңа Мәсәви исемен онытырга кушты. Мин Мәнзүмгә әйләндем. Сиңа да үзеңнең Тажит икәнеңне онытырга туры килер. Пир ата Мәҗит булырсың..

Мака сар илчесе Бабул көннең кызуы сүрелеп, күләгәләр озыная башлагач кына уянды. Урыныннан сикереп торды да, үзенең кайдалыгын төшенә алмыйча, ары бәрелде, бире бәрелде—кулын, тезен авырттырды, маңгаен авырттырды һәм коты алынып кинәт бар көченә кычкырырга тотынды. Тавышка шундуы Кәбир килеп житте. Аңа моннан ерак китмәскә, куышка, олы кунакка күз-колак булып торырга кушылган иде.

—Кем кирәк? Нәрсә кирәк?—диде ул, Бабул каршысында калкып.

—Ник яптыгыз мине монда?—дип кычкырды Бабул.—Беләсезме, мин кем? Мака сар Аланча илчесе мин!

Куркудан аның аяк-куллары калтырады, тавышы өзек-өзек булып, колакка ятышсыз булып чыкты.

Кәбир чыпта ишекне күтәреп куйды.

—Чыгасың килсә, әйдә, менә моннан...—диде ул

Бабул атылып тышка чыкты, авызын ачып, ашыгып тын алды һәм якты көнне, таныш күкне, тауларны-урманнарны күреп, берьюлы тынычланып калды.

—Уф! Жир астына... базга ташлаганнар дип торам,—диде елмайгандай итеп.

—Мин хәзер килермен,—диде Кәбир, каядыр китмәкче булып.

Бабул аның кулыннан тотып алды.

—Тукта! Тамагым кипте,—диде. Кәбир аны чишмә янына алып килде.

—Менә, ятасың да эчәсең,—диде, челтерәп аккан чишмәгә күрсәтеп.

—Чагыр кирәк, чагыр!—бер генә тамчы,—диде Бабул чыраен сытып.

—Хәзер, хәзер, көтеп тор!—диде Кәбир һәм Бабул нәрсә дә булса аңлап өлгергәнче, ашыгып каядыр китеп тә барды.

Бабулның көтеп торыр тәкате калмаган иде ахрысы—Кәбир әйткәнчә ул жиргә сузылып ятты да, чишмә өстенә иелеп, эт кебек лач-лоч китереп, су эчәргә тотынды. Эчеп туйгач аягына баскан иде, каршысында таныш сыман бер кеше күреп, катты да калды. Бу кеше тап-такыр итеп кырылган ялан башлы, ялан аяклы иде, өстенә исә озын итәкле жилән-күлмәк киеп куйган иде.

—Уянгансың икән. Әйдә, куышка керәбезме?—диде пир ата Мәжит, тораташтай тынып калган илчегә эндәшеп.

—Нинди куыш!?—диде Бабул, берни аңламаган сыман.—Минем бит сине каядыр күргәнем бар!

—Син инде әйттең аны миңа,—диде пир ата.

—Турада сине барысы да үлгәнгә саный,—диде Бабул, пир атаны тыңламыйча.

—Үлгән Тажитне мин белмим. Без шулай бер-беребезгә охшаганбыз икән, димәк, ул изге җан булган. Карлы тау келәүлегендә изге булмаган кеше юк,—диде Тажит-Мәжит, мөмкин кадәр тыныч, дәрәҗәле булырга тырышып.—Син үзеңне мака сар илчесе дип белдерден. Мин сиңа бер сүзсез ышандым, капкамны ачтым. Керден, ял иттең—инде сөйлә: нинди йомышы төште мака сарның безгә?

—Менә кызык! Ошагач та охшар икән кеше бер-берсенә! Тавышы да шул ук, төсе-бите дә... Чәче генә юк, киеме башкача,—диде Бабул төштәге сыман сөйләнеп.

—Син чыннан да мака сар илчесеме соң?—диде пир ата, җиңелчә үртәлеп.

Бабул сул кулын югары күтәргәндәй итте, йодрыгын йомарлап, пир атаның күзенә якынрак китерде.

—Менә!—диде горурлык сизелеп торган катгыйлык белән.

Сул кулының урта бармагындагы алтын йөзеккә түгәрәкләнеп бөгәрләнгән җылан төшерелгән иде. Бабулның тышкы якта калган кәрендәсләрендә, атларының маңгайларындагы, күкрәкләрендәге җиз, көмеш калайларда, кешеләрнең бил каешларында, коралларында—һәркайда шундый тамгалар бар иде һәм ерактан ук алар: «Менә ул—без!» дип кычкырып торалар иде сыман. Пир ата аның кем тамгасы, нинди тамга икәнлеген бик яхшы белә иде, әлбәттә. Хәзер менә аның шулай берни белмәгән сыман сорап торуын Бабул чыңга алды ахрысы. Пир ата Мәжитнең турадагы ниндидер «төзүче Тажиткә» охшаган булуы белән кызыксынуы шундук кими төште.

—Кайда сөйләшәбез соң? Шулай аяк өсте генә түгелдер ич?—диде ул, баштагы уйларыннан бүленеп.

Пир ата, ишарәләп, якындагы куышка күрсәтте.

—Менә минем сараем. Әйдә, түрдән уз,—диде.

—Карлы тау келәүлегендәге изгеләр бик иркен яшиләр, ашаганнары бал да май, дип сөйләгән булалар тагын,—диде Бабул, куышка керергә ашыкмыйча.—Мака сар илчесе белән сөйләшергә рәтле бер сараең да юкмени? Миңа ул куышта тын җитми, башыма таш төшәр кебек.

—Алайса сарайда утырырбыз,—диде пир ата, килешеп.—Карлы тау келәүлегеннән иркен сарай юк! Түшәме күккә терәлгән, идәненә болыннар, урманнар сыя, челтерәп чишмәләр агып ята.

—Алай икән,—диде Бабул, пир атаның тел төбен аңлап.—Син мине чишмә суы белән генә сыйлап җибәрмәкче буласың ахрысы.

—Әйдә, алайса, ин элек ашап-эчеп алыйк.

Олы кунакны пир ата өч имән янына алып килде. Көн кичкә авышканлыктан, имән төбендәге күләгә дә икенче якка—кыялар ягына күченгән, иртән ашап утырган таш ачылып, ятырып калган иде. Пир ата уртанчы имән янында туктап, мака сар илчесенә үзеннән уң кул яктагы урынны күрсәтте. Беренче булып үзе утырды, шуннан соң илче утырды. Аларның килүен көтеп торган аксакаллар шулай ук үзләренең урыннарына утырдылар. Өлкәннәрдән читтәрәк, күләгәле якта торган яраннар берниндн шау-шусыз, шулай да бик җитез кыланып, ашаучылар алдына калын чыпталар, чыпталар өстенә көмеш табаклар, көмеш пычаклар куеп чыктылар. Чыпталарның зуррагы, бизәклесе пир ата белән илче алдына куелды.

Шуннан соң ашчылар эшкә тотынды. Капкачлы, ике тоткалы таш табакларда ашчылар томалап пешерелгән каз китерделәр. Беренче табак пир ата алдына куелды. Табактагы бер бөтен казны көмеш табакка алып салдылар да, авыр кайнар табакны, капкачын ябып, сак кына күтәреп, илче Бабул алдына китереп куйдылар.

Яхшылап йолкынган, мәмрәп, тәмле исләр таратып яткан симез казны күрү белән, Бабул елмаеп җибәрде, иреннәрен ялмап куйды һәм

«башлыйбызмы?» дигән сыман, пир ата ягына карап алды. Пир ата исә тагын бер-ике табак килгәнен котебрәк торды да, көмеш пычагы белән казның беркадәр тиресен кисеп, артына, имән төбенә ташлады. Шуннан соң, барысына да ишетелерлек итеп: «Әтекәмә-инәмә!« диде.

Пир атадан соң Бабул да пычагына тотынды, «Әтекәмә-инәмә!« дип садака бирде һәм тәмләп, ләззәтләнеп ашарга тотыны. Пир ата анын кебек үк ачыкмаган иде, аннан соң анын хәзер бик үк ашыйсы да килми иде кебек. Мака сар илчесе килеп төшкәннән бирле ул үзендә тыелгысыз бер киеренкелек, тынычсызлык тойды. Бу тынычсызлыкны берни белән дә томалап, онытып, юкка чыгарып булмый сыман иде. Бабулның үзен тануы, йөзне жыртып, күзгә карап кирәкмәгән сораулар бирүе генә түгел, гомумән анын монда булуы, үзендә ниндидер серле сүз саклавы өзлексез анын эчен пошырды, саруын кайнатты. Ана карата монда беркем көч куллана алмаячак, беркем аны янадан түрә катына, мака сар катына алып бара алмаячак. Шулай да... ах, шулай да!

Ни хәл итәсен, менә шундый тәмле аш янында да ул тулысынча онытыла, тынычлана алмады, хәтта авызына капкан майлы казы да сөяк булып тамагына аркылы утыргандай булды. Кисеп алган боттан ул бер-ике генә капты да, артына борылып Кәбиргә ым какты.

Үзенә сузылган кисәкне Кәбир эләктереп кенә алды.

—Әһә!—диде анын янындагы Әлзәм, искәрмәстән.

Анын «әһә»сен пир ата ишетеп калды. Шунан соң икенче ботны да кисеп алды, аны да бер-ике мәртәбә тешләде дә, борылып «Әһә»гә тоттырды. Пир атаның кирәгеннән артык юмартлануын башкалар да күреп алдылар. Алар да, билгеле, үзләренең яраннарына шундый тәмле кисәктән өлеш чыгара алган булырлар иде. Ләкин беркем дә андый хәрәкәт ясарга ашыкмады—Карлы тау келәүлегенә көн дә илчеләр килеп тормый һәм мондый майлы казлар да көн саен пешеп тормый. Һәркем үз табагына иелеп, бирелеп ашавында булды. Ләкин ни кадәр тамаксау булмасыннар, алар инде хәзер элекке яшь чагындагы аучылар да, балыкчылар да, дингезчеләр, юлбасарлар да түгел иде. Көн дә ике мәртәбә туйганчы ашап, эшсез-хәрәкәтсез ятып, күптән инде аларның карыны тараеп, кысылып беткән—анда хәзер бер бөтен каз түгел, анын яртысы да сыярлык түгел иде. Ашап туйгач, аксакаллар, майлы иреннәрен, кулларын сөртештереп, иттән аерылып, шәрәләнеп калган сөяк-санакларны, ашалмаган кисәкләрне көмеш табагында калдырып—барысын бергә яраннарга бирделәр.

Ул арада ашчыларның берсе озын муенлы, очлаебрак торган тар авызлы авыр чүлмәк күтәреп килде. Чүлмәкне ул пир атаның сул ягына утыртып куйды. Карап торышка иске, борынгы тоелган, шулай да ак, зәнгәр, кара, кызыл буяулар белән төшерелгән бизәкләре уңмаган юан корсаклы чүлмәк авызы балавызлап томаланган, балавызга батырып аркылы-торкылы жеп сузылган, жепнең очы балавыз шарга батырып, шарга тамга сугылган иде.

—Карлы тау келәүлегенең изгеләре чагыр эчми, табада томаланган кош ите ашамыйлар дигән булалар тагын,—диде илче Бабул, үзалдына сөйләнгән сыман, тулы чүлмәк ягына караштырып.

Ул моны, билгеле, шаяртып әйтте, ләкин мондый шаяртуларга күнекмәгән кайберәүләргә бу ниндидер киная булып тоелды.

—Олуг илчеләрне сыйлаганда чагыры да, кош ите дә изгеләргә язык түгел,—диде пир ата, уңайсыз тынлыкны йомшартып.

Балавызның шарын тартып ул башта жепнең очын алды, аннары жепне тартып, чүлмәк авызындагы балавызын ватты да, алтын савытка кара кучкылланып торган утлы чагырны агызды. Уты сүрелә төшсен өчен савытка су өстәде, болгатты да, шуннан соң алтын кәсәгә салды. Башта үзе авыз итте,

аннан соң илчегә бирде. Бабул шулай ук, алтын кәсәдәге чагырны беркадәр авыз иткәч, аны үз янындагы күршесенә суздьі. Чагырлы алтын кәсә аксакалларның барысын да йөреп чыгып, янадан пир атага әйләнеп кайткач, мака сар Аланча илчесе Бабул, ике кулын симез корсагында кушырып тоткан килеш, изге картларга күз йөртеп чыкты да, күптән көтелгән сүзен әйтте.

—Карлы тау келәүлегенә Аклан иленең баш мака сары Аланча киләчәк. Мина менә шуны әйтергә кушылды,—диде ул.

Бу хәбәрне ишетеп барысы да тынып калдылар. Аксакаллар бер-берсенә карадылар, пир атага карадылар. Пир ата Мәжит беркемгә дә карамады—күз алдына туры килгән чыптага, чыпта өстендәге алтын кәсәгә, беренче кат күргән кебек, текәлеп тик утырды. Илчедән соң ни дә булса әйтергә тиешлеген ул бик яхшы аңлады, ләкин кирәкле сүз нишләптер тел очына килмәде.

—Карлы тау келәүлегенә... мака сар киләчәк...—диде ул илче сүзләрен кабатлап. Кайчан килерен белеп булмыймы?

—Сезгә кайчан жайлы—шунда,—диде илче.—Сезнең белән киңәшергә кушылды. Шушы бер ай төшендә.... бер айдан да сонармастан....

—Ник килә?—анысын да белеп булмыймы?—диде пир ата тавышын әкренәйтә төшеп.

—Ник килә дисеңме?—диде илче, чиктән тыш гажәпләнеп.—Шуны да белмисезмени?!

—Турадагы яңалыклар безгә бик сонлап ирешә. Белмәвебез дә бар,—диде пир ата.

—Бөтен ил, бөтен Аклан шау-гөр килеп тора. Көллесе шуны сөйли,—диде илче, жанланып, кулларын ботап.—Илгә яңа юсык кирәк. Мака сарлар, түрәләр, аксөякләр аллалар язып калдырган юсыкка буйсынмыйлар. Кая карама, бозыклык, азгынлык! Ата улны, ана кызны белми...

—Анысын беләбез,—диде пир ата тыелып кына.

—Белгәч?!—диде Бабул.—Илгә яңа юсык кирәк, тәртип кирәк! Борынгы мака сарлар, тугыз ел тәхеттә утыргач, Карлы тауга килеп, тау куышына кереп аллалардан киңәш сораган, юсык сараган. Кырык жыл тәхеттә утырган Карун бер мәртәбә дә Өрәк белән киңәшмәгән. Аннан элегрәк утыз жылга якын утырган Арысби киңәшмәгән, Селәүтин киңәшмәгән. Белекле галимнәр әйткәннәр—йөз дә ике жыл инде мака сарлар Карлы тау келәүлегенә аяк басмаганнар, изгеләр белән дә, аллабыз Өрәк белән киңәшмәгәннәр. Белекле галимнәр әйткәч, мака сар Аланча Карлы тауга килергә булды. Нурлы бикә дә каршы түгел. Шаулашкан караларның, аксөякләрнең авызын томалау өчен генә булса да, мака сар Аланча сезнең янга килеп, тау куышында торып... сездән, аллалардан изге сүз ишетмәкче була.

Пир ата Мәжит төшенеп алды, жиңел сулап куйды һәм башын калкытып, аксакалларга, тирә-ягына карап алды.

—Мака сар Аланчаның тәхеткә утыруына быел.... менә шушы муллык аенда тугыз жыл тула,—диде ул сакланып кына сүзгә башлап.

—Дөрес, тугыз жыл!

—Шулай шул!—диештеләр аксакалар да, телләре чишелеп.

Ләкин шуннан ары беркем берни әйтә алмады. Илче белән, билгеле, пир ата гына сөйләшергә тиеш иде. Аннан соң, монда алай сөйләшеп тә торасы нәрсә юк—килә икән, килә. Тик менә ул ничек килер, кемнәр белән килер, ул килгәч монда ниләр булыр, әлегә беркем дә күз алдына китерә алмады. Ни өчен дигәндә, кайчандыр элекке заманнарда Карлы тауга тугыз жыл саен мака сарлар килүе турында имеш-мимештән күп нәрсә ишетеп белсәләр дә, чынлыкта моның ничек булганлыгын рәтләп белмиләр, күз алдына китермиләр иде. Белсә, пир ата Мәжит беләдер. Кам-каталыкны да, үзенең

серләрен дә пир ата Мәнзүм ана калдырды. Барлык изгеләр арасында иң изгесе, иң санаклысы ул пир ата Мәҗит.

Аксакаллар кинәш-табыш һәм акыллы сүз өмет итеп, пир ата Мәҗиткә карадылар. Ләкин пир ата Мәҗит тә чынында берни белми иде. Күп кенә серләр, тәртипләр турала гына түгел, монда, Карлы тау келәүлегенен үзендә дә онытылып беткән иде. Ләкин мака сар илчесе алдында боларнын берсен дә сиздерергә ярамый иде. Бу мизгелдә пир ата Мәҗит шуны гына чамалый алды һәм Бабул әйткәннәргә җавапсыз калмас өчен генә, болай гына сорап куйды

—Ту анабыз Дикәнең чишмәсе табылмадымы, ишетелмиме?—диде.

—Һи-и! Монда бикләнеп ятып сез чыннан да берни ишетмәгәнсез,—диде илче.—Тапканнар бит ул чишмәне!

—Йа, алла,—диде пир ата, балкып, башын, иелгән гәүдәсен турайтып.

Аксакаллар да күңелле генә гөрләшеп алдылар.

—Куанышырга ашыкмагыз,—диде илче, утлы кузга су сипкән сыман. Бөтен шау-шу шул чишмәдән башланды да инде. Кемдер әйткән: чишмә югалмаган, жиз койма буендагы чүплек астында күмелеп калган, дигән. Каралар ышанган. Шуннан китте дә китте! Сөйләсән—сөйләп бетерерлек түгел. Кыскасы шул—чүплекне юкка чыгарып Нурлы бикә шунда зур багана утыртырга, багана башына үзенең алтын сынын мендереп бастырырга уйлаган. Менләгән колларны китереп чүплекне әрчеделәр, тау буен кистеләр. Карасалар, борынгы чишмә дә, нинди дер кызның таш сыны да чыккан ди. Нурлы бикә чишмә суын жир астыннан арыкка борып җибәрергә, шул төшне таш белән төреп алып багана утыртырга кушкан. Юк, ул кушмаган, аны ана теге атаклы сынчы Әүфил шулай киңәш иткән.

—Сынчы?!—диде кинәт пир ата Мәҗит, кызарынып, ярсып.

Кайберәүләр аның шулай кинәт сорап куюына аптырап калдылар. Кызып-кызып тура хәлләре турында сөйләүче Бабул исә андагы үзгәрешкә бөтенләй игътибар итмәде.

—Чишмә, таш сын багана төбендә, куышта торып калган,—диде ул аңлатып, сүзен дәвам итеп. Баганаы биш җыл өйделәр. Мен кеше бер ай эшли дә, бер ай ял итә, алары урынына икенче мене эшли, алары ял иткәндә, өченче мене эшли.

—Алай икән,—диде Мәҗит тагын үзалдына ярсып һәм үзенең йөзен башкалар күрмәсен дигәндәй, иелеп кәсәгә тагын чагыр агызырга тотынды.

—Быел менә багана салынып бетте диләр. Озынлыгы—йөз колач,—диде Бабул. Андый баганаың дөньяда булганы юк диләр. Йөз чакрымнан күренеп тора ди.—Хәзер менә Нурлы бикәнең алтын сынын бастырып куясы гына калды. Анысы авыррак.

—Ник?—диде тагын да Мәҗит.

—Ул аны саф алтыннан койдырмакчы. Койдырырга җитәрлек алтын юк. Казна буш. Халык арыды, жиләде ул бетмәс-төкәнмәс эшләреннән. Теге багана төбендә калган сынны кайберәүләр анабыз Дикә сыны икән диләр, алладан тынычландыргыч сүз ишетәсе килә мака сарның.

«Болай булгач, төшендек, барысын да сөйләп бирде» дип уйлады Мәҗит, ләкин алтын кәсәне илчегә суздыда әйтеп куйды:

—Ил-көн белән, изгеләр белән киңәшмичә, мин сина бер сүз дә әйтә алмыйм. Җавабын өч көннән әйтербез,—диде...[1]

---

[1] Әсәр кыскартылып бирелде.



Равил
Фәйзуллин

# СОҢГЫ ЕЛЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

## Җиткән вакыт...

**Дөрес булмас уфтанулар гел-гел генә.
Байтак булды шат көннәрем бу гомердә!**

**...Шулай да үзгә бер моңсулык кичләрдә.**

**Ил-йортның ни бәясе—кылган эшләргә?
Гомерем булса, алда янә нишләргә?..
Күрәсең, җиткән вакыт Табигатькә сыенырга.
Аллаһының рәхмәтенә сыгынырга.**

## Диңгез кабырчыгы

**Өстәлемдә диңгез кабырчыгы.
Колагыма куйсам—шавы бар!
Тыңлап, ишетеп, аңлый алсаң аны,
күңеленә кагыла дулкыннар.**

**Үзен-үзе кат-кат төргән бер таш.
Бер могҗиза инде дөресе дә!
...Бу дөньяда шулай йомыла-йомыла,
кабырчыкка әйләнерсең дә!**

***

**Дәүләтсез халыкның хәтере
җелек кебек суырылган...
Үзаңы—тездән түбән.
Горурлык-дан—онытылган...**

**Гавәмнең кумирлары да
үзенә таманкай:
берәр сукбай шагыйрь,
йә үзешчән «бөек» җырчы,
йә берәр шамакай...**

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943)—*Татарстанның халык шагыйре; алты томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

## Аскет

*(Студент шагыйрь)*

Кап-кара төн килә!
Ул—ак күлмәктән...

Шома, тыгыз мускуллардан
дәрт ташый күкрәктә!

Бер көтү хур кызлары
килә җәннәттән!

Ишектә кыңгырау!
Ишетми...

Тынлыкка инәлеп
көтә ул берәүне—
Күктән иңәчәк
Шигъри Мәлне!

## Яхшы...

*(Тынычлану, килешү, әзерләнү)*

*Төрле җирләрдә чәчелгән балалары кулында гомер кичүче туксан яшьлек карт авызыннан.*

Хәзер миңа кайда да яхшы...
Авыздан теш төшкән.
Кулымнан эш төшкән...

Хәзер миңа кайда да яхшы...
Язмыйча чарам юк.
Каләмдә карам юк...

Хәзер миңа кайда да яхшы...
Дөнья диләр гөрли!
Ә мин бит ишетмим...

Хәзер миңа кайда да яхшы...
Дәрт юк, дәрман юк...
Әҗәлдән фәрман юк...

Хәзер миңа кайда да яхшы...
Җанымда аваз бар.
Кальбемдә намаз бар!

...Хәзер миңа кайда да яхшы...
Суда бүрткән ярма да яхшы.
Күктә очкан карга да яхшы...

* * *

Мәдхия—ахмакка!
Мораторий—әхлакка!
Ярты Илеңне сатып ала
миллиард җыйган бер «маңка!»

Кемдер әйтә:
шул кадәрле урлый алгач
була алмый ул—маңка!

Сәлам демократка!

* * *

Сандугач сайрар ул!—
аталанасы бар!
Яшь кеше сөяр ул!—
хаталанасы бар...

Яшәү—инстинкт.
Мәхәббәт—фасады.
...Бу мизгелдә күпме
яңа җан ясалды!..

## Теләк яздым такмаклап...

Мәчетләр иман нурын гел
тарата торган булсын!
Юллар—озаткан яшьләрне
кайтара торган булсын!

Зиратлар зурайса да,
авыл кечерәймәсен.
Сабантуе сөлгеләре
сандыкта черемәсен.

Киштәләрдә шешә түгел,
китаплар тулып торсын!
Өлкәннәрнең урыннары
түрнең башында булсын!

Сөрелмичә, чәчелмичә
кырлар кыргыйланмасын.
Алмалар пешеп аллансын,
умарталар баллансын.

Яңа гаилә корган ирләр
киң буралар бурасын.
Яшь киленнәр, чират торып,
чишмәләрдән су алсын!

Ишле парталары белән
мәктәпләр гөрләп торсын.
Кичләрен татар көйләре
урамнарны тутырсын.

...Якташларга теләкләрне
дәвам да итеп була.
Булмастай теләкләр түгел,
морадка җитеп була.
Иман булса, берлек булса
еракка китеп була!

## Бер каләмдәшкә

Сүзең—алтын. Әйткәннәрең—
ташка чокып язарлык!
Уйма-өтерге табылмый,
киткән бездән базарлык!..

Кем ишетсен? Мөнбәр түгел,
баскан төшең—бер түмгәк.
Әле кемдер әйтеп куя:
«Чё говорит ул имгәк?»

***

*А. Хәлимгә*

Орып атты өстенә килгән
гайбәтләрнең әрҗәсен!
Булган данына өстәде
хаҗилык дәрәҗәсен!

## Ни исемле фәрештә бар?..

*Кем язмышы кемнәрдә!..*

Кем багар да, кем бәһаләр
асыл җәүһәр бөртеген?
Кульяулыгым чиста микән
күз яшеңне сөртергә?

Нинди йөкләр өйгән язмыш
Синең нәфис иңнәргә?
Ни исемле фәрештә бар
Синең белән тиңләргә?

## Юаныч

Гавәм дигәненә ышана алмыйм.
Дус дигәннәре дә бер бизәр...

...Барсы онытса да,
Аккош күлендәге берәр черки
«Ул яшәде!» диеп безелдәр.

* * *

Күзләр шактый уңсалар да,
яз дәртен тоялар!

...Җил канатына сыенган
яңгырдан яшәреп
яшьләнгән кыялар.

## Борынгы карталарга карагач...

Бер якта—Бөек Кытай диварлары!
Янәшәдә—Бөек Тартария!...
...Бәлки, Дума канун чыгарыр әле
Берәр Урыс бугазы турында.

* * *

Тыелып торган дәрт—
бүселеп ташыр буа.

Бәламе ул, баламы—
барыбер туа.

* * *

Аерым Кеше хокукы!—
демократия шул диләр.

Халык-милләтләр кырыла!—
Акаеп... «күрмиләр».

## Ялгызлык

*Яшьлек ялгызлыгы—бер уен.*
*Картлык ялгызлыгы—ике чын.*

Авыру халәт... Йокысызлык...
Шешенгән күз алмасы...

...Хәзер бүтәннәр язсыннар
Ялгызлык Елъязмасын!..

***

Бу дөньяда бар микән ул
бер хәсрәте булмаган?
Андый кеше йә ул мәрхүм,
яисә әле тумаган!

## Замана

Юньле кеше килеп җылына да алмый...
Юк! Бу—без яккан учак түгел!

Хатирәләр белән яшәр көн килсә дә,
мескен булып яшәр чак түгел!

***

*Сак булыгыз, гамьсез Гулливерлар,*
*Лилипутлар килә Шигырьгә...*
Ш. Маннур

Җыйнак фидакарьләр, сак булыгыз!
«Нечкә билләр»—
корсаклылар килә мәйданга!

...Габаритларынча нәфселәре:
хакимлеккә, малга һәм данга...

## Бер мизгел ялвару

Шахтага эләккән кошчык күк
халәттә мин. Караңгы...

Күңелем әзрәк яктырмасмы?—
бер елмаеп кара әле!

## И, Туган тел!...

Сырхау телдә язам. Илһам кача.
Үзем дә, имеш, авыру икән...

Моң көче белән минекенә тиңдәш
Тагын берәр тел җирдә бар микән?

***

*Дәүләт, имеш, Дәү үләт!..*
*Гаурәтеңне түгел, Дәүләтеңне күрсәт!*

Дәүләт дигәне булмаса да,
«әшлеклеләре» очрый.

Ил-Дәүләт рухын әлегә
Шигырь һәм Моң асрый.

***

**Кавыша алу—үзе бөек җиңү!**
**Кушылыплар алу—үзе бер яшәү!**

**...Тик шунысы бар: Ут белән Су**
**берсен берсе бетерешә!..**

***

*Җаннарның*
*тәхете Күктәме?*

**Безгә аңлашылмас сер белән**
**Җиргә атылалар йолдызлар!**

**...Ләхетләре яктырып аладыр ул**
**Кеше дигән бөекләрнең—**
**җаннарының күләгәсе.**

***

**Күзәнәкләр көн дә кими...**
**җиңеләя барабыз.**
**Уй-исәпләр арта бара...**
**Авырая барабыз.**

**Ал, дип уйлап, артка карап**
**без каядыр барабыз.**

## Бәлки, тагын бер кат янып булыр...

*Күмерчеләр утынны*
*томалап яндыралар.*

**Эчтән янам. Ялкынланып янсам,**
**тиз булыр ул көлгә чыгулар!..**
**Ил гамендә янгач, ни дисәң дә,**
**түзеп була. Кирәк чыдарга!**

**Көлгә әйләнеп бетсәм, мин бит кабат**
**әверелә алмам күмергә.**
**Бәлки, тагын бер кат янып булыр**
**безсез без булачак гомердә?..**



Альберт
Хәсәнов

# КЫЗЛАР КҮРСӘМ...

ХИКӘЯ

Быелгы җәй әллә нindиерәк, дорфа дип әйтимме, сәеррәк булды бит, әй. Прәме аптыраш. Йә тота да, иләмсез кыздыра. Йә шунда көтмәгәндә генә күк йөзен болыт баса. Әйтерсең, бөтен күк гөмбәзе буйлап йөзләгән мичкә тәгәрәтәләр. Даңгыр-доңгыр күк күкрәп, ялт та йолт яшен яшьнәп чиләкләп орып яңгыр явып китә. Менә бүген дә иртәдән үк көннең көе-рәте булмады. Таң беленә башлау белән болытлады, теш арасыннан гына кысып яңгыр пыскырга кереште. Бер дә кирәкми иде югыйсә.

Мин юлда әле. Итәгемә прәме ут кабып, Ак Күл станцасына ашыгам. «Жигули»не камчылаганымны килештереп, спидометр шаян күз кыса, йә туксанны, йә йөзне үк күрсәтә. Ашыкмаска, ни—юлга соңлабрак чыктым, каһәр. Үз йорт-җирең белән торганда, өйдә эш бетәмени ул? Бетеп куйса, хатының шундук яңасын табып тоттыра.

Ак Күл станцасында бик зур кунагым Николай Александрович Жуков төшәчәк. Менә шуны каршы алырга ашыгуым. Мәскәү кунагым, баздан гына алып чыккан салкын сөзмәне агач кашык белән каерып-каерып, мактый-мактый ашарга, ел да бер шулай килеп чыга. Николай гына димә-ә! Бер холыксызлансамы, җүләр!? Дилбегәсе көпчәккә бер чорналсамы? Минем аның белән күргәннәрме? Хәер, үземне дә мактамыйм: киренең киресе! Үҗәтлеккә килгәндә мине уздыручылар бармы икән әле дөньяда? Бар бит, бар. Николай миннән дә үзсүзлерәк, тәмам киребеткән Смоленск урысы. Николай Александровичның хатыны Валентина Викторовна безгә карап: «Вы два сапога пара!» дип әйтеп куя да, алай гына микән? Николай миннән күп өлеш үзсүзлерәк. Әмма ул минем әсәрләремне русчага тәрҗемә кылган кеше, бик кадерле кунагым.

Мәскәүнең «Современник» нәшриятына берничә повестемны кыяр-кыймас кына илтеп тапшыргач, Ходайның рәхмәте белән, бик җылы гына эчке рецензия язганнар. Кыскасы, юлын юлга тәрҗемә ителгән повестьларымны ошатканнар! Редактор билгеләгәннәр. Сез язганнар безнең өчен перспективалы, кызыклы. Әйдәгез, аларны русчага тәрҗемәләп, киң катлау укучыларга тәкъдим итик, диделәр. Чәчләренә бераз чал керә башлаган, гречанкалар кебек җыйнак һәм зифа буй-сынлы, бик чибәр редактор ханым Софья Ивановна, кулындагы сигаретын читкә куеп:

—Повестьларыгызны мин инде укып та чыктым. Тормышны белеп язылганнар. Безнең өчен иң әһәмиятлесе, геройларыгызга кешелекле сыйфатлар хас, персонажларыгыз укучыда симпатия уята. Мондый авторга әйбәт

тәржемәче кирәк бит инде,—дип, мина төбәлде.—Минем бик яхшы бер тәржемәчем бар барын. Әгәр ризалашса... Анын тәржемә алымнарын сез ошатсагыз, ин әһәмиятлесе, бер-берегезгә карата психологик якынлык сизсәгез, бүгеннән үк эшкә керешегез.

—Ике арада психологик якынлык та кирәкмени? Ул турыда башыма да китермәдем,—дип сорап куйдым. София Ивановна шунда мәгънәле итеп кенә елмайды.

Мәскәү нәшриятлары редакторлары искиткеч югары зәвыкка ия. Авторларына гаять ихтирамлылар. Сүз уңаенда алар, синнән кайда урнаштыгыз, торган җирегез иплеме, кире юлга акчагыз җитешлеме, булмаса, гариза языгыз, бераз аванс бирербез, дип тә кайгырталар хәтта. Чөнки нәшрият хәтле нәшриятка редактор итеп урамда тундырма йә сыра сатып торган маржаларны куймыйлар инде.

Булачак тәржемәчем белән беренче күрешкәндә, дошман тылына «тел» алырга барачак разведчикларча, бер-беребезгә бик озак төбәлешеп, сүзсез сынашып карап тордык. Ул мине безләде, мин аны. Шунысы ярады, Николай Александрович белән без яшьтәшләр булып чыктык. Икебез дә тормыш тегермәнендә бодайны байтак тарттырганбыз, шуннан башларыбызга кунган онны бер сыпыруда гына читкә очырышлы түгел.

Минем өчен иң отышлысы тагын шул булды, костюм-җиләнне, аяк киемнәрен дә икебез бер размерны киябез икән. Аның өр-яңа костюмнарын шифоньердан гына алып киеп, бер араны тәмам кинәндем. Кайчакларны: «Нәшриятка призентациягә үзем киеп барасы костюмымны алып кигәнсен бит!»—дип сукранып та ала, бичарам. Мин бит Алла Пугачева да, Филлип Киркоров та түгел. Мәскәүгә биш чемодан кием-салым төяп килмим. Бар булган өс-башым кулымдагы дипломатымда. Ә кайвакытларны айдан артык торып кайткан чаклар да була. Николайның костюмын утын бушатырга, йә цемент төяргә кимим ләбаса. Юкка сыкрый ул. Кайчакларны: «Бу яңа туфлиемне карабрак ки, үкчәсенә баса күрмә!» дип тә мыр-мыр килеп ала. Вакчыл инде, түзешле түгел. Мәскәүнең рафинадланган интеллигенты бит. Анын кайчакларны бер дә юктан шыңшып алуына түзәргә, өйрәнергә кирәк. Үзе минем өр-яңа йөнтәс бүрегемне башыннан да төшерми. Мин исә башкала буйлап чаңгычы спортсменнар кия торган иске генә йон калфак киеп йөрим. Бүрекне сал, дип тынымны да чыгарганым юк. Метрога кергәндә йә чыкканда минем бу матур бүрегемне Николай башыннан Мәскәү жуликлары алмасалар ярый инде дип төннәр буе йокламый ятканны белми ул.

Шунысын да әйтеп китү кирәктер. Николайның күтәреп мактар яклары чутсыз күп түгел. Алай гынамы?! Колак төбенә бер-бер артлы менеп төшәрлек ачуны китергән, мине күрәләтә үчектергән чаклары да җитәрлек. Нишлисен? Тәржемәчем бит. Бер хәлең юк, түзәргә туры килә.

Шуның өстенә Николай дустым коточкыч шовинист кеше, бары үз милләтен генә таный, тик аны гына мактый. Андый затларны тулырак тасвирлау өчен руслар үзләре «оголтелый», ягъни «шәрәтән» дигән сыйфатны кулланалар. Баштарак мин аның бу сыйфатын сәяси яктан өлгереп җитмәгәнлектән күрә идем. Алай гына булып чыкмады шул. Шовинистик рух белән аның мие балачактан ук агуланган. Үз заманының тулып пешкән җимеше. Николай әлеге мәгънәсез принципка бөтен яшәү рәвешен кормакчы. Кормый гына торсын әле. «Шалишь, брат, на поворотах будь особо осторожен»—дип мин аңа еш кына бармак яныйм. Чөнки ике сүзнең берендә үзенең минем «старший братым», ягъни өлкән туганым булуын искә төшерә. Димәк, һәрнәрсәдә ул мине өйрәтергә, ә мин ул әйткәннәрнең барысына да ләббәйкә китеп: «Ярар, ярар!»—дип торырга, каршысына басып, үрә катырга тиеш.

Мин үзем холкым белән болай күндәм генә зат шикелле. Әмма, милләтләр мәсьәләсенә килгәндәме, урамдагы ата күркәгә кызыл күрсәтмәвең, миңа сүз әйтмәвең хәерле. Николай, зиһенен җыеп, «Старший брат» булуы турында сүз кузгатуга, мин дә аның канына тозны шундук учлап сибәм. Алай гына калмыйча, кан тамырлары буйлап утлы шар булып йөри башлыйм. Чөнки «Второсортный» булып яшәргә не согласен, лутчы мин яу кырында җиңәм, йә үләм.

Дөрес, Николай дустым үзен миннән күпкә гыйлемрәк саный. Чөнки ул Мәскәүнең Ленин тауларындагы Михайло Ломоносов исемендәге университетны тәмамлаган. Ә мин Казанныкын гына... Николай фикеренчә, Казан—глубокая провинция. Кешеләре дә өметсез провинциаллар. Юкса, мин дә анда биш ел буена туп тибеп йөрмәдем, шар тәгәрәтмәдем. Дөньяга карашлары буенча безнең профессорларыбыз да Мәскәүнекеннән ким түгел иде. Фәлсәфә профессоры Генрих Брауде Европаның күп университетларында танылган галим иде.

Телләрне дә тырышып укыдык. Бөек философ Иммануил Кантның: «Әгәр кеше чын хакыйкатьне белә торып та, шул хакыйкать белән яшәми икән, бу кеше хакыйкатьнең чын дошманы!» дигән сүзләрен оригиналда, ягъни шартлатып алманча әйтеп биргәч, Николайның да күзләре шар булды.

Николай МГУда укыган елларын еш кына исенә алып, без анда Кытай, испан, әфган, немец, Вьетнам, һинд, Конго егетләре белән бергә укыдык, дип горурланып сөйли. Ә мин башыма гыйлемне бер дигән чуаш, удмурт, урыс, мари, мордва, башкорт егетләре белән бергә тутырдым. Безнең группадан мари егете Геннадий Айплатов соңыннан танылган фәлсәфә докторы булды. Докторлык диссертациясен МГУның үзенә барып яклады. Арабызда чем-кара тәнле негр егете дә барые, азатлык атавыннан. Фидель Кастроның вәкаләтле вәкиле булгач, Хосе Христаныбыз антрацит таш күмере төсле чем-кара булса да, аны мыскал да җәберләмәдек. Киресенчә, Хосены үзенең Кубасына, бер дигән татар кызы Васфиягә өйләндереп, башлы-күзле итеп озаттык. Мондый хөрмәт турында Мәскәү университетында укыган чит ил егетләренең күбесе хыялланмаганнардыр да әле.

Болар өстенә Николай дустым Максим Горький исемендәге әдәбият институтының икееллык сценаристлар курсын тәмамлаган. Ике сүзнең берендә, мин дөньякүләм танылган кинорежиссер Роман Кармен житәкләгән семинарга йөрдем, дип куя. Роман Лазаревич белән без кул бирешеп күрешә идек, ди. Андый корифейлар белән аралашу аңа күпме җан азыгы, рухи байлык биргәндер, дөньяга карашын киңәйткәндер! Сокланам мин аңа, хәтта бераз гына көнләшәм дә... Аның каравы Николай дустым Тукайның бер шигырен белми. Монысы шулай ук минем башка сыймый. Ничек инде бөек Тукайны белмәскә мөмкин? Ә мин аның «Шүрәлесен» татарча, русча һәм алманча яттан беләм.

Нәкъ Казан артында бардыр, бер авыл Кырлай, диләр.

«Шүрәле»нең кытайчасын да кулга төшергәнием, әмма сүзләрен әйтү кыенрак. Ничава! Кытайлар үз телләрендә әнә ничек матур сөйләшәләр. Мин дә күнегермен. «Шүрәле»не ике миллиардларга житеп яшәп яткан бөек Кытай халкы телендә сөйләргә дә өйрәнермен. Егетләр сүзе!

Николай Александрович белән мәдәният, вәзгыять, милләтләр язмышы турында бәрелешүләр безнең гадәттә Мәскәүнең мин яшәгән арзанлы гына, әмма бик ипле ВДНХ[1] кунакханәсенең бер кешелек номерында бара. Бүген баш күтәрми тәржемә өстендә эшлибез, дип күрешәбез югыйсә. Мөгезгә мөгез килеп сөзешә башлау һәрчак юктан гына килеп чыга. Ул башта сакал-

[1] ВДНХ — Выставка достижений народного хозяйства.

мыегын кырып, матур күлмәк киеп, шома гына тәрҗемә кылып утырган әсәрдәге «катык» сүзен кислое молоко дип тәрҗемә итмәкче.

Стоп! Стоп! Не спеши, дорогой!

—Кислое молоко... кадерле туганым, бердәнберем, Николай Александрович, синең Матрёна түтәең, кичтән сауган сөтен базга төшерергә онытып йә иренеп, өй алдында гына калдырган сөт. Ул иртәнгә әчегән... Кислое молоко... менә шул сөт була инде— дим.—А катык у нас квасят из топленого молока! Специально, әчеткеч салып. Катык, бигрәк тә салкын сөзмә—мировой ризык! Аны Кутузов та бик яраткан. Дунай буйларында төрекләр белән сугышып йөргәндә, денщигы Прохордан, катык ясата торган булган.

—А причем монда тетя Матрёна?!—дип Николай кызып китә.—Не обижайся, какой злой твой язык! Как терпит тебя твоя жена Кадерия-ханум!

Шушы төштә мина кылычымны кынга гына тыгасы да. Юк шул, һаман баш өстендә болгыйм.

—Катык—югары сыйфатлы һәм бик шифалы ашамлык. Мөселман дөньясында аны белмәгән, татып карамаган зат гомумән юктыр. Ә менә сез, ихтирамга лаек өлкән братым, белмисез. Әллә белеп тә белергә, танырга теләмисез. Салкын чишмә суына әче катык туглап ясаган әйрән булганда, кока-колаларың бер читтә торсын! Утыз градуслы эсседә, дингезенне йотардай булып сусауны момент баса!

—Прәме уж белмибез! Безнең Шаболовка кибетләрендә сплошь и рядом саталар бит аны. Син шулай авыз суларыңны корытып мактагач, кичә бер пакет алганыем. Фу, бер дә ошамады, чыгарып түктек.

—И-и, диваналар да инде сез! Кем инде катыкны түгә? Хәер, Мәскәү кибетләрендә сатылган катык ул бит кайнаган сөткә махсус әчетке салып оеткан катык түгел. Бутафория! Эрзац, дускаем. Подражание на оригинал! Подделка, дип атала ул. Катыкны ясамыйлар, ә оеталар. Ә инде сөзмә дигәнен тагын да катлаулырак технология белән оеталар.

Мөхтәрәм вә бик булган, үтә дә укымышлы тәрҗемәчем икенче бер әсәремдәге «тастымал» сүзен «салфетка» дип кенә кертмәкче. Стоп! Стоп! «Тастымал» калсын. Бөек рус теле, Пушкин, Толстой, Маяковский, Есенин теле татарның шушы матур сүзе хисабына да баесын. «Салфетка» үзе дә рус сүзе түгел бит. Житмәсә, соңгы чорларда бөек рус теле алты-җиде катлы сүгенү сүзләре хисабына гына байый түгелме? Согласись со мной, дорогой!

—Безнең бөек телебезне «тастымал» сүзе белән генә баетырга калса, белмим, корабны грунтка утыртмагаек,—ди ул, ачы ирония белән елмаеп.

Тагын китә тарткалаш. Бер кузгалсын гына. Өстәл артына нинди максат белән утыруыбыз да онытыла. Күп кенә киртәләрне сикереп-сикереп кенә узабыз да, милләтләр язмышына барып керәбез. Минем женем сөймәгән явыз Иванга аның мыскал да тел-теш тидерәсе килми. Минем өчен Явыз Грозный—дәүләтчелегебезнең башына житүче. Ә Николай Александрович өчен ул Бөек рус дәүләтенә нигез салучы.

—Представь себе, дорогой, әгәр сезнең ул зәгыйфь психикалы вәхшиегез ут һәм кылыч белән яулап алмаса, без инде суверен дәүләт идек. Әйтик, Латвия һәм Эстония кебек... Һәм мин Казаннан суверен дәүләт гражданины, чит ил кешесе булып сина кунакка киләсе идем. Мина карата мөнәсәбәтең дә бөтенләй башка буласы иде!—дим мин моңа.

—Не захвати Иван Грозный вас в 1552 году, вы бы всеравно не смогли сохранить свою государственность...

Бик тирәнгә керәбез бугай. Бу бәхәсне шушы төшендә туктату хәерле. Юкса минем бу үзсүзле тәрҗемәчемнен ипи шүрлегенә менеп төшүем бар.

Бераздан без кайтып төшәбез. Үз милләтенне үтереп мактау, күкрәк сугып горурлану белән генә эш бармый. Нәшрият бездән кулъязма көтә.

Редакторыбыз Софья Ивановна тагын да ашыктыра.

—Әгәр, егетләр, өлгерә алсагыз, кульязманы шушы кварталда ук производствога җибәрергә булырые. Нәшрият планында бер китаплык кына «окно» бар. Менә шунда сезнең җыентыкны кертәбез дә җибәрәбез. Дерзайте, парни,—ди.

Бер хикәямдәге «колхоз рәисенең Рәисә исемле, дегет чиләге хәтле генә хатыны бөтен авылга хуҗа», дигән фразаны тәрҗемәчем бөтенләй тәрҗемә итәргә теләмәде. Хатын-кыз образын дегет чиләге белән чагыштыруны килештермәде. Как можно сравнивать образы наших женщин, воспетые в поэмах Пушкина, Байрона, Шиллера с ведром с дегтем?—дип карышты.

—Бу бит гади бер деталь генә. Хикәядә образы бик мул тасвирланган.

Николайны бәхәсләшеп җинәрмен димә. Ул шунда ук классикадан мисаллар китерергә кереште. Бу очракта бәлкем ул хаклыдыр да. Ләкин автор мин бит. Әсәрләремне, алардагы образларны, персонажларны мин тудырам, иҗат итәм. Укучыларым алдында да җавабын үзем бирермен.

Кайбер көннәрне тәрҗемә өстендә бүлгәләнми генә эшләү өчен Николайларга куна киләм. Мин ишектә күренү белән аның хатыны, һәрчак мөлаем Валентина Викторовна:

—Бүген бездә янадан Ледовое побоище на Чудском озере була икән,—дип куя. Кызы, җиде яшьлек Рита белән биш яшьлек улы Игорьне ала да, Мәскәүнең икенче башында ук яшәгән әнисенә куна китә. Смотрите у меня! Савыт-сабаны кырмагыз!—дип кисәтә дә әле.

Уены-чыны шунда инде. Кайчакларны артык кызып китсәк тә савыт-сабага ук тигән юк анысы. Ялгышлык белән өстәлдән чәй чәшкеләрен төшереп ватканны исәпкә алмаганда.

Бәхәсләшеп тәмам арыгач, төнге өчләрдә, иңбашыннан зур йөк төшергәндәй җиңеләеп, без кухня якка чыгабыз. Бәхәсләшкәндә карын тиз ача бит ул. Әвен сугып кайтучылардан болаерак ачыгып, Валентина Викторовнаның суыткычта калдырган кәбестә шулпасын җылытып ашыйбыз.

Безгә бер бүлмәдә куну мөмкин түгел. Аның атмосферасы тискәре электр зарядлары белән шул хәтле тулган ки, ялгыш кына ширпы сызсаң да ут чыгу куркынычы бар. «Әгәр шушы китапны исән-сау тәвәккәлләп чыгара алсак, иске кирза итек төсле кәкрәеп каткан шушы Смоленск урысына бүтән әйләнеп тә бакмас идем. Соңыннан тагын берәр җыентык чыгарырга ниятләсәм дә, Мәскәү хәтле Мәскәүдә тәрҗемәчеләр бетмәс әле, дип әйткән чакларым күп булгандыр. Үҗәт бит. Киренең дә иң тискәресе. Ә Николай исә иртән, берни булмагандай, минем аркадан кага.

Минем номерда кунган чакларны Николай: «Русский—барин! Татарин—кучер!»—ди дә, минем урынга менеп ята. Бер кешелек номерда мендәр дә бер генә. Мин баш астына йодрыгымны салып, идәндә кунам. Кунагымны караваттан куып төшерә алмыйм бит инде. Бу әйтемнең дә чын әйтелеше: «Татарин—барин, русский—кучер» бит. Аптыраш бу тәрҗемәчем белән.

Шулай чын хакыйкатьне эзли-эзли без аның белән бик матур китап чыгардык. Сөенечем эчемә сыярлык кына булмады. Егерме биш табак! Йөз илле мең тираж белән. Тиражы йөз меңнән арткач, өчләтә гонорар түләнә! Минем кебек кутырлы борын татар малаеның хыялына сыешлы шатлыкмы, диген?! Америка булып Америкада иң танылган классиклар китапларын күп булса ун мең тираж белән генә чыгаралар. «Нинди иркен минем туган илем!» дип бер дә юкка гына җырламаганбыз икән. СССР иде бит Туган илебез. Халкыбыз ике йөз алтмыш миллионнан артып киткәние түгелме соң? Бу хәтле халыкка, укучыларга китапларны миллионнарча данә белән чыгарсаң да, күп түгел. Нинди зур держава күз алдыбызда таркалды, җимерелде дә куйды.

Кузнецкий мост тукталышында аена бер тапкыр «Яңа китаплар» күргәзмәсе була икән. Софья Ивановна безне шунда җибәрде. «Радость» дип исемләнгән җыентыгыбызның тышы да бик матур. Кул куеп, автографлар язып та өлгерә алмадык, өч йөзләп китабыбызны күз ачып өлгергәнче алып бетерделәр. Безнең «Радость»ка карата «Литературное обозрение» журналында да бик җылы рецензия булды. Анда авторның кемлеге, тәрҗемәченең дә талантлы булуы турында бик матур әйтелгән юллар бар иде.

«Бу кире беткән Смоленск урысына бүтән әйләнеп тә карамас идем», дигән сүзләр өйгә кайту белән онытыла. Аралашу чорында булган тик яхшы, күңелле мизгелләр генә искә төшә. Озак юанмыйм. Бер җаена төшкәч, яңа әсәрләремнән бер җыентык туплыйм да, Уфа-Мәскәү поездына утырам. Мәскәүнең Казан вокзалында мине бик горур кыяфәттә, авызын ерып, колачын җәеп, Жуков әфәндем каршы ала.

—Старик, бу юлы озакладың,—дигән була әле.—Бик кызыклы тәкъдимнәр булып алды. Мин син килгәнне көттем.

Мәскәү егетем өстемдәге җиләнемне мактый. Үзенә бик килешеп тора дигән була. Теләсәме?! Йомшак теле белән ул сине әсир дә итә ала, шайтан! Ю-ук! Хөрмәтле тәрҗемәчем белән алай талашып кына тормыйбыз. Кайчакларны ул һич көтмәгәндә генә: «Ты настоящий талант!» дип куя. Мин дә шунда ук: «От такого слышу!» дияргә ашыгам. Мин дә бит бәйдәге бурзай кебек һаман «һау да һау!» дип кенә тормам инде.

Без бит бөек Чыңгызханның оныклары! Үзебез турында беркайда да, беркайчан да начар тәэсир калдырырга ярамый.

Тәрҗемәчеләремнең уңганлыгы, тырышлыгы һәм талантлы булуы аркасында бүген минем китапларым Калининградтан алып Магаданга чаклы чиксез зур географик киңлектәге китапханәләрнең барысында да бар. Язучы өчен тагын ни җитмәгән! Лотореяга очраклы рәвештә «Мерседес» отуың бер читтә торсын!

Менә шушылардан соң «киребеткән Смоленск урысы» Николай дустымны бишеккә салып тирбәтсәм дә, кулыма алып, үчти-үчти итсәм дә бер дә артык, бер дә күп булмас. Дөресендә^шовинист дустымны мин ихлас күңелдән ихтирам итәм, ирләр арасында гына була торган үзенә бер кырыс ярату белән яратам. Беләсезме, тора-бара аның аурасына мохтаҗлык сизә башладым. Күрешмичәрәк торсак сагынам үзен.

Минем чит илләргә йөргәнем юк. Әмма замандашларымнан калышмас өчен, хөрмәтле Сенкевичның «Вокруг света» тапшыруларын берсен-бер калдырмыйча карап барырга тырышам. Мәшәкатьсез-нисез, диванга кырын ятып. Төсле телевизордан, кыздырган көнбагыш яра-яра...

«Кругозор» дигән хикмәттә Николай дустымнан, бәлкем, күпкә калыша булырмын. Аның каравы ул чалгы тапый белми, әй! Ничек инде чалгы тапый белмәскә мөмкин? Мужик башың белән! Үзе мин авылда үстем дип күкрәк суга. Ә янавычны бөтенләй тота белми. Бер җәйне безгә нәкъ печән өстендә кайтканые ул. Барам, барам, дигәч, өмәгә алып бардым. Авылда үскән егетем печән дә чаба белми. Уттай итеп янап биргән чалгы белән үләнне пәч тә пәч кыйный гына. Мин покоска салган печәннәрне кабартып, җиләк ашап йөрде инде шунда. Күбрәк ике каен күләгәсендә утырды. Салкын әйрән шупырды. Ике каен күләгәсендә яткан килеш тә үзенекен сөйли.

—Старина, Синең, конечно, Большой театрда булганың юк инде?—ди.

—Тысячу раз! дим.—Соңгысында синең белән «Руслан и Людмила»да булдык. Берсендә «Князь Игорь»не карадык. Ул чакта син безгә билетларны дусларың аша правительственный рәтләргә тапканыең. Бездән сулдарак ирле-хатынлы, чем-кара Тогомы, әллә Ганамы илчесе утырды. Римский Корсаков татар өммәтеннән булмады микән? Андагы кыпчак биюләре, музыкасы чын

үзебезчә һәм искитмәле матур.

—Мин бөтенләй башка нәрсә турында әйтмәкче идем,—диде Мәскәү кунагы.—Хәтерендәме, увертюраны башкарыр алдыннан оркестр базындагы скрипкачылар скрипкаларын ничек озак көйлиләр. Залда үзенә бер тантаналы тынлык урнаша. Тамашачыларның күзе әлеге оркестр базында. Менә беренче скрипкада уйнаучы маэстро. Аның исеме дә, уйнау осталыгы да күпләргә таныш. Аның кулындагы скрипкасы да илле-алтмыш мең доллар гына булыр. Бөек маэстро Страдивариның үзе ясаган инструментыдыр әле. Шулай булмыйча соң! Большой театр оркестры бит!

—Йә шуннан?—дип бүлдердем кунагымны.

—Хөрмәтле авторым, мин синең шул хәтле житдилек, осталык, виртуозлык белән һәм ижади онытылып чалгы янавыңны, Большой театрның симфоник оркестрындагы танылган маэстроларның скрипкаларын көйләүләренә охшатам... Ике очракта да алар бер төрлерәк чынлыйлар төсле. Ты хоть кумекаешь, о каких высших ценностях я гутарю?

—Алла-а-а! Әйтеп тә куясың инде бер тора торгач. Как уж тут не кумекать. Ферштею, конечно!

—Шулай да әйт әле, чалгыңны чынлатканда син нәрсә турында уйлыйсың?

—Берни турында да уйламыйм. Миңа чалгымны ут итәргә кирәк. Чәчкә капсын. Ут булмаса, үләнне аударып булмый.

—Бу турыда минем скрипкачы маэстролардан да сораганым бар. Алар да, берни турында да уйламыйбыз, диләр. Дөнья классикасына кергән әсәрләрне башкарырга җыенабыз бит, монда мыскал да фальш булмаска тиеш, диләр. Согласись, вот настоящая философия нашего бытия!

Кунагымның, ике каен күләгәсендәге фәлсәфи ачышларын тагын да кинәйтергә исәбе бар. Ләкин ике каен төбе минем Мәскәүдәге «ВДНХ» кунакханәсендәге номерым да, Николай дустымның Шаболовкадагы фатиры да түгел. Карагай тавы артыннан, бик усал кыяфәттә, кәләпүш хәтле генә болыт калыкты. Килеп чиләкләп коя башласа, бөтен тырышканны юкка чыгарачак. Кипкән печәннең бер өлешен әнә теге баштан «КамАЗ»га төйи дә башладылар. Аның да кулына сәнәк тоттырдым.

Гаҗәп тә бер кеше ул минем тәржемәчем. Кайчакларны мине һич көтмәгән уңайсыз хәлләргә дә куя. Берчакны шулай «Дневник красавицы Гюльчиры» дигән повесть өстендә килешеп кенә эшләп утырганда, каләмен шып читкә куеп:

—Добрый из добрых, почтенный из почтеннейших, благородный из благороднейших, талантливый из талантливейших мой автор, мине бер бик чибәр татар кызы белән таныштыр әле. Үтенеп сорыйм, димәссеңме! Мин аптырашта, хәтта тотлыгып калдым. —Кайсы гына әсәреңне алсак та, «Безнең татар кызлары тегеләй, безнең татар кызлары болай, аларга тиң гүзәлләр жир йөзендә юк!—дип язасың. Боларны тәржемә кыла-кыла минем кулларым талды. Шушы сүзләреңнең дөреслеген чынбарлыкта расла. Таныштыр мине берәр нечкә билле, кара кашлы Әлфия, Сания, Нәфисә белән. Вәт булырсың чын дус! Юкса ты уже сколько лет соловья кормишь лишь баснями.

—Ни сөйлисең син, картлач! Хатының, ике балаң бар.

—Булса соң! Алар белән мин ниндидер усал ният белән танышырга җыенмыйм. Дус булып, аралашып йөрү өчен. Сезнең культурага, матур гореф-гадәтләрегезгә якынаю, өйрәнү максатыннан. Валентина Викторовнаның ике бала белән башы каткан. Иртән тора да Игорьны балалар бакчасына, Ританы махсус инглиз мәктәбенә илтә. Аннары эшкә йөгерә. Ә без ул чибәркәй белән әдәбият әһелләренең Александр Фадеев исемендәге Үзәк Йортына истәлекле очрашуларга, кичәләргә, тусовкаларга, призентацияләргә генә йөрербез.

Сул күзен бераз кыса төшеп:

—Кем белә-ә-ә...—дип суздьі ул.—Сезнен дин буенча хәтта дүрт хатын алырга да мөмкин икән бит. Мин моны бик хуплыйм. Нинди катлаулы проблеманың нинди гадел чишелеше! Иң борынгы заманнардан бирле гел сугышлар чыгып торган, ирләр кырылган. Җәмгыятьтә парсыз, яклаучысыз күпме хатын-кыз заты! Алар нишләргә тиеш? Аларның да итәк тотырып балалар үстерәсе киләдер. Ә яшьли тол калган хатыннарның җирләрен кем сөрер, малларын кем көтәр? Су үтә башласа, искергән түбәләрен кем ябар? Кешелек җәмгыятенең гаять катлаулы проблемасы сезнең динегездә бик гадел һәм акыл белән хәл кылынган. Кулыңнан килсә, асрый алсаң, дүрт хатын ал. Ятимнәрне бәхетле ит, парсызларга пар бул. Ә хатыннар дүртесенә бер ир белән торсалар да, барысы да ипиле-ашлы. Җирләре сөрелгән, ашлыклары сугылган, үзләре ир канаты астында. Җиде төн уртасында, исереп килеп, аларның тәрәзәсен берәү дә чиртми. «Аня, открой! Это я, Гришка!», дип кирза итеге белән аның ишегенә берәү дә типми.

—Уйлама да! Мәскәү буйлап сиңа татар кызлары эзләп йөрисем генә калган икән. Булмаганны!—дип бүлдердем үзен.—Чык та үзең таныш, бик теләсәң. Ун миллионлап халык яшәгән Мәскәүдә—һәр унынчысы татар. Теләсә кайсы кибетенә кер дә кассирына барып сүз кат. Касса артында утырган ханыммы, туташмы, һичшиксез татар кызы булачак. Әнә, Патрис Лумумба исемендәге (хәзер ул «Дружба народов» дип атала бугай) университетка барып чык. Безнең Казан кызлары анда да бик күбәү укыйлар. Араларында бер күрүдә зиһенеңне чажлатып эретерлек чибәрләр бар.

—Үзең булышмыйсың инде алайса... Шулай дип нәтиҗә ясыйк.

—Ике аягымның берсен дә атламыйм. Ләкин бер талпыну белән дә хәл ителә торган мәсьәләдән трагедия ясамыйк әле, мсье Николь.

Тирән ихтирам итү һәм бик рәхмәтле булу йөзеннән бүген мин синең статусыңны, ягъни дәрәҗәңне тулы бер башка күтәрәм. Заманында безнең татарлар арасында бик популяр булган «Тылмач» дигән сүз ошыймы сиңа? Моннан соң мин сиңа да бөек Тылмач дип эндәшә башларга ниятлим.

—Тылмач? О-о, матур сүз бу.

Алай гынамы?! Тирән мәгънәле һәм акыл, зиһен үткерлегенә ишарәле торган сүз. Безнең халкыбызны, вокзалда йөк ташучылар, базарда ит чабучылар итеп кенә түгел, ә беренче чиратта бик зирәк акыллы дипломатлар, илчеләр итеп бәяли торган сүз—«Тылмач». Между прочим, әле Урта гасыр башларыннан ук безнең татар тылмачлары Русь дәүләтен ныгытуга бәяләп бетерә алмаслык өлеш керткәннәр. Кирәксә, мисаллар да китерә алам... Казан татарларыннан Агиш Грязной 1668 нче елда Русь патшасының Төркиядә һәм Кырымда илчесе булган. Аның туганы Агиш Федор патша йомышлары белән Англиягә һәм Голландиягә йөргән. Әле 1510 нчы елны ук чукынып, Русь патшасына хезмәткә ялланган Григорий Иванович Адашевның уллары Александр һәм Даниил Адашевлар Мәскәүнең танылган хәрбиләре һәм дипломатлары булганнар. Дипломат-тылмач, дворянин Алтышев патша Петр I не Персиягә походы вакытында озата барган. Аннары Персиядә һәм Кырымда илче булып торган. Өч туган Барсук, Руслан, Арыслан Әминевләр бөек князь Семен Гордыйның (әле 1349 нчы еллардан башлап, Алтын Урда да) илчеләре булганнар.

Бәлкем шушы кадәресе дә җитәр? Теләсәң, дустым, мин сиңа тагын йөз фамилия китерәм. Сүзне тагын да зурга сузмыйча, шуны гына әйтәсем килә: без татарлар сезгә үзебез «өлкән брат» түгелме икән, дим. Мондый сүзләрдән соң тылмач дустымның җилгә арты белән баскан күркәнекедәй йоннары кабара.

Ну, кеше буларак ул барыбер әйбәт егет. Менә шуны каршы алырга баруым әле. Бер кайтуында, Мәскәүдән бик зур язучы килә дигәч, КПССның

шәһәр комитетыннан мина көне буена «Волга» бирделәр. Кунагыма бик иркенләп районыбызны, авылларны, ындыр табакларын, чишмә буйларын, мәчет-зиратларыбызны, яшәү, көн-күрешләребезне күрсәтеп йөрдем. Татар катыгының, сөзмәнең, авыл каймагының, әйрәннең нәрсә икәнен күрсәттем. Әйткәнемчә, Николай бит ул рафинадланган интеллигент. Ә андыйларны үзегез беләсез, һәрнәрсәдә гаеп табарга, бер дә урынсызга зарланырга гына торалар. Беркөнне мин аны өч мәчетле, ике таш клублы, өч катлы мәктәпле, өч китапханәле, өч мен йортлы Тау асты Бәркәтәгә алып бардым. Моннан нәкъ бер атналар гына элек бездә бик көчле яңгырлар явып узган иде. Нәкъ авылга кергәндә генә Коры инеш аша күперне ташу алып киткән. Күпердән бераз гына читтәрәк, трактор салган юл аша үтмәк булдык. Гел асфальт юлдан гына йөрергә күнеккән горком шоферының әллә тәҗрибәсе, әллә кыюлыгы җитмәде, машина арт көпчәкләре белән сазга утырды. Кара «Волга» фыр да фыр килә, ни алга, ни артка бара алмый. Югыйсә алай озак та утырмадык. Шул тирәдә уйнап йөргән малайлар тиз этеп чыгардылар. Әмма мсье Николаебыз, гадәтенчә дәшми калмады.

—Күрәсеңме, урта гасыр бит монда! Шушы күперне дә рәтләп куймаганнар. Салгач, салгач аны капитальный итеп салырга иде. Екатерина IIнче салдырган күперләрдән үрнәк алырга кирәк. Аның күперләре бүген дә исән. Сезнең халык беспечныйрак,—дип колак төбендә шыңшый башлады.

Мәскәүдә булсак, мин аңа җавапны астына сиярлек итеп бирер идем дә, монда ярамый. Кунагым бит. Әмма мин дә гел авызыма су кабып тормам әле. Җае гына чыксын, әче кикерүен китерми калмам.

«Кызлар күрсәм, кызамын, уң кулымны сузамын» дип укучым күңеленә башта ук коткы салып куюым хак. Әлегә исә Николай кунагымны каршы алырга Ак Күл станцасына ашыгам. Карабаш чатына җитәрәк, юл уртасында туктап калган бер иномаркага юлыктым. Әллә бензины беткәнме? Иномарканың ике ягына икесен бер кашык су белән кабып йотардай ике чибәр кыз чыгып басканнар да, яулык болгап туктавымны сорыйлар. Бик ашыксам да ничек инде туктамаска? Кызлар күрсәм...

Машинамны сүндерми генә яннарына килдем.

—Нәрсә булды?—дип тә сорый алмадым. Чөнки абау да чибәрләр! Сүз катырга телең тотлыгырлык. Хан кызларың бер читтә торсын. Кашлары яңа гына явып үткән яңгырдан соң калыккан салават күпере. Үзләреннән бер тын алу белән һушыңны җуйдырырлык, затлы француз хушбуе исе килә. Боларның гүзәллегеннән әсир калуымны җиңеп, аларга сүз ката алмый торганда кызларның берсе, минем яктагысы, саф татарчалап:

—Чибәр абзыкаем, Хак Тәгалә сезне безгә үзе юлыктырды. Зинһар ташлап китә күрмәгез,—диде.—Әллә инде безнең тирәдәге бар халыкны мур кырган. Кайчаннан бирле көтәбез, яныбыздан хет ник бер велосипедчы узсын. Ярады, Ходай сезне бирде,—дип кызларның икенчесе дә безнең янга килеп басты. Монысы үзенә килешле кыска җиңле ак кофта кигән, шәмәхә вельвет джинсадан.

—Җәмилә! Су буенда, басма өстендә керләр чайкый сай җирдә,—дип кулын сузды.—Ә менә бу принцесса минем апам—Камилә.

Мин үземне Нияз дип таныштырдым.

Өр-яңа япун машинасы бу. Иң югары класслысы. Нилектән генә сүнде икән соң? Сәбәбен белер өчен чит илдән килгән белгеч булырга кирәк.

Инде капотын ачкач, бөтен җире электроникага корылган бу затлы машинаның әле бер, әле икенче чыбыкларын тарткалап карыйм. И-их, шайтан алгыры, шушы минутта мин беренче класслы автомеханик булсам соң! Кулым тию белән бу чибәркәйләрнең машинасын дерт итеп кабызып җибәрсәм. Бу фириштәләр алдында минем дәрәҗә ничек үскән булырые.

—Юк шул, чибәркәйләрем, машинагызның нидән сүнүен ачыклый алмадым. Гаеп итә күрмәгез инде, зинһар,—дидем. Булдыксызлыгымны яшерүдән ни файда?

—Нияз абый! Кадерлебез, мәрхәмәтле кеше иканегез йөзегезгә чыккан. Син безне жиде юл чатында ташлап китә күрмә инде. Әлмәткә хәтле генә булса да буксирга ала күр, дип, икесе бер авыздан ялвардылар. Мондый фирештәләр сораганда, карышып буламы соң? Минем «Ноль четверкам» бу гигант машина янында малай гына. Алай да кырмыска кебек көчле ул. Тигез юлдан «КамАЗ»ынны да үргә өстерәр. Ни дисән дә туксан ат көче бар бит анарда.

Ул арада кызлар багажникларыннан матур итеп үргән сары капрон аркан алдылар. Кич кырын бу ике бичара туташны жиде юл чатында ташлап китү шулай ук егетлек түгел. Тактым боларны. Аллага тапшырып, әлбәттә. Ипле генә итеп, газга да чама белән генә басып, кузгалып киттек. Әлмәт ерак жир түгел, әнә сөзәк үрне генә менеп төшәсе. Хәзер кайтып житәрбез. Тизлекне егерме-утыздан арттырмый, жайга гына барабыз. Юлның байтак өлеше тимер-юл белән рәттән, параллель чаба. Бераздан безне бер пассажир поезды куып житте. Шул үзе, мин каршыларга тиешле Мәскәү-Уфа поезды. Кунагым нәкъ менә шушы поездда килә инде. Әнә, сигезенче вагон тәрәзәсеннән бер ак баш карап бара. Николай түгелме икән? Безнең як табигате белән хозурланып кайта булса кирәк. «Тайота» тагып чыккан «Жигулине» күрсә дә, мине күрми инде ул.

Әлмәтнең бу башында ук, олы юлдан йөз метрлар гына читтә, тәүлек буена эшли торган СТО (Станция технического обслуживания) бар икән. Өсләренә зәңгәр төстәге бик чиста комбинезоннар кигән, атлет гәүдәле ике егет, «Тайота"ны ремонтка бик теләп алдылар. Алмаска! Мондый «тачканы» сафка бастырудан аларга да табыш мулдан керәчәк.

Камилә шунда мина борылып:—Нияз абый, машина монда калгач, өебезгә ничек кайтабыз инде? Шушы биек үкчәле «лодочкаларыбыз» да, жимерек-ватык асфальттан, бөтен Әлмәтне икегә ярып, аксап-туксапмы? Эшләребез бөтенләйгә кәкәйләнеп китте бит әле.

Каршыма Жәмилә килеп басты. Кара карлыгач канатыдай сызылып киткән кашларыннан аның йөзендә аерым бер горур гүзәллек. Теләгән кешесен үзенә буйсындыру көче өстиләр төсле.

—Кызлар-р! Үтерәсез сез мине-е-е! Пычаксыз суясыз бит,—дип ыңгырашудан гайре нишлим? Боларны монда ташлап та китеп булмый бит. Илтергә кирәк. Әй-й, нәрсә ул хәтле өзгәләнәм соң? Николай килеп төшсә, авызына имезлек капкан нарасый түгел әле. Килеп житмәсәм, көтәр бераз. Юлда ни булмас? Минем машинам ватылырга, йә юлда мине ГАИ хезмәткәрләре тоткарларга мөмкин. Станциядә чак кына көтсә дә бүсере төшмәс.

Жәмилә әйтмешли, аяз көнне башыма төшкән бу баләләрне илтә киттем шул. Әлмәтнең аеруча бай түрәләре, ягъни нефть корольләре, шаһлары, генераллары яши торган аулак бистәсендәге, Яна барокко стиле белән, Төркиядән махсус китерткән кызыл кирпечтән салынган, ике катлы особняк каршында туктадык.

—Ярар, чибәркәйләрем, сау булдык! Шушы кыска гына вакыт эчендә сезнең белән аралашуым, соңгы вакытларда минем тормышымда булган иң кадерле хатирәләрнең берсе булып исемдә калачак. Сау булдык, матуркайларым!—дип машинамны кирегә бора башладым. Шул чак:—Гражданин Нияз абый, именем закона вы арестованы!—дип болар мине икесе ике яктан эләктереп алдылар.—Сау булыгыз, имеш! Нинди сүз ул? Берәр чәшке искитмәле хуш-исле Шри Ланка чәеме, Бразилия кофесымы эчмичә,

сезгә свободу век не видать, это Вам я говорю!—дип Җәмилә җинемнән эләктерде. Бу кызый энә күзеннән дә берниндитоткарлыксыз узар, валлаһи! Һай, үткен күренә.

Ике кулымнан тотып ишегалдына, өйгә үк өстерәделәр. Капканы ачып керүгә:

—Апаларым нинди арестантны тотканнар? Минем дә ярдәмем кирәкмиме?—дип каршыбызга тана тикле сенбернар килеп җитте. Камиләнен:—»Пиночет»! Үз урыныңа!—әмеренә буйсынып, дәшми-тынмый гына үз оясы янына барып ятты.

Мәр-мәр шома баскычлардан, туп-туры икенче катка күтәрелдек. Зиннәтле, әмма бик нечкә зәвык белән бизәлгән, иркен залга кердек.

—Бә-а-а! Яши белүчеләр дә бар икән ошбу дөньяда! Кая эләктем мин? Һиндстан шаһы йә төрек солтанының сарае түгелме бу? Ялгышып килеп кермәдекме?

Бер араны шулай исемне җыя алмый торган арада, кызлар өстәл яптылар. Төрек чинарыннанмы, әллә Буковина наратыннанмы ясалган, көзгедәй шома әлеге өстәлгә алар затлыдан затлы бик күп ризык-нигъмәтләр чыгарып тезделәр.

—Нияз абый, син бүген безнең иң якын кешебез. Энә өстендә утыргандай боргаланмагыз. Нәкъ үз өегездәгечә булыгыз,—дип елмая Камилә.—Борчылмагыз, билгеле бер шартларда гына, билгеле бер вакыткача гына безнең тарафтан арестованный сез. Ә шәрабнең ниндиен тотасыз? Беренче класслы виски бар, шотландиянең үзеннән кайткан. Әллә француз коньягымы? Безнең әти боз кисәге салып, виски тотарга ярата. Әлбәттә, вак-вак кына кофе йоткалап.

Кызлар үзләренә грузин виносы «Кабернэ» куйдылар. Ә мин, хуҗаның үзе төслерәк, кашык очына гына боз кисәге эләктереп, бер рюмка вискидан авыз иттем. Шә-әп нәрсә, каһәр! Боз кисәге белән. Бу нигезнең хуҗасы да төпле кеше булырга тиеш. Дөньяда яшәүнең тәмен белә.

Камилә шоколад кисәге сындырып капты. Йөзенә чак кына елмаю билгесе йөгерде:

—Көн артыннан көн уздырып, менә шушы әтиебез әйтмешли, Таш өндә әкрен генә картаеп ятмыш инде без.

Камилә каршы як стенада, матур рам эчендә, ап-ак чәчле, тулы йөзле бер ир һәм сөйкемле генә бер ханым төшкән фотоларга ымлады.

—Тагын берәр атнадан кайтып та җитәрләр инде. Әтине сорап дүрт-биш җирдән факслар килде.

—Сездә, кызлар, алайса аулак өй икән бит,—дидем.

—Менә шул аулак өйдән тәмам туеп, гараждан машина алып, кичке яктарак тугай-болыннарны айкап кайтыйк дип чыккан идек инде без.

Бу чибәркәйләр искитмәле кунакчыл җаннар булып чыктылар. Әйтерсең, без бер-беребезне күптән беләбез. Бүлмәдә тартынусыз-нисез, күңелле атмосфера урнашты. Аларның эчкерсез кунакчыллыгы аркасында инде. Бәллүр рюмка да шундый зәхмәт бит ул. Берәрне тотып куйгач, монарчы чыраен сыткандай тоелган дөнья да, иң мажор төсмерләр ала. Әллә каян гына сөйләр сүзләре дә табыла. Кайгы-хәсрәтләрең дә шундук тарала. Мин дә Николай дустымны каршы аласымны бөтенләй онытгым.

ГАИ егетләре мине космик кораб белән дә куып җитәчәк түгелләр. Үзебез дә бит алай ике-өч рюмкадан гына тәмам мәлҗерәп төшүчеләрдән түгел идек. Монарчы...

—И-и, кызлар! Сезнең белән очраштырган өчен язмышка ихлас рәхмәтлемен. Сездә зур кунак булдым,—дип урынымнан күтәрелдем.—Миңа кузгалырга вакыт. Күптән, күптән...

—Нинди сүз сөйлисез! Бу хәлдә без сине бер кая җибәрмибез. Нәрсә, күрәләтә торып авариягә юлыгасыгыз киләме? Безнен аркадамы? Якты дөньядан, матур тормыштан туйдыгызмы? Адым да атлатмыйбыз! Төрле вак-төяк комплекслардан без инде күптән арынган шәхесләр, кадерле Нияз абый. Тартынып-нитеп тормагыз. Әнә диван. Урынны тотабыз да өчебезгә бергә җаям. Сыярбыз. Җәеп җибәргәч, футбол кыры кадәр була ул,— диде Камилә, аяк өсте баскан килеш кенә кофе йота-йота.

Иртүк уянып мыштым гына чыгып ычкынырга җыенган идем, кая ул. Кызлар да минем арттан ук торып бастылар. Шундук чәй дә өлгерттеләр. Китәр алдыннан Камиләнен җитди сүзе дә бар иде.

—Әйткәнием бит инде, безнең Җәмилә дә Парнас колы. Әниемнең бер туган сенлесе Зөһрә апанын кызы ул. Берничә калын дәфтәр шигырьләре, үткер эпиграммалары бар. Русча яза. Берәүгә дә күрсәтми. Берәр журналга да салып карамый. Бер белмәгән чиновниклар кулына тапшырып, көлкегә калганчы, берәр күренекле язучы белән танышып, шигырьләремне аңа күрсәтеп карыйсым килә, ди. Ул кунагыгыз белән дә таныштырсагыз, без сезгә Урал тавы кадәр рәхмәтле булыр идек. Бу мөмкинме?

—Баш өсте, чибәркәйләрем! Менә адресым, менә өй телефоным. Иртәгә үк килеп тә чыга аласыз.

Машинанны кабыз да выждырт үзебезнең Актүбәгә! Кайткач ни буласы, ниләр күрәсем күз алдымда. Хәтта вак-төяк детальләре белән. Җингәгез мине капка төбендә каршылаячак. Уклау тотып. Холкын яхшы беләм мин анын, йолдызымнын.

—Моргларга, милицияләргә, селәгәенне агызып караган барча күрше-тирә тол хатыннарга да шалтыратып чыктым, карт чучка, кайда йөрден?—дип каршы алды ул мине бу юлы да. Мондый чакны ситуацияне үз кулына алырга кирәк. Юкса беттем диген.

—Ә Мәскәү кунагым, Николай? Килеп җиттеме сон?

—Кире китә алмаган шул. Сине көткән көткән дә, такси яллаган. Синең белән_бер-бер хәл булгандыр дип, бик борчылып килеп керде. «Бер дә борчылма, Николай Александрович, пычагым да булмагандыр. Юлда берәр кыска итәккә юлыккандыр»,—дип тынычландырдым. Шулай түгел диген, ялганчы! Бик күнелле каршы алдың инде олы кунагыңны. Анын урынында үзем булсаммы!?

—Беләм, беләм, сандугачым, кара кашым, карлыгачым,—дидем.—Кире киткән булырыен.

—Ике дә уйлап тормасыем.

—И-и, әнисе, матуркаем, бик зурга җибәрмик сәнә,—дидем дә атылып өйгә кердем. Керсәм, Николаем алдына тастымал салып, кашык белән каерып-каерып, сөзмә ашап утыра. Анын бераз гына үпкәсен сиздереп, профессорларча карашына:

—Мсье Николай, дорогой, үтәдем заказынны. Берәр чибәр генә татар кызы белән таныштыр дигәниен. Хәтта шигырь яза торганын таптым. Шунын артыннан йөрдем,—дидем.

Кочаклашып күрештек, әлбәттә. Бер-беребезне ихтирам итүебез, бераз күрешми торсак, сагыныша башлавыбыз хак бит. Ике чынаяк чәй эчтекме икән, телефон шылтырады. Трубкада Камилә туташ тавышы.

—Мәскәү кунагыгыз исән-сау килеп җиткәнме? Кәефләре ничек? Үзләре бик тыйнак, җитмәсә бик оялчан ике татар кызы белән танышырга исәбе юкмы олуг кунагыгызның? Әйтик, менә, үз ягыбыздан безнен теләгебез ихлас бик зурдан. Шушы минутта ук рәхим итегез. Ишек-капкабыз сезнен өчен төбенәчә ачык.

—Камилә туташ, кызкаем, болай зурлап чакыруыгыздан баш тартырлык,

аны кире кагарлык потенциаль көч юк бездә, Бүген үк өлгермәсәк, иртәгә килеп чыгарбыз. Җәмиләкәй дә алай дулкынланмасын, борчылмасын. Өйрәнчек шигырьләрен бергәләп укып карарбыз. Кирәксә, киңәшләр дә әйтербез. Иң яхшыларын бәлкем «Юность» журналына сайлап алырбыз. Зур әдәбиятка керәү дә тып итеп кенә килеп басмый. Парнасны йөгәнләп, аның сыртына ияр салганчы күп шагыйрьләргә бик вак күзәнәкле иләк аша узарга туры килә. Көтегез. Килеп чыгарбыз. Минә кунагым Николай Александрович та бик дәртләнеп, барабыз, барабыз, чакырган җиргә нигә бармаска дип тора.

Ә Николайның танырлык түгел. Ике кулын югары күтәргән. «Берәр татар кызы белән таныштыр», дип мин сиңа уйнап кына әйткәнием бит, ә син шуна чынлап ышандыңмы? Кит инде? Что ты наделал? Татар кызларыннан түгел, мин үзебезнең рус кызларыннан да, шайтан бисмилладан өреккән төсле, котым алынып качам.

—Ләкин сыкрарга соң шул инде. Мин, җанымны кырыкка ярып, аңа бер дигән кызлар таптым. Ә ул задний хут бирмәкче. Не выйдет, дускаем. Барабыз. Галстугыңның иң матурын так. Мыек очларыңны да тигезлә. Кызларның берсе, Җәмилә исемле чибәре, шигырьләр дә, поэмалар да яза. Әйдә, барып тыңлап карыйк. Яңа Анна Ахматова ачарбыз. Белла Ахмадуллинага татарлар арасында алмаш үсми, дисәң, ник ялгышасың. Бар алар бездә, бар. Табарга гына кирәк, акылың, исемеңне җигеп, күтәреп җибәрәсе генә бар,—дип үгетлим кунагымны. Безгә дә кирәк чакта кыю була белергә бик вакыт, дип тылмачыма акыл бирәм.—Ә кызлары! Кызлары! Күрсәң үзләрен, шунда ук һушың китәр. Просто во!—дип баш бармагымны күрсәтәм.

Николай йөзенә тирән бер сер чыгарып, башын кашып алды. Көзге алдына басып, чәчен төзәтте. Чемоданыннан ак күлмәк чыгарды.

—Әдәбиятыбыз өчен яңа Анна Ахматовалар, Белла Ахмадуллиналарны ачарга булганда, мин амбразурага капланырга да әзер,—дип әкрен генә җыена башлады...

**Редакциядән:**

***Бу айда язучы Альберт Хәсәновның 70 яшьлек юбилее. Каләмдәшебезне ихластан тәбрик итәбез, аңа сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.***



Зиннур
Хөснияр

# ДИСБЕ ҖЕБЕ ӨЗЕЛГӘЧТЕН...

## Тимерче әтиемә

Балта остасы син менә дигән,
Коеп куйган маһир тимерче...
Безнең капка ябылып тормады:
—Зыя, атны дагалап бирче!

Тимерче һәм балта осталары—
Безнең нәсел гомер гомердән.
Дөнья каты,
Бу малай да каты булсын диптер,
«Чүкегәнсең» мине тимердән...

Дагалале, әти, Дөньяны да,
Аяк асты бигрәк бозлавык.
Тая-тая, күрәшеп яту әле—
Кошларда бар ирек, бездә юк...

Бу Мәскәүне дагалале, әти,
Кайчакларда таеп киткәли.
Авызлыгын кигертте дә, хәзер
Алга бар син диеп типкәли..

Йә булмаса, малаеңа тапшыр—
Чүкеч, сандалларың бир әле.
Аяк асты яман тайгак һаман,
Миңа да бер чыгар кирәге...

Зиннур ХӨСНИЯР (1961)—*прозаик; «Таң ата да кич була», «Тәгәри китте язмышлар», «Терсәк сугышы» (роман) һ. б. китаплар авторы. Шигырьләре журналыбызда беренче тапкыр басыла. Казанда яши.*

## Тормыш җыры

Онытылмый күрешүләр
Былбыл кунган бакчада.
Өч кенә көн узган кебек,
Күпме сулар акса да.

Уалмасын, ватылмасын,
Язмыш бәллүр пыяла.
Без пар бөркет кыяда
Бу өч көнлек дөньяда.

Без пар бөркет кебек идек
Тормыш дигән кыяда.
Үпкәләшеп нәрсә оттык
Бу өч көнлек дөньяда?!

Ялгышулар, саташулар,
Сабактыр ич сиңа да:
Аерылышып ни җимердек
Бу өч көнлек дөньяда?!

Ачы сүзләр, кайнар яшьләр,
Ә ярату—хыялда.
Саклыйк әле мәхәббәтне
Бу өч көнлек дөньяда...

## Сизәрсең әле

Елмаясың, көләсең син.
Нигә сөям димисең?
Мәхәббәтең юлга чыккан,
Ник каршына килмисең?

Таң сызылгач, тәрәз ачып,
Күк йөзләренә кара.
Килер бер көн, сизәр әле,
Үпкәләп булмый ярга.

Җанымдагы ут-ялкынны
Сизмисең икән, сизмә!
Көлалганда көл инде син,
Моңая гына күрмә.

Йөрәккәен ялкын алгач,
Үзе дә белер әле.
Сердәшенә бик яшерен
Сүз итеп сөйләр әле.

Басмалардан чыккан чакта
Күләгәң суга иелә.
Әнә килә—көлә-көлә,
Чын сөю үзе килә!..

## Көзге аерылышу

Очар кошлар бездән китеп бара,
Әллә җитте инде көзләр?
Аерылганда нигә шулай моңлы
Карый икән синең күзләр?

Моңсу да шул, бигрәк ямансу да
Бу җәйләрдән китеп барыш...
Аерылышулар-кавышулар,
Шушыдыр ла безнең язмыш...

Мәхәббәткә озын гомер телик,
Гаепләмик әле көзне.
Очар кошлар канат сынагандай
Язмыш үзе сыный безне.

Моңсу да шул, бигрәк ямансу да
Бу җәйләрдән китеп барыш.
Аерылулар-кавышулар,
Шушыдыр ла безнең язмыш...

Язлар безне кабат якынайтыр
Артта калыр моңсу көзләр
Синең күзләр, кавышуны көтеп,
Очар кошлар юлын эзләр...

Моңсу да шул, бигрәк ямансу да
Бу җәйләрдән китеп барыш.
Очар кошлар кайткан ямьле чакка,
Якты язга илтер язмыш!...

* * *

*Тәүфикъ Әйдигә*

Ямансылыйм, җирсием,
Җирне ятып иснием.
Үз илләрем булмагачтын
Ят җирләрдә нишлием?!

Илгә нигә татар кирәк,
Орышка барасы юк.
Үз милләтен яклый торган
Дәүләтле каласы юк.

Чит җирләргә чәчелгәннең
Монда да рәхәте юк!..
Саклар иде, яклар иде—
Ханы бар, тәхете юк!...

Балалары таралган да,
Җирнең мае таланган.
И каргана әти-әни:
Малай марҗа апкайткан,
Ә кыз үзбәккә барган.

Әдип Әйди ничек түзсен,
Сыкранмасын ник җаны!
Чыгып киткән сәфәргә ул
Эзләргә дип боларны.

Тәүфикъләгең әйдәгәндер
Тынгысыз җан—рухыңны.
Сине көтеп торган ласа
Идегәйләр токымы!..

Дисбе җебе өзелгәчтен
Хөрмәләре таралды.
Берәмтекләп барлап чыктың
Үксез кавем татарны.

Очып-очынып яшәдең
Ышанып табасыңа.
Канат куйдың читтә йөргән
Һәр татар баласына.

Үзеңне дә язмыш куды
Кавемеңне эзләтеп...
(Денсез ясаган хатаны
Әйди йөрде төзәтеп.)

Күңел күзең яшьләнгәндер,
Дымлангандыр күзлегең.
Йөрдең, күрдең, эзләп белдең
Милләттәшләр күплеген.

Хәзер күңел сине эзли,
Күбәләкләргә карап.
Читтә генә йөрисең күк
Кардәшләреңне барлап...

♣

Әхәт
Сафиуллин

## КӨТЕЛМӘГӘН ОЧРАШУ

И-и ходаем, дөньяда хатын-кыз өчен ялгызлыктан да яман нәрсә юктыр. Вакыты-вакыты белән шул ялгызлык чарасызлыгыннан бүре кебек улардай буласың.

Менә инде ничә еллар буе Гөлназда да шундый халәт. Әйе, ул да ялгызлыкның ни икәнен кешеләрдән ишетеп түгел, аны бөтен барлыгы белән үзе татып яши. Көн-төннәре, атна-ай һәм еллары шушы афәттән нишләргә белмичә үтә. Ә хатын-кызның бу газабын исә беркем дә, хәтта дөньяда иң якын кешесе булган әнисе дә түгел, ә төннәрен кочаклап яткан, үзенең кайнар яшьләре тамган мендәре генә белә—алар үз кайгыларын кешеләрдән яшерә белә, аны бары тик мендәрләренә генә ышанып тапшыра...

Дөрес, дөньяда кешене ялгызлыктан коткара торган нәрсәләр дә бар. Шуның беренчесе—эш. Шөкер, Гөлназ бу яктан бәхетле—яраткан эше бар, абруйлы бер фирмада икътисадчы булып эшли. Моннан берничә ел элек финанс-икътисад институтын тәмамлаган иде, инде мул гына тәҗрибә туплап өлгерде, эшен биш бармагы шикелле белә. Ялгызлыгы да онытылып тора.

Кешеләр арасында күбрәк булу, туган-тумача, дуслар белән аралашу да коткара. Ләкин, мин ялгыз, сезгә шуны оныту өчен килдем, дип кенә кеше-карага еш барып булмый. Дусларга түгел, якын туганнар катына да килешми ешлау. Аннары тагын бер нәрсә. Берәрсенә бардымы, аларда бала-чага булмый калмый. Ә бала-чаганы күрде исә, Гөлназ үзенә урын таба алмый—ялгызлыгы, киресенчә, кырык мәртәбә арткан шикелле була. Андый йөкне ничек күтәрмәк, аңа ничек түзмәк кирәк, Ходаем?! Ә хуҗалар, анын йөрәк ярасына тозны тагын да күбрәк сибәргә теләгәндәй, балалары белән әвәрә киләләр: йә шигырь сөйләттереп, йә ни булса да сораган булып, анын нинди тапкыр җавап бирүе белән мактаныргa тотыналар. Ә син, эчендә мәчеләр сугышса да, елмайган булып, шуларның менә шулай бала-чагалы гаиләдә яшәүләренә, шунын белән бәхетле булуларына эченнән көнләшеп утыр... Андый чакларда тизрәк чыгып китәсе, бала-чагалы бу өйне тизрәк онытасы, хәтта... ялгыз каласы килә. Әйе, әйе, мондый вакытларда хәтта ялгыз калуы хәерлерәк тә шикелле.

Яңа елда ничәмә-ничә көннәр буе ял итүне кайсы юләре уйлап чыгаргандыр. Башка бер җирдә дә юктыр мондый нәрсә. Ял итә-итә хәтта көннәр чуты югала башлый, тәмам ялкауланып бетәсең. Менә хәзер дә инде сәгать тугызынчы ярты булып килә, ә ул әле һаман тормаган.

Гөлназ, сөякләре шытырдап куйганчы, рәхәтләнеп киерелеп алды. Хәтта, нииндидер ләззәт кичереп, моңарчы түшәмдәге бер ноктага текәлгән күзләрен йомып, юрганын иягенә кадәр күтәрде, Әле генә күңелен биләп, җанын сызлатып торган тынгысыз уйларыннан арынып, ничектер тынычланып калгандай булды. Ләкин күзенә барыбер йокы кермәде. Бу халәтендә озак

ята алмады, юрган итәген ачып атты да, үзенең төз, матур аякларына карап бакты. Әйе, йөзе, бөтен килеш-килбәте генә түгел, ә аяклары да узып киткән ир-ат борылып-борылып карарлык. Ләкин менә мондый килешле, коеп куйган кебек төз, озын, матур аяклардан ни файда? Кем кызыгыр, кем сокланыр, куллары белән сак кына кем кагылыр, кем сыйпар өчен алар? Юк бит, юк янында аларны сыйпап ятучы ир-ат кулы! Урын-җире һаман буш һәм салкын бит аның... Дөрес, үтеп-сүтеп киткәндә дә, эшләрендә дә аның йөзенә дә, аякларына да сокланучы ир затлары күп, әлбәттә. Ләкин алар узып баручылар гына бит, аларның берсе дә аныкы түгел...

Гөлназ, уйларының кабат элеккеге эзенә төшүенә ачуы килеп, әйтерсең мона аның матур аяклары гаепле, ниндидер ачу белән юрган итәген янадан ябып куйды.

Шунда кинәт чылтыраган телефон тавышы аны сөендереп җибәрде. Ул, тиз генә торып халатын иненә салды да, телефон янына килде.

—Сәлам, сәлам, Зөлфия! Юк, тормаган идем әле...—диде ул трубкага.—Кая? «Химиклар» сарае янына? Менә хәзер, көпә-көндезме?! Син нәрсә, чыршы ул кичен, утлар яндыргач кына матур була ич. Шулай дисеңме? Ярар, алайса, көтәм.

Бергә эшли торган хатын чылтырата иде. Ярый әле, менә шушындый дусы бар. Ул аның ялгызлыктан ничек газаплануын аңлый, шуңа күрә төрле-төрле сәбәп тапкан булып, аны өеннән, ялгызлык тырнагыннан аерып алып чыгарга тырыша. Театрларга да, концертларга да гел бергә йөриләр. Хәтта ул быел аны икеме-өчме мәртәбә музейга да алып барды. Менә хәзер Яңа ел чыршысын карап кайтырга чакыруы да тикмәгә түгел бит аның. Үзенә генә ничек авыр икәнен яхшы аңлый Зөлфия. Чөнки үзе дә ялгызлыкны күп еллар татыган хатын. Бәхете бар икән, былтыр кияүгә чыкты да ничә еллар буе җанын ашаган ялгызлыгыннан котылды. Ире—тфү, тфү, күз тимәсен!—бик яхшы, бик тыныч, аны ярата, хөрмәт итә торган кеше. Бәхет дигәнең кызык нәрсә икән ул: бер караганда, Зөлфиянең әллә ниткән чибәрлеге дә юк, ә үзе нинди ирне эләктерде!

Гөлназ чәй эчеп утырганда Зөлфия дә килеп җитте.

—Әйдә, әйдә, үзең генә сөрсеп ятма, апакаем!—диде ул, пәлтәсен элгечкә элә-элә.—Кешеләр карап, үзебезне күрсәтеп кайтыйк әле бер! Бәйрәм көннәре ләбаса!

—Дөрес сукалыйсың, өйдә яту күңелле нәрсә түгел. Шушы көннәрдә ике китап укып чыктым инде! Гел-гел укып утырасы да килми, телевизор да туйдыра. Тизрәк бетсен генә бу Яңа ел каникулы!

Бетәр, бетәр, ана бер дә эчең пошмасын! Дөньяда бетми торган нәрсә юк ул, апакаем,—дип, Зөлфия бүлмәгә күз йөгертеп чыкты.—Әй, озак та йоклыйсың инде, Гөлназ!

—Нинди йокы?! Ятасың инде шунда, тиле кеше сыман әллә ниләр уйлап...

—Ә син әллә ниләр уйлама, апакаем! Гел матурларын гына уйла! Ярар, җыен, әйдә, җыен! Җиткән сиңа өйдә ятырга! Бер чокыр гына чәй ясa да...

Алар «Химиклар» сарае янына килеп җиткәндә сәгать унбер чамасы иде бугай. Мондагы чыршы, һәр елдагыча, быел да бик тә матур итеп бизәлгән. Хәтта анда көндезен үзенә бертөрле аерым матурлык бар сыман. Мондагы халык, мондагы халык! Олылар да күп, ә бала-чаганы әйткән дә юк! Алар күңелен ачу өчен ниләр генә ясап бетермәгәннәр дә, нинди генә аттракционнар эшләми! Бөтен парк—бәйрәм мәйданын хәтерләтә.

Зөлфия белән Гөлназ, сөйләшә-сөйләшә, ашыкмыйча гына паркның төрле уеннар бара торган һәр почмагын да йөреп чыктылар. Кайберләре янында озак-озак туктап тордылар. Күңелле! Хәтта гел эчне тырнап торган кара мәче тавышлары да, күңелне гел борчулы халәттә тоткан күңелсез

уйлар да онытылгандай булды.

Инде янадан күккә ашкан мәһабәт чыршы янына таба атлаганда Зөлфия белән көлешә-көлешә ни турындадыр сөйләшеп килгән Гөлназ, кинәт кенә: «Сәлам, Гөлназ!» дигән тавышка, барган җиреннән сөрлеккәндәй, шып туктап калды. Нинди таныш тавыш әле бу?! Әйе, бик таныш иде аңа бу тавыш. Инде ничәмә-ничә еллар үтүгә карамастан, аны менә шулай барган җиреннән туктата алырдай тавыш иде ул...

Гөлназ башта нигәдер бар гәүдәсе белән калтыранып куйды, аннары, бөтен ихтыяр көчен җыеп, башын тавыш килгән якка борды. Караса, алардан өч-дүрт адым читтә элеккеге классташы Алмаз басып тора! Ике ягындагы ике малайның кулларыннан тоткан, үзе елмая, карашы серле дә, сынаулы да бугай.

Гөлназ, аны күреп, башта каушап калды, аннары каушавы үзе дә аңлый алмаган ниндидер башка халәткә күчте. Хәер, нишләп аңлый алмаган булсын? Аны, гадәттә, коелып төшү, диләр кебек. Төсе дә үзгәрде бугай, янында берни аңламыйча басып торган Зөлфия моны шундук сизеп алды, хәтта курка да төште, ахры, әкрен генә:

—Син нәрсә?!—дип, аны айнытырга теләгәндәй җиңеннән тартып куйды.

Тик бернинди җавап та ишетмәде—Гөлназ ир-атка карап катып калган иде. Менә, ниһаять, ул исенә килде бугай, гаепле кеше сыман әкрен генә:

— Исәнме, Алмаз!—диде. Аннары, бөтенләй аңышып җиткәндәй, тагын, инде бу юлы күтәренкерәк тавыш белән:

—Исәнме, Алмаз, исәнме!—дип кабатлады.—Нәрсә, Яңа ел чыршысын карарга килдекме?

— Менә малайларны алып килдем!—диде Алмаз һәм, елмаеп, аларның башта берсенә, аннары икенчесенә карап алды.—Әле быел монысын күрсәткәнем юк иде. Бик күңелле икән монда!

Сүзсез калдылар. Икесе дә, аны ничек дәвам итәргә белмичә аптырап, шактый вакыт бер-берсенә карап басып тора бирделәр.

Гөлназ үзен аерата уңайсыз сизде. Моның сәбәбе бар иде... Кайчандыр ул бу классташын (алар 9-10 нчы классларда бергә укыдылар, Алмазлар гаиләсе Үзбәкстаннан күрше авылга күченеп кайтты) бик каты рәнҗеткән иде. Дөрес, ул вакытта яшь кыз моны рәнҗетү дип уйламады да бугай, шул чакта егет күңелен ничек яралавын еллар узгач кына аңлады Гөлназ. Ә ул чакта чегән шикелле кара тутлы, тимерчыбык кебек каты чәчләре бер якка да ятырга теләмәгән, гел төрле тарафка тырпаеп торган, буе да кечкенә булган Алмаз аңа үзенең сөюен белдерә-белдерә аптыратып бетергән иде. Хәер, әллә ни «аптыратып бетергән иде» дип тә әйтерлек түгел инде—кош теледәй өч хат язды ул аңа. Ә матурлыгы, юк, чын мәгънәсендә гүзәллеге белән егетләрне генә түгел, иптәш кызларын да сокландырган Гөлназ аның ул хатларын, аның сөюен ниндидер дәрәҗәдә үзен мыскыл иткән дорфалык дип кабул итте, бары тик өченче хатына гына җавап бирде. Анда да бары бер генә җөмлә белән: «Син, бер мәртәбә генә булса да, көзгегә карап ал әле, салпы колак!» Әйе, моннан берничә ел элек нәкъ шулай дип язган иде ул менә хәзер яннарында басып торган шушы Алмазга. Аның кушаматы да «Салпы колак» иде ул чакта...

Аның хаты бик нәтиҗәле булды: шуннан соң Алмаз аңа ник бер сүз катып карасын, ник бер хат кисәге язсын! Ул кызга, чыннан да, бар күңеле белән гашыйк иде, шулай да башка беркайчан да аңа үз хисләрен кабат белдермәде, түзде. Дөрес, ул бөтенләй үз эченә йомылып калды, ә икенче елда параллель класска ук күчте...

Дөрес, инде еллар үткәч, Гөлназ Алмазга карата нинди каты күңелле, артык дорфа, мәрхәмәтсез булуын аңлады, шул сүзләре өчен аның алдында

үзен гаепле санап, бер генә җөмләдән торган шул хаты өчен оялып йөрде. Ярый әле, шуннан соң бер вакытта да очрашмадылар... Тик менә хәзер генә...

Хәер, ул аның турында барын да белеп торды: егет урта мәктәптән соң КАИ ны тәмамлаган, кайсыдыр заводта инженер булып эшли, өйләнгән, берме, икеме малае бар... Моннан ел-ел ярым чамасы бугай, автокатастрофага эләгеп, хатыны үлүе турында да ишетте. Хәтта вакыты-вакыты белән ни өчендер аның үзен эзләп килеренә дә өметләнеп-өметләнеп куйгалады. Бу өмет дигәне үзенең гаилә тормышы барып чыкмаганнан соң иреннән аерылып, суык урын-җирендә мендәре белән икесе генә калгач тагын да көчәя төште.

Әйе, Гөлназның гаилә тормышы кыек-мыек булып чыкты. Элек, башта институтны тәмамларга кирәк, дип яшәде—бик яхшы гына егетләр өйләнергә теләгән иде ана—аннары, ни гаҗәп, ир-егетләр әллә аның чибәрлегеннән куркып, аны буй җитмәс фәрештә дип санады, кайбер кыюларын үзе ошатмады, аларны үзенең гүзәллегенә туры килми дип санады. Хәтта әнисе дә: «Артык сайланмыйсыңмы икән син, кызым?» дип борчылды. Аннары андый кыюлар бөтенләй күренмәс булды. Менә шунда—ә гомер бара, инде ана егерме сигез тулып килә иде!—хатынын аерган бер ир-ат тәкъдимен кабул итәргә мәҗбүр булды. Тик бу ир-ат кисәге тормыш алып бара торган кеше түгел, ә хатын-кыз өстендә яши торган зат булып чыкты. Бу кешедән шулкадәр күнеле кайтты, аннан бала табасы килмичә, хәтта йөклелеген өзле. Шуннан соң табиблар аның бүтән беркайчан да баласы булмаячагын әйттеләр... Дөрес, чибәрлегенә сокланучылар хәзер дә бар, ләкин алар арасында бергә-бергә, инне-ингә куеп тормыш алып барырга дип тәкъдим ясаучылар юк. Инде өченче дистәне ваклагач, булырына өмет тә калмады дияргә була... Менә ни өчен ул, үзеннән-үзе яшереп булса да, кайчакларда менә шушы Алмазны исенә төшергәли иде. «Авырдыр ана үзенә генә ике баланы тәрбияләве...» дип куйгалый үзалдына. Ул моны кемгәдер атап, нәрсәгәдер өмет итеп, бу сүзләренә, бу очракта ана мин ярдәм итә алыр идем, дигән мәгънә төреп әйтә иде бугай... Кемнәндер: «Әйе, авырдыр шул, аңа синең ярдәмең кирәк» дигән сүзләрне ишетергә тели шикелле иде ул. Ниндидер яшертен өмет бар иде аларда...

Ләкин көннәр үтә торды, аны искә алучы да, ана Алмаз тарафыннан ниндидер тәкъдим дә булмады, бу турыда сүз дә ишетелмәде. Ә менә хәзер шул Алмаз аның алдында басып тора: елмаюы да шул ук («Кара, нинди чибәр ир-атка әйләнгән!»), шомырттай кара күзләре дә, нәкъ шул чактагы шикелле, ничек яндырып карый («Карале, күз карашы нинди ягымлы!»). Тик буй-сыны гына ул чактагы кебек түгел—колагыннан тартып үстергәннәр диярсең!—уртачадан да узып киткән ул хәзер («Кара, ничек үсте икән ул бу кадәрле?!»). Хәтта Гөлназга менә хәзер аның колаклары да сөйкемле булып тоелды.

Бер-берсен сынаулы күзәтү, әллә бу очрашуның көтмәгәндә килеп чыгуы аркасында югалып калу идеме бу, шактый озакка сузылды. Бу халдән аларның икесенә дә, хәтта көтмәгәндә генә очрашкан бу икәүгә гаҗәпләнеп карап торган Зөлфиягә дә, уңайсыз иде.

— Йә, эшләр ничек, Алмаз? Ничек яшисең?—диде беренче булып телгә килгән Гөлназ.

— Эшләр бара... Ә яшәү ... минем яшәү хәзер менә шушы «егет»ләр белән бәйле инде...—Алмаз иелеп малайларының башта берсен, аннары икенчесен кочаклап, аркаларыннан кагып алды. Без әнисез...

— Ишеттем...—дип бүлдерде аны Гөлназ.—Авырдыр?

—Җинел түгел инде, әлбәттә... Тик барыбер бирешергә исәп юк. Өч «егет» бит без!..—Алмаз кап-кара мыегы астыннан елмаеп куйды. Аның мыегы

барлыгын хәзер генә күргән Гөлназ, күнеленнән аның аңа килешеп торуын абайлап алды.—Бирешмибез, Алла боерса!—Ул сәгатенә карап алды.—Ярый, Гөлназ, без әнә теге тауга таба атлыйк әле, «егетләр»емне бераз тауда шудырасым килә... Ярата алар моны...

—Ярый, хуш, Алмаз!—диде Гөлназ, сиздермичә генә аңа ачулы караш ташлап.—Шуасылары килә икән, шусыннар, әлбәттә!

—Ярый, хушыгыз!—Алмаз акрын гына китеп барды. Ләкин ике-өч адым атлауга ук кырт борылды да:—Карале, Гөлназ, минем колакларым һаман салынкы булып калды бит... —диде.

—Ярар инде, Алмаз, гафу ит син мине... Синең колакларың да ... гомумән, менә дигән егет син, Алмаз! Кичер, яшьлектәге яшьлектә калсын!..

—Ярар ла, калса—калсын! Болай гына мин...—дип елмайды Алмаз һәм, ике малаен җитәкләп, ясалма тауга таба китеп барды.

Гөлназ кымшанырга да курыккандай, алар артыннан шактый вакыт карап торды. Ике күзе дә яшьле иде. Ләкин ул аларны сөртергә ашыкмады.

—Ни булды, нигә терәлеп каттың, апакаем!—дип җилтерәтте аны Зөлфия.—Карале бала-чага сыман көпә-көндез балавыз сыгуың! Кем иде бу, апакаем?

—Әйтермен әле. Ә бүген миннән берни дә сорама! Ярыймы? Зөлфия, аның белән килешкән сыман, иңнәрен сикертеп куйды.

---

*Алхәбәр. «Казан утлары»—2008.*

Рәис Сафин

## АТЛАНДЫМ АТНЫҢ БИЛЕНӘ

### ЧИК САКЧЫСЫ ЯЗМАЛАРЫ

...Без бераз ял итеп алырга тукталдык. Әйләнә-тирәбездә бер генә шәүлә-карачкы да күренми, бер генә җан иясенең дә барлыгы сизелми. Тирә-як буп-буш, аны дөм карангылык чолгап алган. Жилкәләребезне җилгә куеп, Аллаһының бер үзенә тапшырып, янә китеп бардык. Безнең исәп буенча, күлнең яр буйлары кыя-гауларга килеп тоташырга тиеш иде. Ул шулай булып чыкты да. Кая барганыбызны белмичә йөри торгач, ниндидер ташларга килеп абындык. Без инде коры җирдә басып тора идек. Безнең өчен бу зур шатлык булды. Алдыбызда кар белән капланмаган кара-кучкыл кыя басып тора иде. Кыялар куышсыз-ярыксыз булмый ул. Бөтен өметебез шундыйрак бер урын табып, бу аяусыз җил-бураннардан яшеренеп төн уздыру, ял итеп алу иде. Биштәрләребезне таш өстенә куеп, шундый оя-куыш эзләргә керештек. Һәр биш-ун минут саен әйберләребезне калдырган урында очрашырга дип сүз куештык. Олег сул якка, мин абына-сөртенә уң якка китеп бардым. Аякларым белән карны капшап ерак та үтмәдем, аягым ниндидер куышка кереп китте. Чүгәләп, теге чокырны актарырга тотындым. Актарган саен эчкәрәк үтә бардым. Эчкә үткән саен куышның авызыннан кергән карлардан ераклаштым һәм ташдиварга килеп төртелдем. Кесәмнән шырпы алып, оямны яктыртып җибәрдем. Әйе, бу нәкъ без хыялланган куыш иде! Ул дүрт-биш метр озынлыкта булып, уң як почмагындагы кул сыярлык ярыктан җылы, дымлы һава өрә. Конуска охшаган түшәме биеклеккә, карангылыкка кереп югала. Кыскасы, Аллаһының рәхмәте белән юлыккан менә дигән кыя ярыгы иде бу!

*Татарстаннан читтә яшәүче каләмдәшләребез*

## УДМУРТИЯ

*Бу сәхифәдә без Ижауда чыга торган «Яңарыш» газетасы каршында оешкан Риза Шәфи исемендәге әдәби берләшмә әгъзаларының иҗаты белән таныштырабыз.*



# Ринат Батталов

### Көтү

Әүвәл көттем: әткәй кайтып керер,
Бөтен икмәк булыр кулында.
Әнкәй бүлеп бирер унбер телем,
Онытмас ул ятим улын да...

Һәм яшәдем—көтеп: урамнарда
Гүзәл йортлар, юллар калкыр дип.
Күз яшьләре, салкын бураннар да—
Бар да узар, артта калыр дип.

Мин гел көттем: төшәр әле беркөн
Иңнәремнән михнәт капчыгым.
Учларыма алып ризык иттем
Идәндәге икмәк валчыгын...

Көтеп яшим—Ходай биргәненә
Шөкер итеп, әле дә шат булып:
Шигъри юллар булып иңгә шуңа
Килеп куна мәллә ак болыт?!

***

Чылбырын чыңлатып, як-якка
Шыгырдап ачыла җил капка.
Минем дә гамьле уй, онытылып,
Чылбырдай сузыла яшь чакка.

Хәтерем дисбесен яңарта
Тын өйнең күкеле сәгате.
Гашыйклар иленең җәннәте—
Бу кичтә мәхәббәт ләззәте.

Серме бу, әллә дим гөлләрме—
Яшьнәгән яшьлектән бер тотам?
Җырмы бу, әллә соң шәрабмы—
Изгеләр күленнән бер йотым.

Бер җаным аз кебек—тоярга
Җылысын бу тәннең, кочакның!
Йөз кочып, йөз кабат кабатлыйм:
Син җаным! Син моңым! Син татлым!

Чын бәхет, шатлык ул—мәхәббәт,
Сөеклең өчен ул—җан ату...
Гел яшә күңелләр күгендә,
Ләззәтле гүзәл хис—ярату!



Ибраһим
Биектаулы

# МИЗГЕЛЛӘР

## Татар аты

Татар Аты—
сәхраләргә
мәңге гашыйк—
Мәҗнүндер,
җанын
язмыш бугазлагач,
тән сакларга мәҗбүрдер...
Татар Атын
хөррият-болын
ымсындырып та куя,
баш күтәреп кешнәгәндә—
тимер авызлык тыя.
Татар Аты
очар иде
чәчеп тояк утларын—
вата алса бу абзарын,
вата алса утарын!
Нигә заман әче көлә,
ник һаман алдамакта,
ник хөр аваз ишеттерә
бу тоткын Аргамакка?

Татар Аты—тышаулы,—
хуҗасына охшаулы...

***

Йөрәгемне йолкып алам:
Газапларым—бары аннан…
Җиргә утыртам мин аны—
үссен бер дафнә куагы—
Булсын халкы өчен көрәшкә
күтәрелгән Батыр тажы!
Батыр шаны…

***

Мәрмәрдә, бакырда
сакланмам хәтердә…
Шуңамы уфтану?
Шагыйрьнең хәсрәте—
күзләре йомылгач,
җырлаудан тукталу…

***

Исә җилләр…
Җаннар күккә аша
иңрәп-иңрәп…
Ак болытлар булып
акбүзатлар оча—
күкләр иңләп…

***

Катлам-катлам ята килгән-киткән…
Фал китабы—елга ярлары.
Вакыт үрли күкләр кыясына,
Җиргә түшәп арган җаннарны…

***

Аккошлардан күлдә каурый.
Ат аунаган җирдә—төк…
Туган илдән аерылганнар—
тарих өчен авыр йөк…

***

Рухым
күптән күккә ашар иде,
кызганмаса
мескен җәсәден…
Җиде күкләр
күкрәп яшьнәгәндә
орыла-бәрелә
Җирдә яшәдем…

---



# Гөлфия Исхакова

## Кабат язлар килә

Ашыкмыйча, кабат язлар килә,
Үз кыйммәтен белгән кыз сыман.
Иртән чыкмый кояш ялындыра,
Җирнең өстен каплый ак томан.

Карлар гына түзми, ап-ак карлар
Кара көя юллар чатында...
Күгәрченнәр оча гөр-гөр килеп,
Тагын җырлап сөю хакында.

Табигатьнең серле, сихри көче
Тамчылардан бозлар үптерә.
Иңнәреннән мамык шәлен салган
Ак каеннар бөре бүрттерә.

Язгы көннәр яшәү яме бирә,
Тылсым тулы кояш нуры да...
Бу халәттән, хистән илһамланып,
Шигырь туа сөю турында.

Иртәгесен әле, иртәгесен
Сайрар кошлар бизәр таңнарны.
Сандугачлар җырын сузган мәлдә
Парлы итәр ялгыз җаннарны.

Язлар белән назлар килә бергә:
Бар җиһанны күмә иркәлек,
Күкрәк тутырып алган һавадан да
Сафлык, сөю тора бөркелеп.

## Фалчы чәчәк

Яланаяк атлыйм борма юлдан,
Җор яшьлегем бара озатып.
Юл чатыннан ак чәчкәләр өзәм,
Кояш көлә миңа күз атып.

Җилдәй җитез, гөлдәй гүзәл чаклар,
Үткән гомеркәйнең бер мәле...
Ромашкалар кебек сафмы хисләр?—
Күрәзәчем, агым, әйт әле?

Моңнар ярган, серләр сарган юлда,
Чуклар гына калган өзелеп.
Табышмактай,—«соя-сөйми»,— дигән
Кичерешләр калган тезелеп...

Фалчы чәчәк туй күлмәге төсле
Бәхет нуры сибә йөземә...
Сөюемне, ярсу еллар аша,
Алып барам көмеш көземә.

---



Зөһрә Вәли

# УРЛАНГАН ТӨН

ХИКӘЯ

Бүген Марсель белән Энженен туй көне. Кунаклар йорт тулы. Кияүнен әтисе заманча итеп салдырган коттеджның аскы катында зур зал. Монда туган-тумача, күрше-күлән урнашкан, яшьләр табыны иркен бакчада, әтисенен «хәтәр» әшнәләре—эшмәкәрләр—хужанын кабинетында кәефләнеп утыра. Боларның яннарында тән сакчылары, кулларында затлы сигара, ара-тирә кесә телефоннары аваз бирә.

Мөһим тостлар инде әйтелгән, бүләкләр тапшырылган, хәзер һәркем үзенчә күнел ача. Зур залда—гармун тавышы, бакчада яшьләрнен үз музыкасы янгырый. Энже—урта буйлы, сылу гәүдәле; елык-елык килеп торган ак күлмәк кигәч, үзе дә энже бөртегенә охшап калган. Кин жилкәле, озын буйлы Марсель белән алар Африка жырчысынын дәртле ритмына буйсынып биләр. Менә егет кызны күтәреп, әйләндерә башлый... Барысы да кул чаба, барысы да шат, көләч. Махсус чакыртылган официант поднос белән эчемлекләр, соклар тәкъдим итеп йөри. Тост әйтер өчен Энженен классташы Женя Демидов сүз ала: «Я любил Энже с 1-го класса,—ди ул, Марсельгә карап.—Только она не обращала на меня внимания. Эта жемчужина досталась тебе, береги её!» Туйда бүтән егетнең хисләрен ачуы сәеррәк тоелса да, елмайдылар, хупладылар. Йөзенең житдилеге белән шаһит кыз Миләүшә генә аерылып тора иде. Ул Энже белән бер шәһәрдән. Кызлар мәктәптә дә, техникумда да бергә укып, дуслашканнар. Монда ул бүген иртән килеп төште. Марсельнен әнисе ана кечкенә, ләкин бик ямьле, зиннәтле әйберләр белән бизәлгән бүлмә бирде—туй өч көн дәвам итәчәк иде, булачак килене дус кызы белән бергә булсын диде. Өйнен зурлыгы, бүлмәләр күплеге, затлы, купшы жиһазлар Миләүшәдә көнчелек хисен дөрләтеп жибәрде. Кияү дә ана күптәннән ошый иде—Энже янына килгәндә күргән иде. Миләүшәнен туйдагы уйчанлыгынын сәбәпләре шул иде. Шулай да, үзенә сүз катсалар, биергә чакырсалар, кыз йөзенә елмаю чыгарды, сөйләште. Тик бу кыяфәт маска гына иде. Вакыт-

вакыт кыз, ул масканы ташлап, начар уйларын куып, чын күңелдән гомум шат халәткә кушылып карый: шаяра,көлә, табан астыннан очкын чыгарып биеп тә ала. Менә хәзер дә ул «Чегән кызы» биюен очып-очынып башкарды, алсуланып, нурланып киткән йөзен кулъяулыгы белән җилләтеп, беседкага кереп утырды. Бераздан аның чыраена тагын гаҗизлек, гасабилану билгеләре чыкты.

...Кунаклар тарала. Яшь парны өске катта бизәлгән бүлмә көтә. Ата-аналар верандага урнашырга тиеш. Кияү белән кәләш лакланган баскычтан өскә менеп бара... Шулчак Миләүшә дус кызының бер генә минутка үз янына килүен сорый. Энҗе туктап кала. Елмаеп торучы Марсельнең колагына: «Мин хәзер киләм. Сөйләштек, утны яндырма. Мин оялам»,—дип пышылдый да, Миләүшә янына төшә. Тегесе аны үз бүлмәсенә тарта. Арыган һәм дулкынланган кәләш бүлмәгә килеп керү белән, иптәш кызы аның битенә хлороформга манчылган чүпрәк каплый. (Ул шешәне мәкерле кыз көндез ванна бүлмәсендә күреп алган иде.) Энҗенең тыпырчынуына карамастан, Миләүшә аңа чүпрәкне йөзеннән йолкып атарга ирек бирми. Йомшарып, авыраеп киткән кызны караватка аудара. Авызын ябышкак тасма белән ябыштыра, кулларын өскә таба сузып, караватбашына капрон бау белән ныгытып бәйли. Үзе тиз генә кулларын юып, ефәк төнге күлмәк киеп, башына-битенә Энҗенең һушбуен, иреннәренә аның иннеген сөртә. Бүлмәне бикләп, өске катка ашыга. «Чәчләребез бертөсле, буй бераз калкурак та инде, ярар... Бүлмәдә караңгы—тынлаган сүзне, әрекмән колак! Тыңламаса да, көндез рубильникның кайда икәнен күрдем... Барысы да мин дигәнчә булыр!»

Марсель «кәләш»нең каршына килә. Куллары шома төнге күлмәккә тигәч, «Син инде өстеңне дә алыштыргансың», дип куя. Берәм-берәм каптырмаларны чишеп, фатасын, бизәнү әйберләрен салдыруны уйлап утырган егет бераз турсая, ләкин кызның чәченнән килгән таныш һушбуй исе аның башын әйләндереп җибәрә... Мәхәббәт кичәсе дәвам итә. Кызмачарак егет берни сизми, чөнки Миләүшә үтә сак кылана, дәшми, киявенең сорауларына «әһе» дип кенә, пышылдап кына җавап бирә.

Егет йокыга талгач, Миләүшә торып китмәкче була. Марсель, уянып, аны тагын үзенә тарта. Иртәнге дүрттә инде бүлмәгә сүрән генә яктылык җәелгән була. Миләүшә, йөзен яшереп, аркасы белән борылса да, егет аның Энҗе түгеллеген абайлап ала. Аптырап, күзләрен угалый: ятакта шаһит кыз бит!

—Нишләп син монда?! Энҗе кайда?!

Миләүшә, мәсхәрәле карап, әйтеп сала:

—Каян белим мин? Кичә Женя Демидов сорагач, чакырып алдым. Беседкага чыктылар. Ә мине Энҗе үз урынына синең янга җибәрде. Әллә сиңа минем белән ошамадымы?

—Булмас, булмас! Энҗе андый түгел!

Марсель, тиз генә киенеп, Энҗесен эзләргә йөгерә. Өске каттагы бүлмәләр буш. Беседкага чыга—беркем дә юк. Әллә урладылар инде Энҗесен? Әгәр Женя турында әйткән сүзләр дөрескә чыкса? Хурлык бит, хурлык! Марсель каравылчы янына йөгерә. Әзмәвердәй егетне уятып, сораулар яудыра: кемнәр чыкты төнлә? Кем килде? Ничәдә китте?

Каравылчы саный: уникенче яртыда официантлар китте. Беренче ун минутта—соңгы кунаклар. Капканы бикләдем, этне ычкындырдым—чебен дә очып чыкмалы түгел.

Марсель янадан өйгә керә. Сумкасын тотып бүлмәсеннән чыгып баручы Миләүшәне этә-этә кире кертеп җибәрә дә, артыннан керә. Күз алдында коточкыч күренеш пәйда була: таушалып беткән ак күлмәкле Энҗе, бәйләп торудан шешенеп беткән куллар, скотч белән ябыштырган иреннәр... Керфек буявы изрәп аккан, йөз танымаслык булып үзгәргән. Тоныкк күзләрендә—

әрнү һәм рәнжеш... Марсель, Энже янына ташланып, кулларын чишә, дерелдәгән бармаклары белән ябышкак тасманы кубара. Берөзлексез «Кем эшләде моны, кем?» дип кабатлый. Зәгыйфь кенә тавыш белән Энжесе «Су»,—дигәч, кухняга йөгерә. Су агызганда домофоннан: «Теге кунак кызы китмәкче, чыгарыйммы?» дип сорый сакчылары. Марсель «Чыгарма!» дип кычкыра, үзе кәләше янына ашыга. Су эчкәч, Энже хәлсез, төссез бер тавыш белән: «Миләүшә», дип әйтә дә тагын күзен йома. Аның башы авырта, косасы килә, кул чуклары үтереп сызлый. Нишләп Марселе аның янына хәзер генә килде? Хлороформ тәэсиреннән айныгач, ул күпме бәргәләнде бит—урын-җир әйберләре идәнгә шуып төште. Богаулардан арынырга теләп күпме тарткалашты, хәтта капрон җепләр беләзекләренә суелып керде... Инде яктырган... Төне буе Энжесен нигә эзләмәде ул? Йокладымы икән? Әллә инде? Коты алынып, кыз садистлар турындагы бер киноны исенә төшерде: баулар, кул богаулары кулланучылар бар икән бит. Нигә Марселе һаман бер сүз дә дәшми?

Ә егет һаман чигәләрен кысып утыра, газаплы уйларының очына чыга алмый. Нәрсә соң бу? Энже туй көлмәгендә... Димәк, ул чыннан да төне буе Миләүшәне назлап чыккан. Акылдан язарлык хәл! Ә бәлки монда, аның сөйгәне янында, каһәр суккан Демидов булгандыр? Юк, юк! Марсельнең күз алдына, тоныкк кына булып, яшьләрнең чыгып китү күренеше килде. Женя инде машинасына утырган, сигнал биреп юлдашларын ашыктыра. Кире кайтса, сакчы да әйтер иде. Энже үзе дә бит ап-ачык итеп, «Миләүшә», диде. Егет, караватт кырыена утырып, Энженең кулларын сыпыра-ышкырга тотынды. Әкренләп нәфис бармаклар үз төсенә керә башлады. Энже үксеп елап җибәрде. Бераздан ул юыну бүлмәсенә кереп китәрлек көч тапты. Марсель янына «Нинди хакың бар мине чыгармаска?» дип җилләнеп Миләүшә килеп керде. «Нишләдең син? Ни өчен?»—дип илереп Марсель аны җилкәсеннән күн канәфигә таба этеп җибәрде.

—Ана гына булмасын әле бөтен нәрсә! Демидов та аны ярата имеш. Укыганда мин берәр егет белән танышсам, аларының күзе гел Энжедә булды. Инде менә хәзер ул сиңа, шундый йортка, кияүгә чыга... Бер генә төнегезне булса да урларга теләдем...

—Бу бит, бу бит... җинаять!.. Хлороформ, скотч, бәйләп кую. Моның өчен, беләсеңме... Мин сине...

Марсельнең телефонга үрелгәнен күреп, явыз кыз шаркылдап көлде:

—Чакыр, чакыр. Шәлперәйгән әрекмән мин, диген. Кәләшемне бүтән кыз белән бутадым, диген. Гаилә тормышыңны хыянәттән башладың бит син! Мине кулга алсалар, әйтермен: кияү кушуы буенча эшләдем, диярмен. Әйт тизрәк карачкына, чыгарсын мине!—дип ишеккә юнәлде ул.

Бу сөйләшүне ишетеп торган Энже, пычрак нәрсәгә орынмаска теләгән сыман, кискен тайпылып, ана юл бирде. Әле генә юынып чыккан, битендә косметиканың әсәре дә булмаган, ап-ак йомшак мунча халаты кигән кыз сафлык фәрештәсен хәтерләтә иде. Марсель, киресенчә, үзен пычранган, гаепле, гөнаһлы итеп тоюдан, бик теләсә дә, Энжегә бер-бер ягымлы сүз әйтергә дә, гафу үтенергә дә, кочып алырга да базмады. Ике кулын, чәчен йолкып алырдай булып, бөдрәләренә батырып тора бирде. Бу киеренке халәттән аңы кичә язылышкан хатыны, егерме яшьлек саф күңелле, гөнаһсыз кыз бала Энже коткарды. Йомшак җилкәсенә кагылып: «Бар, син дә душка кереп чык. Пакьлән,—диде ул.—Бүген туебызның икенче көне. Бер төнебезне урлаганнар икән... (Аның иреннәре дерелдәп китте, күзеннән ике бөртек яшь тәгәрәде.) Алда әле—тулы бер гомер.



# Эльмира Нигъмәтҗан

## Дусларыма

Бөтен дөнья сагыш тулы,
Сары сагыш төсе лә,—
Ник агачлар үз сагышын
Ташлаган җир өстенә?

Җыйыйм дидем бу сагышны,
Сыймады учларыма,
Сыймады куш кулыма да,
Сыймады кочагыма.

Карлар яуды, ап-ак карлар,
Каплады яфракларны.
Сары сагыш өсләренә
Кабат ак бәхет яуды...

...Җанга сары сагыш керде,
Сарды бу хисләремне.
Сагышларым яшьләр булып
Каплады күзләремне.

Янар иде йөрәк дөрләп
Сагышым учагында—
Моң-зарымны уртаклаштым
Иң якын дусларыма.

Алар юатты, таратты
Булган барлык моң-зарым...
Ап-ак бәхеткә тиңлимен
Якын дусларым барын.

## Мин дөньяны җәй дип кабул итәм

Кайберәүләр сыман, күлмәк киеп
Тумасам да мәгәр бу җиргә,
Колач җәеп дәртле июль ае
Каршы алган мине биргә.

Мин яшәүне җәй дип кабул иттем—
Бу дөньяда җәйдә килгәнмен.
Тәүге тапкыр көлүем дә, бәлки,
Кабатлаудыр кояш көлгәнен.

Көзләр юк ул, бу бит бары җәйнең
Бер мәл ямансулап алуы.
Кар, салкыннар—җәйнең, усаллашып,
Җиргә бераз тәртип салуы.

Усаллыкны да мин җәйдән алдым
Һәм җитәрлек алдым назларын.
Кызганмамын җылым, туңганнарның
Эретергә күңел бозларын.

Җәйдә тудым, шуңа күбәләктәй
Канатланып очам еш кына.
Балачакта тугайлардан җыйган
Чәчәк исе сеңгән учыма.

Мин яшәүне җәй дип кабул иттем,
Җәй дип кабул итәм кышын да,—
Язмыш, рәхимле бул, бәхет эзләп,
Күчеп йөрми торган кошыңа…

---



## Гыймран Сафин

***

Авырлыкларны җиңәргә
Куеп бөтен көчен—
Кеше тырыша—бу җирдә
Бәхет табар өчен.

Тик, Фәрештә булган җирдә
Бар икән—Иблис тә…
Бәхет тапкач, аны саклау
Нигә керми искә?

Бары саклый белгәннәрдә
Бәхет кала—китми.
Табар өчен—җитә акыл,
Сакларга тик—җитми?!.

### Нәсел агачы

Кешене—тарих ясыймы,
Әллә тарихны—кеше?!
…Нәсел агачың өйрәнеп,
Бабайлар тавышын ишет!

Шатлык—җирдә шәҗәрәңнең
Агачы мәңге үссә.
Кызганыч: нәслең өзелеп,
Корыса… йә киселсә!

# I БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ГАЛИМНӘРЕ ФОРУМЫ

2007 елның 19-22 сентябь көннәрендә Казан шәһәрендә Татарстан Фәннәр академиясе, Бөтендөнья татар Конгрессы оештырган I Бөтендөнья татар галимнәре җыены булып узды. Аның эшендә дөньяның төрле кыйтгаларыннан килгән 500дән артык татар галиме катнашты. Пленар утырышта, секцияләрдә техник, табигать һәм гуманитар фәннәр үсеше буенча ясалган докларда, чыгышларда, фикер алышулар барышында галимнәр киләчәктә дә Татарстанда, Россиядә һәм дөньяда фән үсешенә үзләреннән өлеш кертү мәсьәләсендә уртак караштa торуларын ачыкладылар. Чыгыш ясаучылар арасында дөньякүләм танылган галимнәр булуы форумның дәрәҗәсен күтәреп, киләчәк очрашуларга өмет уятты. Җөмләдән, галимнәр мәҗлесендә төрле фәнни юнәлешләргә караган чыгышлары белән катнашучылар арасында Алманиянең Макс һәм Планка исемендәге астрофизика институты директоры, Россия Фәннәр академиясе академигы Рәшит Сюняев, Мәскәү океанология институты директоры, академик Роберт Нигъмәтуллин, академик Камил Вәлиев, армия генералы, РФнең хәрби фәннәр Академиясе президенты, академик Мәхмүт Гәрәев һәм башка дөньякүләм танылган галимнәр бар иде. Корылтай эшендә Татарстан Фәннәр Академиясенә күптән түгел сайланган шәрәфле академиклар–Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин белән Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин да катнашты.

Татар галимнәре җыенын Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә. Мазһаров ачканнан соң, җыелышны сәламләү сүзе белән Дәүләт советы рәисе, сәяси фәннәр докторы Фәрит Мөхәммәтшин чыкты. Җөмһүриятебезнең бүгенге иҗтимагый һәм игътисади барышы белән таныштырганнан соң, «Без бүген ил һәм дөнья буйлап сибелгән татар галимнәренең төрле фәннәр үсешенә керткән өлешен әле күз алдына китерү мөмкинлеген алдык», диде ул. Аның, «ниһаять, без аралашу, өлгергән мәсьәләләрне уртага салып сөйләшү җаен таптык һәм киләчәктә бер-беребезне югалтмабыз, чөнки горурланырлык эшләребез бар» дигән сүзләре алкышларга күмелде.

Форумны ачканда Премьер-министрның беренче урынбасары Р. Моратов, Россия һәм Татарстан Фәннәр академиясе академигы К. Вәлиев, Казакъстан Милли Фәннәр академиясе президенты М. Журинов, Румыниянен Төркмәнстандагы илчесе, академик Т. Җәмил, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р. Закировларның чыгышлары булды.

Пленар утырышта Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә. Мазһаров, ТР Президентының сәяси мәсьәләләр буенча Дәүләт киңәшчесе, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Р. Хәкимов, Татарстанның икътисад министры М Сафиуллин, М. Планк исемендәге җәмгыятьнең Астрофизика институты (Алмания) директоры Р. Сюнәев, Россия Фәннәр академиясенең Океанология фәнни-тикшеренү институты директоры Р Нигъмәтуллин, РФ Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институты профессоры А. Әхтәмҗан, Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире, профессор Х Миңнегулов, Россия Хәрби Фәннәр академиясе президенты, армия генералы М. Гәрәев доклад белән чыгыш ясадылар.

Пленар утырышта да, гуманитар бүлек эшендә дә сүз күбрәк татар халкының

язмышы, аны милләт буларак саклап калу, телен, милли үзанын үстерү, гасырлар дәвамында халыкнын менталитетын, яшәү рәвешен чагылдырып килгән әхлак нормаларын киләчәк буыннарга индерү турында барды. Татар халкынын рухи үсешендә, милләт буларак саклануында, галимнәргә дә зур бурыч йөкләнүе турында фикерләр кат-кат әйтелде.

Шик юк ки, татар зыялыларынын очрашып, төрле дәрәжәләрдә аралашып, фикер уртаклашып алулары, һичшиксез, эзсез югалмас! Шулай да Фәннәр академиясе тарафыннан һәр яктан уйланылган, яхшы оештырылган корылтай төп бер үзенчәлеге белән күнелдә төер дә калдырды. Ул Мәскәүдә уздырыла торган форумнардан аралашу чарасы белән әллә ни аерылып тормады. Читтән килгән галим нотыкчылар Россиянен бүтән шәһәрләрендәге форумнардагы шикелле, нигездә русча сөйләделәр. Гуманитар фәннәр бүлегендә татар тарихы, теле, әдәбияты, милли үзан, халыкны инкыйраздан–бетүдән котылу юллары турында лаф оруларнын байтагы рус телендә барды. Яшьләрнен татар телен белмәүләре, өйрәнергә теләмәүләре, милли хисләрнен сүнә баруы, коллык психологиясеннән арына алмаулары турында кызып-кызып сөйләүләр, залда утыручыларнын күбесе анламыйлар дигән сылтау белән (кызганычка каршы, андыйлары да шактый иде) башка ләгатьтә барды. Әйтерсен лә, сүз кайчандыр яшәгән, инде гамәлдән төшеп калган тел турында бара. Казан галимнәрен татар халкы милләт буларак бары тик Татарстанда гына сакланып калырга мөмкин дигән борчулы уйлары табигый иде. Дөрес, Россиядә, БДБ илләрендә яшәүче татар галимнәренә Румыния Фәннәр академиясе академигы Җәмил Тайсин тарихи үткәннәр турында Тукай телендә сөйләп күрсәтте, бөтендөнья татарларынын тарихын язу эшенә керешергә вакыт диг[illegible] эшлекле тәкъдим кертте.

Татар галимнәре җыены эшендә бер төркем язучылар да катнашты. Чаллыдан килгән Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмоваларнын эмоциональ чыгышлары хәтердә калырлык булды.

*Форумда татар әдәбиятынын үткәненә, бүгенгесенә, анын чит илләрдә иҗат ителгән өлешен барлауга багышланган чыгышларны, филология фәннәре докторлары, Казан дәүләт университеты профессорлары, «Казан утлары» журналынын редколлегия әгъзалары Хатыйп Миннегулов белән Тәлгат Галиуллин ясады. Укучыларыбызга шул чыгышларнын язмасын тәкъдим итәбез.*

---

## Гасырлар чатында...

Хәзерге сүз сәнгатебез нинди үзенчәлекләре белән җәлеп итә, башка чорлардан кайсы яклары белән аерылып тора? "Хәзерге татар әдәбияты" төшенчәсе үткән гасырның соңгы унъеллыгында һәм XXI гасыр башында иҗат ителгән әсәрләрне эченә ала дип уйлыйм. Туксанынчы еллар башына хас азатлык рухы, шашкын мәйданнар хисе тудырган әдәбиятның йогынтысы, киләчәккә ышанычы әле күпмедер күләмдә безнең көннәрдә дә саклана. Шул ук вакытта әдәбиятны чорларга бүлүнең шартлы булуын, алар арасында Кытай стенасы тормавын да онытырга ярамый. Бер дәвер сүз сәнгате икенчесеннән шытып чыга, җанлы үсентеләр аша өченчесенә барып тоташа.

Хәзерге татар әдәбияты сәяси вәзгыятьләр үзгәрүне, буыннар алышынуны, тел-сүз бизәкләре яңаруны кичерә-кичерә яшәвен, үсешен дәвам итә. Аның бай һәм данлы, сөенечле вә фаҗигале үткәне булу һәм катлаулы чорыбыз калкыта килгән мәсьәләләре хәзерге язучыларга кул кушырып, битараф тынычлыкта утырырга ирек бирми. Кол Галинең йолдыз кебек балкып, кыя кебек калкып торган "Кыйссаи Йосыф" әсәре, Алтын Урда чоры әдәби ядкарьләре, халыкны уяулыкка чакырып,

сискәндереп, байлыкка, хакимлеккә омтылунын милли фажигага алып килүен искә төшереп торган халык ижаты энжесе—"Идегәй" дастаны—Казан ханлыгы чоры шагыйре, поэма остасы Мөхәммәдьяр нәсихәтләре, халык азатлыгы өчен башын салган Кол Шәрифнен фәлсәфи лирикасы, туры Тукай, көрәшче Гаяз, гыйсъянчы Такташ, самими Туфан, эчкерсез С. Хәким, зыялы Әмирханнар мирасы хәзерге әдәби эзләнүләргә фатиха биреп, дәртләндереп тора.

Хәзерге татар әдәбиятын илгә һәм дөньяга алып чыгу көченә ия өч юнәлеш ачык төсмерләнә. Беренчесе—борынгы һәм урта гасыр әдәби истәлекләренең фәлсәфи-әхлакый эчтәлегенә, сюжет-мотивларына таянып яна әсәр иҗат итү булса, икенчесе—татар кешесенең ташны тишеп чыккан үлән кебек яшәү дәртен, холкын, фигылен, гомумкешелеккә хас сыйфатларын калкытып куйган әсәрләр һәм өченчесе—әһәмияте буенча греклар җиһанга бүләк иткән олимпия уеннары кимәленә якынлашкан Сабан туе, аның әдәби мөхиткә йогынтысы, шигъри сыны.

XIII гасыр башы шагыйре Кол Гали әсәрен оеткы-өлге итеп алган, каһарман шагыйребез М. Җәлил исемен йөрткән театрда куелган балетның, шул исәптән либретто авторы, Татарстанның халык шагыйре Р. Харисның 2006 елда Россиянең дәүләт премиясенә лаек булуы татар халкының талантын тану да иде. "Идегәй" дастаны Р. Харисны шул исемдәге поэма язуга рухландырса, Р. Мингалим, Ю. Сафиуллин кебек драматурглар дастан каһарманнарын интеллектуаль югарылыкта сәхнәгә күтәрделәр. Казан ханлыгы чорының олы шәхесләре хәзерге татар әдәбиятының иң унай каһарманнары дисәк тә зур ялгыш булмастыр. Ә.Рәшитнең "Сөембикә", "Колшәриф", "Мөхәммәдьяр" исемле поэма-трилогиясе, Батулланың "Сөембикә" роман-кыйссасы, Ф. Латыйфиның "Хыянәт", М. Хәбибуллинның "Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный" романнары татар халкының соңгы мөстәкыйль дәүләтенең чәчәк атуын, ни өчен, ни рәвешле юкка чыгуын шактый тулы күз алдына бастыралар. Роберт Әхмәтҗанның "Татар иртәсе" шигыре дә тарихыбызның әрнүле, үкенечле чоры турында:

*Әле татар чукындырылмаган,*
*Җимерелмәгән Казан диварлары,*
*Кол Шәрифне кылыч чапмаган,*
*Сөембикә әле үсмер бала...*
*Кара яла ягып ак дөньяга,*
*Шаһгали дә денен сатмаган.*

Икенче юнәлеш үсешенә Г. Исхакыйның "Сөннәтче бабай" хикәясеннән алып хәзерге әдәбиятыбызга чаклы мисаллар бихисап, мәгәр иң отышлысы—Татарстанның халык язучысы Т. Миңнуллинның элегерәк язылган булса да һаман заманча янгыраган, "Әлдермештән Әлмәндәр" фәлсәфи комедиясе дип фаразлыйм. Халкыбызга хас кешелеклелек, ярдәмчеллек, рух сафлыгы кебек күркәм сыйфатларны үзенә туплаган Әлмәндәр карт караңгылык, үлем шәүләсе—Әҗәл белән көрәшә-көрәшә, үзенең көр күнеллелеге, юморы белән сокландырып ил буйлап сәяхәт итә.

Ир-егетлек, көчлелек, тазалык, житезлек һәм гаделлек символы булган Сабан туе образы, батырлар биленә яткан ак сөлгесен җилфердәтеп бик күп әсәрләр рухына үтеп керә. "Бәйрәмнәр күп... Сабан туйга житә сирәге!"—дип яза шәрәфле академик Р.Фәйзуллин, горурлыгын, мактанычын яшерә алмыйча. "Кипкән инеш..." парчасында халык шагыйре әлеге фикеренә ачыклык кертә.

*Кипкән инеш тә*
*ташу чакларда*
*бер гөрләп ала!*

*Халык рухы да*
*Сабантуйларда*
*бер дөрләп ала!*

Р. Фәйзуллинның "Девиз иде сынатмаска Дөнья сабан туенда!" ("Халәт") юлларын Бөтендөнья татар галимнәре форумына эпиграф итеп алып булыр иде.

Әдәбиятыбызның фәлсәфи, әхлакый нигезендә нинди көч ята, таяныч ноктасын нәрсә тәшкил итә? Борынгы һәм Урта гасыр төрки сүз сәнгатенә яшәү куәсен, кодрәтле, илаһи көчне Ислам тәгълиматы иңдерә. Дин табигать баласын физик үлемнән өстен булырга, курыкмаска, язмыш басымына бирешмәскә, чыдап булмастай авыр мизгелләрдә Аллаһка таянырга өйрәтә. Ходайның бөеклеген, иң олы көч икәнен тану, шигърияттә хакимияткә карата үзенчәлекле оппозиция булган, суфичылык фәлсәфәсенен нигезенә ята.

Совет чорында диннән, Ходайдан ваз кичү, дәһрилек, сыйнфыйлык әдәбиятны ярлыландырса да, аның үсешен туктата алмады. Хәзерге чорыбыз укучыга ирештергән уңышлы әсәрләрнең фәлсәфи, әхлакый нигезендә дин өйрәтмәсенә, фән, сәнгать казанышларына, зиһен, акыл үсешенә таянган миллилек, халкыбызны инкыйраздан, бетүдән, юкка чыгудан саклап калу өчен көрәш рухы ята. Шул олы хис—тәсбих дисбеседәй дөнья буйлап сибелгән татар халкын берләштерүнең үзәк юнәлеше, әдәбиятта төрле буын, стиль, жанр, агым вәкилләренең эзләнүләренә юнәлеш бирүче көч. Искә төшерә һәм саный китсәң, хәзерге татар әдәбиятының мөхтәрәм исемнәргә бай, эчтәлеге буенча күп тармаклы икәнен күрәбез.

Тынгысызлык һәм янага омтылу рухы милләтпәрвар, татар әдәбиятына диңгез сулышын, төрле кыйтгалар язмышын алып кергән М. Юныс ("Шәмдәлләрдә генә утлар яна", "Альбатрос язмышы), техник фәннәр докторы, милли жанлы З. Зәйнуллин ("Агыйделнең аръягында", "Һаваларда ялгыз торна"), һәр әсәрендә яңача ачыла килгән М. Әмирханов ("Тәкъдир", "Тояк эзе"), 1941-45 еллар сугышын мактанмыйча, ялган пафоска бирелмичә, халык фаҗигасе итеп сурәтләгән Х. Камалов ("Безне өйдә көтәләр", "Үлгәннән соң яздым" һ. б.), психологик анализ остасы, шагыйрь, драматург һәм прозаик Ә. Баян ("Урланган ай", "Кызыл ут"), хикәя жанрына яңа рух өргән М. Хуҗин ("Айның уты сүнгән", "Е953;Ерактагы кыялар"), "Таң җиле", "Бәхетсезләр бәхете" романнары белән явызлыкның, миһербансызлыкның ахыр да барыбер җиңеләсен сәнгать чаралары ярдәмендә раслауны үзәккә алган Ф. Садриев, шәфкатьлелеккә өндәгән әсәрләрен детектив жанрга караган роман-повестьлары белән тулыландырган М. Маликова һәм тагын А. Хәлим, Р. Хәмид кебек өлкән буын сүз осталарының аһәңен М. Галиев, К. Кәримов, Ф. Сафин, Д. Салихов кебек прозаикларыбызның, драматургларыбызның үзенчә яңгыраган тавышлары тулыландыра.

Хәзерге татар әдәбияты тормыш күренешләренә, яшәеш ваклыкларына еракланрак, тарих, дөнья барышы күзлегеннән карарга өйрәнә, вәгазьчелекне, катып калган традицияләрне кире кагып, калку метафорага, пластик детальгә, шартлылыкка таяна. Шул җөмләдән, тарихи үткәнебезне дөрес итеп сурәтләү мөмкинлеге ачылуга, «светофорда яшел ут кабынуга» язучыларыбыз Тукайның "Без тарихта эзлебез!" дигән бөек җөмләсенең эчтәлеген, мәгънәсен "ачыклауга", тәфсилләүгә керештеләр.

Татар тарихына Н. Фәттах атаклы "Итил суы ака торур" романы белән башлап җибәргән сәяхәтне М.Хәбибуллин ("Кубрат хан", "Шайтан каласы", "Илчегә үлем юк"), В. Имамов ("Сәет батыр", "Утлы дала", "Казан дастаны"), С. Шәмси ("Идел Болгарстаны", "Низаглы йортта"), Зәйдулла ("Татар тажы") һ. б. халык тарихына сизгер сүз осталары дәвам иттерделәр. Ерак һәм якын үткәнебездә тулпар атларда гәүдәләрен туры тотып утыра алган яугирләребез, асыл затларыбыз күп булган икән. Тарих катламнарына үтә һәм ташка, кәгазьгә уелган истәлекләрне күтәрә белү генә кирәк. Татар һәм дөнья фәне үсешенә зур өлеш керткән галим-голәмәбез язмышы, иҗаты игътибарга лаек. Заманында М. Госманов мәгърифәт тарихыбызның якты йолдызы Х. Фәезханов турында әдәби-документаль әсәр язып чыккан иде. Бу юнәлештә аның М. Гайнуллин, Я. Агишев, Х. Хисмәтуллин кебек әдәбият-тел белгечләре турындагы язмалары фидакарь шәхесләребезгә ихтирам уяталар. Бу юнәлеш әле ачылып кына килә. Киләчәктә Ш. Мәрҗани, И. Гаспралы, К. Насыйри, Г. Исхакый, С. Максуди, Ю. Акчура һ. б. олы шәхесләребез турында күләмле

документаль-әдәби романнар (гыйльми эзләнүләр, шигырь-поэмалар) язылыр дип өметләнәбез. Читтә яшәүче кан-кардәшләребез дә игътибардан читтә калмасын иде! Тәүфыйк Әйди башлаган изге гамәлне журналист Хәмзә Бәдретдинов эләктереп алды, читтә яшәүче асыл затларыбыз турында ике китап бастырып чыгарды, бу юнәлешне язучы Айдар Хәлим дә дәвам иттерә. Һәрхәлдә, аерым өзекләре вакытлы матбугатта күренгән, берничә романнан торган "Хунвейбин" әсәре мөһаҗирләр язмышын сурәтләүнең бер мисалы.

Кешелек дөньясы яшәешендә, аерым затларның үз-үзләрен тотышында борынгыдан килгән һәм аңлашылмый торган сәер, серле күренешләр булуы мәгълүм. Янага сизгер сүз осталары да әнә шундый «коллектив аң заманында» туган мифологик катламга, мистикага, тәңречелек фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итәләр. Әлеге эзләнүләр жимеше буларак Р. Фәйзуллиннның "Нюанслар иле" бәйләме, И. Юзеев поэмалары, Сөләйманның җир белән күк эзотерикасын бәйләп сурәтләргә омтылган лирикасы, Зәйдулланың, Г. Моратның шул юнәлештәге шигъри әсәрләре пәйда булды. Проза белән драматургиядә мондый тәҗрибәләр аеруча Ф. Бәйрәмова ("Болын", "Күл балыгы", "Алыплар илендә"), Г. Гыйльманов ("Албастылар"), Н. Гыйматдинова ("Сихерче", "Кыргый", "Ак торна каргышы"), М. Кәбиров ("Сары йорт сере"), З. Хәким ("Кишер басуы"), М. Гыйләжев ("Бичура") иҗатларында ачык төсмерләнде. Татар әдәбиятының дөнья мәдәниятендә барган үзгәрешләрдән калышмавына, фикерләү дәрәҗәсенең шактый үзенчәлекле булуына дәлил булган модернистик эзләнүләр һәм катлаулы шартлылык халыкның көндәлек мәшәкатьләре, хәзерге хәсрәт-сөенечләре белән яшәгән, реализмга турры сүз сәнгатебезнең магистраль юлы түгел, әлбәттә.

Модернизм алымнары белән мавыгып алган Ф. Бәйрәмова да соңгы елларда үз тарихи яшәү җирендә фаҗигагә юлыккан милләттәшләребез язмышын үзәккә алган "Караболак", Себер ханлыгына багышланган "Күчем хан" романнарында тормышчан һәм реалистик, үтемле сурәтләү чараларына өстенлек бирә.

Татар әдәбияты шигырьдән башлана, дибез. Милли поэзиябез хәзер дә үз югарылыгын бирми, сыйфат ягыннан дөньяның теләсә кайсы шигърияте белән бәйгегә чыга ала.

Вакыт галиҗанәпләре соңгы ике елда М.Әгъләм белән Зөлфәт кебек талантлы шагыйрьләребезне арабыздан суырып алса да, шигъри мәйданыбыз бушап калмады. Алтмышынчы елларда шигъриятькә язгы ташкын кебек шаулап килеп кергән, эчтәлекне, бигрәк тә сурәтләү чараларын янарткан, шәкли эзләнүләрдән дә тартынып тормаган Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Р. Гаташ, Г. Рәхимнәр буыны хәзер дә янадан-яна әсәрләре белән сокландырудан туктамый.

Әлеге буыннан соңрак килгән Х. Әюп, З. Мансуров, И. Гыйләжев, Р. Вәлиев, Р. Миннуллин, Н. Әхмәдиев, Р. Корбан, Р. Низамиев, Мөдәррис Вәлиев, Ә. Мәхмудов, тагын да яшьрәкләрдән М. Мирза, Зәйдулла, Г. Морат, М. Закиров, Р. Аймәтләр татар шигъриятенең ныклы йолаларына таянып, поэзиябезгә яңа буяулар, төсмерләр өстиләр, эзләнүләрен төрле юнәлешләрдә алып баралар. Хәзерге татар шигъриятен, аның үсешенә нәзакәтлек, хисси матурлык, нурлы моң алып килгән хатын-кыз шагыйрьләребез иҗатыннан башка күз алдына китерүе кыен. Ф. Гыйззәтуллина, Э. Мөэминова, Р. Вәлиева, К. Булатова, С. Гәрәева, Л. Шагыйрьҗан Э. Шәрифуллина, кебек шигърияттә үз сүзләрен әйтеп, рухи дөнья тирәнлегенә тиң сурәтләр таба алган буын янына, һәркайсы үз моңы, үз аһәңе белән килгән яңа исемнәр өстәлә тора: А. Юнысова, Ф. Тарханова, Ш. Җиһангирова, Ф. Мөслимова, Ф. Солтан, Р. Рахман, Л. Янсуар... Бу исемлеккә югары уку йортларындагы, урта мәктәпләрдәге шигъри олимпны яулауга ашкынып торган яшь буынны да өстәп булыр иде.

Татарстанның Язучылар берлегендә 300 ләп каләм тибрәтүче әгъза булып санала. Иҗатка омтылып торучы сәләтле яшьләребез байтак булса да, аларның нигездә Татарстаннан, һәм анда да Саба, Балык Бистәсе, Мөслим, Актаныш кебек берүк районнардан гына килүләре борчылуга, шөбһәгә урын калдыра. Илнең башка төбәкләреннән, мөстәкыйльлек алган төрки дәүләтләреннән, татар әдәбиятының иң мул чыганакларыннан берсе—Башкортстаннан—килүче язучылар да аз. Егерменче-кырыгынчы елларда илнең иң ерак почмакларыннан, соңрак татар

әдәбиятының классиклары дәрәҗәсенә күтәрелгән, исемнәре телдән төшмәгән олы затлар килде: Һ. Такташ, М. Җәлил, Г. Кутуй, Ш. Камал, К. Нәҗми, Г. Әпсәләмов... Башкортостаннан татар әдәбияты үсешенә бәяләп бетергесез өлеш керткән М. Әмир, Ф. Кәрим, Ә. Еники, Н. Фәттах. Татарстанның изге туфрагына сонрак аяк баскан Ә. Баян, Нил белән Илдар Юзиевләр, Р. Гаташ, Фәиз һәм Ләис Зөлкарнәевләр, Г. Садә, Р. Миннуллиннар милли әдәбиятыбызның якты йолдызлары дәрәҗәсенә күтәрелделәр. Казакъстан утызынчы елларда татар сүз сәнгатенә ике олы талантны юллый—И. Сәлахов һәм Н. Арсланов. Икесе дә Күкчәтау шәһәрендә татар мәктәбендә, туган телләрендә белем алалар. Хәзерге мөстәкыйль төрки дәүләтләренең берсендә булса да татар мәктәбе бармы икән? Ә бит татар мәктәбе яшәгәндә генә телебез, милләтебез яшәр, әдәбиятыбызга да яшь көчләр килә торыр. Тормыш-яшәеш шартларына бәйле рәвештә дип уйлыйм, талантлы татар егетләре-кызлары "син"нән "һин"гә күчеп, җиңел генә башкорт язучылары булып китеп, Уфада төпләнеп калуны кулайрак күрә башладылар.

Әдәби әсәрне язуы укучыга житкерүдән җиңелрәк дип зарлансак та, халык күңеле тирәнлекләрен иңләгән талантлы әсәрнең басылмыйча калганы юктыр. Базар мөнәсәбәтләренә бирешмичә, хөкүмәт ярдәмендә Казанда Татарстан китап нәшрияты һәм "Мәгариф" нәшрияты заманча эшләп, язучыларыбыз мәнфәгатьләрен канәгатьләндереп киләләр. Шулар белән беррәттән химаячеләр исәбенә дистәләгән нәшриятлар китап чыгарып ята. Сыйфат дәрәҗәләре төрле булуы аңлашыла. Татарстан китап нәшрияты халык язучылары, шагыйрьләре Т. Миннуллин, Х. Камалов, Ш. Галиев, Ә. Баянов, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Миннуллиннарның күптомлыкларын затлы бизәлеш, яхшы кәгазьдә бастырып мәктәп китапханәләренә таратты. "Тере классикларыбыз" иҗаты, олы рухи хәзинәбез читтә яшәүче милләттәшләребезгә дә барып житсә, укучылары табылыр иде әле. "Мәгариф" нәшриятының "Балачак әдипләре", "Хәзинә", "Милли әдәбият китапханәсе" кебек даими чыгып килгән серияләре әдәби байлыгыбыз белән таныштыруга, аларны саклауга хезмәт итә. Рухи байлыкны күрсәтә, күрә белү дә—һәр милләтнең балигълыгы, өлгергәнлеге билгесе.

Гомер бакый бер-берсенең җылысын тоеп, һәрдаим аралашып, мөгаллимнәре, әдәби ачышлары белән уртаклашып, яшәгән төрки халыклар, хәзер диңгездәге кораблар кебек бер-берсеннән ераклаша баралар. 1917 ел түнтәрелешенә кадәр төрки халыкларның мәдәни һәм мәгърифәти Мәккәсе булып Казан шәһәре торды. Хәзер үзенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында аның бу олы миссиясе югала бара. Төрки телле галимнәрне совет чорында "Тюркология" журналы да очраштырып, берләштереп килде. Хәзер аның турындагы мәгълүматны белгечләрдән генә алырга мөмкин. Ил, дөнья буйлап таралган татар галимнәрен ничек, ни рәвешле якынайтып була? Бәлки, Татарстан Фәннәр академиясе яисә Казан дәүләт университеты карамагында (яки икесе бергә) Югары аттестация комиссиясендә теркәлгән (ВАК) журнал чыгару турында уйлашырга кирәктер? Татар, инглиз, рус телләрендә нәшер ителгән андый басма татар галимнәрен әзерләшеп, тел, әдәбият, тарих, фәлсәфә (нигездә гуманитар юнәлешле) кебек фәннәр яңалыкларын биреп барыр иде.

Ниһаять, Татарстан Фәннәр академиясенең энциклопедия институты карамагында татар язучыларының энциклопедиясен төзүче бүлек ачу ихтыяжы көн тәртибенә куелырга тиешле мәсьәләләрнең берсе дип саныйм. Җәмәгать эше тәртибендә хәтта Тукай энциклопедиясен дә тиешле югарылыкта, билгеләнгән вакытка башкарып чыга алмыйбыз. Бу изге эшкә алынган филология фәннәре докторы З. Рәмиев хәзер ярга ташланган балык кебек бәргәләнсә дә, күпме генә тырышса да, бер үзе генә Тукай рухы алдындагы бурычыбызны үти алмаячак. Ә бит юбилейлары унае белән уздырылган фәнни конференцияләрдә Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, М. Җәлил энциклопедияләрен булдыру кирәклеге дә искәртелде. Ш. Мәрҗани, К. Насыйри кебек шәхесләр хакында да уйланырга вакыттыр.

Безгә милләтебезне кечерәйтүче, мыскыллаучы алымнардан һәм коллык психологиясеннән арынып, үзебезне бөек халык баласы итеп тоярга өйрәнергә кирәк. "Бу дөньяда һәммә кеше кебек үк, һәр халык та үзенең батырлыгын,

өстенлеген күрсәтергә тырыша... жир йөзендә мәртәбәле урын даулый".—дип язуы белән М. Галиев хаклы. Ә әдәбият ул—үткәндәге бөеклекне, хәзерге халәтне күрсәтүнең иң үтемле чарасы. Чыннан да, һәр милләтнең сау-сәламәт булуын, үз киләчәгенә өмет, үсә килгән буынга ышаныч белән каравын аның күңел көзгесе—әдәбиятының—дәрәҗәсе буенча чамаларга, мөмкин.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы*

---

# Мөһаҗирлектәге татар әдәбияты

Кешене—кеше, милләтне милләт итүдә сүз сәнгатенең, ягъни язма әдәбиятның һәм фольклорның роле искиткеч зур. Чөнки анда күпгасырлык яшәеш тарихы, әби-бабаларыбызның рухи тормышы, кайгы-шатлыклары, теләк-омтылышлары, буыннан-буынга тапшырылып килгән әхлакый байлыгы, тереклек тәҗрибәсе гәүдәләнеш тапкан. Укый белеп укысаң, мәсәлән, Мөхәммәдьяр поэмалары аркылы Казан ханлыгы чорының тарихи вәзгыятен дә, кешеләренең күңел дөньясын да шактый тулы күзалларга мөмкин. Шәрифинең "Зафәрнамәи вилаяти Казан" язмасы (1550)—Казан ханлыгы һәм Мәскәү мөнәсәбәтләрен ачыклауда, шул чор татарларының басып алучыларга карашын билгеләүдә бәһаләп бетергесез чыганак. Г. Кандалыйның яисә М. Гафуриның шигырь-поэмалары безгә инсаннарның уй-кичерешләре, татарның менталитеты хакында гаҗәеп күп нәрсә сөйли. Милләтне милләт иткән, этник кавемнең асылын тәшкил иткән тел дә бөтен тулылыгы һәм кыйммәте белән бары сүз сәнгатендә генә ачыла. Әдәбият—чын мәгънәсендә укытучы-остаз, хәтер сакчысы, милли барлыкны һәм берлекне тәэмин итүче гаять куәтле чара. Кызганыч, бу билгеле хакыйкатьне соңгы вакытларда, ничектер, оныта башладык. Кайбер акыллыбашлар тарихны өйрәнүдә, халкыбызның үткәнен ачыклауда үзебезнең сүз сәнгатен, тел байлыгын читтә калдырып, таш, чүлмәк китекләрен, читләр биргән мәгълүматларны барысыннан өстен куярга керештеләр. Шуның нәтиҗәсендә Болгар, Хәзәр, Алтын Урда кебек төрки-татар мәмләкәтләренең этник ягы бөтенләй төссезләнеп кала, әйтерсең, аларда безнең әби-бабаларыбыз түгел, ә бөтенләй чит-ят кавемнәр яшәгән. Татар телен белмичә, оригиналь чыганаклар белән эш итмичә халкыбызның рухи мирасын өйрәнүчеләр дә күзгә ташлана.

Мәгълүм ки, төрки-татар әдәбиятының мең елдан артык тарихы бар. Борынгы төрки карынында туып, Хәзәр, Болгар, Кыпчак, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Нугай, Себер, Касыйм мәмләкәтләре чорын кичереп, колониаль изелүнең коточкыч афәтләрен күреп, XX йөз башында гаять зур үсеш алып, ул хәзерге чорга—XXI гасырга килеп житте. Шушы вакыт эчендә татар әдәбияты искиткеч бай хәзинә туплады. Кол Гали, Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Кандалый, Акмулла, М. Гафури, Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Дәрдемәнд, Ш. Бабич, Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан һәм башка бик күп әдипләребез теләсә нинди милли әдәбиятны бизәрлек!

Меңьеллык татар мәдәни мирасын өйрәнү һәм киң катлам укучыларга җиткерү юнәлешендә соңгы ярты гасыр эчендә зур эш башкарылды. Күптомлык фольклор китаплары, алты томлык татар әдәбияты тарихы, күренекле язучыларыбызның басмалары, дәреслек-хрестоматияләр, уку әсбаплары һәм башкаларның дөнья күрүе—әнә шундыйлардан. Мин университетта илленче-алтмышынчы елларда белем алдым. Ул вакытта әле Тукайгача чор әдәбияты турында мәкалә-хезмәтләр, әсбаплар бөтенләй диярлек юк иде. Ә хәзер Урта гасыр сүз сәнгатенең күпчелек әсәрләре басылган, алар хакында махсус хезмәтләр, диссертацияләр язылган. Әдәбият тарихының башка чорлары турында да шушы сүзләрне әйтергә була. Әмма әле

әдәби мирасны барлау һәм өйрәнү өлкәсендә эшләр муеннан. Шактый гына язма истәлекләр, аеруча Октябрь инкыйлабына кадәргеләре шәхси кулларда, архивларда, төрле фондларда үзләрен тикшерүчеләрне көтеп ята. Аерым әдипләребезнең әсәрләре йә бөтенләй нәшер ителмәгән, яисә өзек-көтек кенә басылган. Нәшер кылынганнарының да шактые хәзерге укучыга барып җитәрлек түгел.

Һәр чор, һәр буын рухи мираска үзенең эчке ихтыяҗларыннан чыгып якын килә, аны үзенчә эшкәртә, аңлый һәм аңлата. Бу аеруча җәмгыятьтәге кискен борылышлар вакытында көчле була. XX-XXI гасырлар аралыгы—халык, ил, дөнья тормышында көчле үзгәрешләр чоры. Элеккеге кыйммәтләр, мирас кабат, тәнкыйди карала башлады, яңа карашлар, концепцияләр туды. Бу хәл әдәбиятчылар алдына да җитди бурычлар куйды. Элекке хезмәтләр генә инде бүгенге укучыны канәгатьләндерми. Җәмәгатьчелек, бер яктан, үзебезнең милли традицияләребезне, үзенчәлекләрне дәвам иткән, икенче яктан, рус, дөнья гыйльми, эстетик казанышларын файдаланган яңача, заманча тикшеренүләр, мәкалә-китаплар көтә. Әмма бу эш шактый авыр бара. Тиешле әзерлекле кадрлар җитмәү, матди проблемалар да үзен нык сиздерә. Тупланган материалларны саклау һәм файдалануда да кыенлыклар күп. Аеруча Казандагы "Мирасханә"нең язмышы борчу тудыра. Аны тиешле бина белән тәэмин итү—кичектергесез бурыч.

Әдәби мирасны тәрҗемә итеп, башка халыкларга җиткерү эше дә бик сүлпән бара. Бу юнәлештә безгә Равил Бохараевтан үрнәк алырга кирәк. Аның татар шагыйрьләрен инглиз, рус, венгер һәм кайбер башка телләрдә яңгыратуы чын мәгънәсендә мактауга лаек. Бүтән халыкларның иң матур әдәби үрнәкләрен татарчага тәрҗемә итү дә—бездә иң артта калган өлкә. Бу эштә, аеруча әсәрләр сайлауда, читтәге милләттәшләребезнең дә катнашуы зарур.

Үткән гасырларга күз ташласаң, тарихи язмышның халкыбызга кырыс каравы, кайгы-газапларны кызганмавы ачык күренә. Татарның, яһүдиләр кебек, бөтен дөнья буйлап сибелүе, таралуы да, иң беренче чиратта, матди кыенлыкларга, хокуксызлыкка бәйле. Бит беркем дә, кагыйдә буларак, үз ирке белән җиту тормышны, туган җирен, Ватанын калдырып, мөһаҗирлек юлына басмый. Бу адымны ясарга аны гадәттән тыш вәзгыять, чарасызлык мәҗбүр итә.

Татарлар арасында мөһаҗирлек инде Урта гасырларда ук күзәтелә. Мисыр-Сүриягә, Урта һәм Кече Азиягә, мәсәлән, күпләгән кавемдәшләребезнең күчеп китүе мәгълүм. Өч гасырга якын Мисыр белән идарә иткән атаклы Мәмлүкләр династиясенең дә зур өлеше—Идел-йорттан күчүчеләр. Анда төрки-татар телендә бай әдәбият туа. Безгә әле аның тик бик аз өлеше генә мәгълүм. Мисырда мәмлүкләр чорыннан калган бай архивларның, материалларның саклануы билгеле. Аларга әле безнең татар галимнәренең һаман кулы җитми.

Татарлар арасында мөһаҗирлек аеруча халкыбыз үз дәүләтчелеген югалткач, колониаль изелү елларында көчәя. XX гасырның беренче яртысында ул иң югары дәрәҗәсенә җитә. Ике бөтендөнья сугышы, инкыйлаблар, аклар-кызыллар арасындагы көрәш-бәрелешләр, күмәкләштерү, дингә каршы көрәш татар тормышын тәмам туздырып ташлый. Милләттәшләребез, камгак (перекати-поле) кебек, Евразия киңлекләренә генә түгел, хәтта Америка, Африка, Австралия кыйтгаларына кадәр үк тарала. Шунысы мөһим: татар мөһаҗирләре чит-ят җирләрдә булуына карамастан, үзләренең телен, моңын, рухи мирасын, гореф-гадәтләрен сакларга, үстерергә, алдагы буыннарга тапшырырга омтылган. Шул максатны күздә тотып, китаплар язган һәм бастырган, газета-журналлар чыгарган, төрле мәдәни, тәрбияви чаралар уздырган. Шунысы мөһим: мөһаҗир татарлар Идел-йорттан үзләре белән төрле басма һәм кульязма китаплар да алып киткәннәр, төрле кыенлыклар, киртәләр булуга да карамастан, тарихи Ватаннарыннан да аерым басмалар алганнар.

XX йөздәге татар мөһаҗирлегенең мөһим мәдәни төбәкләре берничә: Кытай, Япония, Финляндия, Төркия, Алмания, Польша, өлешчә Румыния. Аларда татар-мөселман җәмгыятьләре, курслары, мәктәпләре эшләве, татар басмаларының дөнья күрүе мәгълүм. Токиода, Хельсинкида хәтта татарларның үз нәшриятләре дә эшли. Японияләге "Матбагаи исламия"дә узган гасырның 20-40 елларында күп санлы китаплар нәшер ителә. Болар арасында Тукайның биштомлыгы, дини, педагогик

басмалар, күпләгән әдәби әсәрләр бар.

Мөһаҗирлектә чыккан татарча газета-журналлар саны өч дистәдән артып китә. Болардан бигрәк тә берничәсе мәдәни-тарихи яктан игътибарга лаек. "Яңа милли юл" (әүвәл ул "Милли юл" исеме белән чыга)—1928—1939 елларда басылган журнал. Барлыгы—136 сан. Нигездә, Берлиндә нәшер ителә. Берничә саны Варшауда дөнья күрә. Баш мөхәррире—Г. Исхакый. "Милли Байрак"—1935—1945 елларда Мукдендә нәшер ителгән атналык газета. Ул да Гаяз Исхакый тарафыннан нигезләнә. Төп хезмәткәрләре—профессор Надир Дәүләтнен әти-әниләре Рокыя һәм Ибраһим Дәүләткилделәр. "Яңа япун мөхбире" (баштагы исеме—"Япун мөхбире"). Бу айлык журнал узган гасырның 30-40 елларында Токиода нәшер ителә. Анын җитәкчесе—Токио имамы Габделхәй Корбангали. "Азат Ватан" мәҗмугасы 1952-53 елларда Мюнхендә татар һәм рус телләрендә басыла. Аны Алманиядәге "Татар-башкорт милли тәшкилияте" чыгара. Тәүге җитәкчесе—мәшһүр Тамурбәк Дәүләтшин (1904—1983). Бу затнын 1974 елда Лондонда нәшер ителгән "Советский Татарстан: Теория и практика национальной политики» китабы заманында Советлар берлегендә сенсация тудырган иде. "Kazan"—Төркиядә 1970—1980 елларда өч айга бер чыккан журнал. Барлыгы—23 сан. Төрек һәм татар телләрендәге бу мәҗмуганы әзерләүдә Әхмәт Тимер, Надир Дәүләт, Әмрулла Агый һәм башка билгеле милләшләребез катнаша.

Татарча газета-журналларнын иң күп чыккан урыннары—Финляндия, Кытай. Суоми илендә: "Мәгърифәт" (газета, 1925), "Шималь очкыннары" (мәҗмуга, 1943—1977), "Ак юл" (газета, 1967—1974), "Тавыш" (газета, 1967), "Ислам мәхәлләсе" (Мәҗмуга, 1956-1951) һ. б. Кытайда: «Ерак Шәрык" (1920-22), "Азад Шәрык" (1923), "Шәкердләр таңы" (1934-1935), "Шәрык авазы" (1939-40), "Чаткы" (1932-33) һ. б. газета-журналлар. Боларның барысы диярлек гарәп графикасында.

Мөһаҗирлектәге вакытлы матбугат һәм әдәбият үзара тыгыз бәйләнешле, алар үзара керешеп киткән. Ни өчен? Чөнки газета-журналларда эшләүчеләрнең шактые әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә. Бу—бер. Икенчедән, читтәге татар әдипләренең әсәрләре күбрәк газета-журналларда басыла. Аерым китап рәвешендә нәшер кылу очраклары чагыштырмача сирәк.

Мөһаҗирлектә XX йөздә иҗат иткән татар әдипләренең саны шактый: Хөсәен Габдүш (1901—1944), Сания Гыйффәт (1899—1957), Хәсән Хәмидулла (1900—1988), Шаһвәли Келәүле (Илдәр) (1900—1970), Минһаҗ Исмәгыйли (1910—1995), Гәүһәр Туганай, Исфәндияр Ишгай, Әхмәд Ләбиб Каран, Садрый Хәмид, Гайсә Хәкимҗан, Наилә Бинарк, Мансур Арсланбәк һ. б. Әлбәттә, боларның талант дәрәҗәләре, язганнарының сыйфаты төрлечә. Әмма бу мөхтәрәм затларның мөһаҗирлек шартларында да туган телебезне, әдәбиятыбызны яратулары, үзләренең уй-кичерешләрен кәгазьгә төшереп калдырулары, милләтебез турында яну-көюләре үзе үк фидакарьлек.

Узган гасырның беренче яртысында һәм урталарында чит мәмләкәтләрдә яшәп иҗат иткән татар әдипләренең иң күренеклесе, җитәкчесе, остазы,—әлбәттә, Гаяз Исхакый. Юкка гына Әхмәд Ләбиб Каран аның хакында бу юлларны язмаган:

Гаяз Исхакый—татарның бер олуг инсаныдыр,
Татар әдәбиятының тажлы бер хаканыдыр.

Г. Исхакыйның куәтле йогынтысы татар сүз сәнгатендә, публицистикада гына түгел, сәясәттә, фәндә, мәдәнияттә һәм гомумән татар рухи тормышының башка тармакларында да тирән эз калдырган. Бу бөек затның эшчәнлеге хакында уйланып, икенче бер мөһаҗир шагыйрь Минһаҗ Исмәгыйли үзенең бер парчасында болай ди:

*Гаяз ага, син бит безгә кояш идең,*
*Синең юлың ак юл, бәхет юлы иде.*
*Шуңа күрә курыкмадың дошманнардан,*
*Чөнки син бит батыр татар улы идең!*

*Күкрәк киереп син атладың алга таба,*
*Татарларың курыкмый хәзер алга бара.*

*Бер көн килер, Идел-Урал азат булыр,*
*Шуны көтә, шуны көтә халкың алда.*

Тиздән Г. Исхакыйның тууына 130 ел тула. Моны без бөтен татар дөньясында зур вакыйга рәвешендә билгеләп китәргә бурычлы.

Мөһаҗирлектәге татар язма әдәбияты төрле төрләрдә һәм жанрларда: чәчмә, тезмә, драма, роман, повесть, хикәя, сәяхәтнамә, очерк, комедия, сатира, җыр, дастан, поэма, ода-мәдхия, робагый, марш һ.б.

Идея-тематикасы да шактый бай һәм күпкырлы: тарих, хәзерге заман, дөнья хәлләре, сәясәт, мәхәббәт, әхлак, халыкларның үзара мөнәсәбәтләре һ.б. Әмма үзәктә—татар язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге, дөнья кавемнәре арасындагы урыны. Милләт, ил язмышы—һәр авторның бәгырендә, җанында. Финляндиядә гомер кичергән Хәсән Хәмидулла үзенең "Куанычым" шигырендә болай яза:

*Сөям мин бик татарлыкны, татар булып үлим, Раббым.*
*Сүгән бер эшне эшләү берлә мин гомремдә тәм таптым.*

*Күченмәк юк бу фикеремдән, оялмыйм һич татарлыктан,*
*Үкенмим, сакласын Аллам мине андый начарлыктан.*

*Көләм мәсхәрле күз берлән, татарлыкны—яшергәндән,*
*Итәм нәфрәт эчем берлән, көләм мин инде ул "мән"дән.*

*Татар булгач татармын мин, шуңардан бәхтиярмын да,*
*Көләрмен һәм татар бәхтенә, хасрәткә җыларммын да...*

Мөһаҗир шагыйрьләрне кайчандыр бөек, дәүләтле булган татарның бүгенге хокуксызлыгы, теленең, мәдәниятенең кысылуы гаять борчый. Алар халыкны бердәм, әхлаклы, иманлы булырга чакыра, үз укучыларында киләчәккә, азат тормышка өмет, ышаныч тәрбияләргә омтылалар.

Сания Гыйффәт:

*Алга, туган, алга! Җиңәнгәчә,*
*Ил юлында тиңсез тартышка!..*
*Бергә, туган, бергә! Үлгәнгәчә,*
*Ирек өчен изге тартышка!..*

Исфәндияр Ишгай:

*Кайда гына булма, аерылма син*
*Үз динеңдән, милли юлыңдан.*
*Милли байрагыңны югары тот,*
*Һич төшермә аны кулыңдан.*

Минһаҗ Исмәгыйли:

*Илебезгә якты нурын чәчәр*
*Зөһрә йолдыз—Казан каласы.*
*Хуҗа булыр тагы үз иленә*
*Изелеп килгән татар баласы.*

Туган җирне, туган илне, Ватанны сагыну, җирсү тойгылары мөһаҗирлек әдәбиятының бөтен тукымасын сугарган. Хәсән Хәмидулла күңелендәге сагынусагыш хисләрен басар өчен искән җилләргә мөрәҗәгать итә:

*... Ни бәхет, җил кайтса илгә, сөйләсә миндән сәлам,*
*Әйтсә анда—мин аларны нинди күп сагынып калам.*

Сания Гыйффәтнең "Сагынганда" шигыре дә бик тәэсирле.

*Ил йөзен күрсәм бераз,*
*Шат булыр идем, бәлки.*
*Мин дә мин дә, мин дә, аһ,*
*Җан алыр идем, бәлки.*

*Сагындым дияр идем,*
*Туфрагын үбәр идем,*
*Кочаклап коча-коча,*
*Күз яшем түгәр идем.*

*Кайгылы ил ташларын*
*Сыйпап җуатыр идем,*
*Җылы, үз кочагында*
*Назланып ятыр идем.*

Туган илне, туган халыкны сагыну хисләре еш кына Казан, Сөембикә, Тукай образлары аркылы бирелә. Алар, ничектер, татарның бер символы рәвешендә күзаллана. Шаһвәли Keләүле, мәсәлән, Тукайны «ил йолдызы» дип атый:

*Ил йолдызы сүнмәс, якты янар,*
*Ил догасы белән бизәлер.*
*Шигыреңнән халык азык табар,*
*Яктылыкта мәңге тирбәлер.*

Тукайның исеме, рәсеме, әсәрләре читтәге һәр татар басмасында диярлек күзгә ташлана.

Минһаҗ Исмәгыйли өчен Казан—татар халкының кыйбласы.

*...Казан, Казан—*
*Син бит безгә кыйбла,*
*Син бит мәркәз татар халкына.*
*Күптән инде сине ташласам да,*
*Һаман йөрәк сиңа талпына.*

Татар мөһаҗирлек әдәбиятында, аеруча публицистикасында, большевиклар сәясәтен тәнкыйтьләү, Советлар режимының тискәре якларын да күрсәтү көчле. Бу ягы белән ул илдәге шул чор әдәбиятыннан шактый аерылып тора. Миллилек, мөселман әхлаклылыгы, иманлылык, төркичелек, милли азатлык, бәйсезлек идеяләрен үзәккә кую мөһаҗирлек әдәбияты өчен хас. Ул үзенең рухы, тел-стиле белән шактый дәрәҗәдә XX йөз башы әдәби традицияләрен дәвам итә, үстерә. Әмма чит илләрдәге татар әдәбияты, гәрчә үзенчәлекләре булса да, Ватандагы сүз сәнгате белән гомумән табигый бәйләнешле. Алар икесе ике нәрсә түгел, ә бер бөтеннең кисәкләре.

Фән, бүгенге тормыш, милли барлык рухи мирасны, шул исәптән мөһаҗирлектәге байлыкны да мөмкин кадәр тулырак, объектив барлауны, өйрәнүне таләп итә. Кызганыч ки, гыйльми тикшеренүләрдә әле һаман әнә шул тулылык, бөтенлек җитми. Г.Исхакыйның, башка мөһаҗир әдипләрнең иҗаты совет чоры татар әдәби процессын өйрәнүдә файдаланылмый диярлек.

Соңгы ике дистә елда мөһаҗирлектәге татар әдәбиятын һәм матбугатын барлау, өйрәнү, халыкка кабат кайтару юнәлешендә шактый эш башкарылды. Бу өлкәдә Әбрар Кәримуллин, Илбарис Надиров, Миркасыйм Госманов, Надир Дәүләт, Мәхмүт Таһир, Тәуфыйк Әйди, Лена Гайнанова, Әхмәт Сәхапов, Ибраһим Нуруллин, Резедә Ганиева, Искәндәр Гыйлаҗев, Фәридә Гаффарова, Флүн Мусин, Окан Таһир, Наилә Бинарк, Рөстәм Гайнетдинов, Римзил Вәлиев, Илсур Мансуров һәм

башкаларның эшчәнлеге игътибарга лаек. Хәзер Төркиядә яшәүче яшь галимәләребез Чулпан Зариф-Четин, Илсөяр Рәмиевалар да мөһаҗирлек мәдәниятен барлауда, тикшерүдә уңышлы гына алымнар ясыйлар. Без фәкыйрегез дә читтәге татарларны өйрәнү белән 20 елга якын шөгыльләнеп килә. Шуның нәтиҗәләре 67 мәкаләдә, дүрт китапта (Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты.—К.: Таткитнәшр., 2004.—368 б.; Чит илләрдәге татар әдәбияты.—К.: Мәгариф, 2007.—399 б...) бәян ителгән.

Илдәге һәм чит мәмләкәтләрдәге галимнәребез, зыялыларыбыз тырышлыгы ярдәмендә Төркиядән, Алманиядән, Финляндиядән мөһаҗир татарларга мөнәсәбәтле шактый гына материаллар Татарстанның архивларына, китапханәләренә кайтты. Акрынлык белән булса да бөек Исхакыйның 15 томлыгы чыгып килә. Аның иҗаты, күпкырлы эшчәнлеге дистәләгән докторлык һәм кандидатлык диссертацияләрендә, монографияләрдә яктыртылды. Садрый Максудый, Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш язмаларының да зур өлеше бүгенге укучыларга мәгълүм. Әнвәр Мәхмүд һәм Али Нәдрәтләр Румыниядәге татар әдәбиятын ныклап өйрәнәләр, аларның берничә монографиясе, җыентыгы дөнья күрде. «Яңа милли юл», «Kazan» кебек журналлар хакында да күзаллауларыбыз кинәя бара. Әмма әле мөһаҗирлектәге татар әдәбиятын, матбугатын ачыклауда, илгә кайтаруда, тикшерүдә башкарыласы эшләр гадәттән тыш күп. Читтәге күп кенә газета-журналларның эчтәлеген без әле юньләп белмибез. Алар исә күбрәк аерым кулларда саклана. Хәсән Хәмидулланың тау кадәр китаплары, язмалары тикшеренүчеләрне көтеп ята. Япония, Кытай, Төркия, Алмания, Ватикан, Финляндия, Польша архивларында, китапханәләрендә татарга мөнәсәбәтле материалларның саклануы билгеле. Аларны ачыклауда без, ин беренче чиратта, чит мәмләкәтләрдә яшәүче милләттәшләребезгә өмет баглыйбыз. Әгәр дә без вакытны сузып, хәзерге форсатны файдалана алмасак, кыйммәтле язмалар шәхси кулларда таралып, тәмам юкка чыгарга да мөмкин. Мөһаҗир милләттәшләребездә алар үзләре тудырган ядкарьләрдән тыш, гомумән элеккеге мәдәни мираска мөнәсәбәтле истәлекләр дә теге яки бу күләмдә бар.

Милләттәшләребез ерак чит илләрдә генә түгел, элеккеге союздаш республикаларда да, Россиянең төрле регионнарында да яши. Алар да татар мирасын тулыландыруга билгеле бер өлеш кертәләр. Мәсәлән, Казакъстанда, Кыргызстанда соңгы вакытларда гына татарча көндәлек басмалар, дистәләгән китаплар чыкты. Украинада «Дуслык» журналы басыла. Харьковта яшәүче милләттәшебез Салих Шакир углы Җамалиев үзенең берничә китабын татар, украин, рус телләрендә бастырып чыгарды. Башкортостан, Төмән, Пермь, Ижевск, Санкт-Петербург, Әстерхан һ.б. төбәкләрдә дә татарча, татарга мөнәсәбәтле көндәлек басмалар, китаплар нәшер ителә. Боларны Татарстанның Милли китапханәсенә туплап бару, гыйльми өйрәнү, пропагандалау—кичектергесез бурыч. Татарга мөнәсәбәтле һәр факт, һәр мәгълүмат, аеруча милли телебездәге язмалар гыйльми тикшеренүләрдән читтә калырга тиеш түгел. Бары шунда гына без халкыбыз тарихын, аның рухи байлыгын чагыштырмача тулы, бөтен итеп күз алдына китерә алырбыз.

Мәдәни мирас—безнең әби-бабаларыбыз меңәр ел буена туплаган кыйммәтле хәзинә, рухи терәк. Шуны өйрәнеп зиһенебезнең хәзинәсе итсәк, безнең алга баруыбыз, татарның сакланышы һәм үсеше дә шулкадәр нәтиҗәлерәк булыр.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
*филология фәннәре докторы*

Рифат
Сверигин

# ТОРМЫШ ЧОҢГЫЛЛАРЫ ҺӘМ ТАРИХ ТӨПКЕЛЛӘРЕ АША...

## МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИНГА 80 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕННАН

Ул үзенең чордашларына караганда күпкә яшь күренә: ачык чырай, теләсә кайсы киноартистны сокландырырлык мөлаем, тормыш дәрте бөркелеп торган матур йөз, чын спортчылардагыдай төз гәүдә-сын, ачык фикерле, тирән мәгънәле әңгәмәдәш—әгәр дә күренекле татар әдибе Мөсәгыйт Хәбибуллинга 80 яшь тулып килгәнлеген әдәби белешмә чыганаклары буенча яхшы белмәсәм, мин бу дата белән килешмәс идем—күңелем исә әле дә моңа ышанып җитми. Һәр кешенең туу метрикасы, паспорт мәгълүматларыннан тыш, яшәештәге рәвеше, Раббым биргән халәте һәм сәләте бар. Кеше дигән затның кем икәнлеген белү өчен әнә шул соңгылары да бик җиткән шикелле үзе.



Әмма үтелгән гомер юлының мәгълүм бер баскычына менеп житкәч, әнә шул биеклектән ирешелгән казанышларга, уңышлы нәтиҗәләргә күз салырга, шуларны барлап, алдагы офыкларга омтылырга да адәм баласының тулы хокукы, хакы бар—әгәр дә барларлыгың булса, гомереңнең шул үтелгән этабында эз калдырган булсаң...

Мөсәгыйт Хәбибуллин үзенең тормыш һәм иҗат бәйрәменә бик күп әсәр алып килде: «әйе, болар барысы да минем гомеремнең иҗат җимешләре, боларны мин тудырдым» дип горурланып әйтә ала. Моны раслау өчен аның укучылар бик яратып һәм ябырылып укый торган өч дистә китап язып бастырганлыгын әйтеп узу да җитә. Аларның ике дистәсе татар телендә, дистәгә якыны рус телендә һәм икесе быел «Сказание за Казан» һәм «Хан Кубрат» исемнәре белән Софиядә болгар телендә дөнья күрде.

Ә шушы озын гомер юлында күпме искә алырлык хәлләр, вакыйгалар, борылышлар, үзгәрешләр булып үткән?! Башка берәү булса, шул хәлләрнең чирек генә күрсә дә, инде калын-калын автобиографик романнар чыгарган булыр иде! Мөсәгыйт Хәбибуллиннан без аларын да көтеп калабыз. Әмма хәзергә аның татар прозасында сызган ап-ачык ике буразнасы күренеп тора: 1) үзәгенә замандашларыбыз образлары куелган реалистик хикәяләр, повестьлар, романнар;, 2) татар халкының еракта калган тарихи сәхифәләрен яктырткан әсәрләр. Бүгенге көндә әдипнең иҗат төрәне тулысынча шушы буразналарның икенчесенә, ягъни тарихи темалар ягына авышканлыгын һәм менә нәкъ шушы өлкәдә каләменең дә аеруча нык танылганлыгын әйтеп узарга кирәк. Бу хәл әдипнең биографиясе һәм иҗтимагый вәзгыятнең мәгълүм үзгәрешләре белән дә тыгыз бәйләнгән.

Каләмен илленче елларда ук тибрәтә башлаган булса да—мәсәлән беренче хикәясен ул яшьләр җыентыгында 1951 елда бастыра—олы әдәбиятка ул урау юллар

үтеп, зур тормыш тәҗрибәсе туплаганнан соң, алтмышынчы еллар ахырында гына килә—1969 елда анын «Жиде юл чатында» исемле беренче повесте—китабы дөнья күрә. Инде гомер елларынын дүртенче дистәсен түгәрәкләп килгәндә генә анын исеме язучы буларак әдәбият дөньясында танылды. Мона артык гаҗәпләнәсе дә юк: язмыш кайберәүләргә әнә шулай, ашыкмый гына яшәргә, барысына да өлгерергә, сабыр гына зур эшләр майтарырга жай һәм мөмкинлекләр бирә. Бу шәхесне мин шундыйлардан, һәр игелекле һәм олы максатына үз вакытында барып житәргә өлгерә торган бәхетле затлардан дияр идем. Сүз унаенда гына булса да, кайбер «ямь-яшел» килеше һәм тормыш тәҗрибәсен тупламый торып, әдәби сәләте һәм зәвыгы булмаса да, язучы исемен йөртүчеләргә һәм башкаларга тормыш, әдәбият сабакларын «өләшүчеләргә» мин Мөсәгыйт Хәбибуллин биографиясенә күз салырга, зур һәм катлаулы тормыш дәрьясын кичеп кенә чын әдип булып житешү мөмкинлеген исләренә төшерер идем.

Без дә анын биографиясен күздән кичерик:

Мөсәгыйт Хәбибуллин Оренбург өлкәсенең Татарстан янәшәсендә урнашкан Абдуллин районындагы Габдрахман дигән авылда хәлле генә крестьяннардан саналган Мөдәррис һәм Мөнәвәрә гаиләсендә 1927 елнын 25 нче декабрендә туа. Башлангыч белемне бала үз авылларындагы мәктәптә ала, аннан соң Татарстанның Баулы районында Яна Шалты жидееллык мәктәбенә йөреп укырга тотына. Мөсәгыйт жиденче сыйныфны тәмамлаганда Бөек Ватан сугышы башланып китә. Авылга каникулга кайткан малай колхоз эшенә тартыла: тракторчылар янында сукачы булып эшләп китә. Ары таба аны язмыш Магнитогорск каласына алып килә. Ул анда һөнәр мәктәбендә укый, заводта эшли. Сәләтле, уңган, тырыш егетне спорт житәкчеләре дә күреп алалар, тиз арада Мөсәгыйт шактый өметле хоккейчы һәм футболчы буларак таныла: ул «Металлург» командасы уеннарында жиде ел дәвамында катнашып, уйнап йөри. Минемчә, булачак әдипнен әлеге шөгыле, дә эзсез калмаган—кайчандыр спорт белән нык дус булуы бүгенге йөреш-торышында да чагыла шикелле. Мөсәгыйт Хәбибуллиннын озаклап, армый-талмый эшли алу сәләте, спортчыларда гына була торган үҗәтлек белән үзенен төп максатына бара белү осталыгы мөгаен әнә шул елларда ук анын холкына салынгандыр.

Шуннан сон Мөсәгыйт Хәбибуллиннын тормыш юлы, чуар калейдоскоптагы сыман, кырыкка кырланып, гел алмашынып, үзгәреп тора башлый. Башта чирәм жирләрне үзләштерү кампаниясенә кушылып китеп, ул чынлыкта туган авылына кайтып төшә—чөнки бу жирләр дә сөрелмәгән чирәм икән. Авылда ул—электрик та, инженер-механик та, шофер да. Колхозда дүрт йөк машинасы бар. Урманнан утын, агач ташыйлар, өйләр бурыйлар—авыл да күзгә күренеп янара башлый. Кичләрен клубка жыелалар, спектакльләр куялар. Пьесаларны Мөсәгыйт үзе яза. Кыш кергәч, авылдан-авылга йөреп, спектакльләр уйныйлар. Ул арада армиягә барырга чакыралар һәм... Мөсәгыйт тагын яна роль үзләштерә: Куриль утраулары янына барып чыга һәм зур десант корабльләренен берсендә сигналчы булып хезмәт итә башлый. Әмма, бәхетебезгә күрә, илдә яна жилләр куба—армияне кыскартырга керешәләр. Ана офицерлар мәктәбенә керергә тәкъдим итәләр, әмма булачак әдип моннан баш тарта һәм, бик дөрес эшли. Минем ышануымча, язмыш аны берничә тапкыр дөрес юлга этәргән, әлбәттә, хәрбиләр арасында да, спорт дөньясында да ул танылмый калмас иде—әмма әлеге очракларда татар әдәбияты, мөгаен бер олы әдибен югалтыр—Мөсәгыйт Хәбибуллинсыз калган булыр иде.

«Язмыш мине янадан Татарстанга алып килде,—дип яза автор үзенен истәлекләрендә.—Һәм һич уйламаганда бөтенләйгә калдым.

Бер елга якын йөк машинасында эшләп алдым. Аннары мине механик иттеләр. Тагын бер елдан квартира бирделәр. Янә бер ел үтүгә, мине Баулы район газетасына эшкә чакырып алдылар. Менә кайчан мина язу чире кагылды. Мин тормышымда күргән-белгән гадәти булмаган хәлләр турында хикәяләр язарга тотындым.»[1]

Нәкъ тиешле вакытында, булачак әдип әлегә жиде юл чатында торганда, ана әдәбиятыбызнын күренекле шәхесләре белән очрашырга насыйп була. Шагыйрь Сирин, укытучы-галим Шәйхи Садретдинов, язучылардан Гариф Ахунов, Гамил Афзал ана кыйммәтле киңәшләрен биреп, белем һәм әдәбият дөньясына кереп китәргә ярдәм итәләр.

---

[1] Хәбибуллин М. Әдәбиятка юл салганда (үткәннәрдәге мизгелләр). Кульязма.

Әмма әдәбиятның олы мәйданына чыгып танылганга кадәр бик күп борылмалы сукмаклар, киртәләр, каршылыклар аша узарга кирәк икән әле. Тормыш дигәнең егетне әле унга, әле сулга ора. Аларның төп бәһасен—һәм зыянын, һәм файдасын дигәндәй—барысын бергә кушып карап, автор үзе генә бәяли һәм үлчи алгандыр. Тик, безгә калса, шул тормыш дигән казанда кат-кат кайнау юбилярыбызга бүгенге югарылыкларга күтәрелергә ярдәм иткән кебек тоела. Чын, олы әдәбиятка аз гына соңлабрак аяк басса да, тора-бара икеләтә-өчләтә дәрт һәм көч салып эшләп, Мөсәгыйт Хәбибуллин теге калышу яисә «югалту»ны артыгы белән компенсацияләчәк—ягъни иҗат активлыгын кушып, укучыга артыгы белән «түләячәк». Дөресрәге, моны югалту дип санап та булмый, чөнки ахыр чиктә нәкъ менә тормышның үзеннән чумырып алынган байлык, тәҗрибә аның иҗатына реаль буяулар, төсмерләр өсти, әсәрләрендә гәүдәләндерелгән характерларга дәлилле куәт, ышандыру көче сала, аларны тирән кешелеклелек, идеяләре белән сугара.

1961-62 елларда М. Хәбибуллин Баулыдагы «Байрак» исемле газета редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. Шул чорда кичке урта мәктәпне аннары, читтән торып укый. 1971 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. 1966-68 елларда ул Азнакай эшчеләр поселогында яши һәм районның «Маяк» исемле газетасында сәнәгать, төзелеш һәм транспорт бүлегенә җитәкчелек итә. Аннан соң ул Таҗикстанга китеп бара һәм Ленинакан төбәгендә Чорух-Дайран дигән җирдә, урта мәктәптә тарих һәм җәмгыять белеме фәннәре укыта. Ниһаять, 1971 елның июнендә Казанга килеп, шушында төпләнә һәм озак еллар дәвамында Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең оештыру эшләре буенча секретаре вазифаларын башкара.

Алтмышынчы еллар ахырында, бигрәк тә җитмешенче елларга чыккач, М. Хәбибуллин прозаның төрле жанрларында шактый кызыклы тәҗрибәләр ясый. Аның «Гөлсәхрә», «Киселгән каен», «Казан алмады», «Туй балдагы», «Яңа өй», «Өченче вагон» хикәяләрендә заманыбыз кешеләренең хәтердә калырдай образлары чагылып үтә—автор төрле профессиядәге һәм тормышка төрлечәрәк, үзләренчәрәк караучы кешеләрнең эш-гамәлләрен психологик яктан ышандырырлык итеп нигезләүгә ирешә.

«Хәтер ярлары» (1977), «Унсигезенче яз» (1969), «Икмәк кадере» (1968), «Тау белән тау очрашмаса да» (1970) повестьлары, бигрәк тә «Чонгыллар « (1973) һәм сиксәненче еллар башында иҗат ителгән «Сулар үргә акса да» (1983) романнары прозабызга тормышны бик яхшы белүче һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җанлы геройлар образлары аша анлатырдай каләм остасы килгәнлеген хәбәр иттеләр. Бу иҗат башка каләм әһелләренең, тәнкыйтьчеләрнең, тәҗрибәле әдәбият галимнәренең игътибарын да җәлеп итте. Каләмдәшләреннән Гариф Ахунов, Рафаэль Мостафин, Атилла Расих, Фәрваз Миннуллин, Флүн Мусин, Хәсән Сарьян, Мансур Вәлиев, Фоат Галимуллин, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Фатих Урманчиев, тарихчы галимнәр Әбрар Кәримуллин, Фаяз Хуҗин әдәбият сукмакларыннан үзенчәрәк атлап киткән, әле һаман да күпләргә яшь әдип булып тоелган Мөсәгыйт Хәбибуллинга кыйммәтле киңәшләрен бирергә ашыктылар, әсәрләрендәге кайбер кимчелекләрне дә күреп, аларны алга таба булдырмау ысулларын эзләштеләр, уңышларын күреп, сөенештеләр.

Һәр яңа әдәби күренешкә аеруча сизгер тәнкыйтьчеләрдән саналган Фәрваз Миннуллин «Яңа өй» хикәясен укып, болай дип яза: «Язучы геройларның үзара мөнәсәбәтләрен, эчке кичерешләрен бик оста сурәтли, ул мәхәббәтнең һичкем башына килмәгән якларын ача, кеше күңеленең, кеше җанының әллә кайдагы тирән упкыннарына барып җитә»[1].

Әдәбият галиме Фоат Галимуллин әдипнең күп әсәрләрен күздән кичереп, тикшереп чыга, аларның укучыны мавыктыру серләрен ачарга тели, һәм моның әлеге әсәрләргә бик мулдан салынган тойгы-фикерләр—бигрәк тә кешеләрне ярату, аларга карата игелеклелек, мәрхәмәт хисләре, кешелекле мөнәсәбәтләрдән башка була алмавын дәлилле исбат итә. Шулай итеп ул М. Хәбибуллин иҗатының үзәген һәм алга таба үсеш юнәлешен һәм киләчәген бик дөрес билгели[2].

Моның шулай икәнлеген 1976—1986 еллар аралыгында Казанда ике тапкыр татар

[1] Миңнуллин Ф. Хикәя һәм хикәячеләр // Балта явызлар кулында. — К., Таткитнәшр. 1994., 60-61 битләр.

[2] Галимуллин Ф. Игелеклелек // Офыкларны алдан күреп. — К., Таткитнәшр., 1995. 130-146 б.

телендә, Мәскәүдә өч тапкыр рус телендә китап булып басылып, дөнья күргән «Чоңгыллар» /»Водовороты»/ романы раслый. Әдәби җәмәгатьчелек, тәнкыйть әсәрне югары бәяләде.

Роман чыгуга Хәсән Сарьян аны күп язмышлы, җитди проблемалы әсәр, дип бигрәк тә баш герой, колхоз җитәкчесе Талип Бикмуллин образы уңышлы эшләнгән, дип билгеләп үтте. Роман безне дә Талиянның уй-хыяллары, реаль эшләренә җәлеп итеп алып кереп китә—ә бу эшләр, бүгенге көндә дә гаять актуаль булган проблема—авылны яңача яшәтә башлау—аның тормышын индустриаль рельсларга күчерү мәсьәләләре белән дә бәйләнгән иде. «Роман әдәби яктан да нык кул белән эшләнгән, һәм ул авторның әсәрдән әсәргә осталыгы үсә барганлыкны раслый. Хәбибуллинның әдәби теле нык. Бер кемдә очрамаган өр-яңа тәгъбирләре, чагыштырулары бар. Мин бу романны һич булмаган житезлек белән укып чыктым. Чөнки андагы кешеләр язмышы күңелләргә үтеп керә—«тагы ни була, тагы ни була?» дип мавыктырып ияртеп алып китәләр.[1]

Үз вакытында тәҗрибәле каләмдәшенен хәер-фатихасын алган М. Хәбибуллинга шушы үз күңеленә якын һәм иҗади яктан өметле күренгән темаларны ачасы да ачасы гына иде бит!? Әмма ни гаҗәп! Нәкъ шушы үзенә зур уңыш һәм абруй алып килгән «Чоңгыллар» романы бүгенгәчә аның заман темасына язылган соңгы әсәре булып кала бирә. Әдип бу темадан бөтенләй читләшә—әлеге темага язудан туктый. Нәрсә булды икән соң?

Аның иҗатында зур борылыш ясала—ул алдагы иҗатын тулысынча тарихи романнар язуга багышлый. Әдип үзе моны болай аңлата:

«Мине Таҗикстанга—дөнья читенә язмыш үзе алып килгән булып чыкты. Мин мәктәптә тарих фәне укыта башладым. Ә дәреслекләрдә татарларга карата үтә ачы каһәр укыла. Еш кына дәрестә үк, мине бимазалы уй баса иде. Безнең татар бабаларыбыз шул чиккә җитеп явыз булганнар микәнни?.. Үзем сөйлим, үзем үз бабаларыбыз турында уйлыйм. Нигә безнең бабаларыбызны Русия тарихчылары шул дәрәҗәгә җитеп яманлыйлар. Мин еш кына бабаларым өчен ояла идем, ул вакытта Русия тарихчылары язмаларына ышана идем әле. Ничек алар язган, шулай булгандыр кебек иде»[2].

Шул вакытта ул тормышында һәм иҗатында зур рухи борылыш ясаткан затларны—татар халкының чын тарихын яхшы белүчеләрне—Оренбург имамы Мөхәммәтҗан аксакалны, Габдрахман Таһирҗановны һәм олы галим-тюрколог Лев Николаевич Гумилевны очрата, аларның дәресләрен, лекцияләрен тыңлый, ихластан әйтелгән киңәшләрен ишетә, алар ярдәмендә кыйммәтле тарихи чыганаклар белән таныша. «Болар минем бабаларым тарихы белән кызыксынуыма яңа ялкын өстәп җибәрделәр,—ди әдип.—Мин монысын да янә язмышыма юрадым. Соңрак, инде тәгаен тарихи әсәрләр язарга керешкәч, бу олы галимнәрне миңа Аллаһ Үзе җибәргәндер дигән фикергә килдем» (кульязмада).

Шул көннән алып әлеге ялкын сүнми-сүрелми—әдип иҗатын яктыртып тора. Л. Н. Гумилевның «әдәби әсәрләр аркылы чын тарих мәгълүматларын үз халкыгызга тизрәк җиткерә алырсыз» дигән сүзләренә колак салып, М. Хәбибуллин ныклап, дөнья галимнәре туплаган төрле чыганаклар буенча тарихны өйрәнергә, эшкәртергә, тәртипкә салырга керешә. Бу эзләнүләрнең беренче нәтиҗәле җимеше буларак 1985 елда «Кубрат хан» романы туа.

Алтынчы гасыр азакларында болгар ханы Кубрат, Таман ярымутравы, Азов диңгезе буйларын һәм Тын елгасының түбән якларын биләп, «Бөек Болгар» дәүләтен төзи. Бу урында без сүзне тарихны яхшы белүче Әбрар Кәримуллинга бирик:

«Кубрат хан турында Мөсәгыйт архивлардан һәм төрле борынгы чыганаклардан бик күп мәгълүматлар җыя. Һәм, ниһаять, үзе хыялланган «Кубрат хан» романын язарга керешә. Әнә шунда аның күз алдында борынгы бабаларыбызның төс-йөзләре генә түгел, шөгыльләре, кием-салымнары, холык-фигыльләре, ни ашап, ни эчеп яшәүләре, ни белән көсеп итеп, тереклек итүләре җанлана башлый. Әмма әле ул Кубрат ханнан еракларак китәргә кыймый, гәрчә төрки-татар бабаларыбызның бик борынгылары—һуннар, кыпчак-болгарлар хакында белсә дә. Чөнки Кубрат

---

[1] Хәсән Сарьян. Уеңны уйдырып сал...: Тел, Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1977 ел. 18 бит.

[2] Хәбибуллин М. Әдәбиятка юл салганда (үткәннәрдәге мизгелләр). Кульязма.

хан турында, төрки-татар бабаларыбыз хакында мәгълүматлар аз була. Мәгәр өйрәнә башлагач, моңа да ачкыч табыла. Мина калса, татарлар турындагы мәгълүматлар буенча беренче урында, һичшиксез, Кытай чыганаклары тора. Икенче урында—фарсылар, өченче урында әрмән һәм Рим-Византия тарихчылары, дүртенче урында—гарәпләр, бишенче урында—урыслар, алтынчы урын биреләдер татар галимнәренә. Әнә шуларның барысын да сөреп чыгып, чагыштыра-фаразлый алганда гына татар халкы турында хакыйкый тарихны язып булыр кебек мина. Мөсәгыйт Хәбибуллин исә моңа әдәби образлар аша ирешеп ята»[1].

Эзләнә торгач, М. Хәбибуллин бик кызыклы нәтиҗәләргә килә: татар халкы бик борынгы халык икән һәм аның тарихи язмышы башка күп кенә халыклар тормышы белән аралашкан, тыгыз бәйләнештә булган—шулай булгач, ул халыкларның борынгы тарихларын да белергә кирәк икән. Әмма боларны үзең генә белү җитми—укучыларга җиткерә белергә дә кирәк. Моңа тарих дәресләкләре аша гына ирешеп булмаячак. Кызыксынучылар аудиториясен киңәйтим, чын тарихны күп санлы укучылар массаларына җиткерим дисәң, шул темаларны инләгән матур әдәбият әсәрләре иҗат итәргә кирәк. Ә әдип моны эшли ала—һәм М. Хәбибуллин тарихи романнар язарга керешә—ул гына да түгел—алга таба үзенең иҗат кыйбласы тик шушы юнәлештә генә икәнлегенә инана.

1981-84 елларда иҗат ителгән «Кубрат хан» романының үзәгендә моннан 14 гасырлар элек хәзерге Төньяк Кавказның Таман ярымутравында күп санлы ыругларны берләштергән Бөек Болгар дәүләтенең барлыкка килеп, яшәп ятуы анда христиан һәм ислам диннәренең көчәюе, мәҗүси йолаларның алар тарафыннан йотыла баруы һәм, ниһаять, дәүләтнең таркалуы, андагы шәхесләр һәм ыруглар фаҗигасе сурәтләнә. Кубрат хан белән Төптәнре Ирсан арасындагы көрәшне әсәрнең төп тамыр сызыгы дип санап була. Алардан башка укучының күз алдыннан бик күп җанлы образлар—Кубратның якыннары, балалары, аның даирәсенә кагылышлы күп санлы персонажлар үтә. Хатыны Аппак, кызлары Чәчкә, Илбарис баһадир, Балкар илхан, Аспарух илхан, Аслан илхан, шулай ук Византия илчеләре, философлары һ. б. бик күпләр әсәрнең шактый чуар һәм кызыклы образлар җыелмасын тәшкил итә.

Тарих сәхифәләрен эзлекле актара торгач, М. Хәбибуллин һәр татар кешесе өчен истәлекле һәм кадерле чорга—12-13 гасырның тарихи вакыйгаларына—Урта Идел-Чулман буйларында Болгар дәүләте яшәгән чорга килеп чыга. Аның төзелүе, ныклап аякка басуы, чәчәк атуы турындагы «Илчегә үлем юк» (1990), шул дәүләт белән идарә итүчеләрнең берсе—Илһам ханның баскынчы дошманнарга каршы көрәше үзәккә куелган «Хан оныгы Хансөяр» (1997) һәм «Аллаһы бүләге» (1999) романнарын иҗат итә.

Ул гына да түгел, әдипнең игътибарлы карашы чиксез тарих дәрьяларының бик зур киңлекләрен инләп ала. Ул үзенең игътибарын бер-берсеннән байтак, нык аерылып торган ике дәвергә юнәлтә һәм бердәй тырышлык белән ике өлкәне: бик ерак тарихны һәм яралары, җәрәхәтләре күңелләребездә әле дә төзәлеп җитмәгән чорны—моннан әле биш йөз еллар элек кенә яшәгән Казан ханлыгы чорын—күрсәтергә теләп, каләмен тибрәтә.

Бик ерак тарих дигәне «Атилла», (2001), «Батый хан һәм Ләйлә» (2002), «Айбиби» (2004) исемле тарихи романнарда чагыла. Миңа калса, бу китаплар арасында хәзерге укучыга аеруча уңышлы рәвештә тәкъдим ителгәне дип, шәхсән, әнә шул соңгысын—»Айбиби»не әйтер идем. М. Хәбибуллин романнары арасында озынраклары, хәтта кирәгеннән артык озынга сузылганнары да очраштыра. «Акбиби» исә геройларның образлылыгы, хисләренең эмоциональ сурәтләнеше, диалогларның оста бирелеше өстенә, үзенә бер төрле җыйнак пөхтәлек белән аерылып тора. Автор китапны зур тарихи белешмә белән ачып җибәрә һәм хазарлар, Хазар дәүләте һәм аның без—татарларга бәйләнеше-мөнәсәбәте турында дөнья галимнәренең тарихи чыганаклары буенча татар һәм рус телендә язылган белешмә белән тәмамлый. Шәхсән, минем үземне әнә шул тарихи мәгълүматлар әлеге әсәрнең эстетик эшләнеше белән бер үк дәрәҗәдә җәлеп итте.

Казан ханлыгы чорына багышлап, М. Хәбибуллин «Шайтан каласы» (1993), «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» (1996) романнарын язды. Авторның күп

[1] Кәримуллин Ә. Татар тарихына килгән әдип: китапка сүз ахыры // Хәбибуллин М. Хан оныгы хансөяр. Тарихи роман.—Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1997. 248 бит.



*Бер төркем язучыларыбыз «Казан утлары» редакциясе хезмәткәрләре белән. Сулдан уңга (алгы рәттә): Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рафаэль Мостафин, Миркасыйм Госманов, Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин; икенче рәттә: Харрас Әюп, Зөлфәт, Ркаил Зәйдулла, Зиннур Мансуров, Нур Әхмәдиев, Флүс Латыйфи, Мөдәррис Вәлиев, Әхәт Мушинский, Тәлгать Бариев, Газинур Морат. 2003 ел.*

әсәрләре берничә тапкыр һәм татар, һәм рус телләрендә басылып чыгу фактларын да искә алсак, юбилярыбызның нинди олы, кирәкле, игелекле эшләр башкаруын күреп, тан каласын.

М. Хәбибуллин әсәрләрдә сызган эзләрдән йөреп, укучы үзенең хыялында яисә фаразларында гына булган күренеш-картиналарны янарта ала. Автор иҗат иткән романнар эзлекле бер бөтен, хәтта ниндидер бер система хасыйл итәләр. Әлбәттә, аларны кабул итү өчен укучының үзеннән дә ниндидер, омтылыш, кызыксыну сорала—татар җанлы, ата-бабаларын һәм аларның ерак буыннары белән кызыксынучы татар баласы өчен бу бигрәк тә кирәк—автор үзе дә иң беренче чиратта нәкъ әнә шундыйларны күз уңында тотып, иҗат итә булса кирәк. Һәм укучының үзеннән, аз-азлап кына булса да, тарихның, чын барышын ачыкларга теләү, аның хакыйкати чыганакларына таянып, шуларның тәгаенлегенә ихтирамлы ышанычы булдыру бу әсәрләрнең дөньяны танып белүдә һәм кешеләрне тәрбияләүдә әһәмияте тагын да үскәнлеген аңларга кирәк була торгандыр.

Әдип зур осталык белән аерым бер чор яисә вакытның фаразлай кабул ителерлек ноктаtotal кагыла, кызыклы әдәби сюжетлар тудыра, алар шул заманның җанлы образларына, сурәтләренә әвереләләр һәм безне—бөтен рухыбызны, батырлыгыбызны, җаныбызны—шунда алып китәләр. Вакытлыча гына булса да, үзебез дә шул чор, шул заманнарның җанлы шаһитларына, замандашларына әвереләбез. Шул ук вакытта, әсәрләрдәге тормыш күренешләрен тик иҗатчы тарафыннан җанландырылган фараз яисә шартлы вариация рәвешендә кабул итәргә кирәклеге хакында да онытмыйбыз.

Авторның үз алдына укучыларны кызыксындыру, мавыктыру, билгеле бер тарихи чорның геройларына, шәхесләренә, хәлләре-вакыйгаларына, фактларына игътибарыбызны юнәлдерү бурычын гына куйган булуы да мөмкин—әгәр дә шулай икән, монысы да кечкенә әйбер түгел. Ерактагы калын-калын катламнар астында күмелеп калган, чуар һәм буталчык тарих сәхифәләрен, нәкъ булганынча төп-төгәл һәм тулы дәреслегендә ачып бирүгә әдәбиятчылар дәгъва итә алмыйлар һәм ана омтылмыйлар да. Бу эш, башлыча, тарих фәне белән махсус шөгыльләнүчеләргә—профессионалларның үзләренә кала. Ә язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм аның кебек башка берничә «саф әдәбиятчыларыбыз» исә әнә шундый галел тарихчыларның күзәтүләренә, ачышларына колак салырга

тырышалар һәм, дөреслек юлыннан барып, матур нәтиҗәләргә ирешәләр.

Әлеге мәкаләбез юбилей рухында язылса да, күңелне борчып торучы кайбер мәсьәләләргә дә тукталып үтәргә кирәк дип саныйбыз. Мәгълүм ки, тарихи жирлектә әдәби әсәрләр язарлык әдипләр бездә бармак белән генә санарлык: прозада юбилярыбыздан кала тагын Вахит Имамов, Рабит Батулла, Ркаил Зәйдулла һәм тагын бер-ике исемне телгә алуга бу рәт тәмамланып та куя. Алар зур һәм игелекле эш башкаралар. Әмма аларның язганнары күп очракта тиешле, әтрафлы бәя ала алмый. (Мәрхүм Нурихан Фәттахның ике романын искә алмасак...)—укучыга аларны аңлатучы, күрсәтүче, пропагандалаучылар юк. Чөнки тәнкыйтьчеләребез тарих проблемаларын, ә тарихчы галимнәребез әдәбият серләрен, нечкәлекләрен белеп җиткермиләр ахрысы. Шуңа күрә, бу типтагы әсәрләргә ике ярнын кайсы ягыннан сузылсаң да, алар колач җитмәс урында—бушлыкта, «вакуум» да калалар. Аның караvы, аерым әсәрләргә, хәтта язучыларга мөнәсәбәттә берьяклы карашлар—бик зур булмаган кимчелекләрне табып, алардан тискәре нәтиҗәләр ясап, каты гына бәрелергә тырышу очраклары күренгәләде.

Тарихи гаделлекне торгызу юлын сайлаган хөрмәтле әдипләребезнең иҗатларын һәрьяклап һәм җентекләп өйрәнү һәм укучыларга аңлатып бирү әдәбият фәне әһелләренең әлегә үтәлмәгән бурычы булып кала бирә. Мондый әдәбиятның иң алдынгы сафында торучы Мөсәгыйт Хәбибуллин иҗаты да әтрафлы өйрәнүчеләрне, тикшеренүчеләрне көтә.

М. Хәбибуллин—киң карашлы сәясәтче, үткен телле публицист та. Мәкаләбездә без аның бу өлкәдәге эшчәнлегенә бөтенләй кагыла алмадык. Анысы да махсус тикшерүгә бик лаек.

Язмабызның ахырында без гомер көзләрен дә матур язларга әвереләдереп яши белүче олы шәхесне—Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесен, Россия язучылар берлеге бүләге, Татарстанның Кол Гали һәм Габдулла Тукай исемендәге бүләкләр иясен—Мөсәгыйт ага Хәбибуллинны олы юбилей датасы белән котлыйбыз. Ул озын-озак еллар дәвамында алга таба да сау-сәламәт булып, иҗади уңышлары белән безне гел сөендереп яшәр дип ышанып калабыз.

---

*Алхәбәр. «Казан утлары»—2008.*

Адлер Тимергалин

## АЛЛА

ФӘЛСӘФИ УЙЛАНУЛАР

Табигать фәннәре буенча галимнәр, теге яки бу фәнне тирәнрәк белгән саен, динне, иманны кире кага торган дәлилләрне күбрәк таба дип уйлаучылар байтак. Чынлыкта исә фән үзеннән-үзе галимне беркайчан да Алласызлыкка алып бармый. Чын галим,—биологмы, физикмы яки математикмы ул,—әйләнә-тирә дөньяның чиксезлегенә, дөньядагы тәртипнең искиткеч оешканлыгына, максатчанлыгына, анда мәгънәсез бер генә нәрсәнең дә булмавына торган саен ныграк ышана. Бу тәртипнең очраклы рәвештә генә урнаша алмавына кире каккысыз математик дәлил бар, аны ихтималлык теориясе бирә.

Галимнәрнең эзлекле, мантыйкый фикер сөреше ахыр чиктә аларның бөтенесен колачлый торган көчкә—Аллага ышануга китерә.

Герман галиме Динард, дөньякүләм танылган галимнәрнең бер төркеменнән фикерләрен сорашып, мондый нәтиҗәләргә килә: галимнәрнең 20се нинди дә булса дини карашны якламаган, 242 галим Аллага ышана башлаган, фәкать 20се генә дин белән кызыксынмауларын таныганнар. Шулай итеп, галим-голәмәнең 90 проценты—дингә ышанучылар һәм бик азы гына дәһри-атеист булган. Өстәвенә соңгылары дингә ышанмаучы хезмәттәшләренә карата берничнди дә ихтирамсызлык күрсәтмәгәннәр...

Фәрит
Бәшир

# АЧЫДЫР ХАКЫЙКАТЬ ЮЛЫ...

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ 70 ЯШЕН КАРШЫЛАП

Татарстан китап нәшрияты соңгы елларда бик тә игелекле эш башкарып килә: күренекле әдипләребезнен—халкыбызның ихтирамын һәм мәхәббәтен яулаган, хаклы рәвештә әдәбиятыбыздагы мәртәбәле бүләкләргә ия булып, "халык язучысы (шагыйре)" исеменә лаек булган, милләтнең җан авазына әверелгән иҗат әһелләребезнен—сайланма иҗатын туплап укучыларыбызга ирештерә.



Шул мәртәбәле һәм абруйлы агымнан алдымдагы бер дулкынга сокланып карап торам. Бу—Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай, Муса Җәлил исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты Фәнис Яруллинның биш томлык "Сайланма әсәрләр"е. Үзем хөрмәт иткән әдипнең иҗатын бу рәвешле бөтен килеш күрү көнелдә көчле хисләр ташкыны тудыра. Рәхәт хисләр ул. Аларны сүз белән генә аңлатып бетерүе кыен.

Беренче томны кулыма алгач бераз аптырабрак калдым: "Повестьлар"... Туктале, ә нигә проза? Ф. Яруллин үз иҗатын "халык шагыйре" дәрәҗәсенә күтәргән поэзиядән башлаган иде бит! Ә бәлки хикәя-повестьлар аның иҗатында зур урын алганга, ә дөнья күргән китапларының байтагы проза әсәрләре булгангадыр? Болай аңлату үтә гади булыр иде. Бераздан аңладым бугай. Томны ачып җибәргән "Җилкәннәр җилдә сынала" повестенда авторның үз биографик мизгелләре дә мул сибелгән икән. Димәк, бу әсәр биштомлыктагы иҗат үрнәкләрен аңлауга, фикерләүгә ачкыч булып тора. Тукайның да бит татар халык шагыйре дәрәҗәсенә күтәрелүен аңлауга нәкъ менә "Исемдә калганнар" дигән кечкенә генә күләмле, әмма һәр сүзеннән җан кычкыруы ишетелгән чәчмә әсәре ярдәм итә. Димәк, биштомлыкның бисмилласы булып урнашкан "Җилкәннәр җилдә сынала" повесте һич тә очраклы түгел икән. Шушы повесть аша укучыга Ф. Яруллин иҗатына керү өчен җирлек әзерләнә, әдип күңеленең лабиринтларында адашмау өчен ут-маяк кабызыла.

Повесть гаять ашкынулы-ярсулы бер чорда—узган гасырның илтмешенче еллары башында мәйданга чыга. Гаять тә күтәренке, ыргымлы заман бу! Дөнья шаулый, тормыш кайный. Нефть! Гигант төзелешләр! Әле генә ерак чирәм җирләрне айкап кайткан герой очар кошлар янәшәсенә тартыла. Кайбер язучылар ашыга-ашыга актив, хәрәкәтчән, җир катламнарын актарып ыргытырлык, таулар күчерерлек бәдәнле әнә шундый каһарманны калыпларга керештe. Шул вакыт кәнфитләнгән, һәрчак елмаюлы портрет йөзләр арасына Ф. Яруллинның кителмәгән фаҗига аркасында дүрт дивар эчендә бикләнеп калган, тәненең һәр күзәнәгенә шыплап тулган газаплар күзләренә сеңгән Фәнияры килеп керде. Килеп тә керде—укучының үз якынына да әверелде. Лирик геройның мәрхәмәтсез авыру богаулап

алган язмышы укучы җанында әрнү катыш өметле, уйлы, гамьле кайтаваз тапты. Әсәрнең төп тәэсир көче нәрсәдә икән дип кат-кат уйланганым бар минем. Җавап таптым да кебек. Яшәү көченең асылында, яшәү мәгънәсендә. Язмыш сынауларында сыгылмауда. Вакыйгалар армиядә имгәнү алып урынга берегеп калган, шулай гомер уздырырга мәҗбүр булган Фәнияр образына туплана, повестьтагы башка образлар аның янында хәрәкәт итәләр, кичерәләр, зураялар, әсәр дәвамында теге яки бу сыйфатлары белән ачыла баралар. Әнә шулай һәркем сынау уза. Язмыш—сынау ала. Аның имтихан сораулары шактый катлаулы мәсьәләләргә җавап эзләргә боера: яшьлек һәм гомерлек фаҗига, тугрылык һәм хыянәт, тән көчсезлеге һәм рух көче, өметсезлек һәм тормышка иксез-чиксез мәхәббәт. Бу сорауларны читләтеп үтеп булмый. Әнә шулай әсәрдәге Фәүрия дә, Илсөя дә, Фәнияр үзе дә әлеге сораулар ташкынында һәрдаим ачыла баралар.

Биредә бер нәрсәгә тукталу зарур. Еш ишеткәнем бар: повесть авторын мәгълүм әдип Николай Островскийның рухи туганы дип атыйлар. Бу—дөрес тә, түгел дә. Дөресе—язмышлар охшашлыгы һәм автор белән үзәк каһарман арасында шактый гына бергәлек булу—автобиографик моментлар уртаклыгы. Дөрес түгеле—заман башка, ситуация башка, фаҗиганең асылы һәм аның белән тартышу максаты башка. Н. Островскийның Корчагины—революция ташкынында кайнап, гражданнар сугышы ялкынында көеп, кыйналып, яньчелеп, авырдан да авыр имгәнүгә тарыган зат. Аның бөтен гомере халык бәхете өчен көрәштә узган. Димәк, бар газаплары да—халык бәхете өчен. Менә бу ышаныч ана үз язмышы белән тартышырга көч бирә. Шушы хис-кичереш аны кулына каләм алырга этәрә. Чөнки көрәш дәвам итә, ә аның хәзер бердәнбер коралы—каләм. Ә альтруистик хис—үз гомерен бәрабәренә башкаларны бәхетле итәргә тырышу—аның яшәү мәгънәсенә әверелә.

Ф. Яруллин, димәк ки аның герое Фәнияр да мондый фикергә таяна алмыйлар. Биредәге шәхес фаҗигасе—очраклы бер бәла нәтиҗәсе. Димәк, анарга яшәргә көч алу өчен башка төрле таянычлар кирәк. Иң әүвәл, әлбәттә яшьлек. Яшьлек—романтик хыялый дөнья. Ул бөтен кыенлыкларны, килеп туган мәшәкатьләрне тиз арада җиңәчәгенә ышана. Аның өчен бөтен авырлыклар—тик вакытлы гына. Татар әдәбиятына таныш бу хәл. Егерме бер яшендә паралич сугып, гомергә хәрәкәтсез калырга хөкем ителгән Фатих Әмирхан башта һич тә үз хәле белән килешергә теләми. Якыннарына күндергән хатларында ул "тизлектә таякта өстерәлә башлармын...", дип хәбәр итә. Ике елга якын өметен сүндерми: чираттагы хатында "бер дүрт-биш көннән фактически йөри башлавымны көтәм", дип, дусларыннан битәр үзен ышандырырга тырыша. Ә хакыйкать исә ачы... Димәк, әүвәлдә терәк булган яшьлекнең килешмәүчән бунтарьлыгы инде үз хәленне дөрес аңлауда киртә була башлый. Әнә шул татлы, ымсындыргыч халәтне кырыс чынбарлыкка алыштыра алу—үз-үзенне җиңү ул. Фәнияр өчен бу иң мөһим көрәшләрнең берседер. Язмышыңны таныган хәлдә яшәү көчен, яшәү ямен югалтмау—рухи батырлык ул.

Ф. Яруллинның "Кыйгак, кыйгак каз кычкыра" повестенда тормышта еш очрый торган үтә нечкә, үтә катлаулы бер проблема—ялгызлык күренеше бәян ителә. Заманыбызның гаять авыр бәлаләреннән берсе бу. Ялгызлык төрлечә була. Дәрья уртасында, карурманда, киң далада ялгыз калырга мөмкин. Әмма бу—физик ялгызлык. Әсәрдә сүз рухи ялгызлыктан туган сыңар канатлылык турында бара. Рухи ялгызлык... Иң хәтәр, иң авыр ялгызлыктыр ул. Аны хәтта ялгызлыкның эзе дә күренергә тиеш булмаган "бердәм совет халкы", "күмәк хуҗалыклар" дигән дәүләт системасы да бетерә алмады. Киресенчә, шушы системада мөстәкыйль уйлаучыларны ээзәрлекләү ул ялгызлыкны көчәйтте генә. Бу җәһәттән фикер йөрткәндә повестьтагы "ялгызлык" төшенчәсенең иҗтимагый-социаль тамырлары ачылуын күрәсен.

Әсәрнең үзәгендә—дуадак каздай ялгыз хатын Сәхия... Чынбарлыкның ачы вәзгыяте аны шулай итеп чарлаган ки, ул хатын-кызларга хас нәфис сыйфатлардан баш тартып, "ирдәүкәҗан" дигән исем алуны кулай күргән. Бу—аның тормыштагы гаделсезлекләргә үзенчә протесты. Шушы хәлләргә китереп җиткергән җәмгыять ахыр чиктә аның үзен каһәрле—ялгыз картлык, авылдашлары каршында дуадак каз...

Шулай да автор әсәрне тәмамән өметсезлек белән тәмамламый. Ф Яруллинның тасвир алымы шундый: ул дөньяның ин карангы почмагында да якты төсләр күрә, ин пычрак җирләрендә дә сафлык, чисталык барлыгын тоя. Ялгызлык богавыннан бушануның төп юлы тормышта терәк табуда ди ул: "Кешегә гел таяныч кирәк. Кеше җылылыкка һәрвакыт мохтаж". Сәхия үзенә насыйп булмаган әнә шул җылылыкны апасының балалар йортындагы улына бирергә карар кыла. Шул рәвешле ул гомер көзендә булса да яшәү мәгънәсен таба. Кеше язмышы өчен борчылу, кемгәдер кирәклегенне анлау ана хатын-кыз сыйфатында, ана сыйфатында асылына кайтуга этәргеч була.

Кайту... Ф. Яруллин әсәрләрендә зур мәгънәгә ия ул. Гомумән, әдип иҗатында символлар мөһим роль уйныйлар һәм төп фикерне укучыга җиткерүдә хәлиткеч чара буларак каралалар: "җилкән", "җилләр", "ялгыз каз"... Һәм менә—"кайту". Бу төшенчә әдипнең чираттагы повестена исем буларак алынган.

Повесть татар әдәбиятында әлегә кадәр кагылмаган теманы—бөтен дөньяга көч һәм куәт иясе булып танылган Совет Армиясенең эчтән таркалу процессын яктырта. Советлар Союзы дигән биниһая зур мәмләкәтнең санаулы вакыт эчендә уптым илаһи ишелеп төшүенә гаҗәпләнергә дә кирәкмидер. Сәбәп зур, сәбәп тирәндә: империянең арка терәге—дәһшәтле кораллы көчләре—эчтән көпшәкләнгән, мыртайган, черегән булган икән. Мондый очракта ишелү—котылгысыз хәл. Әмма җимерекләр арасында—кешеләр язмышы. Кемдер ырып-җырып өскә күтәрелә, кемдер изелеп, тапталып кала, кемдер исә, яньчелеп, гарипләнеп чыга.

"Кайту" повестеның төп каһарманы полковник Фәрит Шәйхиев—бөтен гомерен хәрби хезмәткә багышлаган офицер, социализм идеяләренә баш-аягы белән бирелгән типик совет кешесе. Рәсми идеология ничә дистә еллар буе тырышып-тырышып калыплаган милли хисләрдән азат космополит бер фигура. Улын да "интернациональ шәхес" итеп үстерүне максаты дип куйган: "Балага рус исеме кушабыз, рус сүзләре белән теле ачылсын. Русча уйласын. Татарлыгын онытсын. Ул үзенең баласына тагын рус исеме кушар. Шуннан аның татарлыгы өч буыннан онытылыр". Ә менә улы Олегның хәрби бурыч үтәгәндә түгел, ә генералларга өй җиһазы ташыганда һәлак булуы (дәресрәге, күпне күргәнгә, белгәнгә үтерелүе) ата кешене сискәндереп, уятып җибәрә. Мәрткә киткән сымак озакка сузылган йокысыннан айну полковникның монарчы ышанган, табынган хыял-идеалларын чәлпәрәмә китерә. Фаҗигагә сәбәп булган хәрбиләрне дә фаш итә алмый ул—чөнки җинаятьчел сәясәт үзенең иярченнәрен саклый да, яшерә дә белә. Ни эшли ала соң чарасыз ата ике башлы ерткыч каракош каршында? "Соң булса да уң булсын, инде менә бабаларың янына алып кайтам. Чит-ят туфракларда сөякләрең рәнҗеп ятмасын. Үзебезнең йолаларыбыз белән догалар укып, чын мөселманча итеп җирләячәкбез сине. Кешеләр исән чакта гына түгел, үлгәч тә үзенең нәсел-нәсәбенә якын булырга тиешләр. Шунда гына аларның җаннары тынычлык табачак". Улының җансыз җәсәден алып туган җиренә дип юлга кузгалган ата бәгырендә әрнү, әрнү... Авыр, газаплы уйлар белән чорналган кайту юлы бу. Хакыйкать ачылган юл ул. Озак-озын еллардан соң асылына кайту—тагын да авыррак. "Чөнки мин моны сине югалту бәрабәренә таптым". Ә кайтырга кирәк! Киләчәктә кабат адашмас өчен үткәннәргә кайту зарур. "Бүген мин таяныр ноктаны таптым шикелле—ул атамнар нигезе икән. Мин шуна ышандым: туган якларымда гына мин кабат тернәкләнә алачакмын".

Ачыдыр хакыйкать юлы...

Беренче томга кергән бик тә үзенчәлекле повесть "Яралы язмышлар" әсәре кешелекнең гөнаһсыз чәчәкләре булып яралып та ертлач җәмгыятьнең артык кисәкләренә әверелгән ятим балалар хакында. Реаль нигезгә корылган вакыйгалар бер ятимнәр йорты кысасында гына барса да, биредә заманыбызның күп, үтә кискен проблемалары күтәрелә. Сугыш чоры түгел ләбаса! Ә тыныч тормышта, башка илләргә тыныч яшәү фәлсәфәсен өйрәткән олуг мәмләкәттә ятимлек үткен мәсьәләләрнең мәсьәләсенә әверелгән! Әсәр нигездә контрастлыкка корылган. Бер якта—шыксыз чынбарлык, җан өшеткеч ятимлек, әхлаксыз бәндәләрнең чиркангыч гамәлләре, икенче якта—сабыйлар язмышын үз җаннары аша уздырырга сәләтле мәрхәмәтле затлар, игелекле ниятләр, шәфкатьлелек, миһербанлылык... Шушы

каршылыкларның үзәгендә—"бик күп үксезләрнең ачы яшен сөртүче һәм аларның кайгыртучан әбиләре булып киткән" Минсылу. Үзе дә тормышның ачысын-төчесен күп татыган, ятимлекнең ни икәнен үз язмышында кичергән, сабый вакыттан ук явыз бәндәләрдән каһәрләүләрне күп күргән Минсылу җай гына эшләп йөргән жиреннән кубып, ятим балалар мохитенә килеп эләгә. Бу гамәленә ул инде бөтен гомере буе килә, ачы язмышы, мәнге төзәлмәс яралы җаны аша килә. Хикәяләү аның исеменнән алып барыла һәм көндәлек формасында тәкъдим ителә. Бу олуг зат сөйләм-гамәлләренә кешелек җәмгыятенең асыл нигезен саклап торучы сыйфатларның барысы да сыйган: гореф-гадәтләр, гасырлар буе чарланган халык педагогикасы, әхлаклылык, шәфкатьлелек...

Минсылу, беренче чиратта, балалар үзләрен гаиләдә итеп тойсыннар өчен тырыша. Таянырга әтиләре, назланырга әниләре булмаса, бала кимсенеп, китек күнелле үсә. Ә җәрәхәтле йөрәк белән тулы канлы гражданин булып житешү мөмкин түгелдер ул. Миңсылу шуның өчен дә бөтен барлыгы белән сабый тормышындагы әнә шул бушлыкны тутырырга тырыша. "Яшьтә язган—ташка язган", ди халык—Миңсылу әнә шуны бик яхшы аңлый. Шат күңелле, яшәү тәмен белүче булып үсәме бала; бәгыре каткан, бөтен дөньяга үчле бәндә булып формалашамы—барысы да яшьтә ничек язудан башлана. Балаларны башка жирләргә тараткан вакытта аның әйткән сүзләре дә түбәндәгедән гыйбарәт: "Безнең иркәназларыбыз иң кыен чакларыгызда күңелегезне җылытсын, җаныгызны яктыртсын иде. Таянырга—иң, бушанырга теләгәндә—тыңлаучы, егылганда торгызышырга кул кирәк булганда без барын онытмагыз. Үчкә—үч, яманлыкка—яманлык белән кайтармагыз. Сезнең җиргә тамган яшьләрегез шәфкать гөлләре булып үсеп чыксын да жирдәге ятимлек чылбырын мәңгегә өзсен".

Минсылу образында Ф. Яруллин татар әдәбиятына бөтенләй үзгә, өр-яңа герой алып килде. "Казан утлары" журналында ике ел дәвамында "Безнең заман герое" дигән темага дискуссия уздырылды. Кемнәр генә аталмады анда! Кол Шәриф, Сөембикәләрдән алып, Батыршаларны кертеп, Жәлил, Матросовларны узып Шәймиев, Мөхәммәтшиннарга кадәр килеп җителде. Шул ук вакытта янәшәбездә генә йөргән, әмма күзгә бәрелеп тормаган менә дигән каһарманнарыбыз бар икән бит! Алар игътибарга дәгъва кылмыйлар, үзләрен күрсәтеп йөрүдән бик ерак һәм өстен торалар, алар эшлиләр генә. Яхшы гамәлләр башкарам, изге эшләр эшлим дип фәлсәфәгә дә бирелмиләр. Бу—алар өчен намус, вөждан эше. "Яралы язмышлар"дагы Миңсылуның прототибы Миңлегөл Рафикова (повестьның икенче кисәгендә ул үз исеме белән кертелә), реаль шәхес—шулай ук бөтен гомерен үксез сабыйлар бәхетенә багышлаган Әсгать Галимжанов (нәкъ менә әсәр башында аның исеме аталып ителә) әнә шундый изге җанлы бөек шәхесләр затыннан. Тирәбездә яхшы кешеләр күп безнең, тик аларны күрер өчен Фәнис абый күзләре, әдәби образга әверелдереп, укучыга күрсәтә алу өчен Фәнис абый каләме кирәк.

"Яралы язмышлар" әсәре—беренче томга кергән ахыргы повесть. Гомумән, бу жанр формасы Ф. Яруллин иҗатында төп тармакларның берсе буларак характерлана. Шуңа да "Сайланма әсәрләр"дә әдипнең янә өч повесте урын алган: "Бүләк", "Портрет", "Мәхәббәт упкыны". Бу әсәрләр күпмедер дәрәҗәдә үзара охшаш эчтәлеккә ия һәм, бу җәһәттән, алар бер-берсен тулыландырып киләләр. Сюжет артык катлаулы түгел, мавыктырып үзенә ымсындыручы олы вакыйгалар да юк бирелә. Гап-гади тормыш-көнкүреш хәлләре, без көн саен диярлек күреп, очратып йөри торган геройлар—кыскасы, бу повестьларда безнең бүгенгебез сурәтләнә. Ф. Яруллинның әдип буларак осталыгы шунда—ул әнә шул безнең күз алдыбыздан бер төсле генә агып барган бүгенгебезнең вакыт пәрдәсен күтәреп, заман проблемасын, үзебез дә сизми-тоймый уралыплар беткән тормыш сорауларын бөтен барлыгына һәм куәтенә алдыбызда ачып салуда. Искитәрлек хәл: баксаң, без гади вакыт агышы итеп кабул иткән бүгенгебезнең тирән, эчке агымы бар икән ләбаса! Урыны белән ярсулы да, тыныч та, урыны белән болганчык та, чиста да икән ул. Ә ул катламга үтеп керүнең юлы бер—ул Ф. Яруллин иҗатының буеннан-буена сузылып баручы әхлак кануннары. Бүген җәмгыять тә, һәрбер җәмгыять әгъзасы да әхлакый сынау узалар. Сынау барышында кеше психологиясе, гуманлылык, вөждан психологиясе, җан диалектикасы, күңел хәрәкәте кебек

төшенчәләр гаять тирән һәм киң мәгънәгә ия булып, көнүзәк мәсьәләләргә әверелделәр, иманга кайту юлында төп юнәлеш итеп билгеләнделәр.

Әхлакый сынау—кемлегенә карамый, тормыш юлында каршына чыга да, маңгаена төбәп сорау ала икән. Һәркемнән! Һәр кылган гамәл өчен! Бигрәк тә ярамаганнары өчен, әхлакый кануннардан тайпылганнары өчен. Сыннарыңны сындырып җавап ала сынау. Монда инде шайтан коткысына бирелдем, башкаларның котыртуына аңсыздан иярдем дип кенә котылып булмый. "Гамәл вә җәза"—кырыс, катгый, ташламасыз канун.

"Буләк" повесте... Тыныч кына, авылның көндәлек мәшәкатьләре белән ипле генә гомер уздыручы гап-гади бер гаилә... Мәхәббәт турында артык сүз куертмый гына һәр туар таңны шөкеранә итеп каршылап яшәүче Ләйлә һәм Гарифулла... Менә тын күлне чайпалдырып килеп төшкән таш сыман, шәһәрдән Ләйләнең сеңлесе Зөһрә кунакка килеп чыга. Апалы-сеңелле, әмма болар үтә дә капма-каршы затлар. "Аттан ала да туа, кола да туа", дигәндәй, чиста күңелле Ләйлә янында азгын, оятсыз, әхлакый тыюларны чүпкә дә санамаган Зөһрәнең кыланмышлары тагын да чиркангычрак булып күренә. Нәтиҗә исә ачы: җимерелгән ике гаилә, "гөнаһтан туган гөнаһсыз җан"—сабый бала. "Кем гаепле?" дигән сорауга "Зөһрә" дип кенә җавап бирер идек тә бит кана, тик бу бик гади чишелеш булыр иде. Инде җитәрлек күрдек, Ф. Яруллин беркайчан да җиңел юлдан бармый, ул укучы дикъкатен мәсьәләнең башка, эчкәрерәк катламнарына юнәлтә. Зөһрә кыланмышлары, иң әүвәл, Гайфулланы тормыш сынаулары аша узарга мәҗбүр итә. Таза бәдәнле, аю гәүдәле Гайфулла буыны бик тә сыек бәндә булып чыга. Болай да аның тирәсендә чуалган хатын-кызларның үзенә игътибарыннан туарылып киткән ир (ә андый хатыннарның фәлсәфәсе үтә "заманча": "Кәкре дөньяда бер мин генә төз яши алмам!") Зөһрә белән гыйшык уйнавын да зур гөнаһка санамый. Әмма "гамәл вә җәза" кануны—кырыс хөкемдар, үзен саңга сукмаганнарга ул әле рәхимсез дә. Зөһрәдән туган сабые Гайфулланы четерекле сораулар алдына китереп бастыра: "Аһ, бала! Бәгырь җимеше!... Дөньяга тууыңда синең бит һичбер гаебең юк. Гаепле кешеләр сине ташлап кача башласа, кая барып, кемгә сыенырсың?"

Алда ни булыр?—бирелә әзер рецептлар бирелми. "Гайфулла яшертен кылынган гөнаһ ләззәте өчен тәмугка кереп китте"- повесть әнә шулай тәгәлләнә. Вакыйгалар эчендә кайнаучыларның алдагы язмышларын фараз кылуны әдип укучы ихтыярына калдыра.

Ф. Яруллин, шул рәвешле, геройларын гап-гади тормыш кысасына куеп, сынап карый. Чынлап та, гап-гади тормыш, ә дикъкать беләнрәк карасаң—адәм баласының кешелеге раслана яки инкарь ителә торган иң катлаулы мәсьәләләр, каршылыклар, мәнфәгатьләр бирелә!

"Портрет" повесте дә нәкъ менә шул җәһәттән бәян ителә. Игътибарлы укучыны монда да тормыш тудырган җитди мәсьәләләр каршылый. Үзәктә сердәш дуслар Илсөяр һәм Җәүһәр. Әмма алар никадәр якын ахирәтләр булсалар да, гаилә, тормыш, бәхет мәсьәләсенә капма-каршы фикердә торучы кешеләр. Җәүһәр—иң әүвәл саф хисләргә тугры кыз, ул мәхәббәте аша чын бәхеткә ия булырга омтыла—һәм моңа ирешә дә. Авторның бирелә позициясе ачык—Җәүһәр кебек чиста күңелле, керсез намуслы затлар гаиләдә дә, тормышта да һичшиксез бәхетле булырга тиешләр. Илсөяр исә яшәү максаты итеп, дәрәҗәле, бай егеткә кияүгә чыгуны саный. Шуның өчен җан тартыша. Ахыр чиктә аның янында бер слесарь торып кала. Ул шуңа кияүгә чыгып, шыксыз, мамыксыз бер бүлмәдә яши башлый. Ире аны никадәр генә булганына канәгать калып яшәргә үгетләсә дә, Илсөяр һич тә тынычланырга теләми. Җәүһәрнең иркендә, муллыкта, бәхетләргә уралып яшәве анда кара көнчелек тудыра, тора-бара бу хис үч тойгысына, аннан инде яман бер чиргә әверелә. Җәүһәрнең оста рәссам ясаган портреты каршына басып, төш белән өнне, хыял белән чынбарлыкны аермас халәттә бәхәс алып барулары аша Илсөяр бөтен эчке дөньясын, бик тирәнгә яшеренгән уй-фикерләрен ачып сала. Шушы алым белән Ф. Яруллин заман фәлсәфәсенең катлаулы катламнарына үтеп керә, психологик алым аша җәмгыятьнең караңгы почмакларын яктыртуга ирешә. Образларның һәрберсе артында безнең замандашларыбыз тора, аларның яшәү мәгънәсе хакындагы фикерләү үзенчәлекләре ачыла, тормыш драматизмын хасил итүче көчләрнең

холкы, табигате күрсәтелә.

"Мәхәббәт упкыны" повестенда да геройлар әхлакый сынау күперен узалар. Сират күпередәй кылдан нечкә, кылычтан үткен ул күпер. Һәркем үтәргә тиеш аннан. Әнә шулай өелешеп кереп китәләр дә, аргы якка азлар гына барып чыгалар. Заман үзгәргән саен аларның сафы тагын да сирәкләнә. Әсәр үзәгендә—яшьлеккә генә хас омтылыш, ыргымлы хисләр ташкыны, хыялый очышның акылдан өстен чагы. «Мәхәббәттә сыналу—шул ук әхлакый канун» дигән сүз—хөкемдарның тануы яки инкарь итүе инде ул. Нишләмәк кирәк, яшьлек—яшьлек инде ул, аның кысаларга гына сыеп торасы да килми: гореф-гадәтләрнең гасырлар буе чарланып, милләтне милләт итеп саклап калган кануни таләпләрнең аның ашкынулы-ярсулы җанын ирексезләү булып тоелганда чырай сыту кебек холык та хас аңа... Көтмәгәндә ишелеп төшкән сөю, ярату хисенең гомерлек бәхет булуына ышану яшьлектә шул кадәр көчле була ки, ул бер көнлек хыялый очышны мәңгелек аллы-гөлле дөнья итеп кабул итә. Әмма очар кошлар да, иртәме-соңмы, җиргә сыенган кебек, аңа да чынбарлыкка кайтырга туры килә. Бу—тормышның кырыс кануны. Кемнәрдер ул очыштан тагын да канатланып, саф хисләренең куәтле дулкынында тагын да биеккәрәк күтәрелергә ышаныч, яңа омтылышларга әйдәүче чиста җаны белән кайта, ә кемнәрдер хыял күгеннән өшәнеп, канатларын талдырып, кабат инде беркайчан да очыш дигән бөек җан күтәрелешен татымас хәлдә гомерлек газап, үкенеч белән ашкынулары көл булып сибелгән җиргә—чынбарлыкка чүгәләр. Хакыйкать юлы ачы... "Кызның исеме—кыл өстендә, кылдан төшсә—ил өстендә" дигән мәкаль янә бер кат раслана бу повестьта. Татар халкында туганнан алып, гүр иясе булуына кадәр кеше өчен каттый йола кануннары эшләнгән. Шуларны санга сукмыйча кызыкка кызыгып, үзләре дә сизми бозыклык баткагына тап булганнар гомерлек үкенеч, җан газабы белән яшәргә дучар ителәләр. Яшәү дип әйтеп булса инде аны... Моңа кадәр яшәгән нәселнең дәвамчысы икәнлеген, мохит, якын кешеләре, ахыр чиктә, үз намусы алдында җаваплылык хисен оныту төзәтеп булмаслык хаталарга да китерергә мөмкин. Үткәннәргә кайтып, хак яшәргә иде дә бит... "Ялгышны төзәтеп, язмышны үзгәртеп яшәсәң, яшьлек кире кайтыр кебек...", дип җырлыйлар да бит, әмма Тукай кисәтә: "Үткән эш кайтмый, үкен син, үл, җыла!"

Повестьта, бу җәһәттән, Әлфред исемле егетнең язмышы гыйбрәтле. Ул—замана баласы, җиңел көн итү, бер көнлек рәхәтлеккә хушлану аның тәмам яшәү рәвешенә әверелгән. Мәхәббәтне дә ул кием алыштыру сымак гап-гади һәм еш башкарылучы бер гадәт дип кенә саный. Заманча яшәү шушыдыр инде дигән инану аның җанына, канына каерып алалмаслык булып сеңгән. Шул вакытта аның юлына фәрештәдәй пакь, саф хисләре белән дөньяны балкытырдай самими җанлы Миләүшә очрый. Әлфредкә дә шулай бәхет елмая. Чын бәхет! Димәк, аңа да пычраклыктан чистарынырга, бозыклык сазлыгыннан котылырга, кылынган гөнаһлардан арынырга мөмкинлек туа! Ә нигә, үткән эшләргә тәүбә итеп, чисталыкка омтылган кешенең бәхетле булырга хакы юкмыни? Шулай эшләсә, авторга һич кенә дә дәгъва булмас иде. Киресенчә әле... Әмма Ф. Яруллин каләме җиңел, шома юлдан китми, хакыйкатьнең ачы сутын беткәнче татыта ул үз героена. Башкаларга гыйбрәт булсынга, җаннарны тетрәндерерлек сабак булсын өчен! Әнә шул рәвешле, алгы планга вөҗдан психологиясе чыга. Бу—Әлфреднең Миләүшәгә язган беренче һәм соңгы хатында (бәхилләшү хаты дип аңларга кирәктер) ачык күренә:

"Бозыклык юлына бер атла гына икән—аннан сазлык кебек ул үзе суыра", дип әрни егет. Юк, ул бу хәлгә таруына дөньяны да, тормышны да, кешеләрне дә гаепләргә җыенмый. Үзен каһәрләгән хәтле ул беркемне дә каһәрләми. Чистарынасы килә аның, бик килә! Менә бит, аның таплы күңелен пакьләрдәй ак күбәләкнең саф мәхәббәте янәшәдә генә, шуны өркетмичә сак кына кушучыңа алырга гына бит! Кул сузымлык арада гына бәхете... Кул сузырлык кына арада! Югалтасы килми! Әмма егет җаны икегә бүленеп, алар арасындагы тартыш бик тирәнгә, бик эчкә киткән булган икән инде. "Мин үз-үземә ышанып җитмим,—ди ул бер әрнеп, бер гаҗизләнеп.—Җанымда туктаусыз иблис белән фәрештә көрәше бара".

Уйласаң, баткаклык, мәкер, хөсет, икейөзлелек мохитендә дә гомер уздырырга мөмкин бит—андыйлар азмыни?! Моңа егетнең чиста калган вөҗдан өлеше рөхсәт

итми. "Мин синең кичерүеннән куркам"—менә бу парадокс олы хакыйкать булып егетне әхлак сынавы алдына китереп бастырган. Җанының үзендә барган рәхимсез, һич ташламасыз көрәш аны урталыкта калдырган. Ә бу бик куркыныч халәт. Кыйбласыз, маяксыз торгынлык аның яшәү мәгънәсенең үзеген сындырган, хаят максатын куе томанга ураган. "Уйлар өермәсендә калып саташыр хәлгә житкәч, мин китү-югалу ниятенә киллем. ... Үткәннәрнең барысын көлгә очырып, мәңгелеккә китәм". Менә ул кырыс, ачы намус хөкеме! Менә ул гамәлләрен өчен җавап тотар хакыйкать мизгеле! Әлфреднең, инде армия юлларын узган булса да, кабат үзе теләп хәрби хезмәткә китүе һәм, димәк ки, үлемен дә тизләтүе әнә шул ачы хакыйкатьнең әрнүле кайтавазы иде.

Повесть жанрында үзен иркен хис иткән, бу чәчмә төрдә сүзен өздереп, кистереп әйтә алган Ф. Яруллин, иҗатындагы әлеге юлны хикәяләрдән башлаган иде. Прозаның шушы тармагында беренче мәртәбә каләмен сынап караган әдип—хәзер инде күп сандагы бик әйбәт хикәяләр авторы да. "Сайланма әсәрләр"нең өченче томы тулысы белән шушы жанр үрнәкләреннән төзелгән. Әдипнең повестьларында күтәрелгән идея-фикерләр, вакыйгаларны укмаштыручы төзелмә-эпизодлар, персонаж сыйфатларын тәгаенләүче сурәт-тасвирлар күп очракта хикәяләрдә сынау узды, чарланды һәм шул рәвешле олы прозага җирлек әзерләнде. Фәнис Яруллинның хикәяләре бер гади генә вакыйга эченә тыгыз, киеренке хис-кичерешләр тупланмасын сыйдырып, фикерне биек-биеккә күтәрергә сәләтле булулары, уйлар ыргымын күз иңли алмаган офыкларга әйди алулары белән җанны тылсымлыйлар. Әсәрләрнең эчке суты турында сүз барганда, кыска гына итеп, аклык белән сорылык капма-каршылыгына һәм бергәлегенә нигезләнгән тормышның әхлакый төс-тасвирлары дип әйтеп булырдыр. Ә инде чынбарлыкның шушы мозаикадан гыйбарәт сурәтен укучы күңелен алгысытырлык итеп үткәзә алу—язучының ихласлыгына бәйле.

Зур сүз ул—ихласлык. Укучы аның, акылын ясалма, әмма купшы фикерләр, өсте кетердәгән, асылы биздергеч төче идея-вакыйгалар, ясалма ялтыравыклар белән адаштырып та, буташтырып та буладыр әле ул, әмма аның күңелен болар белән яулап алу мөмкин түгел. Булмый ул алай! Җаннан саркып чыккан Сүз генә җанга үтеп керә ала. Хакыйкый һәм ихлас Сүз генә күңелнең иң нечкә кылларына кагылып аһәңле кайтавазга әверелергә сәләтле. Фәнис Яруллинның хикәяләре әнә шул ихласлыгы, укучы белән эчкерсез әңгәмә кора алу җәһәтеннән игътибарны җәлеп итәләр.

Әдипнең бу өлкәдәге иҗатын әдәбиятыбызның күренекле вәкиле Әмирхан Еники әсәрләре белән янәшә куеп күзәтү урынлы булыр иде. Аларда артык мавыктыргыч вакыйгалар да, "шаккаттыризмга" тартым эпизодлар да, купшы персонажлар да юк—барысы да гади генә, һәммәсе дә гадәти генә хикәят-бәяннәрдән гыйбарәт. Язучы каләме әнә шул реаль яшәештәге тыныч тасвирлаулардан тормышның эчке асылын аерып чыгара, күңел дөньясының тирән катламнарына үтеп керә, тышкы калыпларны куптарып, күзгә күренмәс матурлыкны көн үзәгенә күтәрә, җанда ургылган хисләрнең тылсым катыш сихәтле кайтавазына әверелдерә.

Күңел матурлыгы... Гаҗәепләр дә серле дөнья ул. Тоя белгәннәргә таң калырлык гүзәллек багы ул. Ә. Еникинең "Матурлык" исемле хикәясендә шәкертләр үз шәриктәшләренең әнисен беренче күргәндә, аның рәхимсез зәхмәттән коточкыч ямьсезләнеп калган йөзенә карап бер тетрәнү кичерәләр. Хәтта аларда ниндидер чиркануга хас хис тә уяна. Әмма соңыннан ана белән бала арасындагы эчкерсез, серенә төшенеп бетеп булмый торган олы мәхәббәт хисен күрү, тою аларның күңелендә үзгә дулкыннарны кузгата, җаннарын айкый-чайкый торган хиссият ташкынына бөтереп ала.

Ф. Яруллинның "Урман кызы" хикәясендә шушы ситуациягә тартым вакыйга тасвирлана. Табигатькә гашыйк, күңеле белән рәссам булган Таһир исемле егет урманда сәйран кылып йөргән вакытта сәер генә бер кыз белән таныша. Дөресрәге, әүвәл ул аның тавышын ишетеп соклана. Бераздан бу хис мәхәббәткә әверелә. Тик, ниһаять, кыз аның каршында пәйда булгач, ул тетрәнеп кала: гүзәл йөзенә багып таң калса, тәнендәге шокатсезлекне күргәч ул тәмамән имәнеп кала. Әмма бу вакытлы гына каушау була. Чөнки ике хыялый җан инде бер-берсен тапканнар, күңелләрнең

үзара тартылуын мондый вакытлы киртә генә (автор безне шуна ышандыра да) туктата алмый. Күнел сафлыгы, ихлас хисләр аша яралган мәхәббәт дөньясы адәм баласын гомере буенча нурландырып торучы гаҗәеп бер серле көч ул.

Ә. Еникинең янә бер гүзәл хикәясенә игътибар юнәлтик: "Туган туфрак". Шәһәр кызы Клара бабасының васыятен үтәү йөзеннән аның туган ягына кайтып килергә ният кыла. Бары тик бабасының гозерен игътибарсыз калдырмау өчен генә. Авыл аңа ят, ниндидер салкын, пычрак, карангы бер төбәк. Кай жирен сагынасың ди аның? Шуңа да ул бабасының "Клара бәбкәм, безнең Каракошны бер кайтып күрер идең, ата-бабаңның туган туфрагы бит ул!" дигән сүзләрен колак төбеннән үткәрә килә. Әнә бит әтисенең, шул авылда туып-үскән булса да, сагынып бер дә телгә алганы юк. Ә бабасы дүрт стена арасында ниндидер таулар, үзәннәр, яланнар, урманнар исемнәрен атый-атый өзлексез сагына. Соңгы сулышына кадәр. Бакыйлыкка күчкәнче... Ә инде бабасының туган җиренә кайтып андагы мәһабәтлекне, андагы гүзәллекне, туганнарының аны эчкерсез сөенеп, ихлас яратып каршылауларын тойгач, кыз үз күңелендә ниндидер үзгәрешләр башлануын сизә. "Бар икән ул туган туфрак дигән кадерле җир!" Кыз җанында яралган бу изге инану—ата-баба рухының авазы, бу—нигез чакыруы, бу—кан тартуы.

Кешене кеше итеп саклаучы, асылына алып кайтучы бу галиҗәнап хис Ф. Яруллинның "Туган ил башланган җир" исемле хикәясенең дә үзәгенә ята. "Туйдым, гарык булдым!"—дип авылдан китәргә уйлаган Зөлфәткә иң әүвәл аның кызы Әлфия каршы төшә. Әтисенең: "Син бит Казагыстанда туган бала. Синең өчен кайда яшәсәң дә барыбер түгелмени?"- дип гаҗәпләнүенә аның җавабы әзер: бу аның өчен туган авыл, туган җир. Әдип әлеге фикергә зур мәгънә сала: "Кеше күнеле өчен туган як кирәк. Еракка китсә, сагыныр өчен, картайса, балалыгына кайтыр өчен, дошман керсә, яклар өчен. Ерак җирләрдә йөргәндә, кеше читтәге матурлыкны әнә шул үзенең туган ягы белән чагыштыра. Туган ягы аңарга биеклеккә сикерү ноктасы, гүзәллек үрнәге булып хезмәт итә". Әлфия шушы гүзәллекне бу авылда тапкан, рухи яктан ул шушында туган. Шунын өчен дә кыз бу изге җирне ташлап китүгә катгый каршы чыга.

Шушындый ук тема "Хуҗа" хикәясенең дә үзәгенә алынган. Рөстәм армиядә хезмәт иткән вакытта авылда аның әбисе үлеп китә, өен исә оныгына яздырып калдырган була. Егетнең әнисе улы кайтканчы (авыл өе шәһәр баласына нәрсәгә?) йортны сату хәстәренә керешә. Рөстәмгә инде тиешле кәгазьләргә кул куясы гына кала. Шунда егет катгый үз сүзен әйтә: "Мин хуҗа кеше. Өйгә генә түгел, үземнең язмышыма, киләчәгемә хуҗа. Миңа авыл ошый... Бәлки, минем бәхетем шушындадыр". Шунда ул әбисенең сүзләрен дә искә төшерә: "Кеше бәхет эзләп читкә киткәндә туган җире елап калыр".

Туган җир, туган туфрак дигәндә безнең татар әдипләре авылларны күздә тоталар. Чөнки алар барысы да авылдан чыкканнар. Авыл—татар халкының, татар теленең бишеге. Бишек тирбәлгәндә җан җырлый, каләм сөенә-сөенә бәян кыла. Бишек эленгән кадак кына калу мөмкинлеген уйлаганда кан туңа, җан сыкрый, гаҗиз каләм сөйли алмау чарасызлыгыннан ак кәгазь өстендә чәбәләнә. Шәһәрләшү дигән процесс авылдан тулы бер буынны суырып алды. Бу инде киселгән, югалган буын. "Хуҗа" хикәясендә төп йортны сату мәшәкате белән мәш килгән хатынга авыл карты: "Син монда тугансың. Син үзең сагынмыйсыңмы җирне?" дигән сорау биргәч, шундый җавап ала: "Минем тормышым, дөньям шәһәрдә. Авылны сагынып торырга вакытым юк". Татар тормышыннан тартып алынган бу буын җан тартуына битараф, кан кычкыруына саңгырау, нигез чакыруына гамьсез. Халык язмышын үз язмышлары итеп таныган әдипләр буыннар өзеклегенең нинди фаҗигаләргә китерәчәген бар тулылыгына аңлаган хәлдә гаҗизлек, чарасызлык аша сүнеп бетмәгән өмет карашларын өченче буынга—югалган буынның дәвамчыларына юнәлтәләр. "Аталар хатасын балалар төзәтер" дигән ышаныч аларда шундый ихтыяҗ тудыра. Ә. Еникинең Клcostasы ("Туган туфрак"), Ф. Яруллинның Әлфиясе ("Туган ил башланган җир"), Рөстәме ("Хуҗа") әнә шул әрнү, сызлану белән сугарылган өметнең асылы булып мәйданга куелалар.

Ф. Яруллин хикәяләрендә еш кына үзәккә сабыйлар язмышы, тормышларының беренче адымнарыннан ук дөньяның кырыс сынауларына дучар ителгән нәни

жаннар алына. Әдип өчен бу бик мөһим тема. "Оясында ни күрсә, очканда шуны эшләр"—ди халык. Кешенең киләчәктә кем булып житешәсен балачактагы язмышы билгели. Юл башында алган яра еш кына әрнү, газап булып адәм баласын гомере буе озатып бара. Бар дөньясына нәфрәт, каһәрле каргыш булып та әверелергә мөмкин ул. Бу инде жәмгыять өчен куркыныч продукт. Кешенең бәхетенә көенүче, бәхетсезлегенә сөенүче әхлаксыз тип булачак. Куркыныч чир төзәлмәслек булып азганчы башында ук дәвалау зарур. Сонарырга һич кенә дә ярамый. Ярамый, шайтан алгыры! Яралы язмышларны бәгырь тамырларына сеңдергән әдип борчылып, сызланып, тирән уйланып кечкенә жаннарның рәнжү белән тулышкан олы күңел дөньяларын ачарга алына, укучының игътибарын шунарга юнәлтергә тырыша, битарафларның гамьсез йөрәкләрен сискәндереп, кырыс заман ритмы белән тибүенә ирешергә омтыла.

"Сандугач оясы" хикәясендә Нәжип кечкенәдән чирләшкә булып үсә. Шуна да үтә нечкә күңелле, гаделсезлекләрне бик авыр кичерүче, боек, сагышлы йөзле бер балага әверелә. Ә инде авыруларга, ямьсезләргә һәрвакыт чирканып караучы әнисенең ташлап китүе анын бәгырен актарып ташлый, ул үз эченә бикләнә, йомыла, йөзендә елмаюның әсәре дә калмый. Әтисе өйгә үги әни алып кайткач, күңел сыныклыгы тирә-юньгә ачу, нәфрәт булып ташып чыга. Әмма шәфкатьлелек, миһербанлылык, наз, жылы мөнәсәбәт ахыр чиктә анын бәгырь бозларын эретәләр.

"Аксак Тимер" хикәясендә Тимержан исемле яшүсмер бөтен авыл малайларының котын алып йөри. Ятимлегеннән үч алырга теләгәндәй әти-әнилеләрне кыйнап кинәнә. Нииндидер явыз ләззәт, куркыныч бер рәхәтлек белән кыйный ул көчсезләрне, кечкенәләрне. Аларны кыерсытудан әллә нинди генә бер тәм таба. Үзенең хәйлә-фокусларына ышанмаган Ихсанны канга батырып кыйнагач, үзе дә кинәт капланып елый башлый һәм шунда бөтенләе белән ачылып бетә: "Әллә минем бәхетле буласым килми дисезме?.. Барыгызга да үзегез генә калерле. Әллә минем йодрыкларым кычытканга сугыша дисенме? Юк, йодрыгым кычытмый минем. Сезнең бәхеттән ыржайган авызыгызны күрсәм, каным кайный башлый. Шуна дөмбәслим мин сезне. Сезне канга батырып ташласам жиңеләеп китәм". Димәк, явызлык, кансызлык ул тышкы пәрдә, кимсенүле язмышын каплаучы бер тышча гына икән. Ләкин бар дөньясына, кешеләргә карата булган рәнжү, үч киләчәктә анын жанын бозга әйләндергән рәхимсез бәндә итеп чарламас дип кем ышанып әйтә ала? Андыйлардан бозыклыкка, жинаятьчелеккә, наркоманлыкка бер генә адым. Нәкъ менә шундыйлар бер гөнаһсыз кыз баланы һәлак итәләр ("Төнге янгын"). Шушылар ук Искәндәр исемле яшүсмерне вөжданына каршы барып, үзенә күпме яхшылыклар эшләгән кешегә хыянәт итәргә мәжбүр итәләр, рухын сындырып куркак жанга әверелдерәләр ("Кем син, абый?..")

Ф. Яруллин хикәяләре шуны раслый, кеше гомере буе әхлакый сынау уза. Бала чактан әхлак кагыйдәләренә тугры калу гомернең төрле чорларында сынауларны узганда ышанычлы терәк була, намус, вөждан дигән төшенчәләрне керләндерми яшәргә ныклы таянычка әверелә.

Ф. Яруллин прозасының бер үзенчәлеге шунда, әдип портретлар ижат иткәндә иң әүвәл кешенең эчке дөньясын ача, уй-хисләре аша тулы канлы образлар галереясен мәйданга куя. Әдәбиятта озак вакытлар бер чир яшәп килде (хәер, ул хәзер дә типик бер хәл буларак үзен нык сиздерә әле): унай герой сурәтләнгәндә әсәр башында ук анын гүзәл портреты тәкъдим ителде: буй-сыны тасвирланганда Караәхмәт диярсең, валлаһи. Ничек инде шундук сокланмыйсын ди, әгәр дә: "көчкә тимер сынса һәм су чыкса баскан эзеннән..." Унай хатын-кыз образы икән, фәрештәләр мөкиббән китәрлек булып чыга. Төс-кыяфәтне әйткән дә юк инде, Йосыф-Зөләйха, Таһир-Зөһраләрең бер якта торсын.

Инде тискәре образларның портретларын бирергә кирәк булганда, бетте! Болар—һәммәсе шөкәтсез, чиркангыч төс-кыяфәтле бәндәләр. Мондыйларның кылачак гамәлләрен дә фараз кылу кыен түгел. Пөхтә, төгәл сызыклар белән ясалган, әмма жансыз, салкын курчакларны хәтерләтүче геройлар һичничек укучы анын тәэсирләндерергә сәләтле түгелләр. Мондый әсәрләр зиһенле укучы күңелен яулый да алмыйлар, чөнки ул укыганчы ук вакыйгаларның ни рәвешле бетәчәген белеп тора: "безнекеләр жинәчәк!"

Бу тип образлар хикәяләү барышында ачылмыйлар, аларда "җан хәрәкәте" юк. Ф. Яруллин исә нәкъ менә шушы хасияткә төп дикъкатен юнәлтә: аның геройлары яраталар, хыянәт тозагына эләгәләр, ашыгалар, ялгышалар, сөенәләр, үпкәлиләр, үкенәләр (кеше күңелен ачучы иң көчле хис. Хәтерлик: "Үткән эш кайтмый, үкен син, үл, жыла..."), өметләнәләр, газапланалар, сокланалар, нәфрәтләнәләр, сагыналар, ашкыналар... Кыскасы, тормышта үз урыннарын табарга, барыр кыйблаларын ачыкларга, үз-үзләрен танытырга тырышалар, яшәү мәгънәсе нәрсәдә икәнен белергә омтылалар, "мин кем?" дигән дөньяви сорауга җавап эзлиләр. Әнә шул рәвешле укучы алдында әүвәл төсмерләнәләр, аннан һәрдаим ачыла баралар һәм, ахыр чиктә, бөтен барлыклары белән аның алдына килеп басалар.

Кеше күңеле карурманга тиңдер. Аның ешлыгында әллә нинди хисләр йокымсырап ятадыр әле. Аваз гына сал, кирәкле аһәңгә туры килерлек кылга гына кагыл—бөреләр ачылырлар да, теге яки бу рәвешне алып, мең тармаклы күңел лабиринтлары аша үтә-үтә кеше холык-фигыленең автор гына белгән якларын сыйфатландырып, кызыклы һәм гыйбрәтле сурәткә әверелерләр. Бу очракта инде әдип оста сынчы буларак гамәл кыла. Күз алдында ташның артык өлешләрен кырып, китеп, чүкеп ала-ала хыялында яралган сын-сурәтне тудыра да, аңа җан өреп, укучының күңел дөньясына уздырып җибәрә.

Бу җәһәттән Ф. Яруллинның "Курку" исемле хикәясе гыйбрәтле. Курку... Күп тармаклы, күп сыйфатлы эчке хасият ул. Туганнарыңны, дусларыңны, яхшы исемеңне югалтудан курку бар. Кеше рәнҗетүдән, куркыныч авырудан, имгәнүдән, кеше күзенә карап җан асрарга мәҗбүр булырлык бәлагә юлыгудан, дөньядан ваз кичәрлек хәлгә тарудан... Азмыни соң бу тормышта курку тудырырлык хәл-әхвалләр. Бу рәвешле караганда курку бик табигый хис буларак кабул ителә, кеше күңелендәге реаль бер халәт сыйфатында таныла. Дөньяда бары тик баш миендә сынар сызык та булмаган, аз гына уйланудан да, аңлаудан да гомерлек мәхрүм тумыштан дивана хода бәндәсе генә курыкмыйдыр ул. Әмма куркуның башка төрләре дә бар бит әле. Кешенең кешелеген үтерә торган курку... Хайвани курку! Ә андый куркудан хыянәткә бер генә адым. Үз-үзенә хыянәт, намусына, хыялларына хыянәт һәм, ахыр чиктә, ватанына, халкына хыянәт (йә, Ходам, мәрхәмәтеңнән ташлама)...

Ф. Яруллинның хикәясендә дә әнә шул хис үзәккә куелып, әсәр героен катлаулы кичерешләр чолганышына алып керә. Вакыйга бик кискен, гадәттә детектив сюжетка хас булган төенләнештән башланып китә: "Әмирнең кара канга батканчы сугышасы, кемне дә булса эт итеп кыйныйсы яисә бернәрсә хакында уйламаслык хәлгә килгәнче тукмаласы килде. Ут өереп сугышып ятканда милиция алып китсен иде дә ябып куйсын иде. Менә шунда, ялгыз камерада, тормыш турында, үзенең узган һәм узачак юлы турында төпле фикергә килер иде, бәлки". Әлегә берни дә аңлашылмый. Әлегә әсәр героеның гасаби халәттә бәргәләнүен генә күрәбез. Менә ул шашкын хисләрен тыю ниятеннән шомлы мажара эзләп шәһәрнең караңгы тыкрыкларын гизә. Һәм теләгенә ирешә дә: бер почмакта яшь кенә кызга бәйләнеп торган дүрт әзмәверне очрата. Егет ниндидер бер кыргый ләззәт белән хулиганнарга ташлана. Менә хәзер ул кыйналган, изелгән килеш больницада ята. Палатадашлары белән ачылып сөйләшми, һәм ни гаҗәп, үз янына әти-әнисен кертмәскә куша. Аңлашылмаучылык куера, әмма сизәсең, нидер бар, нидер булачак. Бу куеруы, киеренкелеге белән соң дәрәҗәгә житкән халәт бер шартларга тиеш бит инде. Билгесезлек пәрдәсе бер умырылырга тиеш. Һәм менә ул! Үзе коткарган кызның хәл белергә килгәч, ярдәм чакырмый да качып китүенә акланып, "курыктым..." дигәч, Әмир тетрәнеп куя: "Аның үзенең фаҗигасе дә әнә шулай куркудан башланды түгелме соң?" Вакыйгалар шушы ноктадан ачылу сукмагына төшәләр. Әмиргә әтисе еш кына үз машиналарының рулен тапшыра торган була, янәсе "өйрәнә торсын". Чираттагы "өйрәнү" фаҗига белән төгәлләнә: төнге юлда Әмир кеше таптата. Бәлки исәндер дип, кире борылырга теләгән егетне әтисе кырт кисә, бу хакта авыз ачуны да тыя. Әлеге хәлдән исәнгерәп калган егет тә әллә ни карыша алмый: курку... Әмир күңелендәге намус белән кылынган гамәлләрнең фаразланган нәтиҗәсе шул кадәр кискен бәрелешкә керәләр ки, бу тартыш егетне бик озак киеренке халәттә тота. Инде тынычлана башлаган кебек тә була, әмма көтелмәгән бер хәл Әмирнең бәгырен кабаттан актарып ташлый. Яратып йөргән кызының

каты авырудан урыныннан да тора алмаучы әнисе белән беренче танышу аны бер сискәндерсә, бу фажиганең сәбәбе "бер машина бәргән" булуын белгәч, ул бөтенләй шашынып кала. Шушы ярсулы хис аны шәһәрнең караңгы тыкрыкларына куа, хулиганнар белән канга батып сугышуга китерә. Шулай аз булса да тынычлану килмәсме дип өметләнә. Ә нәтиҗә... Нәтиҗә исә шул: "Эт урынына кыйналып, тәнендәге һәрбер күзәнәге сызланса, җанына җиңелрәк булыр төсле иде, әмма болай да җиңеллек килмәде".

Ачыдыр хакыйкать юлы...

Адәм баласы гел уйланып, моңланып, көрсенеп кенә яшәми бит әле.

Фәнис Яруллинның юмористик хикәяләре дә байтак. Һәм бу юнәлеш әдип мөмкинлекләрен яңа яктан ачып җибәрә. Ф. Яруллин юморы нечкә, йомшак көлүдән гыйбарәт. Ул тормыш ситуацияләреннән, бераз гына сәер беркатлы кешеләрдән җиңелчә генә шаяртып, рәхәтләнеп көлә һәм көлдерә. Андый вакытларда кинәнеп ял итәсең, дөнья мәшәкатьләре, вак-төяк ыгы-зыгылар онытылып торгандай була. Томга кергән барлык хикәяләрне дә инләү мөмкин түгеллеген аңлаган хәлдә характерлы берничә әсәргә тукталып үтик.

Менә "Җан җимеше" хикәясе. Әсәрдә Хәйри исемле кеше соңгы вакытларда әллә нишләп кенә китә: берөзлексез өенә тимер-томыр ташый. Бар дөньясы шуның белән тула. Хатынының, бу хәлгә бик аптырагач: "автомобиль җыягадыр" инде дигән уе да тормышка ашмый. Баксаң, аның башында бер бик шәп фикер өлгереп килә икән: бишектә яткан "җан җимешенә" ике атна була. Тиздән "әттә, әннә" дип тә әйтә башлар. Аннан мәктәбенә дә китәр, «бишле»ләр тәяп кайтып әти-әнисен сөендерер. Тик менә бер нәрсә бар, мәктәптә балаларга өстәмә эшләр дә тапшыралар икән ләбаса. Шулардан берсе—бала-чагага тимер-томыр җыйдыралар. Димәк, алдан хәстәрен күреп кую һич тә артык түгел икән ("Унынчы классны бетереп чыкканчы җитәрлек булсын"). Бу фикерне хатыны да күтәреп ала: мәктәптә балаларга янә иске кәгазьләр дә җыйдыралар икән бит дип, бүгеннән үк шуңа керешәчәген әйтә.

Бәхетле яшь әти-әнинең гамәл-хыяллары көлке ситуация тудырса да, балага булган мәхәббәтләрен дә ихтирам итми мөмкин түгел.

"Уртак куаныч" хикәясендә дә сюжет элементларын укмаштыручы сәбәп булып бала туу вакыйгасы алына. Хатынын бала табу йортына озаткан Ибрайның күршеләре өзлексез хәлен белеп торалар: "Йә, кайчан малай алып кайтасыз?"- дип теңкәсенә тиеп бетәләр. Чынлап та, малае тугач, котлаулар көчәя. Бәхетле атаның сөенечен уртаклашып һәрберсе бүләккә (нишләптер?) хоккей өчен кирәк булган әйбер алып керә. Тимераяктыр анда, хоккей кәшәкәседер (ә малай әле бала табу йортында!)... Моңарчы күршеләре хакында гел начар гына уйлап йөргән Ибрайның тәмам күңеле нечкәрә, "нинди әйбәт кешеләр икән бит" дип кинәнә. Бу хикмәтнең асылы иң ахырда гына ачыла. Ибрай күршеләренә: "Кыз булса, туу белән пианино алып бирәм, музыкант итәм, малай булса атаклы хоккей уйнаучы ясыйм",—дип вәгъдә биргән булган икән. Ә хоккей ул урамда уйнала, димәк йортта тынычлык булачак. Шул сәбәпле малай туу хәбәре күршеләр өчен чын мәгънәсендә уртак куанычка әверелә.

Әнә шундый хәерхаһлы көлү аша Ф. Яруллин кызыклы вакыйгалар һәм хәтергә уелып кала торган кызыклы образлар иҗат итә. Ә аның Закиржаны ("Хатын авыргач") күләмлерәк, яки башка жанрдагы әсәр кысасына да соралып тора сыман.

Йомшак көлү остасы булган Ф. Яруллин вакыт-вакыт "чеметкәләп" тә алгалый. "Хәзер чыгарга ярыймы?" хикәясе моның характерлы мисалы. Рафаэль исемле малайның әти-әнисе аны һәрвакыт яшьтәшләре белән уйнаудан тыеп киләләр. Чөнки Рафаэль—гаять зур урында эшләүче кешенең баласы, ә тегеләр—бик гади гаиләдән. Дусларын шул гадиләр арасында тапкан малайга һәрвакыт тукып киләләр: "Ярамый..." Әмма бер көнне "зур дәрәҗәле" ата өенә бик өшәнеп кайтып керә. Баксаң, аны урыныннан төшергәннәр икән. Бар да хәсрәттә, чөнки хәзер "Тормышны өр-яңадан башларга туры киләчәк. Түбәннән". Бу хәлгә иң нык сөенгәне исә Рафаэль була. Чөнки аңа да дуслары белән уйнарга ярый дигән сүз.

Хикәя Тукайның "Баскыч" дигән шигырен күпмедер хәтерләтә. Анда да бит диварга сөялгән баскычның югары басмасы түбәндәгеләргә кимсетеп, мыскыл белән

карый. Янәсе, ул иң өстә, аның урыны гали, бөек, шуна ул һич тә аскы басмалар белән тиңләшә алмый. Шунда бер адәм килә дә баскычны әйләндереп куя. Нәтиҗәдә: "Түбәндәге басмалар менде, югаргысы түбән төште". Тукай шигырендә дә, Ф. Яруллин хикәясендә дә бик үткен киная бар. "Дөнья куләсә, әйләнә дә бер баса" дигәндәй, кайдан чыкканлыкларын, кем булганлыкларын онытып, бүгенге вакытлы дәрәҗәләре белән кукрайган бәгъзеләргә юнәлтелгән ул киная. Киләчәктә үз урыннарыннан егылып төшеп, җан тырмашып түбәннән күтәрелергә азапланганда япаялгыз калачакларын ник уйламый икән бәндә дигәнең? Ә бит ул хәл иртәме-соңмы барыбер булачак. Шуңа да мин Ф. Яруллинның "Хәзер чыгарга ярыймы?" дигән тыйнак кына, әмма гаять тыгыз фикерле хикәясен "гыйбрәт әсәр", "киная әсәр" дип атар идем. Күркә кебек кабарынган, куык кебек өретелгән кемсәләргә чынбарлыкны тою хисләрен җуюлары өчен тормыш сынаву узарга мәҗбүр булачакларын искәртә ул хикәя.


*Фәнис Яруллин китапларының берничәсе.*

Ачыдыр хакыйкать юлы...

Фәнис Яруллинннның дүртенче һәм бишенче томнарында шигырьләр урын алган. Аңа «Татарстанның халык шагыйре» дигән мәртәбәле исем, Г. Тукай һәм М. Җәлил исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты дәрәҗәсен китергән күңел җимешләре алар. Шагыйрьнең бәгырь авазлары, җан, күңел кайтавазлары... Укучы белән язмыш кычкыруы, хыял, өмет, әрнү, шатлык, сагыш аша туган әңгәмәсе... Дөньяга, кешелеккә, тарихка дәшүе... Чын ир-егетнең хакыйкать юлында туган уйланулары... Бөтен тормышы, гомер юлы... Тагын... Хәер, санап кына бетерерлекмени соң ул тойгы-халәтләрне, кичереш-омтылышларны.

| | |
|---|---|
| *Акыллы чак минем әллә булган,* | *Кем соң инде унөч яшьтә чакта,* |
| *Әллә инде бер дә булмаган:* | *Мәхәббәттән тилереп елаган?* |

И, яшьлек иртәсенең гөнаһсыз мизгелләре! Кайсыбыз гына узмаган инде ул вакыт таңының саф чыклы сукмакларын! Әле бит ул хисләрне мәхәббәткә тиңләп карау уйда да юк. Була бит инде шундый пычтыйк бер классташың. Шуны үртәп елатасы, чәченнән тартып китәсе генә килеп тора. Хиснең чыны исә сонрак туа. Ул чагында инде бөтен дөньясы нурга чума:

| | |
|---|---|
| *Ялкын телләренә баса-баса* | *Кара болытларны ера-ера* |
| *Мендек мәхәббәтнең тавына.* | *Юл тоттык без кояш ягына.* |

Аннан соң гына «мәхәббәт» дигән якты үрләрдә кара болытлар йөзүен дә, шомлы җилләр исүен, салкын, җан өшеткеч яңгырлар сибәләвен дә аңлый барасың. «Бәхет чишмәсеннән су эчкән» чакларыңны оныттырырлык булып сагыш, үкенеч, үпкә хисләренең энгерле күләгәләре бәгыреңне сыкратачак мизгелләрне дә кичерәсен.

«Бар да уза» диләр халыкта. Шулайдыр да анысы... Тик эзсез генә узмый инде ул. Шагыйрь хаклы:

| | |
|---|---|
| *Озак канар әле ике йөрәк,* | *Карап торыр күктән мәхәббәтнең* |
| *Төзәлсә дә калыр эзләре.* | *Үпкә белән тулы күзләре.* |

Юк-юк, шагыйрь һәркемнең язмышына хас котылгысыз нәтиҗәләр чыгарудан ерак тора. Кемнәрдер беренче мәхәббәтләре белән аерылгысыз булып бәхетле яшәү

кичерәләр. Аларның үз ышанулары:

*Матур яшәү—тирән сер ул*
*Без төшендек шушы сергә.*
*Бөтенесен тигез бүлдек—*
*Яндык бергә, көйдек бергә.*
*Гел янәшә бардык җирдә.*

Дөнья шул бу... Мәхәббәттән аерылышу да ерак йөрми. Кайвакыт юктан гына үпкәләшү чыгып булмаслык упкынга әверелә. Әмма күнелләрдә калган сөю хисе моң булып, якты сагыш булып адәм баласын гомере буена озатып бара, хәтер ул саф хисләрне тора-тора яңарта.

*Инде бүтән гашыйк була алмыйм,*
*Очрамыймы әллә кешесе?!*
*Чибәрләрне күрсәм, борылып карыйм,*
*Юкмы диеп синең төслесе.*

---

*Алданып та куям кайчакларда,*
*Охшаш йөзләр китсә чалынып.*
*Яшимен мин шулай әллә сиңа,*
*Әллә мәхәббәткә табынып.*

Ф. Яруллин укучыларын хисләргә хыянәт итмәскә чакыра. Мәхәббәт—тормышта терәк ул. Бер-береңнең инен тоеп, җанын аңлап яши белергә кирәк. "Дөнья буйлап күпме кеше йөри Җан җылысы эзләп ни бары",—ди шагыйрь. Үзенең тормышында нинди авырлыклар чигеп тә сынмавын-сыгылмавын җан җылысы табуында, гомер юлында таянырлык ышанычлы терәк булуда күрә ул:

*Бардык-бардык, юллар ярдык,*
*Үрдән үрләргә мендек.*
*Әйтсеннәр иң чыдамнарга—*
*Яшиләр менә болар да*
*Фәнис—Нурсөя кебек.*

Мәхәббәт учагы сүнсә кешенең күнеле катылана, яшәү мәгънәсе югала, җанында бәхетле парларга карата кара көнчелек, явыз үч хисе генә кала. Ул хис аның бәгыренә чуер таш булып урнаша; андыйлар башкаларның кайгы-хәсрәтенә битараф булалар, андыйларда иман, мәрхәмәт, шәфкать кебек изге хисләр яши алмый. Болар—җәмгыять өчен куркыныч типлар. "Кайчандыр сөеп-сөелеп тә, нишләдегез сез гашыйк җаннар, ничек тормыш дәрьясының ике ягында калдыгыз", дип ачынып сорый кебек шагыйрь. Вакыт елгасы—хәтер. Кичеп чыгарга гомерең дә җитмәскә мөмкин. Төзәтеп булмый торган хаталарга үкенүдән дә авыр нәрсә юктыр бу җиһанда. Юктыр...

*Ярлар, ярлар! Кушыла алмый алар,*
*Аһ, бу шундый ачы хакыйкать.*
*Бу хакыйкать минем йөрәгемә*
*Бәреп тора көнгә ничә кат.*

Ачыдыр хакыйкать юлы...
Китаптагы икенче бер зур цикл—"Тормыш лирикасы" исемле.

*Аерылу бар, кавышу бар,*
*Көтүләр бар зарыгып...*

Тагын? "Ашкыну", "дәртләнү", "сүрелү", "адашу", "ялгышу", "сөенү", "көенү"... Әнә шуларның барысыннан да узарга кирәк. Иллә дә катлаулы бу дөнья дигәнең. Шуна да карамастан "ә тормыш дәвам итә", дипраслый шагыйрь. Әнә шушы тормыш чытырманыннан чыгар өчен җан тырмаша адәм баласы. Өмет чырагын маяк итеп тырмаша. Ә ни өчен? Шунын өчен: "Бөркет булып оча хыялларын—Бөтенесе тик бер яшәр өчен". Ничек итепме?

*Әй яшисе килә матур итеп,*
*Рәнҗетмичә хәтта гөлне дә.*

*Ялган, мәкер, уч һәм ачуларны*
*Якын китермичә өемә.*

Фәнис Яруллин әнә шулай укучыга тормыш сабакларыннан дәрес бирә. Баллы ялган белән ымсындырмый, тәҗрибәсезләрне холыксыз карт хәлфәдәй өркетми, юк-бар кыенлыкларны күпертеп каушатмый, курку сеңгән күзләрдән ләззәт эзләми. Ул—ихлас, ә бу тормышта ихласлык кырыслык белән үрелеп бара. Шагыйрь уйлап чыгармый, ясалма киртәле ситуацияләр тудырмый, ул үз язмышын, үз гомер юлын сөйли.

*Мин кабызган утлар арткан саен,*
*Арта бара кара көнчелек.*
*Таш атканга, ташлар атар идем,*
*Таулар төшүе бар ишелеп.*

Дөнья бу, йә! Шагыйрь тормышның әллә нинди борылышларына алып керә, тирән-тирән катламнарын ача, эзли, эзләнә, кисәтә, өметсезлек сазлыгына тап булып туктап калмаска өнди. Тормыш—көрәш, тартышмый торып гаделлеккә ирешү, бәхет яулау мөмкин түгел. "Бәхет—кайгы арасында бара көрәш, бара тартыш",—дип раслый шагыйрь. Әнә шул мәңгелек көрәш эчендә үз урының булырга тиеш. Качып, посып, мескенләнеп тә узарга мөмкиндер гомер юлын. Яшәү түгел инде бу, бичара бер җан асраудыр. Нәкъ менә "Йолкыш эт" шигырендәге сыман койрык болгап йөрүче ялагай көчекләр язмышыдыр: "Койрык болгамаслар иде, яшисе бар—тормыш бит". Йә, Хода, хакыйкатьнең нинди генә төсмерләре юк бу җиһанда! Шул ук вакытта бүгенге җиңүдән канәгатьләнеп, гамьсезлек кочагына чумудан сак булырга да чакыра шагыйрь:

*Әле тормыш сынавының*
*Иң авырлары алда,*
*Иң авырлары алда!*

Сынау булгач сынау инде ул. Адәм баласы гел җинеп кенә яшәми бит. Җиңүләр булган жирдә җиңелүләр дә була. Шул чакта күнел төшенкелегенә бирелмәү, сынмау, сыгылмау, янадан да көрәшләргә чыгарга үзендә көч табу зарур.

*Җиңелүне горур кичерә белү—*
*Үзе җиңү, үзе батырлык.*

Шулай да Ф. Яруллинның бу төркем шигырьләрендә борчылу хисе күбрәк. Аңлашыла инде, заманы шундый. Халкына бөтен барлыгы белән береккән шагыйрь аның бүгенге хәлен күреп сызланмый булдыра аламы соң?

*Язмышымны язам, ә язмышым*
*Аерым түгел илдән, халыктан.*

Вәзгыять чынлап та үтә хәвефле, борчулы бүген. Милләтебез өстенә ябырылып инкыйраз дәһшәте килә. Ул акрын килә. Әмма ышанычлы килә. Шул вакытта милләттәшләр арасында бердәмлек булмау әрнетә шагыйрьне. "Үзара ызгыш-талаш дошман белән сугыштан хәтәррәк" диләр. Хак ул.

*Һәммәбез үз оябызда*
*Утырабыз өнсез.*
*Кыңгыраулар ярык безнең,*
*Кыңгыраулар телсез.*

Ачы хакыйкать авазы Фәнис Яруллин поэмаларының да үзәгенә алынган. "Сайланма әсәрләр"нен бу бүлеге "Нәсел агачы" исемле поэма белән ачыла. Нәсел

агачы... Хәтерсезгә, манкортка әйләнмәгән кеше өчен бик тә кадерле, бик тә изге төшенчә бу. Үз нәселен белгәннәр нинди бәхетле! Шундый кәеф белән мин дә поэманы укырга керешкән идем. Шагыйрь белән бергә бакыйлыкка күчкәннәрнең каберләренә зиярат кылып, рухларына дога күндерүдән бер канәгатьлек хисе алырга ниятләгән идем. Сабыр гына, тыныч кына... Әмма поэманың беренче юллары ук дәһшәт, фаҗига тулы дөньяга алып кереп китте.

*Барган идем авылым зиратына*
*Йөрәгемне чолгап ут алды.*
*Тирә-юньдә ут, ялкын. Бар да яна...*

Яна сүзләр, уйлар, хәтер, истәлекләр. Кабер ташлары яна. Фаҗигаләр тулы дөньяның терәге булган нәсел агачы яна... Бер гаиләнең янган нәсел агачы күмерләрен эзли-эзли шагыйрь безнең алда дәһшәт, кан-яшь белән сугарылган хәтер сәхифәләрен ача. Шагыйрь ике буын оныгы янәшәсендәге Зәйнәп әби кабере янында... Шагыйрь тетрәнгән, ул гасаби бер халәттә. Гүрдән ана инрәү газабы килә:

*Нәселем бетте. Агач төпләредәй*
*Тезелеп калды кабер ташлары.*
*Күрәчәген күреп бетермичә*
*Гүргә керми адәм башлары.*

Хәтер китабының битләрен укуымны дәвам итәм. Аларның һәрберсе жанны өтеп ала. Менә берсе: сугыш чоры; кышкы кич; салкыннан өшеп, һәр шакылдауга куркып калтырап утыручы ач ике ятим б..ла... Шул вакытта күрше Зәйнәп әби килеп керә, балаларны юата, кочагына алып җылыта, тамакларын туйдыра. Ә карчыкның үз хәле яманнардан да яман: сугыш елларының мәхшәреннән җиде баладан бары тик берсе—улы Вәгыйз генә исән-сау кала. Анысы да әсирлекнең бөтен газапларын чиккәннән соң гына. "Нигә кайткан инде мескен", диючеләргә поэмада кырыс хакыйкатьле җавап бар:

*Тартты аны туган туфрак,*
*Хатынының кабере тартты.*
*Тартты ятим калган Рифе*
*Ул бит шуны сагынып кайтты.*

Әмма бу шатлык та озакка бармый. Бер төнне алар өенә дә килеп керәләр. Ул заманда төнлә керүчеләр буш китмиләр инде. Шул алып китүдән Вәгыйз юкка чыга...

Кин дәрьядан инешкә әйләндерелсә дә нәсел дәвам итә әле. Вәгыйзнең улы Риф дәвам итә аны. Аннан Рифнең улы Рамиз туа, үсә, егет була. Димәк, нәсел агачы корымаган, ул яши. Тормышның бар афәтләренә үч итеп яши! Ләкин... Әфган жиреннән кургаш табут кайта. Табутта—берләнберләре Рамиз...

Кеше язмышларында—халык язмышы, ил язмышы... Ачы хакыйкать! Ә ул хакыйкатьнең иң авыры ирләр белән илләргә түгел, аналар жилкәсенә төшә. Бар фаҗига, бар афәт иң әүвәл алар жаны аша уза. Илләр тотарлык ирләр алар бәгыреннән өзелгәннәр бит!

Канлы-яшьле, кара заманнар каһәрләгән Ана язмышы "Коткарыгыз" поэмасының үзәгенә алынган. Поэма дәһшәтле сүзләр белән ачыла:

*Орден сатам, орден сатам!*
*Кемгә кирәк? Йә, алыгыз.*

Сискәнепләр китәм. Тетрәнүле халәттә вакыйгалар эченә атлыйм. "Кырык бишнең шаулы язы, Жиңүчеләр өйгә кайта". Ә кемнәргәдер һәлак булганнарның даны булып күкрәккә бер тапкыр да тагылмаган Орден кайта. Сөенергәдер бит? Ләкин сугыш бетсә дә—үтмәгән икән. Анын салкын сулышы жиңү шатлыгыннан балкыган көнелләрне әледән-әле калтыратып тора: Сабый ирендә бер сүз—ипи,

ипи; тирә-юньдә хәерчелек. Моны вакытлы хәсрәт дияр идең, иң газаплысы—җәбер-золым, хокуксызлык. Ире ил азатлыгы өчен башын салган солдатканың налоглар өчен дип, тормыш итүнең бар өмете булган сыерын алып чыгып китәләр. Һәлак булган фронтовикның орденына, гаҗиз ананың "коткарыгыз!" дип өзгәләнүләренә дә карамыйлар "намусларын күптән сатып эчкән бу бәндәләр". Кайгы-хәсрәтеннән бер мизгелгә акылын җуйган хатын орденны җиргә салып таптый: "Ләгънәтле ил бүләге—Менә сиңа, менә сиңа!" Нәтиҗә—төрмә. Ананың төрмәдән язган хатларында шул ук тормыш, шул ук эш, диелә. Һәм дәһшәтләрдән дәһшәтле сүзләр: "Без инде күптәннән бирле Төрмәдә икәнбез бит". Менә шул вакытта поэманы ачып җибәргән дәһшәтле сүзләрнең асылы аңлашыла да инде:

*Орден сатам, хакы тик шул,*
*Сеңдер аны хәтергә син:*
*Орден белән бирәчәкмен*
*Ул елларның хатирәсен.*

Ачыдыр хакыйкать юлы.

Ф. Яруллин тормышның авыр, дәһшәтле якларын гына сурәтли дип расларга теләмим. Шагыйрь ачы, кырыс хакыйкатьтән кысылган күңелләрне бушатып алырга да җай таба. Мәрхәмәтле көлү белән сугарылган "Мәхәббәт маҗарасы", "Сөйләнү һәм өйләнү", "Кунак кызы" кебек поэмалары нәкъ менә шушы максатка хезмәт итәләр.



*Фәнис Яруллин хатыны Нурсөя ханым белән.*

Алыйк "Мәхәббәт маҗарасы" әсәрен. Поэма герое үзенә гүзәл яр табу мәшәкате белән мәшгуль. Сайлый, сайлана. Менә аның игътибарын бер игълан җәлеп итә: яшь, чибәр, эшчән, мул тормышта яшәүче гүзәл зат тормыш итү өчен яхшы хуҗа кирәген белдергән. Безнең героебыз да шул адрес буенча торып чаба. Бара, күрә. Чынлап та шулай икән, ләбаса! Кыз—гүзәл, йорт-җир—житеш. Мәхәббәт каһарманының күңеле тәмам мәмнүн була. Хатын исә җайлап-майлап кына тәмле тел белән аңа төрле-төрле эш куша тора: егет су ташый, утын яра, кибеткә йөгерә ("Тик эшләр эшләнгән саен бетмәде, артып торды"). Кич белән хатынның хәйләсе ачыла: баксаң, йортында эшләр җыелган саен ул газетага игълан бирә дә ачыкавыз мәхәббәт корбаннары шул кармакка гел дә генә инде каба торалар икән. Гыйбрәтләр алып яшәр заманга бик тә хас хәл-ситуация инде бу. Аңлаган кешегә, әлбәттә. Хәйләкәр хатын һәм мәхлук ир мөнәсәбәте "Кунак кызы" поэмасының да төп эчтәлеген тәшкил итә. Лирик герой авылда бер дигән шәп егет икән (имеш!). Бар кызлар моның артыннан чабалар да егетнең генә аларга исе китми икән. Чөнки уе башкада: ничек тә бер сылу кунак кызын эләктерү. Морадына ирешә дә "шәп" егет. Һәм "шәп" итеп килеп каба да. Әсәрдә бик кызыклы бер эпизод бар. Кунак кызын эзләп аның авылына барганда мәхәббәт каһарманы бер адашкан сарыкка юлыга. Баксаң, ул теге гүзәлләрнеке икән. Әнә шулай ике мәхлук капкадан килеп керәләр. Кыйссаның төп хиссасы аңлашылса кирәк: мәҗнүн герой кыз йортында эш ишәгенә әверелә дә кала—фермер кайнатасының утыз биш баш сыерын сава, базарга барып май сата. Яшь хатыны исә сөт-май саткан акчага алынган фатирда

рәхәт, күңелле, дәртле тормыш алып бара.

Укучы көлә, рәхәт чигә. Мәхлук мәҗнүнгә дә рәхәттер, әнә бит ни дип күкрәк кага: "Әйе, дөньям гөрләп бара, кәеф әйбәт, күңел көр". Шулай да күңеленең бер почмагында бүтән уй: "Үз кулларым белән үзем муенга кидем элмәк".

Ачы ул хакыйкать юлы...

Ә инде шагыйрьнең көлкеханәсен керәксенүчеләр булса, рәхим итегез, бишенче томның зур гына өлешен "юмор, сатира" бүлеге алып тора. Анда тормышның бик күп төсмерләрен, кешеләрнең һәртөрле сыйфатларын күрергә, табарга мөмкин. Көлдерә дә, елмайта да, уйландыра да ул шигырьләр.

Фәнис Яруллинның иҗаты гаять тә киң. Ул әдәбиятның төрле жанрларында эшли. Һәм бик тә уңышлы эшли. Бер мәкалә кысасында гына аны инләү мөмкин түгел. Әдип иҗаты турында әле зур-зур хезмәтләр язылыр, диссертацияләр якланыр (һәм якланды да инде). Бу җәһәттән, шагыйрьнең бик тә гыйбрәтле дүрт юллыгы бар:

*Мин бер утрау, ләкин диңгезчеләр*
*Күрми үтә минем яныннан.*
*Мине ачар өчен җирдә әле*
*Тумагандыр, ахры, Магеллан.*

Ә инде шагыйрьнең иҗаты ни рәвешле бәләкәй инештән киң дәрьяга әверелүен белергә теләүчеләр "Сөенечләр бүлешү" исемле эссега мөрәҗәгать итсеннәр. Анда авторның тормыш юлы да, әдәбиятка беренче адымнарыннан алып бүгенге иҗат үрләренә күтәрелү вакыйгалары да бәян ителә. Нигездә ул Ф. Яруллинга язган хатлардан, башка язучыларның әдипкә бүләк ителгән китапларындагы автографлардан гыйбарәт. Әмма биредә фикер, уйланулар потенциалы көчле. Хикмәт шунда, һәр язучының сүзләреннән соң Ф. Яруллин ул әдип белән кайда, ничек танышуы хакында яки аның турында мәгълүмат бирә, шуңа бәйле рәвештә заманга, әдәбиятка карата шәхси уйлануларын теркәп бара. Шул рәвешле шагыйрьнең иҗат үрләрен ничек яулый ала баруы ачыклана төшә. Беренче чиратта, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләдән ингән сәләт. Аны берничек тә яшереп булмый, ул барыбер шытып чыгачак иде. Икенчедән, шагыйрьнең үз тырышлыгы, әгәр теләсәгез, үҗәтлеге (тормышта бу сыйфат та мөһим бит), авырлыклар килгәндә сынмавы-сыгылмавы, көрәшчә рухлы булуы зарури чыганакка әверелде. Өченчедән, бормалы, катмарлы хәят-иҗат юлында күңел уты сүрелгәндә—дәрләтерлек, абынганда—таянырлык, ачынганда—юатырлык, сөенгәндә—уртаклашырлык кешеләрнең янәшәдә булуы, аларның һәрвакытта да авторга хәерхаклыгы. Ф. Яруллин әнә шундый шәхесләрне хөрмәт белән искә ала, аларга рәхмәтләрен ирештерә.

"Мин дә язмышыма рәхмәтле,—дип яза автор.—Авыр тормыш юлымда ... монда исемнәре аталган олуг затлар белән аралашуым, шулар белән бер казанда кайнап иҗат итә һәм иҗат җимешләремне халкыма житкерә алуым, шатлык-кайгыларымны бүлешеп яшәрлек дусларым булу белән бәхетле мин". Әнә шул хисләрне укучысына житкерә алуы белән дә бәхетле шагыйрь. "Сөенечләр күбрәк кеше белән уртаклашкан саен арта бара бит",—ди шагыйрь. Шулайдыр. Ә көенечләр исә, киресенчә, кимидер.

Биредә тагын бер мөһим мәсьәләгә игътибар итү зарур. «Сөенечләр бүлешү» әсәре, җентекләп укыганда, авторның шәхси истәлекләре кысасында гына калмый, ә тормышның, әдәбиятыбызның мәгълүм бер этабына күзәтү ясау рәвешендә дә кабул ителә. Төрле чор әдипләре, алар белән очрашу истәлекләреннән туган уйланулар аша Ф. Яруллин әдәби тормышның үзенчәлекле якларын ача. Ә бит төптән уйлап караганда, һәр язучы тормыш тәҗрибәсе аркылы әдәбиятка үз таланты кимәлендә нәрсәдер алып килә, нәрсәдер калдырып китә. Язучы язмышы—әдәбият язмышы инде ул. Әдәбият язмышы исә—халык язмышы.

## Фоат Галимуллин

# АНЫҢ СУКМАГЫ

МӘХМҮТ ХӘСӘНОВНЫҢ 80 ЕЛЛЫГЫНА

Мәхмүт Хәсәнов—яшьлеге Бөек Ватан сугышы чорына туры килгән буын вәкиле. Ул Яшел Үзән шәһәрендәге татар мәктәбенең җиденче сыйныфында укыганда бөтен тормышны, хыялларны җимереп, сугыш башланды. Ундүрт яшьлек малайга һөнәр училищесында слесарьлыкка укырга һәм хезмәт юлын башларга туры килә. Аның елгылар (1927), уналты яшьләре тулуга, сугышка да алындылар. Исән калганнары тагын җидешәр ел хезмәт иткәннән соң гына гадәти тормышка кайтты. Мәхмүт, 21 декабрьдә туу сәбәпле, армиягә алынмый, әмма Югары Кибәхуҗа авылында туган, ун яшеннән Яшел Үзән кебек «провинциядә» генә үскән яшүсмернең башына андый теләк каян килгән диген: әле сугыш бетәргә бер ел кала ул Мәскәүгә бара һәм Театр сәнгате институтына гариза бирә. Алалар татар малаен, җитмәсә төп факультетка—актерлар әзерли торганына! Бары тик рус телендә генә, Көнбатыш һәм рус драматургиясенә нигезләнеп укыса да, аның күңелендә туган телдә сәхнә образлары тудыруга булган омтылыш көчәйгәннән-көчәя бара. Аны Казанның Яшь тамашачылар театрына эшкә билгелиләр. Ул елларда ТЮЗда татар төркеме дә эшли. М. Хәсәнов шушы төркемдә иҗат итәргә теләк белдерә. Югыйсә, аны рус телендә уйнарга нык кына кыстыйлар. Тамашачы аның «Кузы Көрпә белән Баянсылу» әсәрендәге мәхәббәт героен башкаруын



яратып өлгерә. Шул ук вакытта, аның уенын күргән Г. Ахунов искә алганча, «ул мәһабәт гәүдәле, аксыл-сары чәчле, зәңгәр күзле бер егет булып күңелгә кереп калган[1]». Яшь талантны Татар дәүләт академия театрының үзенә эшкә чакыруы аның сәләтен тану булып тора. «Күзгә ташланып торган сәләте, мавыгып сөйли белә торган осталыгы бар иде аның»,—диләр аның уйнавын тамаша кылган затлар.

Шундый бер язылмаган канун күзгә ташлана—Мәскәү театр мәктәбен үткән кешеләребез, артист кына булмыйча, әдәбият-сәнгатебезгә хезмәт итүнең башка юлларыннан да китәләр. Т. Миңнуллин, Р. Батулла, М. Харисов, Ә. Зарипов, К. Газизова һәм башкалар моның мисаллары. М. Хәсәнов та—сәхнәдә таныла башлаган егет—әдәби иҗат юлыннан китә. Дөрес, ул театрны да онытып бетерми. «Рамай», «Көя күбәләге», «Нурихан», «Хикмәтле Хикмәтулла», «Язмыш», «Фәрештә», «Яшь кияү» кебек сәхнә әсәрләре дә яза, алар Әлмәт дәүләт һәм Республика курчак театрында, халык театрларында сәхнәгә меңәләр. Азнакайда яшәгәндә ул шактый дәвамлы еллар буена мәдәният сарае каршындагы һәвәскәрләргә җитәкчелек итеп, бу коллективның халык театры дәрәҗәсенә үсеп җитүенә ирешә. Ягъни сәхнә аның гомерлек юлдашларыннан берсе булды дияргә дә мөмкин.

Кырыгынчы елларның ахырында М. Хәсәнов проза язу белән мавыга башлый. Газеталарда исеме еш күренә. Төрле хәбәрләр, репортажлар язудан тотынган эш очеркларга җитә, аннан хикәяләр дә озак көттерми. Ниһаять, 1952 елда дәүләт

[1] Ахунов Г. Намуслы хезмәт җимеше //Социалистик Татарстан.—1988.—8 апрель.
[2] Социалистик Татарстан.—1988.—8 апрель.

нәшриятында аның «Беренче хикәяләр» дигән җыентыгы басылып чыга. Егерме биш яшьлек егет өчен бик зур шатлык була бу. Аның сәләтен күрә, бәяли башлыйлар. Ин беренчеләрдән булып Г. Кашшаф үз сүзен әйтә: «Бу егеттә хикмәт бар[2]». Әдәбият мәйданында күпне күргән бу затның бәясе бик вакытлы була. Әлеге җылы караш М. Хәсәновны тагын да дәртләндереп, иҗатка канатландырып җибәрә. Бу китаптагы әсәрләр минем үземнең дә хәтәремдә бүгенгедәй сакланган. Ул басылып чыкканда, мин дүртенче сыйныфны тәмамлаганмын һәм китапны күпмедер дәрәҗәдә аңлап укырлык булганмын. Бигрәк тә «Кечкенә Джон» дигән хикәя көчле тәэсир иткән. Хикәяләре хәтеремдә калган, әмма язучысының кем икәнлегенә игътибар ителмәгән. Шуннан соң утыз еллап вакыт үткәч кенә кабат минем кулга очраклы рәвештә әлеге җыентык килеп керде һәм мин аларны язган кеше Мәхмүт Хәсәнов икәнлеген белдем.

Минем әле М. Хәсәновның үзе белән танышлыгым юк иде. Көннәрдән бер көнне Казан дәүләт педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасына зур гәүдәле, кулына бизәкләп эшләнгән кәкре таяк тоткан, күзлекле кеше килеп керде. Мөдиребез профессор Ф Хатипов белән бик җылы итеп күрештеләр. Шуннан соң ул сорап куйды:

—Тәнкыйтьче Фоат Галимуллин биредәме?

Мин, үз исемемне ишеткәч, ялт итеп әлеге абыйга борылып карадым. Фәрит Миргалим улы, гадәттәгечә киң елмаеп:

—Менә бит Фоат, шушы егет инде синең иҗатың хакында мәкалә бастырган укытучыбыз.

Әлеге кеше, минем яныма килеп, көрәктәй кулларын сузды:

—Мин Мәхмүт абыең Хәсәнов булам. Менә, минем хакта язганнарыңны укыгач, рәхмәт әйтергә килдем. Мине мона кадәр матбугатта игътибар белән әлләни кинәндермәделәр. Дөрес, Ф. Мусин, Р. Мостафин, Г. Ахунов, З. Камалов, Т. Нурмөхәммәтов, Р. Төхфәтуллиннар яздылар язуын. Әмма болай тулы итеп, иң әһәмиятлесе—әсәрләремне игътибар белән укып язу—беренче тапкыр гына әле. Син дә мәкаләңдә гел генә мактап утырмыйсың, уңышлы яклар белән бергә байтак кимчелекләремне күрергә күзең җиткән. Ин мөһиме шунда, син аларны әсәрләр белән таныш кеше буларак әйтәсең. Ә бит минем әсәрләремне күздән кичермичә генә сүз йөртү бер гадәткә әйләнде. Әдәбияттагы казанышларны әйтеп киләләр дә, берәр кимчелек күрсәтү ихтыяҗы туса, мина тиеп китәләр. Син алай эшләмәгәнсең, шуңа күрә син әйткән төгәлсезлекләрне дә кинәнеп кабул иттем. Белеп әйтелгән сүзнең кадерен күңел сизә, нахагы—җанны изә. Рәхмәт сиңа!

Шуннан соң ул, сынаулы караш ташлап, мина карап торды. Аннан сорап куйды:

—Күп кенә мәкаләләреңне, «Инешләр Иделгә кушыла» дигән китабыңны укыганым бар. Әмма үзеңне күргәнем юк иде. Союз тирәсендә йөрмисең, ахры?

—Мин язучыларны күреп белүгә караганда аларны иҗатлары аша өйрәнүне мәгъкуль күрәм. Бәя дә дөресрәк була.

—Анысы алайдыр да, аралашып та белешергә кирәк.

Ул, ничек шау-шу белән, өермә кебек килеп керсә, шулай ашыгып чыгып та китте.

Менә нинди кеше икән бу «Урман шаулый», «Кыюлар юлы», «Саф җилләр», «Юллар, юллар...», «Кама таңнары», «Инженерлар» «Саумы, Кояш» кебек әсәрләрнең авторы. Тормыш материалын сайлау ягыннанмы, мәүзуг билгеләү, мәсьәләне кую җәһәтеннәнме—гаять киң колачлы язучы булу өчен әнә шундый көч ташып торган, житез хәрәкәтле зат булу кирәктер шул. Мондый кеше кечкенә генә каләм белән ничек язып утыра икән, аның юан бармаклары үз гомерендә ничәмә-ничә ручканы кысып сындыргандыр, дип уйлап калдым мин нигәдер. Чын оста булып җитешкәнче, балта осталары да күпме балта сабының башына җитәләр бит... Кулларының матурлык тудыру маһирлеге арта барган саен, мондый хәлләр сирәгәя төшә, дуамаллык кими, аның каравы күңелен канәгатьләндерерлек нәкышләр күбәя бара. Мәхмүт Хәсәновның иҗади эволюциясе турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Әйтик, «Урман шаулый» повесте. Язучы табигатьнең үзе кебек нәфис килешкилбәтле, матур тавышлы Көлемсәр образын сурәтләүне максат иткән. Ул мона ирешкән дә. Ире Зарифка акылы белән тугрылыклы булып калырга тырышса да, институт тәмамлап килүче Нияз исемле егеткә күзе төшүе дә ана укучы алдында

әлләни куләгә тигерми. Нияз аңа булган мөнәсәбәтендә эзлекле калса, әлеге хәлнең ничек булып бетәсен бик үк чамалап та булмый. Автор исә сюжет сызыгының бу юнәлешен катлауландырмый. Әсәрдән күренгәнчә, тракторчы Көлемсәр өчен мәхәббәт—күңелне били торган бердәнбер нәрсә түгел. Аның әле җир сөрәсе, чәчәсе, урасы, гаиләне алып барасы бар. Хатын-кызны, шул рәвешле, иңнәренә бик авыр дөнья мәшәкатьләре күтәрүче итеп сурәтләү илленче еллар эстетикасында гадәти бер хәл иде. Аның иҗтимагый йөзен алгы планга чыгару традициясе егерменчеутызынчы еллардан килә. Бу җәһәттән Һ. Такташның Галия («Югалган матурлык»), Г. Кутуйның Галия («Тапшырылмаган хатлар»), Ш. Камалның Мәдинә («Матур туганда»), Г. Бәшировның Нәфисә («Намус»), М. Әмирнең Миңлекамал («Миңлекамал») һәм башка образлар билгеле бер калып булдыруга хезмәт иттеләр. М. Хәсәнов та хатын-кыз образларын тудыруда әнә шул такыр юлданрак бара.

Бу аның «Саф җилләр» романында да сизелә. Әмма, шул ук вакытта, авторның образларны тудыруда әлеге романда осталыгы арта төшүен билгеләү дә гадел булачак. Мәдинә һәм Хәдичә образлары сюжет хәрәкәтен тәэмин итүче геройлар булып әверелгәннәр икән, бу инде, һичшиксез, әсәрнең уңышын күрсәтә. Алар икесе ике төрле, капма-каршы язмышлы кешеләр. Әмма бу ике образны берләштерүче як—хатын-кызның эчке дөньясы. Моны тиешенчә сурәтләү өчен автордан аларның күңел дөньясын бик нечкәләп белү таләп ителә. Билгеле, М. Хәсәнов каләменә карата байтак дәгъвалы сүзләр әйтергә мөмкин. Әмма аның бер өстенлекле ягы—хатын-кыз күңелен гаять тирән белеп, аларның эчке дөньяларын тормышчан сурәтләү. Бу яктан аның белән тиңләшү күпләрнең хәленнән килми. М. Хәсәнов үзе әйткәнчә, «Рәссамда ир-ат акылы, хатын-кыз йөрәге, сабый баланың беркатлылыгы булырга тиеш[1]». Бу, әлбәттә, идеал. Ә гамәлдә төрлечә булырга мөмкин. Х. Сарьян кебек әдипләр ир-егетләрнең психологиясен тирән аңлап язган шикелле, М. Хәсәновта хатын-кызны аңлау көчлерәк иде. А. Расихның «Ике буйдак» әсәрендәге Рәхим белән Заһид төрле-төрле буйдаклар булган кебек, М. Хәсәновның Мәдинә белән Хәдичәсе дә бер-берләренә охшамаган толлар. Автор аларны шулай сурәтләп бирүгә ирешкән дә. Беренчесе—сугыш толы, икенчесе—әхлаксызлык толы. Мәдинәсе теләсә нинди шартларда да үз-үзен югалтмаучы, шәхесен тырышлык, үҗәтлек, матур эшләр белән раслаучы, Хәдичәсе исә—каршы искән җилгә туры карап барырга ихтыярсыз кеше. Язучы алтмышынчы еллар башындагы «җепшеклек вакытын» кешеләргә киң сулыш алып килүче «Саф җилләр» белән тиңли.

Язучы иҗатында аеруча тулы һәм камил эшләнгән хатын-кыз образы ул, әлбәттә—«Саумы, Кояш» романындагы Гөлбану. Бу инде Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендәге гаҗизлектән интегүче Гөлбану түгел, бәлки көрәшче хатын-кыз. XX гасыр башы Россия халыклары чынбарлыгында гаять катлаулы бер чор. Романда 1901 елдан алып 1919 елда Казанны чехлардан һәм акгвардиячеләрдән азат итүгә кадәр булган ике дистәгә якын ел аралыгында гаппади авыл кызыннан үз көрәшенең мәгънәсен аңлауга күтәрелгән Гөлбану сурәтләнә. М. Хәсәнов бу еллардагы түбән катламнан булган татар хатын-кызының хәлен шактый дөрес күрсәтә. Әлбәттә, татар хатын-кызларының Сабиралары (Г. ИбраҺимов. «Татар хатыны ниләр күрми»), Шәрифәбикәләре (Г. Гыйззәт. «Наемщик») дә, бу романда сурәтләнгән явыз Мәрхәмбикәләре дә бар иде. Ә алар янәшәсендә боларның авызларына гына карап торырга хөкем ителгән Гөлбанулар да булуын кем генә инкарь итә алыр икән? Бу образ М. Хәсәнов иҗатында иң уңышлы, тормыш һәм сәнгать дөреслеге югарылыгында иҗат ителгән дип тулы ышаныч белән әйтә алабыз. Дөрес, романның зурлар күзаллавы аша гына сурәтләнүе баштарак бала, соңыннанрак яшүсмер булган кызның күңел дөньясын бирүгә бераз комачаулык иткән итүен.

Кайбер язучыларның иҗаты сәнгатьчә эволюция ягыннан алга таба атлау юнәлешендә бармый, кире чигенүләр дә булгалый. М. Хәсәнов андый бер урындарак таптану этабын нефть чыгаручыларга багышланган әсәрләр тудырган вакытта кичерде. Бу хакта ул очерклар, хикәяләр, «Кыюлар юлы» дигән шактый күләмле әсәр иҗат итте. Соңгысы «Яңа горизонт», «Сүнмәс утлар» дигән кисәкләрдән тора. Конфликтның үткен булмавы, образларның җанлы булып җитмәүләре сәбәпле әсәр уңыш казанмады. Автор хәтта әсәрнең «Очар кошлар» дип аталган өченче

---

[1] Хәсәнов М. Саумы, кояш. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 254 б.

кисәген дә язды. Монысын инде укучылар шактый җылы каршылады. Әмма хәлне бу гына әлләни үзгәртә алмады.

Бу яктан «Шөгеровлар» романы бәхетлерәк булды. Эш «кара алтын» чыгаручы алдынгы, тырыш гаиләнең берничә буынын күрсәтүдә генә түгел (алар дөресендә плакатны хәтерләтәләр), бәлки татар халкының үткәнен, бүгенгесен кабатланмас хәл-әхвәлләрдә сурәтләүдә. Эш шунда, бу гаиләгә көтмәгәндә Америкадан Шандор дигән миллионер килеп чыга. Аның бабасы, океан артыннан килеп, узган гасыр башында безнең җирләребездә нефть эзләткән икән. Шушы Шөгеровларның Мөхәммәт исемле бабалары әлеге чит ил баена ялланып эшләп йөргән. Хәтта беркадәр Америкада ук торып кайткан. Әлеге Шандорның бабасы (бездә «кара алтын»га юлыкмаганы) үләр алдыннан васыятьнамә калдырган, анда үзендә ялчы булып йөргән Мөхәммәткә дә өлеш чыгарган, имеш. Аның оныкларыннан берсе булган бүгенге Шандор, аманәтне шушы Шөгеровларга тапшыру өчен, махсус бирегә киләсе иткән.

Менә шушы интрига укучының игътибарын тотып тора. Әсәр басылып чыккан елларда бездә капиталист кунакка өстәнрәк, читләтеп карау гадәти хәл иде. Б. Камалов моны барысыннан да кискенрәк итеп әйтте. «Капиталист капиталист булып кала. Ана безнең тормышта нормага әйләнгән күп кенә тәртип-мөнәсәбәтләр аңлашылмый[1]». Аның каравы, Шандорларның эш-гамәлләрендәге кайбер яклар ул чакта безгә дә аңлашылмый иде. Бер Америкаң бабайның Россиядәге икенче бабайга атап калдырган акчасын тапшыру өчен ничек инде җир шарының бер ягыннан икенче кырыена килмәк кирәк? Акчага нигезләнгән мөнәсәбәтләрнең нәкъ менә шундый төгәллек яратуын әле без менә хәзер генә күпмедер аңлый башладык. Монда яшь Шандорны, бурычны тапшырмауның гөнаһ икәнен белүдән бигрәк, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә намуслы булырга кирәклекне аңлау шушы ерак сәфәргә чыгарга мәҗбүр иткән. Автор капиталистка карикатура ясаудан ерак тора, аны эшлекле, акыллы зат итеп сурәтли. Шул ук вакытта Шөгеровларны анардан бер башка югарырак итеп гәүдәләндерергә тырышу да бар. Сиксәненче еллар башында автор башкача эш итә дә алмый иде.

Сүз уңаенда әйтергә кирәк, утызынчы еллар матбугатында әлеге Шандор турында хәбәр күзгә ташланган иде. Әдәбиятчы Г. Гали язуынча, әлеге нефть эзләүче Америка бае, бәхеткә юлыкмагач, үзе казыткан бер забойда харап була[2]. М. Хәсәновта, күргәнебезчә, бөтенләй башка хәл. Әлбәттә, язучының тормышта булганнарны үзгәртеп сурәтләргә дә хокукы бар.

Сәнгатьчә осталыкка күтәрелә бару да «Юллар, юллар...» романы үзенә бер казаныш булып тора. Әсәр хакында халык язучысы Г. Ахунов фикерен китерик. 1978 елда ул болай дип язган иде: «М. Хәсәновның иң уңышлы әсәре, һичшиксез, «Юллар, юллар...». Тик бу роман русчага бик тә йолкынып, койрыгы, канаты киселгән хәлдә чыкты, аны кабат чыгарасы бар[3]». Әйе, бу фикер җитмешенче еллар ахыры өчен дөрес иде. Әмма М. Хәсәнов иҗатта соңгы ноктаны куймаган иде шул әле. Ул 1967 елдан бирле яңа әсәр тудыру гаме белән яшәде. Ниһаять, 1984 елда ана соңгы ноктаны куйды. Бу роман «Язгы ажаган» дип аталды.

1986 елның июнь аенда М. Хәсәнов минем янга тагын килеп чыкты. Тирләгән, пешкән, култык астына бик калын төргәк кыстырган.

—Беләсеңме, Фоат туган, нәшрият соравы буенча Аяз Гыйләҗев шушы «Язгы ажаган» романының кульязмасына бәяләмә язган иде инде. Күп кенә тәкъдимнәрен әйтсә дә, нәтиҗәдә уңай карашын белдергән, бастырып чыгарырга фатиха бирәм, дигән. Әмма нәшрият аның белән генә канәгать түгел, Фоат Галимуллиннан да укытып алыйк әле, диләр.

Ул минем кулыма әлеге төргәкне тоттырды. Кульязма шактый саллы иде. Һәрхәлдә мең биттән дә аз түгел. Мин, үзем дә сизмәстән, әйтеп куйдым:

—Юк, юк, Мәхмүт абый. Хәзер институтта урак өсте. Сессия бара, җитмәсә читтән торып укучы студентларга да лекцияләр укыйсы бар...

Мәхмүт Хәсәнов һич кире каккысыз итеп минем кулны кире этте һәм кискен

---

[1] Камалов Б. Династия язмышы // Социалистик Татарстан. – 1984. – 25 июнь.

[2] Гали Г. Культура турында түгел, культурасызлык турында // Кызыл Татарстан. – 1931. – 27 апрель.

[3] Ахунов Г. Чишмәләр белән сөйләшү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 213 б.

генә әйтеп куйды:

—Алай димә. Тап вакыт. Укы. Эш синдә терәлеп калмасын. «Язгы ажаган» көзге яңгырга әйләнмәсен. Өч көн срок сиңа!

Соңгы җөмләне дустанә елмаеп әйтте.

Мин икеләнеп кенә төргәкне алып өстәлгә куйдым. Мәхмүт абый зур гәүдәсенә хас булмаган җитезлек белән чыгып та югалды.



*Әлмәт язучылар оешмасында очрашу. Утырганнар (сулдан уңга)—Сафа Сабиров, Марат Кәримов (Уфа), Әдип Маликов, (?), Зәки Нури, Гамил Афзал, Юныс Әминов. Сулда басып тора—Мәхмүт Хәсәнов. 1971 ел.*

Мин кулъязманы өйгә алып кайттым һәм укый башладым. Теле әйбәт, җинел укыла, мавыктыра. Ашауны да, ал-ялны да оныттым, өч көн дигәндә укып та бетердем. Шунда ук уникe биттән торган бәяләмә яздым. Әсәрне һич кичекми китап итеп укучыга ирештерергә кирәк дигән нәтиҗә чыгардым. Роман 1987 елда минем «Ул тудырган дөнья һәм образлар» исемле кереш мәкаләм белән басылып та чыкты. Китапның соңгы битенә күз салыгыз, анда «рецензентлары А. Гыйләҗев, Ф. Галимуллин» дип куелган. Гадәттә китапны бастыру өчен бер рецензентның да бәяләмәсе җитә. Ә бу юлы икәү! Моны ничек аңларга? Эш шунда: әлеге әсәр сурәтләнгән тормыш материалы, үткәргән идеясе, чын хакыйкатьне гәүдәләндерүе белән яңа иде. Аны бастырып чыгарган өчен, күрәсең, нәшрият үз өстеннән җаваплылыкны бераз төшерергә тиеш тапты. Бәлки, икенче рецензент әйле-шәйле язса, бастырмый калырга да мөмкин булыр дип уйлаганнардыр.

Бу роман әдәбиятта үзгәртеп коруны башлап җибәргән әсәрләрнең берсе булды. Шуңа күрә ул сиксәненче еллар ахырының әдәби һәм сәнгати тормышында вакыйгага әверелде. Аның буенча күп серияле телефильм төшерелде. 1988 елда әлеге әсәр Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә лаек дип табылды. Сәбәбе—әсәрнең зур осталык, ихласлылык белән тудырылуында. Ә. Рәшитов «Мин «Язгы ажаган»ны халык язмышы эпопеясы буларак кабул иттем[1]», дип язган иде. Бу, чыннан да, шулай. Аны укыган һәркем үзенчә дулкынланды. Берәүләре күтәрелгән мәсьәләләрнең яңалыгы һәм үткенлеге, икенчеләре анда сурәтләнгәннәрнең үз нәсел-нәсәпләре күргәннәр белән аваздашлыгы өчен тәэсирләнделәр. Өченчеләрен бирелә хәрәкәт иткән геройларның язмышлары борчыды. Шуның өстенә роман төзелешендәге, формасындагы яңалыклар да игътибарны җәлеп итте.

Әсәр хатирәләр рәвешендә язылган. Әмма, искә төшерүләр табигый рәвештә бүгенге хәлләр белән үрелеп бара. 1922 елдан башланган вакыйгалар тезмәсе 1957 елда өзелеп кала, ягъни утыз биш ел эчендә кешеләр, кичергән фаҗигале хәлләр гәүдәләнә анда.

Роман кискен вакыйга белән башланып китә—авылча күмәк хуҗалык төзүчеләрнең берсе Хаҗи үтерелә. Аның хатыны Зәйтүнә шушы тетрәндергәч хәл нәтиҗәсендә баласын вакытсыз тудыра. Хатын, шул рәвешле, Рази, Таҗи, Һади исемле өч бала белән тол кала. Хикәяләүчене әлеге бертуган Зәкиевләр язмышы кызыксындыра. Дөрес, ул туганнарның кичерәкләре хакында артык хафаланмый. Ник дигәндә, алар тормышта үз урыннарын табуда артак мәшәкать чикмиләр. Таҗи салкын акылы, коры исәп-хисапка корылган фәлсәфәсе белән үзен җитәкче итеп раслый. Ул карьерага бару юлында бик үк чиста булмаган адымнар ясарга да мөмкин. Әтисе һәлак ителгән көндә туган Һади исә, киресенчә, бәхетен бары тик намуслы эшчәнлек һәм тырышлык юлы белән табу максаты белән яши, Шундый

[1] Социалистик Татарстан.—1987.—11 июль.

булганы өчен «җайсыз кеше» дигән исем казана.

Романда төп игътибар олы малай Газига юнәлә. Ул—яшьтән үк кыю, эшлекле, әтисенең якты исеменә тугры. Рабфакта, аннан медицина институтында укый. Фронтта—хирург. Әсирлек. Аннан котылгач булган газаплар, кыерсытылулар... Ягъни «әсирлектә булган» дигән кара күләгәнең артыннан тагылып йөрүе, күңел газаплары—гомергә калмас авыр йөк. Анын алдында байтак бурыч тора: сугыш башлану сәбәпле өзелеп калган укуын тәмамлап, табип дипломын алу; әсирлектә дә илгә тугры булганлыгын расларлык шаһитләрне эзләп табу; сөйгәне Гөлүсә язмышын белү, аны күрү бәхетенә ирешү.

Әмма романда барлык вакыйгаларны бергә теркәп торган образ—Иргали. Ул әсәрдә гаять катлаулы юл үтә. Гражданнар сугышыннан кайтуына әнисе ачтан үлгән, хатыны белән кызы да чак исән калганнар. Ярлылар комитетында да ул җылы сүз ишетми. Авылдагы фирка әгъзалары да аңа таяныч булырлык түгел. Гыйззәт хәзрәт кенә кешелекле мөнәсәбәт күрсәтә. Әмма бер очраклылык Иргалигә бәхет юлын ачып җибәрә. Ул йорт-җирле, атлы-тунлы булып китә, абзары мал-туар белән тула. Хәтта кибет тә ачып карый... Күмәк хуҗалыкка керергә атлыгып тормый ул. Мондый кеше ул елларда, әлбәттә, сыйнфый дошман дип карала. Нахак бәла тагып Себер җибәрелгән Иргалинең гаепсез икәнен укучы белеп-күреп тора. Бу анын язмышы белән кызыксынуны арттыра гына.

Иргали—халкыбызның затлы сыйфатларын туплаган шәхес. Тормышны хезмәт белән матурлаучыларга хас сәламәтлеккә, төпле акылга ия. Эштән тәм, ләззәт табучы. Себер урманнары уртасында, казык кагып, яңа тормыш башлап җибәргәндә, анын асыл сыйфатлары тагын да ачыграк күренә. Бу көчле рухлы, төпле акыллы, көч-куәтле кеше үзедәй кыерсытылганнарның таянычына әверелә. Табигый сайланыш нәтиҗәсендә дигәндәй үзенең ил агасы булуын раслый. Бу образ татар әдәбияты өчен зур яналык иде. Әсәрнең уңышы барыннан да элек анын белән бәйләнгән. Ф. Миннуллин романның яратып укылуын тагын «мелодраматик әсәр[1]» булуында күргән иде.

Кызганыч, шушы роман белән М. Хәсәнов үзенең иҗат юлын тәмамлады да. Каләме һаман камилләшә, шомара барганда гына туктап калды...

...1990 елның сентябрь башы иде. Без анын белән Язучылар берлеге бинасында очраштык. Монда буласымны белеп, ул махсус килгән иде. Икенче каттагы балконда байтак сөйләшеп утырдык. Ахырдан Мәхмүт абый болай диде:

—Әсәрләремне өч томлык итеп бастыру турында ризалык бар. Синнән кереш сүз. Күңел аны синнән көтә.

—Ярый, Мәхмүт абый. 21 сентябрьдә Кырымга барам. Күктүбәдәге иҗат йортына. Шуннан язып алып кайтырмын.

—Бәй, иртәгә мин дә шунда китәм бит! Без әле Кара Диңгез буйларында очрашырбыз да, болай булгач.

Әмма Мәхмүт абый «Алла боерса» дип әйтмәде булса кирәк. Әйтелгән көндә Күктүбәгә барып төшкәч, шунда хатыны белән ял итүче язучы Радик Фәизов авыр хәбәр ирештерде: моннан өч көн элек биредә ял итүче Мәхмүт абый Хәсәнов, телевизор карап утырганда, кинәт вафат булган. Аны машина белән Казанга алып кайтып киткәннәр...

Йөрәге тибүдән тукталып калган көнне Мәхмүт абый, ничектер, үзен җинел хис итеп, тау итәкләрендә, Кара диңгез ярындагы комлыкларда йөргән, дөньядан китеп бару, кем әйтмешли, ике ятып бер төшенә дә кермәгән. Әмма сулар сулуын беткәч, гомер дәвам итә алмый шул.

...Мин Мәхмүт абый сораган кереш мәкаләне яздым. Ләкин ул әйткән өч томлык чыкмады. Үзе юкның—күзе юк, диюләре шушыдыр.

Мәхмүт Хәсәнов әдәбиятыбызда үз сукмагын салды, шул сукмак буйларында ул иҗат иткән әсәрләр калды. Алар бүген дә рухи байлыгыбызның матур бизәкләре булып яши.

♣

[1] Миннуллин Ф. Балта явызлар кулында.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.—134 б.



Ирек Сабиров

# ФИКЕР БӨРТЕКЛӘРЕ

•

Чиләбе өлкәсенең Законнар чыгару җыелышы бинасында зур бер тантана булды. Халыклар бердәмлеге көненә багышланды бу. Рус, татар, башкорт, казакъ, кореялылар һ. б. милли мәдәни үзәкләрен чакырып, кемнәрнедер бүләкләделәр, кемнәрнендер чыгышын тыңладылар, төрле милләт артистлары җырлады, биеде.Шушы чараны алып баручы хатын бик матур итеп Русиянең күпмилләтле дәүләт икәнлеге, һәр милләтнең ихтирамга лаеклы булуы турында сөйләде.

Ә соңгы җөмләсе менә мондый булды: "Мы разные, а все вместе мы—русские, русский народ".

Вәссәлам.

•

"Глобальләшү һәм татар вазифасы" дигән мәкаләсендә Рашат Сафин зур һәм җитди темага кагылган. Тирән уйлап язганлыгы сизелеп тора. Ләкин нигә фантастика кебегрәк кабул иттем мин аның бу язмасын? Чөнки "татар вазифасын" (ягъни кешелек игътибарын Рәсүлебез тәгълиматы буенча яшәү культурасына юнәлтү миссиясен) тормышка ашырырлык көч, ул көчне оештырырлык шәхес юк бүгенге җәмгыятьтә. Л. Гумилёв әйтмешли, пассионарийлар кирәк.

Тик барыбер—афәрин! Төзек, аңлаешлы теория.

•

Фәүзия ханым Бәйрәмованың иҗтимагый эшчәнлегенә гомер буе бераз сагаеп карыйм, "арттырыбрак җибәрә бу,"—дип уйлап куйган чакларым да булды.

Ә язганын кызыксынып укып барам. Һич тә гомуми агымга бирелми ул, һәр мәсьәләдә үз фикере бар. Менә, "МЖ"да болай дип язган: "...иҗтимагый оешмалар гына халыкны оештырып тора алмый. Милләт эшләре буенча министрлык булдырырга вакыт җитте..."

Хак сүз!

Әмма... Милләт министрлыгы, бәлки, бер булдырылыр, тик тәгаен беләм: татар милләте министрлыгы булмаячак ул. Димәк, аның функциясе татар

---

Ирек САБИРОВ (1950)—*язучы; «Манзара», «Яшим», «Апрель» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чиләбе өлкәсендә яши.*

милләтен үстерү түгел, ә әлеге дә баягы "халыклар дуслыгын үстерү" булачак.

Чынбарлыгыбыз шундый.

•

...Ләкин СССР рус дәүләте генә түгел бит ул. Ул безнең дәүләт тә булган. Көчләп, куып кертелгәнбез, әйе, әмма бу төзелешләрдә минем дә өлешем бар.

Аны сүгү—үземнең тарихымны сүгү була. Шуна күрә мин сүгенеп түгел, ачынып сөйлим ул заман ахмаклыклары турында.

•

"Берүзем яшәсәм, кайгы-мәшәкать тә булмас иде: чыгып кит сәфәргә, әллә нинди илләр анда, океаннар..."

Кайтып сөйләр кешең булмаса, ни пычагыма кирәк ул...

•

Сүз дә юк, мәхәббәт—гүзәл хис ул. Ләкин ирле хатынның бүтән ир гә мәхәббәте һәм шул мәхәббәткә буйсынып никахлы ирен ташлавы турындагы сюжет минем күнелдә чиста тойгылар тудырмый. Ә Рәмзия Габделхакова "Зинһар, югалма..." повестенда Илдания белән Раил арасындагы мөнәсәбәтләрне Галиябану белән Хәлил, Мәйсәрә белән Булат арасындагы мөнәсәбәтләр кебек итеп тасвирлый. Аерма җир белән күк арасындагыдай. Раилне аңларга була, ул тол ир. Ә Илданиянең ире бар бит! Балалары булмаса да, бу бит гаилә дип атала. Әлеге гаиләсенә, әлеге иренә карата кылган хыянәтне киләчәктә яна гаиләсенә карата да кылмас дип кем әйтер? Бу сюжетта, бу повестьта Раил белән Илдания унай геройлар булса, Хәмит кем? Ул кызганыч, ләкин тискәре герой түгел бит! Хыянәтчеләр күп дөньяда. Анна Каренина, әнә, хыянәте өчен фаҗига белән түләгән. Ә монда—happy end,—бәхетле азак!

•

Бер әби сөйли: "Кырык беренче елдан шахтада эшләдем. Иртән эшкә барабыз—үтереп йокы килә, изрәп китәм. Сискәнеп уянам—юл уртасында тезләнеп утырам икән."

•

"Казан утлары"нда Нур Әхмәдиев шигырьләре. Тирән мәгънәле юллар. Ләкин бары рифмаланган фәлсәфә генә. Бераз канат куйсаң, менә дигән шигърият булыр иде. Юкса барысын да дөрес яза, тик күзендә яшь күренми.

•

Кайдадыр бүтән тормыш булырга тиеш. Минем тормыш монда түгел.

•

Үкенмим. "Их, тегеләй эшләгән булсам, болай иткән булсам,"—дип уфтану—акыллы кеше эше түгел ул. Әйе, язмышымда хаталар байтак булды, мин аларны күрәм һәм аңлыйм. Ләкин ялгышулар да, уңышка ирешкән мизгелләр дә, фаҗигаләрем дә, шатлыкларым да—мин үзем ул, минем язмышым, минем бердәнбер гомерем. Шул гомеремә үкенеп, яшәвемнең мәгънәсен юкка чыгарыйммы?

Үкенмим. Һәм шуны холкымның иң кыйммәтле сыйфатларымның берсе дип саныйм.

*

Рафаэль Мостафинның ("МЖ", №31, 2005) "бүгенге татар авылының, үзенең чәчәк ату чорын кичереп, туктаусыз түбәнгә тәгәрәвен" тасвирлап язган мәкаләсе, әлбәттә, бик урынлы. Ләкин ул да үзенең әңгәмәсен чарасызлыктан аптырап тәмамлый: "Өметләрне сүндерергә ярамый,"—ди. Әмма...

Без мәсьәләләрнең көчебездән килгәннәрен көчебез җитмәгәннәре белән бутый башладык, минемчә. Бүгенге авылның (татарныкын гына түгел!)"түбәнгә тәгәрәвен" туктатырлык көч табып буламени бу дөньяда? 40-50 ел элекке вакыйгаларга кире кайтып булмаган кебек, авылның ул замандагы халәтен дә тергезү мөмкин түгел инде. Ә авыл язмышы белән милләт язмышы арасына тигезлек билгесе кую—минем нәселем менә шушы бүген яшәгән фатирым тузып җимерелгәнче генә яшәячәк диган кебегрәк була ул. Әйе, күп гасырлар буе авыл татар милләтенең (татарныкының гынамы?) фатиры булып хезмәт итте. Хәзер авыл үзгәрә. "Түбәнгә тәгәри", "югарыга күтәрелә" дигән төшенчәләрне куллану дөресме монда? Тарихта прогресс, регресс дигән нәрсәләр юк. Үзгәрешләр бар. Бер сыйфат икенчесен тудыра. Авылның бүгенге үзгәрүе—кризис аркылы, бетә язып калу аркылы яңа сыйфат булдыруыдыр, бәлки? Авыл хуҗалыгы кеше дөньясына барыбер кирәк, шуңа күрә, бәлки, без белгән, без күнеккән авыллар урынына бер кырык-илле елдан бай, төпле, нык, ләкин аз халыклы хуҗалыклар үсеп чыгар. Һәрхәлдә, зур һәм тату гаилә булып, үзенчә бер дөнья булып үзенең кабатланмас кануннары буенча гомер иткән авыллар, ни аяныч, тарихта гына калыр, күрәсең.

Ләкин милләт—бөтенләй бүтән төшенчә бит ул. Милләтнең масштабы да, тарихи озынлыгы да бүтән. Милләт язмышын авыл язмышы белән тәңгәлләштерү—милләтнең өметсезлеккә дучарлыгы белән аңлы рәвештә килешү кебек була бит ул.

Элегрәк әйткән сүземне (миңа кадәр шундыйрак фикерне Илдус Гыйләжев әйткән иде) кабатлыйм: авыл бетә дип уфтануның мәгънәсе юк. Татарлыкны саклау көче буларак авыл үзенең әһәмиятен югалтып бара. Урбанизация—без уйлап чыгарган һәм безгә буйсынырлык нәрсә түгел. Безгә татарлыкны шәһәр шартларында саклап калу һәм ныгыту механизмнары булдыру турында уйларга кирәк.

*

Мөхәммәт Садриның 1956 елда чыккан "Йөрәк тибүе" исемле җыентыгы кулыма төште. Монда күбесенчә пропаганда, плакат, штамп фразалары. Рәсми идеологиягә иярмичә язылган шигырьләрендә исә (аеруча—сугыш елларында язылган "Сәлам хат", "Идел егете атын эчертә", "Агыйделкәй суы", "Сөям мин", "Җавап хаты" һ. б.)—чын шигърият, чын лирика.

Шунысы кызык: аның байтак шигырьләре аралаш рифма белән язылган.

*

Марат Әмирхановның "Мөкәррәмә" повестен укыйм.

СССР—Туган ил иде бит, Ватан иде. Ә Ватан белән горурланырга кирәк. Һәм горурландык та без. Тик менә хакыйкать ярылып яткан мондый әсәрләрне укыганда горурлык тамакка тыгылып кала. Мондый Мөкәррәмәләр меннәрчә бит! Бөек империянең мескен коллары. Менә әле бу көннәрдә, шәһәр хакимияте әгъзасы буларак, "Җиңүнең 60 еллыгы" медальләрен тапшырып йөрим. Сугыш вакытында колхозларда, заводларда эшләп саулыкларын

югалткан әбиләр "Президент бүләге" дип бирелгән тәтигә чын күңелдән куаналар, бичараларым...

•

Була шундый әсәрләр: теле дә, сюжеты да шаккатырлык түгел, тик бер укый башласаң, аерылып булмый. Хисам Камаловның "Үксезләр" романы да шундый. Утызынчы еллардагы ерткычлыклар, кырыгынчы-илленче-алтмышынчылардагы башсызлыклар һәм шул җирлектә кемнәрнеңдер хирыска бирелеп түбәнгә тәгәрәве, ә кемнәрнеңдер, намусын сатмыйча, кешелекле һәм хезмәтчән булып калулары—без күп күргән-укыган һәм үз башыбыздан кичергән хәлләр. Шулай да роман "үзен укыта". Әллә чынлап та текстларда энергетика дигән нәрсә бармы?

•

1999 елда чыккан "Татарский энциклопедический словарь"да Таһир Якуповны тапмадым!

•

Күп айлар буе зур күләмле чәчмә әсәр яза башларга җыенып йөрим. Уйлар да, образлар да, сюжет та бар.

Ләкин менә "Казан утлары"нда "Бәхетсезләр бәхете" романының икенче китабын йотлыгып, кай урыннарында күз яшьләремә тыгылып укып чыктым да, уйга калдым: укучыны менә шушылай тәэсирләндерерлек итеп язарга көчем, тойгыларым, сәләтем җитәрлекме минем?

Автор, Фоат Садриев, үзе шушы вакыйгалар арасында кайнагандыр, чөнки персонажлары, аларның холык-фигыльләре бик ышандырырлык. Аеруча Ирек Сабитов образы.

•

Фаҗигага белән тәмамланган әсәрләр гадәттә күңелемә ятмый. Мин әдәбиятны кешелек дөньясының бик көчле тәрбияви факторы дип саныйм,шуңа күрә әсәрләрнең фаҗигале ахыры кешеләрдә төшенкелек, өметсезлек тудыра, дип уйлыйм.

Ләкин Вахит Имамовның "Япон татары" повесте, Касыйм хаҗиның үлеме белән тәмамланса да, бөтенләй бүтән төрле тәэсир калдырды. Беренчедән, повесть үзе мин монарчы белмәгән дөньяны сурәтли. Революциядән соң Харбинга качып киткән рәсәйлеләр турында күп укыганым бар, ләкин монда— татарлар язмышы. Шуның өстенә әле, Харбинга да кызыллар кулы сузылгач, татарлар Япониягә килеп урнашып тамыр җәяләр. Япониядә—зур татар җәмгыяте, мөселман ширкәте! Мәчетләре, мәдрәсәләре...

Касыйм туган авылында үзе җибәргән йөз мең долларга ашык-пошык, килбәтсез итеп салынган мәчетне күргәч, йөрәге түзми егыла. Ләкин бу эпизод аны кызгану хисеннән мең тапкыр көчлерәк безнең үзебезгә гарьләнү хисе уята. Касыйм соңгы гозерен хатыны Салисәгә әйтә: "Берүк, илгә алкайтып җирлә",—ди. "Илгә" дигәне—Япония инде аның. Безнең өчен, Русия татарлары өчен, моннан да усал шелтә булырга мөмкинме!

•

Ир белән хатын, егет белән кыз, ата-ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләрнең асылы, сере безгә, ни кызганыч, гомеребезнең соңгы елларында гына ачыла. Их, дисең, элегрәк аңлаган булсам аны...

*

"Идел"дә Туфан Миңнуллинның "Татарның әхлакый кодексы" чыгып бара. Мин аның бер-ике җөмләдән торган кагыйдәләрен түгел, җентекле шәрехләрен бирелеп укыйм.

Байтак нәрсәгә күзем ачылды.

*

Равил Фәйзуллин бер мәкаләсендә: "...Җир йөзендә татар кимемәде дип уйлыйм,"—дип үз-үзен юата да, "бетә торган милләт түгел бу!"—дип куя.

Алай үз-үзебезне юатып яшәсәк, бетүебез дә ихтимал.

*

2004 елның марты. Матбугат йортында Рафис Корбан яныннан чыгып барам. Коридорда көтмәгәндә Шәүкәт абый Галиевне очраттым. Егерме минутлап сөйләшеп тордык. Мин абайлаган, ләкин акылым барып җитмәгән бер акыллы фикер әйтте ул: "Башыңа килгән шигъри фикерне кичектермичә язып куярга кирәк. Юкса очып юкка чыга ул. Йә үзгәрә. Үз халәтең дә үзгәрә. Мин моннан берничә ел элек язып куйган фикерләремне танымыйм. Шуңа күрә дә әле—язганыңның көнен-аен-елын да куярга кирәк."

*

*Инде син дә чит туфракта сүнгәч,*
*Гакылың җыя алмый ятарлык:*
*Җир Шарында мең ел төзгән соңгы*
*Каралтысы кырыла татарның.*

Айдар Хәлимнең бу шигырен 2004 елның 21 февралендә укып утырам. Колагыма радио хәбәрләре кереп тора: бүгенге көн ЮНЕСКО тарафыннан "Туган тел көне" дип игълан ителгән икән. Чиләбе дикторы, бик тә горур тавыш белән, "безнең өлкәдә берничә дистә телдә сөйләшүче халыклар яши,"—диде.

Бердәнбер татар газетасын чыгаруны дәвам итәр өчен акча юк, ике айга бер чыга торган бердәнбер ун минутлык телетапшыруыбызны ябарга торалар...

*

Һәр үлән төренең, һәр хайван төркеменең табигатьтә үз урыны, үз куышы бар. Бер бөҗәген генә югалтса да, табигать мең аһәңен җуяр кебек.

Ә милләт? Ә һәр милләтнең теле, сәнгате?

*

Истә, истә: яшәү дәртемнән хисләрем ташып: "Дөнья матур, яшәве рәхәт!"—дип кычкырасы килгән мизгелләр еш була иде яшь чакта. Хәзер исә, чак кына шатлык туса, шундук бераз онытылып торган хәсрәт искә төшә. Нәкъ Газинур Морат әйткәнчә:

*Һава ерып, әнә, кошлар оча,*
*Кош томкандай яна күзләрең.*
*Күкне иңләп очкан кошка баксаң,*
*Искә килеп төшә үз хәлең.*

•

*Алма биреп кызыктырып,*
*Бу дөнья алдый инде:*
*Ятлардан калган ярларны*
*Сөяргә калды инде...*

Рафис Корбан шигыре бу. Анда һәм миндә генә түгел, һәр кешенең күңел түрендә гомер буе әллә нинди гарьячи: ниндидер әһәмиятле бер өлештән мәхрүм булганлык хисе.

Ә бер-берсе белән аралашканда тышкы кыяфәте белән жор булырга, сер бирмәскә, мескен булып күренмәскә тырыша кешеләр...

•

"Курчак язмышы... Үз язмышын оештырудан мәхрүмлек..."

Факил Сафинның "Саташып аткан тан" романында бу сүзләрне укыгач, уйлап куйдым: бу дөньяда кем генә үз язмышына үзе хужа икән? Кайсыбызның язмышы—курчак язмышы түгел?

•

Ни әйтсән дә, Равил Фәйзуллин—Равил Фәйзуллин инде ул. Дөрес, кайчак: "Әгәр рифмалар, ритмнарны үлчәп язса, тагын да шәбрәк булыр иде,"—дигән уй туа. Ләкин:

*Ваклар эреләнеп калыр—*
*без киткәч...*

Яки:

*Алмаларда калган җәйгә таң...*

кебек юлларны укыганда кагыйдәләр турында онытасын.

•

Ркаил Зәйдулла язган:

*Ә без? Ә без?*
*Без—имансыз түгел,*
*Ул—күз яшьтә, аккан каннарда...*
*Алар җирдә ятмый!—*
*Сөңге булып*
*Кабат калкып чыга манара.*

Әйбәт. Ләкин миңа мәчет манаралары сөңге булып тоелмый. Ни дисән дә, сөңге—корал ул, үтерү әсбабы. Минем өчен мәчет манарасы—иҗат, барлыкка китерү, тудыру билгесе, ирлек символы.

•

"Трамвайда сөйләшеп утырдык. Ахырда ачыклынды: ул б е з н е ң кеше икән. Менә сиңа мә, урысча сөйләшеп барганбыз!.."

Әти мәрхүм сөйләгән вакыйгаларда "үзебезнеке" дигән төшенчә еш очрый иде. Миңа әтинең шул сүзгә аеруча басым ясап сөйләве бик ошап бетмәде. Мин интернационалист бит! Безнекеме, безнеке түгелме, татармы, русмы, грузинмы—без барыбыз да тигез, дус, кардәш-туганнар, бер гаилә!

Әмма...

Бишенче дистәмне тутырып килгәндә генә күзем ачылды. Руслар белән никадәр генә дус булсам да, мин алар карашында башка (түбәнрәк?) дәрәҗә кешесе булып яшәгәнмен, ахры. Мин чын күңелдән, үземне алар белән бер җәмгыять әгъзасы дип санап, үзем белән алар арасында һич аерма күрмичә, ихлас аралашып яшәдем. Ләкин руслар арасында үткән утыз елдан артык

тормышымны бүген күз алдыма кайтарып бөртекләп, һәр вакыйгасын җентекләп тикшереп чыксам, күрәм: минем туганлык хисләремә шундый ук туганлык хисләре белән җавап биргәннәре булмады. Мин гомер буе (бердәнбер гомерем буе!) аларны өйрәнеп, аларга хас милли һәм дини гадәтләрне белергә тырышып, саксыз сүзем белән алай-болай намусларына тимәгәем дип яшәдем. Алар исә минем милли хисләремне санга сугу түгел, хәтта бөртек кенә кызыксынмадылар да. Аңлау түгел—аңларга теләү дә булмады: хәтта иң якын, иң бирелгән дуслар тарафыннан да.

Кызык хәл: алар белгән, аларга таныш нәрсәләргә кагылып әңгәмә корсам, мине үз итәләр алар; әмма әз генә милли үзенчәлегем күренеп китсә, шундук игътибарлары сүрелә. Ягъни, син безне рус буларак кына кызыксындырасың, ә ят кеше буларак синең безгә кирәгең юк.

Бу юлларны мин явыз ният белән язмыйм. Русларда нык сизелеп торган бу милли эгоизм—аерым кешеләр гаебе түгел. Мин аны: "Менә, Фәлән Фәләнев тарафыннан күрдем,"—дисәм, дөрес булмас иде. Бу—зур милләтнең гасырлар буе шешеп көчәйгән авыруы. "Без бөек халык, без кечкенәләрне үз канатыбыз астына җыябыз, без аларны рәнҗетмибез, бары тик буйсындырабыз гына. Син татармы? Бул. Каршы сүз әйтмибез. Әмма русча сөйләш, рус мәдәниятен бел. Теләсәң, үз телеңне дә бел, ләкин анысы безнең эш түгел."

Ә мин "үзебезнең" кешеләр кадерен, соң булса да, аңлый башладым.

*

Зөлфәт—зур шагыйрь. Ләкин минем өчен аның иң көчле әсәре—шигырь турындагы уйланулары. "Шигырь—тормыш юлы,"—дип башланып китә аның бу язмалары. Шигърият һәм шагыйрь йөрәге турында шулкадәр дөрес, төгәл һәм үзәк өздергеч итеп моңа кадәр һичкемнең дә язганы булмагандыр.

*

Кайбер хыяллар, ниятләр әле дә тормышка ашкалый үзе. Әмма канәгатьләнү шатлыгына ирешкән минутлар елдан-ел сирәгәя бара инде.

*

Балачагымнан каныма сендерелгән тәрбиянең бер өлеше—әңгәмәдәшемне бүлдермичә тыңлый белү. Бу кагыйдәне гомер буе үтәп килдем дип күкрәгемне киереп әйтә алам. Әмма, ни гаҗәп, мин үземне әңгәмәдәшләремә карата никадәр ихтирамлы һәм игътибарлы тотсам, алар шулкадәр тупас булып, сүземне бүлдерәләр.

*

Больница палатасында ике карт, эшсезлектән зарыгып, сөйләшеп яталар. "Шул Горбачевтан башланды инде илдә таркалу,"—ди берсе. Икенчесе, әңгәмәдәше җөмләсен тәмамлаганны көтеп тә тормыйча:

"Минем дә һава үзгәргәндә уң аягым сызлый шул,"—ди. Мин әүвәл, авызымны юрган белән томалап, буылып көлдем. Аннары уйга калдым: бу—чукраклык түгел бит. Эчләре пошканнан гына сөйләшәләр, бер-берсен тыңлау, аңлау әллә ни кирәк тә түгел. Андый диалоглар тормышта күп ул. Кайчак мин дә якын күргән кешемә өзелеп-өзелеп хисләремне сөйлим. Ә ул, аптыраганнан бераз таптанып тора да: "М-да-а-а-а...—ди.—Минем дә булганы бар: бер ун ел элек Чиләбе уртасында карбюратор эштән чыкты. Ике сәгать казынып яттым».

•

Күптән сизәм: диваналар миңа бигрәк тә үз итеп карыйлар. Исәнләшкәндә куанудан йөзләре балкып тора. Үз ишләрен тануларымы микән? Әллә алар бар кешегә дә шулай ягымлымы?

•

Акны карадан, яхшыны яманнан аерып белергә, бутамаска шактый әйбәт өйрәткәннәр мине кече вакытымнан ук. Әмма бик гадиләштереп үзләштергәнмен мин ул хакыйкатьләрне. Менә бер якын танышым: завод директоры. Шәһәрдәге иң хәйләкәр алдакчыларның һәм чиктән ашкан комсызларның берсе ул. Ләкин үзе күңелгә бик ятышлы, сөйкемле кеше, акыллы әңгәмәдәш, файдалы киңәшче. Сүзләрен тыңлап утырсаң—фәрештә!

•

Теге яки бу шагыйрьнең китабында актарына-актарына гаҗәпләндергеч фикерләрне йә җөмләләрне, чагыштыруларны табып, шатланам: менә әйбәт әйткән, янәсе. Илдар Юзеевның исә бөтен иҗаты—"менә әйбәт әйткән". "Уйлый күңелем төрлесен" җыентыгын (1993) укыйм:

*Куларбамны тартып узган чакта,*
*Бөкерәеп, алга сузылып,*
*Икешәр дә өчәр машиналы*
*Күршеләрем кала кызыгып...*

Аның һәр шигыре иң беренче юлларыннан ук игътибарны уята, сагайта. Монда "менә бу җире әйбәт" дияргә мөмкин түгел, шигырь тоташ җәлеп итә укучыны.

*Васыятьләр әйтеп тормыйм...*
*Сездән дә шуны көтәм.*
*Озакламый күрешербез,*
*Яңа Бистәгә китәм...*

Китеп барды шул Илдар абый...

•

Шатлыклы шигырьләрендә дә, ә күбрәк хәсрәтлеләрендә, Харрас Әюп әллә кайларга алып китә.

*Сөяпләр куяр идем дә,*
*Кочаклап елар идем,—*
*Бирмиләр сине...*
*Тыңламый*
*Сүземне еллар минем...*

*...Тәкъдирләргә тиңнәр юк:*
*Кемнәр бар да, кемнәр юк!*
*Исәпләмәгән исемнәр,*
*Уйламаган көннәр юк.*
*..................................*
*Дөнья якты... Гүр кара!*
*Кем китә дә, кем кала...*
*Кая таба карасам да,*
*Ак каеннар ым кага...*

Ритмның җинеллеге фикернең фаҗигале тирәнлеге үзәк өзгеч итә...

*

Минем аңлавымча, сәнгать кешеләре, мәдәният хезмәткәрләре бик саф йөрәкле, нечкә һәм йомшак күңелле булырга тиеш. Менә мине аптырашта калдырган бер күренеш.

Культура сараенда тамашаларны алып баручы хатын белән сөйләшеп торам. Шул арада яныбызга җырчы хатын килеп басты. Араларында мондый сөйләшү булды:

—Мин кайчан җырлыйм?

—Казаклар хорыннан соң.

—Менә сиңа мә! Бу нинди юньсезлек! Хор алдыннан дип вәгъдәләшкән идек бит!

—Мин каян белим аны, әнә худруктан сора! Менә программа, ничек язылган—шулай алып барам, башымны катырма.

—Кем катыра? Ах, оятсыз! Мин әйткәнчә булмаса, бөтенләй җырламыйм мин, аңладыңмы шуны мингерәү башың белән!

—Җырламасаң ни, кемгә кирәк синең чиелдек тавышың! Бар, табаныңны ялтырат моннан, берәр кооператив бәдрәф юарга алыр сине, бәлки!

—Тинтәк!..

—Ахмактан ишетәм! Явызлыгың бугазыңнан ташып тора, шуңа күрә карачкы кебек кибеп беттең бит инде, тире дә сөяк тәнеңдә, күз салырлык җирең юк!

Бер ярты сәгатьтән концерт башланды. Шушы хатыннарның беренчесе икенчесенең сәхнәгә чыгасын болай дип игълан итте:

—Шәһәребезнең йолдызы, сәхнәбезнең сандугачы, яраткан җырчыгыз Фәлания Фәләнова!

Ә тегесе, сәхнәгә йөзеп чыгып, чытлыкланып елмая-елмая, оялган булып, "рәхмәт, рәхмәт,"—дип тәкърарлады.

Менә бу сәнгать ичмасам, чын-чынлап образга керү!

*

Ялгызлык—миңа бик кирәк халәт. Сәгатьләр буе китапларда актарынып, кәгазьләремне берәмтекләп, язгалап-сызгалап утыру—җанымның һәм тәнемнең табигый ихтыяҗы. Шул хаҗәтемне канәгатьләндерергә мөмкинлек булмаганда сәбәпсез ачуым чыга башлый. Ләкин ике-өч сәгать ялгызым утырып бераз талчыккач, сөйләшеп алырга теләк уяна—хатын янына чыгып аралашып керергә кирәк. Шуңа күрә ул өйдә булмаган чакта ялгызлыктан ләззәтләнә алмыйм. Ул өйдә булсын, әмма комачауламасын.

*

Бүтәннәр рәнҗетсә—үпкәләп була, үч саклап яшәргә була, ачуланышып, әйткәләшеп алып була. Шундый "җавап хисләр" йөрәкне бераз юата. Ә җәрәхәтнең сәбәбе үзеңдә булса, андый яралар, озак еллар буе бетәшмичә, сызлап газаплыйлар.

*

Йомыш белән бер конторга кердем. Пыяла аша күрәм—бик матур яшь хатын утыра: җитмәгән җире юк, валлаһи, идеал инде! Клиентлар булмаганга бик бирелеп ахирәте белән сөйләшә, "Тропиканка" турында бугай сүзләре. Мин касса янына килеп бастым, көтәм. Шул ук вакытта шушы фәрештәгә сокланып туя алмыйм, телемә әллә нинди назлы, җылы сүзләр килә.

Игътибарын җәлеп итәр өчен сак кына шакыдым. Мине гашыйк итәргә өлгергән гүзәлем күз ачып йомганчы бер убырлы карчыкка әверелде дә, күзләре белән мине үтәли атып тишкәндәй булды: "Чо скребёся-то! Вы чо, хочете, чтобы я на части разорвалася!"

Назлы сүзләрем әллә кая югалды.

•

Мәхмүт Әхмәтҗанов: "...Эш сөюче татарда бервакытта да "эш бүре түгел, урманга качмас", "эш тиләләрне ярата" дигән мәкальләр, мич башында яткан килеш урманга утынга бару, чуртан ярдәмендә теләгенә ирешү кебек әкиятләр булмаган. Тормыш никадәр генә кырыс булмасын, татарны тырыш хезмәте яшәткән..."

•

"Үзгәртеп кору" башланып, урлау, алдашулар гадәткә кергәч, бик күп төссез-килбәтсез кешеләр "өскә күтәрелде". Иномаркалар, коттеджлар, сәяхәтләр минсинайтим!

Башта, хәлнең көтелмәгәнлегеннән, көнләшкән кебек булган идем. Хәтта мәрхүм әтием-әниемә үпкәләү хисе дә баш калкытты: ник алар мине болай тормышка җайлашмаган итеп үстергәннәр икән? Әти гел тукып торды бит, "Байлыкка кызыкмагыз, укыгыз, белем алыгыз, һөнәр өйрәнегез—шунысы чын байлык аның",—диде.

Хәзер һөнәрлеләр, укымышлылар хәерчелектә калды, хәйләкәрләр, әрсезләр, караклар исә байлыкта коена. Минем уйларымның, рухым-җисемемнең юнәлеше—шигърият, иҗат, язу-сызу, китап; фикер артыннан теләк, теләк артыннан план—вакыт җитми. Ә "тегеләр" көннәр-айлар буе акча ягын кайгырталар.

Тора-бара борчылуым басылды. Аларның тормышы кызыгырлык-көнләшерлек түгел икән бит. Гомумән, нәрсә соң ул—матди байлык? Ярар, ике-өч машина алырсың ди. Ике-өч фатир. Хатынны, сөяркаләрне алтынга киендерергә була. Ә аннары? Тормышның эчтәлеге нидә? Мәгънәсе? Яшәвеннең бүтән максаты булмыйча, акча табып туздыру һәм ай саен яңа машина алу—яшәешеннең бердәнбер максаты икән... коточкыч мескен язмыш бит инде ул.

Дөрес, матди җитешлек кирәк. Әмма ул рухи тормышның нигезе буларак кына кирәк. Әгәр инде туклык идеологиясе җитәкче идеология дәрәҗәсенә күтәрелә икән, тормышның мәгънәсе чуала.

Ә мин исә әти-әни идеологиясенә тугры булып кала алуыма тын гына сөенеп, горурланып яшим.

•

25 апрельдә (2003) Троицкида Тукай бәйрәме үткәрдек. Таралышканда Искәндәр абый Шәмсетдинов мине таякка таянган чандыр гәүдәле, мыеклы бер кеше белән таныштырды. "Менә, Ирек,—диде,—Идел абый, Троицк театрының җитәкчесе һәм иң күренекле артисты."

Фамилиясен дә әйткән иде, исемдә калмаган. Сорарга кирәк булыр. Сораштырып, язарга кирәк мондый кешеләр турында. Һәр төбәктә татар тарихы бар, шулкадәр бай тәҗрибәле, ялкынлы тормыш кичергән бабайларыбыз соңгы елларын (айларын, көннәрен!) яшәп бетереп баралар. Өлгереп булырмы? Урыс губернаторларына, урыс мэрларына кирәк түгел бит бу!

*

“Идел”дә Аяз Гыйләжевнын Тәүфикъ Әйдигә хатлары чыкты. Акыллы фикерләре бик күп.

Тәүбә сүзләре байтак. Танылган әдипнең кайбер каләмдәшләренә ашыгыч, уйлап бетерелмәгән бәяләр биргән вакытлары булган, ахры. Үткәндәге рәнҗетүләренә үкенечен белдерә дә, шул ук вакытта тагын берничә замандашына багышлап кадаулы сүзләр әйтеп ала. Дөрес, бу—милләт язмышы өчен борчылып язылган. Ләкин—чиктән тыш аяусыз, кимсетүле бәяләр бирә ул.

Димәк, холкы шундый булган. Яхшымы бу, начармы дип фәлсәфә сатуның мәгънәсе юк, менә шундый кеше булган Аяз Гыйләжев, һәм—вәссәлам.

Ә үзенең тәүбәгә килүен белдерергә күпләрнең кыюлыгы әле дә җитми. Аяз аганың кыюлыгы да, акылы да җиткән.

*

Рафаэль Сибатның “Шаһ Тур” романын теләр-теләмәс кенә укырга тотынган идем. Мавыгып киттем—Урал шәһәрчеге, күмер шахталары. Нәкъ безнең Еманжелински инде. Ләкин, минемчә, язучы ашыккан, ундүрт еллык гомерне журналның илле битенә сыйдырган. Берничә эпизод—һәм менә сиңа мә: Әлтафның балалары да үскән, хатыны да ямен югалткан.

Авылларыннан кузгалып ят җирләрдә эшләп көн иткән татарлар тормышы зур эпопеяләргә лаек ул.

*

“Казан утлары” редколлегиясенең киңәйтелгән утырышы беркетмәсен укыйм. Равил Фәйзуллин: “Моннан утыз-кырык еллар элек һәр татар гаиләсендә диярлек “Казан утлары” һәм “Азат хатын” журналларын алдыру табигый бер күренеш иде. Хәзер вәзгыять бүтән. Әдәбиятны тәрбия өлгесе дип санаган буыннар китеп бара.”

Туфан Миңнуллин: “Башкортлар...чит өлкәләргә бушка китап тарата. Пермь, Оренбург өлкәләрендәге бөтен татарлар башкорт китабы белән тәэмин ителгән, ә татар китаплары юк...”

Ә мин исә: “Чиләбе өлкәсендә дә шундый ук хәл,”—дип өстим.Казанның читтәге татарларга битарафлылыгы аптыраштa калдыра мине.

*

Рашат Низаминың “Ике мөһаҗир” монологларында менә мондый юллар бар:

*Идел белән Урал арасы ла,*
*Гүя ике күзем арасы.*
*Бәйли-бәйли йөрәк яраларын,*
*Барасы да безгә барасы.*

Идел белән Урал арасы беренче чиратта—татар белән башкорт ул. Ләкин ни булды башкортка соңгы елларда? Чиләбедәге башкорт зыялыларының төп идеясе—татарга дошманлык. Минем өчен—Сәйфи Кудашны, Зәйнәп Биишеваны Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Бәшировларны укыган кадәр укып, Фәридә Кудашеваны Илһам Шакировны тыңлаган кадәр тыңлап үскән кеше өчен—бу бер дә аңлашылмый торган нәрсә. Әллә саташалар микән дип тә уйлап куям.

Ә Рашатның бу дүртьюллыгы бер укудан хәтеремдә уелып калды.

•

Солтан Шәмси "Низаглы йортта" дигән әсәрендә без гомер буе укып-ишетеп белгән вакыйгаларны—Мамай, Туктамыш, Идегәй, Аксак Тимер заманнарын, Куликово сугышын һ. б.—бөтенләй яңача яктырта алган. Моны укыганда шәхси хирыслык, нәфес һәм бүтән бозыклыклар каршында тарихи закончалыкларның никадәр көчсез икәнен сизеп торасың. Гомумән, тарихны гына түгел, бүгенге вакыйгаларны да бүтәнчә аңлый башлыйсың: тугрылыктан хыянәткә бер адым икәнен, яшәү белән үлем арасында бер мизгел, кеше гомеренең хакы бер тиен икәнлегенә күзең ачыла.

•

...Тормышта һәр эшкә шундый илһам белән тотынырга мөмкин булса иде, ә? Юк бит: ризык бирә торган эшем дәртләндерми мине, ә дәртләндерә торган шөгылем—ризык бирми.

•

Җиденче март кичендә завод идарәсенең бер бүлегендә эшләүче өч хатын, кечкенә генә табын корып, хатын-кызлар көнен бәйрәм итәләр. Бер-ике рюмкадан соң "Виновата ли я..." җырын сузып җибәрделәр.

Менә аларның җәмгыяви хәле: Ирина күптән түгел яшь бер алкоголикка кияүгә чыкты; Наталья ике тапкыр кияүгә чыгып аерылды, хәзер бердәнбер кызын ялгызы үстерә, шул ук вакытта мәгънәсез, ваемсыз тормышта әкренләп аска тәгәри; ә Тамарага илле тулып килә, үз хаталарының гарьләрен кичереп бетергән инде ул, хәзер эчкече улы белән җәфаланып яши.

Шулай, кечкенә генә кабинетта Русия хатыннары күптөрлелегенең тулы спектрын күреп була.

•

Соңга калып кына булса да, үземнең бер ялгышымны аңладым: мина гомер буе иң чибәр хатыннар иң акыллы да булып тоела иде.

•

Кешелек тарихының төп сюжеты—вак җинаятьчеләрне җәзалау һәм эре җинаятьчеләргә хөрмәт күрсәтү.

♣

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ШАЙТАН, ШӘЙТАН*** – *Шайтан* сүзенең тамыры борынгы гыйбрани *сатана* сүзе белән бер дип санаучылар бар. Р.Әхмәтьянов: "Төптә семит телләрендә "суд полициясе" дигән сүз булган", – дип яза. Гадәттә шайтан сүзен Иблис сүзенең синонимы дип карыйлар, ләкин бу төгәл түгел. Иблис-шайтаннарның башлыгы, аны *Иблис әш-Шайтан* дип тә йөртәләр. Коръәндә В.Порохованың рус теленә тәрҗемәсендә, шулай ук Рабит Батулла тәрҗемәсендә "шайтан" мәгънәсендә "Тагут" атамасы телгә алына. Әдәбиятта шайтанны *хәннас* дип атау да очрый ("аздыручы", "кызыктыручы" мәгънәсендә).

Борынгы гарәп телендә "шайтан" сүзенең "җылан" мәгънәсе дә булган һәм ул кеше исеме булып та йөргән.

Гомумән, гарәп телендә шайтан сүзе явызлыкка өнди торган һәр затка карата әйтелә.

"Шайтан" сүзенең күплек саны шәкеле: *шәйатин*. Шайтаннар, үзләренең башлыгы Иблис белән бергә, Кыямәт көненнән соң тәмуг утында янарга хөкем ителгәннәр. Иблискә дә, шайтаннарга карата да *рәҗим* (таш атып сөрелгән) эпитеты кулланыла (Коръән, 15:17).

Кешеләрне юлдан яздыру өчен шайтаннар Иблиснең төп кораллары. Алар уттан яки төтеннән яратылганнар, Иблис тарафыннан да тудырылырга мөмкин. Тышкы кыяфәтләре һәм исемнәре төрлечә була. Төрле илләрдә төркем-төркем булып яшиләр. Бигрәк тә Һиндстанда һәм Сүриядә явызлыклары белән яман атлары чыккан имеш.

Һәркемнең үз фәрештәсе һәм үз шайтаны бар дип ышаналар. Алар икесе дә кешенең кальбе өчен көрәш алып баралар.

Иң күп таралган фикер буенча, шайтаннар – җеннәрнең имансызлары һәм явызлары. Икенче бер фикер буенча, шайтаннар – баштан ук имансыз итеп яратылган һәм тәмуг кисәве булырга тиешле затлар, ә җеннәрнең кайберләре Аллаһка сәҗдә кылып, тәмуг газапларыннан котылырга да мөмкин.

Татар телендә шайтанга кагылышлы күпсанлы фәлсәфи мәкаль-әйтемнәр бар. Мәс., "Шайтанның дуслыгы дар агачына кадәр", "Шайтанга кирәк булса, Коръәннән дәлил китерә", "Хәерле эшне ашыктырмасаң, шайтан катыша", "Аргамакны байтал иярлә, әрвахны шайтан иярлә", "Алла шайтаныннан адәм шайтаны яман" шундыйлардан.

*//Адәми шайтан. Җени шайтан.*

***ШАМ*** *ф.* – **1.**Кич. *//Бу дөнйаны бакый санма, булыр фани, Тагатьдә бул шам, сәхәр вакты булса.* Мәүла Колый. **2.**Кичке аш. **3.**Сүрия. *//Шам җире. Шам шәриф* – изге Сүрия. Кәгъбәнең көнбатыштагы почмагы *әр-рөкен аш-шами* (Сүрия почмагы) дип атала. **4.**Димәшк яки Дәмәшекъ (Дамаск) шәһәре-*Бәләду Шам. //Шам кылыч* – Дәмәшкъ корычыннан эшләнгән кылыч. *Намазшам* – кичке (дүртенче) намаз,. ястү намазы, гыйшаэ намазы.

***ШАМАКАЙ*** *тар.* – *Шемаха* (Шәмәхә) сәүдәгәре, цирк клоуны мәгънәсендәге борынгы *шамахай* сүзеннән. Атаклы Шемаха ефәкләре төсен чагылдырган *шәмәхә* сүзе дә шул тамырдан (татар телендә *миләүшә төс* сүзе дә актив, Пермь һәм Киров

---

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

өлкәсе сөйләшендә шәмәхә мәгънәсендә *кукчин* сүзе йөри). Тел белгечләре Казан ханлыгы чорында һәм иртәрәк тә Идел буенда Шәмаха шәһәре циркач-клоуннары (әрмәннәр) гастрольдә йөргән дигән фикердә.

Шамакайны башкача *мәсхәрәбаз* дип тә атаганнар.

***ШАМАН***—Эвенк теленнән кергән сүз. Манжурча *симан*—шашынган дигән сүздән дип санаучылар да бар. Төрки телләрдә *кам* сүзе кулланыла, *бурган би* дигән сүз дә мәгълүм. //*Шаманлык итү—камлау* (рус теленә *камланье* рәвешендә кергән). *Шаманчылык* (шаманизм)—диннең иң борынгы формасы. Камлау төрки халыкларда да таралган була. А.В.Анохин "Алтайлыларда шаманлык буенча материаллар" дигән китабында Маңзыр исемле алтайлы шаманның ата-бабалары рухларына (әрвахларга) мөрәҗәгать иткәндә *Татар* исемле шаманны телгә алып, төрки телдә: "Абыкаем Татар-кам, атаклы һәм бөек кам,"—дип кабатлавы турында яза.

"Шаманның төп коралларыннан берсе—махсус чыбыркы булган. Аны камчы чыбыркысы дип атаганнар. Тора-бара бу тезмәдәге чыбыркы сүзе төшеп калган (чөнки кам сүзе онытылган, шаманизмны башка диннәр кысрыклап чыгарган) һәм камчы чыбыркыны белдерә башлаган." (Р.Әхмәтьянов.)

Шаманлык сәләте ир балага да, кыз балага да әтисеннән һәм әнисеннән күчә алган. Шулай да, мәсәлән тувалыларда, хатын-кыз шаманнар саны 25-30% ка кимрәк булган. Көнбатыш тувалылар шаманнарны гадәттә кичерәк бура эчендә җирләгәннәр.

Казакъ мәгърифәтчесе Чокан Чыңгыз улы Вәлихановның (1835-1865) "Кыргызларда шаманлык эзләре" дигән хезмәте бар.

Татар халык ырымнарында да (мәс., "Бизгәк теле" ырымында) борынгы шаманнар (камнар) әйтә торган текстларга охшашлык сизелә.

***ШАТРАНҖ, ШАТРӘНҖ*** *ф.*—Шахмат уены. Ривайәтләргә караганда, аны Ләҗлаҗ исемле кеше уйлап тапкан. Телдә *шатрач* варианты да бар. //*Юлдан бабаем барды, Шатрач тактасы төшеп калды*. Табышмак (җавабы—*чабата эзе*).

Хәзерге вакытта телдә *шахмат* сүзе генә кулланыла, татар теленә ул рус теле аркылы килеп кергән. Фасмер бу сүзне руслар немец теленнән алганнар дип исәпли, ләкин немец телендә шахмат уенының тәмамлануын белдерә торган schachmatt ("корольгә мат") гыйбарәсе 1691 елдан гына күзәтелә, ә шахмат уены мәгънәсендә аларда schachspiel сүзе йөри. Фарсы телендәге *шаһ мат*—сүзгә сүз тәрҗемә иткәндә "кыйналган, җиңелгән шаһ" мәгънәсен бирә. Гарәп телендә исә "мәүт" *үлде* дигән сүз, ягъни "шаһ мәүт" *шаһ үлде* дигән мәгънәдә булып чыга. П.Я.Черных үзенең "Историко-этимологический словарь современного русского языка" сүзлегендә "шахмат" сүзе Кара диңгез буендагы ирани кабиләләр (мәс., осетиннар) аркылы килеп кергән булырга мөмкин дип саный. "Мат" сүзе борынгы татар әдәбиятында да күзәтелә. Мәс., С.Сараиның "Сөһәйл вә Гөлдерсен" дастанында (1394) түбәндәге юлларны укыйбыз:

*Сөһәйл хөсне ирүр Йосыфдин гали,*
*Итәр мат алманы йөзенең али.*

Ягъни:

*Сөһәйлнең чибәрлеге Йосыфтан да артык,*
*Алсу йөзе алманы да җиңәр, мат кылыр.*

Шахмат уенын Ислам әһелләре башта дошманнарча каршылаганнар, ләкин X гасырлардан соң аның белән килешкәннәр дияргә мөмкин. Сәхл ибн Әбү Сәхл (404/1013 елда вафат): "Әгәр дә мөлкәтеңә зыян килү куркынычы янамаса, намазны калдырмасаң, шахмат уйнау ике дус өчен күңел ачу гына ул,"—дигән. Шулай да шахмат кебек шау-шусыз уен гарәпләр өчен ят булган.

Бу уенны Идел буе Болгар илендә дә белгәннәр.

Суфичылыкта шахмат фигураларының атамалары һәм шахмат терминологиясе үзенчәлекле мәгънәләрдә кулланылган: шаһ—мөршидне, ферзь (фәрзин)—гашыйкны, фил (әл-фил)—горурлыкны, ат—нәфесне, күңел тартуны, пийадә (пешка)—мөхибне, суфины, "мат" ("мәүт"—үлем) исә нәфеснең фәна булуын белдергән. Хатыйп Миңнегулов Сәйф Сараиның "Гөлестан бит-төрки" әсәре турындагы хезмәтендә пешканың "бәйдәкъ" дип, ә шахмат тактасының "мәгънә наттасы" дип аталуын әйтә.

Шахмат уенындагы "ладья" ("тура") фарсыча "шаһ рухы" — "шаһрух" дип аталган. //*Тормыш шатранҗын уйнау* (Котбтан). *Шатранҗ бәсаты* — шахмат тактасы. *Нәвадир әш-шатранҗ* — шахмат мәзәкләре.

***ШАТРАНБАЗ*** *ф.* — Шахматчы, шахмат уйнаучы. Шәригать буенча, мондый уеннарны акчага уйнау тыела.

Күренекле татар шагыйре Шәйхи Маннур гадәттән тыш шатранбаз иде. Җәй көне аны Казан шәһәре үзәгендәге элекке Ленин бакчасында эскәмиядә кызыл галстуклы берәр "вундеркинд" белән шахмат уйнап утырган килеш күрәсең, кичләрен исә ул иске шахмат клубында тәмәке төтене эчендә тәмам уенга бирелеп, дөньясын онытып утырыр иде (шатранбазлар арасында кушаматы "шахи Маннур" булып, өстәвенә басым ике сүзнең дә беренче иҗегенә төшереп әйтелә иде). Шахматка нисбәтле яраткан сүзләре дә бар иде Шәйхи аганың. Шуларның берсен ул бик тә канәгать кыяфәттә әйтә: "Бер кәррә шах!" — диюе еш кына "дошман" якны уйланырга мәҗбүр итә торган иде. "Бер кәррә" дигән сүзен үзе "бер тапкыр" дип аңлатса да, бу очракта "кәррә" сүзе асылда гарәпчә "һөҗүм", "атака" мәгънәсендә булгандыр дип уйлыйм ("шаһка бер һөҗүм").

***ШАҺ ТАМЫРЫ*** — Кешенең муенында уң һәм сул якларда урнашкан зур веналар-югулярислар. Алар канны баштан йөрәккә китерәләр һәм канны йөрәктән башка алып баручы артерияләргә пар киләләр. Шаһ тамыры "Каф" сүрәсенең (50) 16 нчы аятендә телгә алына: "Тәхкыйк кешене без халык кылдык, вә кешегә күңеле нәрсәне вәсвәсә кылганыны без беләбез, вә без аңа җилкә тамырыннан да якынракбыз." Бу термин Р.Батулла тәрҗемәсендә — "муен тамыры" дип, Фәрит хәзрәт Сәлман тәрҗемәсендә "богау кан тамыры" дип алынган (рус телендә ул "яремная вена" дип атала, ихтимал, "богау" сүзе шуннан килеп эләккәндер). И.Ю.Крачковский тәрҗемәсендә бу тамырның "вена" дип түгел, бәлки "шейная артерия" дип аталганлыгын әйтеп китик.

***ШАҺБАЛ*** *ф.* — Кош канатының иң зур каурые, чылгый. Гадәттә язу каләмен шуңардан ясаганнар.

***ШАҺИНШАҺ*** *ф.* — Шаһлар шаһы. Иран шаһларының титулы. Татар телендә *шаһ-шаһин* сүзе дә йөргән. Исламның башлангыч чорында мөселманнар өчен Иран шаһиншаһларыннан да яманрак дошман булмаган. Ривайәткә караганда, Мөхәммәд Пәйгамбәр шаһиншаһны Аллаһ тарафыннан ләгънәтләнгән шайтан кебек итеп күргән. Шуңа күрә хәлифәттә гарәпләр өстен чакта шаһиншаһ титулын кайтару турында сүз дә була алмаган. Ләкин 645 елда Багдадта хакимияттә фарсы династиясе урнашкач, бу династия вәкилләре шаһиншаһ титулын алганнар.

***ШАҺСУАР*** *ф.* — Оста җайдак. //*Кем тәйц сорса атым ул шаһсуар, Атамыз Мәхмүд., догачы, исмем Мөхәммәдьяр.* Мөхәммәдьярның бу бәйтен Шакир Абилов "Атым кем дип сораса ул шаһсәвар, Атам — Мәхмүд, догачы, үзем — Мөхәммәдьяр" дип тәрҗемә итә һәм бит астында "шаһсәвар" / "шаһсуар" сүзенә: "бирелә: хөкемдар" дигән искәрмә биреп китә. Әмма монда бу сүз туры мәгънәсендә кулланылган төсле. Шулай гөманлаганда без Мөхәммәдьярның кушым аты — "оста җайдак" булуын аңлыйбыз, ягъни аның портретына тагын бер сызык өстәлә.

***ШӘҖӘРӘ*** *г.* — **1**.Агач, куак. **2**.Нәсел агачы, генеалогия агачы; нәсел-ыруның тармакларын күрсәткән схема. Борынгы төркиләрдә *каба йегач* ("биек агач" мәгънәсендә). Татарларда һәм башкортларда күбесенчә гаилә-нәселдә очрый торган исемнәрне санап чыгудан гыйбарәт.

***ШӘЙМОРЗА МӘКАМЕ*** — Татарстандагы элекке атаклы Шәйморза (хәзерге Буа районында) мәдрәсәсе дәмеллалары Коръәнне үзләренчәрәк көйгә салып (үзгә мәкам белән) укыганнар. Бу мәдрәсәдән чыккан шәкертләрнең Коръән укуы традицион укудан аерылып торганга, аңа шушындый исем биргәннәр.

***ШӘЙХ, ШӘЕХ*** *г.* — Карт, өлкән кеше; аксакал, юлбашчы мәгънәсендә. Бу исем

Ислам культы хезмәтчеләренә-голямаларга, дәрвиш брадәрлеге башлыкларына, суфиларга (ишаннарга) бирелә. Мәүла Колый үзенең "Хикмәте хаким" дигән поэтик әсәрендә бер-бер артлы 6 мәшһүр шәйхне телгә ала (Шәйх Гаттар, Шәйх Боханә, Шәйх Мансур, Шәйх Госсам эд-дин, Шәйх Бәһауэддин, Солтан Вәйсел Карани, Шәйх Шәмси Тәбриз, Шәйх Шәрхи Бәрхи, Шәйх Шәбаннарны) һәм: "Мәүла Колый шәйхен чөн, Тагъларны күтәр, кучен. Баш, җан хезмәте өчен, Салмага кемгә тикәр?" — дип яза. Алим Гафуров шәех дәрәҗәсенең аксакалларга гына түгел, яшьрәк галимнәргә, вәзирләргә, битекчеләргә, сәүдәгәрләргә һәм хәтта идарәчеләргә дә бирелүен билгеләп үтә. Мәс., мәшһүр Әбүгалисина *Шәйхеррәзи* исемен алган. Бөек фарсы шагыйре Сәгъдине *Шәйх Мөслихеддин Сәгъди* дип атаганнар.

*Шәйхе фани*-бик картайган кеше.

Күплек саны шәкелләре-*мәшаих, шәюх*.

***ШӘМАИЛ, ШАМАИЛ*** *г.* — **1**.Рам эченә, гадәттә пыялага, язып куелган һәм мөселман өйләрендә диварга эленә торган изге текстлар, бизәк-рәсемнәр. Соңгылары "кеше сурәтеннән гайре рәсемнәрдән — Мәккә, Мәдинә, Кәгъбәтулла, Истанбул, Айя-Суфия мәчете, Җәннәт капусы, Нух көймәсе һәм башка шундый дини-тарихи эчтәлектәге күренешләрдән гыйбарәт" булган ("Әдәби сүзлек"). Шамаилләрдә төрле ырымнар, төшнамәләр, астрологик таблицалар һәм календарьлар да очраган. Шамаил язучы осталардан Шәмсетдинов Исмәгыйль Нәҗметдин улын (Әйшә авылы, XIX гасыр азагы), Абдуллин Габдрахманны (XIX гасыр ахыры, аның алтын белән "Мәккә" дип язылган бер шамаиле Казанда В.Еремеев һәм А.Шебаршин типографиясендә басылган), Хөсәенов Шәмседдинне (аның "Иман көймәсе" төшерелгән шамаиле Казанда Дәүләт музеенда саклана) күрсәтергә мөмкин. XX гасыр башларында хәттат Госман Салиев Казанда шәмаил һөнәрханәсе тоткан. Шәмаилләр Польша татарларында да бар, алар аны *"хамаил"* дип атыйлар икән. Тагын кара: *Ләүхә.* **2**.Тумыштан килгән табигать, холык, сыйфат. //*Мөхәммәд галәйһиссәламнең бәгъзе шәмаил-шәриф(ә)ләре.*

***ШӘРАБ*** *г.* — Гадәттә җимеш суын әчетеп ясалган исерткеч эчемлек, хәмер.

"Суфичылык серләре" китабында шәрабның байтак кына синонимик исемнәре китерелә: мәй, бадә, хәмер, чаһик, һабук, аб-и әнгур (йөзем суы), аракы (ракы), бикр, дәм, эчке, әвиҗә, мудам, нәвиз яки нәвит (хөрмә суы), бөлбөли, сәһба (сәбуһ), сәлсаль, сүлафә, үммү-әгд-дәһр h.б.

Электә шәрабны, су эчкән кебек, йә утырып, йә чүгәләп эчкәннәр.

Хәзерге вакытта *шәрап* язылышы актив.

Күплек саны шәкеле — *әшрибә.*

***ШӘРӘФ*** *г.* — **1**.Кадер, хөрмәт. //*Татар филологиясе шәрәфенә шуны әйтергә мөмкин: бездә андый тар милли эгоизм, күршеләргә карата кимсетү, нәфрәт күренешләре юк!* Р.Әхмәтьянов. *Шәрәфле әгъза* — почетлы член. **2**.Затлылык, аксөяклелек. **3**.Бәхет.

*Шәрәф*-нең күплек саны шәкеле — *әшраф.*

***ШӘРӘШИР*** *бор.* — Электә сугыш максатларында кулланылган утлы корал, мәсәлән, утлы ук, утлы туп. Ләкин бүгенге терминологиядә *утлы корал* мылтык кебек дары ярдәмендә ата торган коралларны күздә тота. Рус телендә — *шерешир.* Бу сүз фарсыча "тир-и черх" сүзеннән килеп чыккан дигән фикер бар (*чираг* — ут; чыра). Борынгы мәнҗәникъләр (катапульталар) эченә нефть салынган мөгезләр һәм чүлмәкләр белән аткан булырга да мөмкин.

***ШӘРИГАТЬ*** *г.* — Боерык, күрсәтмә, кануннар мәгънәсендә (сүзнең төп мәгънәсе — туры, дөрес юл). Ислам канунары җыентыгы. Шәригатьнең төзелүе турында "Тәфсир Ногмани"да түбәндәгеләр әйтелгән: "Ий кешеләр, ий мөселманнар, Без сезгә Ислам диненнән шәригать хөкемнәрен төзеп бирдек һәм аның юлын, дәлилләрен күрсәттек, ул шәригатьне Нух пәйгамбәргә һәм сиңа, ий Мөхәммәд г-м, вәхий кылдык, ул шәригатьне Ибраһимга, Мусага һәм Гайсәгә йөкләдек, һәм шул биш пәйгамбәргә үзебез төзегән шәригатьне үзгәртмичә тотарга һәм кешеләргә дә үзгәртмичә өйрәтергә васыять

иттек һәм әмер кылдык".

"Таләбүл гыйльми фәридатүн галәә-күлли мүслимин үә мүслимәтүн." Мәгънәсе: «Шәригать гыйльмен белергә тырышу һәрбер мөселман иргә һәм мөселман хатынына фарыз.»

Ләкин "шәригать" сүзе Исламга гына нисбәтле рәвештә кулланылмый, мәсәлән, чыганакларда "Тәүрат шәригате" атамасы да очрый.

//*Шәригать бәяннары.*

***ШӘРИК*** *г.* — Иптәш; берәр эштә кулдаш, уртаклык итүче, компаньон; сыйныфташ, классташ. Электә мәдрәсәләрдә шәкертләр сабакташларына (бер үк китапны бергәләп укучы иптәш шәкертләренә) шәрик дигәннәр. //*Аллаһыга шәрик катнаштырма.*

Күплек саны шәкеле — *шөрәкя.*

***ШӘРИФ*** *г.* — **1**.Данлыклы, атаклы; олы җанлы, зыялы, пакь. //*Шәриф ай* — рамазан ае. **2**.Пәйгамбәр нәселеннән булганнарның исеменнән соң кушып әйтелә торган титул. Тарырак мәгънәдә — Пәйгамбәрнең оныгы Хәсән нәселенә карата әйтелә, ә икенче оныгы Хөсәен нәселен *сәетләр* дип йөртәләр. 1595 елда Мисырда әс-Сәйид Мөхәммәд әш-Шәриф паша булган вакытта шәрифләр яшел чалма урап йөрергә тиеш дигән фәрман чыга. Бу кагыйдә бөтен мөселман дөньясына тарала, ләкин кайчагында ак яки зәңгәр чалма урау да күзәтелә. Урта гасырлардан соң шәрифләр бөтен мөселман дөньясына таралып яши башлыйлар. Кайбер гаиләләре төрле төбәкләрдә күпмедер вакытка хакимият башына да менә. Тик күпчелек шәрифләр ярлы яшиләр.

***ШӘРЫК МУНЧАЛАРЫ*** — Шәрык мунчаларын гадәттә "уч төбе" принцибы буенча төзегәннәр. Мунча бинасы шәкеле белән биш бармакка охшаган диярга мөмкин. Һәр бармак мунчадагы аерым бүлмәгә туры килә. Бөтенесе "беләзек"тән — мунча алдыннан — 28-34 градуслы бүлмәдән башлана. Монда бераз утырып торырга, җылынырга кирәк, шуннан соң гына эссерәк бүлмәгә күчәләр. Мунчаның идәне җылытыла. Ләкин ул артык нык кызмый, анда йөргәндә аяк табаннары рәхәт җылылык кына тоялар. Аннары әлеге бүлмәләргә күчәләр. Югарыда әйтелгәнчә, аларның саны кул бармаклары санынча — бишәү. Бөтен хикмәт шунда ки, бер бүлмәдән икенчесенә күчкәндә температураның арта баруын — якынча 70 градустан 100 градуска кадәр күтәрелүен тоясың. Мунча алдыннан туп-турыга, уч төбенең уртасында диярга мөмкин, зур гына бүлмә урнашкан. Биредә җылытылган таш яки мәрмәр сәкеләр бар. Төрекләр мондый сәкеләрне "корсак ташы" дип атыйлар. Монда корсакка капланып яткан килеш "тирлиләр". Аннары массажга керешәләр. Массаждан соң сабынлы суда әз генә чылатылган мунчала белән юыналар һәм мунчала җитәрлек кадәр каты килеш кала (урта гасырларда Багдад мунчаларында ышкыну өчен лотос яфраклары кулланылган). Төрекләр, мәсәлән, ат кылыннан бәйләнгән бияләй белән ышкыналар. Шул рәвешле тән тиресенең инде үле катлавы кубып төшә. Тәнне шешәдә җебетелгән сабын белән сабынлыйлар. Хәзер инде каты мунчаланың кирәге юк, тән болай да җиңел юыла. Ахырда бассейнга күчәләр. Бассейннарның беренчесендә су — җылы, икенчесендә җылымса, ә өченчесендә салкынча була.

Борынгы Болгарда да шушыңа охшашлы мунча булган (хәрабәләре "Кызыл пулат" дип атала). Борынгы Казандагы "Таһир мунчасы"ның да бишбармак принцибы буенча төзелгән булуы ихтимал.

***ШӘРЫКШИНАС*** *гф.* — Шәрык белгече, мөстәшрикъ, ориенталист.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Айдар авылы

Айдар авылы Зеленодол районында, район үзәге Зеленодол шәһәреннән—45, Төрләмә тимер юл станциясеннән 14, Козловка пристаненнән 26 чакрым ераклыкта урнашкан.

Тарихи чыганакларда, халык авыз иҗаты әсәрләрендә Айдар авылы атамасын шактый еш очратырга туры килә.

Айдар авылы, күрәсең, Казан ханлыгы чорында да булган. Ул Е.И. Чернышев җыеп чыгарган тарихи исемлектә Ходарова-Айдарова дип бирелгән. Д.А.Корсаковның тарихи хезмәтендә дә Айдар авылы искә алына. Авылда XVIII йөздә ясак түли торган татар һәм 43 керәшен татары яшәгән. А .Артемьев хезмәтендә (1866) Айдар авылындагы 94 хуҗалыкта 294 ир-ат һәм 307 хатын-кыз яшәгәнлеге күрсәтелә. Бер мәчет эшләгән. 1898 елда Айдар авылында татарлар көн күргәне билгеләнә. 1908 елга авылда 936 кеше яшәгән.

Татар шәҗәрәләрен тикшерүче белгеч, филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш гыйльми хезмәткәре Марсель Әхмәтҗанов 14 буыннан тора торган Күгәй би шәҗәрәсен беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертте. Галим бу шәҗәрәнең өч варианты барлыгы турында яза. Күгәй авылыннан табылган З. Әдиатуллин вариантының төп нигезе түбәндәгедән гыйбарәт: Казан бик -> Күгәй би -> Исәнбулат—Сөләйман -> Акбатыр -> Зәйни -> Әхмәди -> Солтан -> Әмир -> Хәйбулла -> Әдиатулла (1885—1975)—Хатип (1929) -> Рифат. Шәҗәрәнең телдән сөйләнгән легендасы бар. 1390 нчы еллар тирәсендә дүрт агай-эне Әрә суы тирәләренә килеп утыра. Аларның өлкәне Күгәй би исемле булып, калганнары Күгеш би, Айдар би һәм Ислам би дип аталганнар. Боларның һәрберсе үз исеме белән авыл нигезләгән: Күгәй би—Күгәй авылын, Күгеш би—Күгеш авылын, Айдар би—Айдар авылын, Ислам би—Ислам (Слам) авылын.

XX йөз башында Айдар авылында ике мәхәллә була. XVIII йөз ахырында оешкан беренче мәхәлләдә 399 ир-ат, ә икенчесендә 205 ир-ат исәпләнгән.

Беренче мәхәллә мәчете 1878 елда төзелә. Ана имам-хатиб итеп 1852 елның 4 сентябрендә Шаһиәхмәт Сәгыйтов билгеләнә. 1880 елның 8 мартында аны Гарифулла Шаһиәхмәтов алыштыра (1858 елның 17 гыйнварында туган).

Бүгенге көндә үзгәртеп төзелгән хәлендә икенче мәхәллә мәчете сакланып калган. Яңа мәчетнең проекты губерна хакимияте тарафыннан 1901 елның 4 августында раслана. Шул ук елны бу агач мәчет төзелеп бетә. 1903 елның 24 июлендә генә икенче мәхәлләнең имам-хатибы итеп Кәлимулла Шаһиәхмәтев рәсми рәвештә билгеләнә (1865 елның 1 февралендә туган).

Авыл атамасы ни аңлата соң?

Айдар авылы исеме Нугай Урдасы татарлары этнонимы «айдар»га мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Авыл янында Иске йорт дип аталган урын бар. Айдар авылы элек шушы урында, Байди ермагы тирәсендә була. Бервакыт урманда кемдер куш имән кисә. Ул имәндә кыргый умарта кортларының оясы булган икән. Бал, кискән урыннан агып чыгып, шундагы бер чишмәгә агып төшә. Авыл кешеләре чишмә суы баллы дип уйлыйлар һәм Айдар авылы халкы шушы «Баллы чишмә»

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

янына, хәзерге урынына күчеп утыра. Бу чишмәнең сере шуннан соң гына ачылган, имеш.

Чынлап та һәр чишмәнең үз дөньясы, үз эчке халәте була. «Чишмә» сүзендә үк табигать куенында бара торган ниндидер тылсымлы күренешләр чагыла сыман. Безнең бабаларыбыз су һәм чишмә-чыганаклар дәрәҗәсен юкка гына ата-ана хакы кадәр дип карамаганнар. Чишмәләр—су башы. Судан башка тормыш юк. Чишмә башларын чистартырга баба-әбиләребез аруланып, чиста киемнәр киенеп барганнар. Торак-авылларны су буйларына, чишмә-кизләү әргәсенә корганнар.

Шушы авыл кешесе Айдар Зариповта саклана торган истәлектә авыл оешу турында түбәндәге вакыйгалар хикәя ителә. Айдар авылының башта кайда утырганы ачык мәгълүм түгел.

«Хәзерге Күгәй авылы юлы белән Бурсык елгасы арасында, Күгәй авылы чигенә якын урында бер кизләү чыккан. Тигез җирдә урыны билгеле булып тора. Элек авыл нәкъ шушы урында урнашкан булган да инде. Ул заманнарда авыл тирә-юне гел урман булган. Безнең көннәргә Нарат асты дигән исеме калган. Су тегермәне артында, Тимеркәй чалуыннан ары Күгәй авылы җирендә Иске зират наратлары бар. Без белгәндә имән буралары да исән иде әле. Безнең Айдар бабай белән Күги би, Күгеш би бертуган, диләр. Кайберәүләр Әрә авылын да безнең Айдар бабабыз белән бертуган шәхес нигезләгән дип әйтәләр.

Бу Иске зират, Иске йорт урынына Айдар бабалар шәһре Болгар тузган вакытларда яки Казандагы сугышлар заманында яудан качып килеп утырганнардыр. Әрәнең суы мул, тирә-юне аулак, болынлык һәм урманлык булган». Бу чыганакта язылганча, Айдар авылы 1721 елда, ягъни беренче ревизия вакытында теркәлгән.

Нәҗия Борһанова мәгълүматларына күрә, Айдар авылы халкы күршедәге Күгәй, Күгеш, Татар Исламы һәм Тау иле авыллары кешеләре белән июнь башларында күңелле итеп Йуа уйыны җыены үткәргәннәр.

Авыл халкы хәтерендә «Келәү боткасы» яисә «Йорт боткасы» дип аталган гореф-гадәт, ырым-йолалар белән бәйләнешле риваять сакланган. Бу ботка йорт ияләре өчен борайдан пешерелә икән. Ашаганда сөйләшмичә ашыйлар икән.

Элек келәүне, бер капчыкка төрле сөякләр, ат башы сөякләре тутырып, келәтләргә, сарай-абзарларга, чормаларга асканнар. Келәүнең тиюенә ышанганнар. «Келәве көтә» дип, аңа атап чат урыннарга акчалар ыргытканнар. Элеккe вакытларда келәү асмаган кеше белән «келәвең дә юк синең» дип кычкырыша торган булганнар. Айдар авылында Сәгъдиева Фәгыйлә апаның бүгенге көндә Чувашстан җөмһүриятенең Кармыш авылында яшәүче 18 яшьлек бер туганының күзенә Фәгыйлә апалар бакчасында ботак төртелә. Шул көннәрдән бирле ул «Келәү тотты» дип ышанып яши. Ел саен күзенә ботак кадалган урынга май аенда борынгы бакыр акчалар китереп ташларга тырыша. Келәү дип ташланган акчаны алган кешеләргә келәү зарар эшли дип ышанганнар.

Фәгыйлә апа сөйләвенә караганда, Айдар авылында келәү аскан кешеләр күп булган әле. Эзләсәң, бәлки, бүген дә очратырга мөмкиндер.

Авыл халкы, әйтерсең лә, табигать белән бергә аерылгысыз берләшеп яши. Авыл янәшәсендә атамаларга лаек урыннар күп.

Айдар авылында композитор Сара Садыйкованың ире Газиз Вәлитов (Айдарский) туып-үскән. Айдарский фамилиясен ул туган авылына нисбәт алган. Һәрберсенең тарихына карата халык хәтерендә нинди дә булса риваять-истәлек сакланып калган.

Авыл янындагы Шәм күлен Билалетдин бабай болай тасвирлады: «Аның суы бик салкын. Тирә-юне элек тоташ кара урман булган. Аның яныннан узганда шәм яндырып кына үткәннәр. Адаштырган, имеш».

Җиде кыз күленең дә үз тарихы бар. Тешләре сызлап үлгән җиде кыз күмелгәнгә күрә күл шундый исем алган. Ә менә кайчандыр булган сугышның корбаннары күмелгән урын Үзән дип аталган.

Авыл тирә-юнендә чишмә-кизләү, ерым-ермаклар, чокырлар һәм басу-ышналар байтак.

Әрлән кизләве. Әрлән казыган урында су чыккан, шуның өчен кизләү Әрлән кизләве исемен йөртә.

Гөбе ермагы. Чат чокырындагы ермакка су алыр өчен гөбе куйганнар. Атама шуна нисбәтән бирелгән.

Авыл кырыенда гына чишмә ага. Аны Шәриф чишмәсе дип атыйлар.

Чокырлардан Пати чокыры, Сахалин чокырын атарга мөмкин.

Шулай ук авыл янында Аэродром басуы, Урман басуы, Шалкан ышнасы һ. б. бар.

Авылга якын гына урындагы тауны Биектау дип атыйлар. Бу урында аерым-аерым ике тау тора. Алып бабай ике аягыннан да чабатасын салып тузанын каккан, шуннан тау хасил булган дип сөйлиләр.

Зират янында колхозның корт бакчасы бар. Корт бакчасында алмагачлар күп. Май айларында бакча ап-ак чәчәккә күмелә.

Бакчаны узгач бер зиратка килеп чыгасың. Халык аны Керәшен зираты дип атый. Электә авыл көчләп чукындырылган булган, ләкин халык зур көч куеп янадан мөселманлыкка кайткан.

Авыл элек-электән үк Такмакчы кушаматын йөртә. Халык төрле вакыйгаларга багышлап такмак чыгарырга яраткан.

Авыл халкы табигый газдан файдалана, юл күтәртелгән. Албаба станциясенә кадәр маршрут автобусы йөри. Мәдәният йорты Айдар белән Күгеш авыллары арасына урнашкан, кибет һәм мәктәп бар.

Революциягә кадәр авылда 2 мәчет эшләгән. Шуларның берсендә мәдрәсә урнашкан булган.

Хәзер авылда мәчет салганнар. Халык зиратны киңәйткән, тирә-юнен тотып алган.

Авыл зураюга таба йөз тота. Ләкин яшьләрнең күбесе шәһәрләргә китеп урнашуны кайгырта. Авылда эш юк.

Айдарский (Вәлитов) Газиз Исхак улы (1898—1933)—актер, режиссер. Ул 1922-24 елларда Казанда Беренче үрнәк театры артисты (1926 елдан Татар академия театры). 1924—1933 елларда Мәскәү үзәк татар эшче театрының баш режиссеры була.

## Арбор (Урбар) авылы

Арбор авылы Балтач районында, район үзәге Балтач авылыннан—28, Шәмәрдән тимер юлы станциясеннән—52, Малмыж пристаненнән 48 чакрым ераклыкта урнашкан.

Арбор (Урбар) авылы халкы 1873 елның 19 март датасы белән «Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии XIX века» (М.-Л., 1936) дигән тарихи чыганакта үз балаларын урысча укытуга каршы чыгуларына нисбәтән телгә алына.

Авыл зыялыларга да бай булган. Шуларның берсе—мелла Үтәгән бине Уразмәт әл-Урбари турында Шиһабетдин Мәрҗани мондый сүзләр яза: «Малмыж өязе Урбар авылы әһалиясеннән. Халык арасында яхшы исеме һәм даны таралган кеше иде. Мелла исеме белән йөртелеп, галимнәр рәтендә саналса да, мелла булып торган кеше түгел. Мәмләкәт кануннарын, дәүләт тәртипләрен яхшы белүче, тирән акылы белән танылган, дөньясы киң һәм тормышы бай кеше була. Авырлыкка очраган һәр кеше аңа киңәшкә килгән. Гомеренең ахырында хаҗ кылырга кызыгып, берничә бәет язган. Хәзерге көндә сакланып калганы шушы:

*Кичкел инде, и Үтәгән,*
*Айрык сүзне сөйләмә.*
*(айрык—булмастай)*

Бервакыт Ташкичү авылында тегермән тоткан. Ашыт суын Давыт чишмәсенә кадәр байтак җир ерып китереп, шул урынга тегермән салучы да шушы зат икәнлеге халык арасында билгеле. 1221 (1806) елда Урбарда вафат булган».

Олылар сүзенә караганда, Арбор авылына беренче кешеләр Мәмсә, Кенәр авылларыннан, Бәләбәй өязеннән, Алатыр якларыннан килгәннәр. Урнашырга

урын карап кайткан кешеләр басуларга менәр өчен үре дә бар дип әйткәннәр. Күчеп килгән кешеләрнең берничәсе хәзерге Садыйков Гайнаннар йорты урынында яшәгән. Ул вакытта Арборның тирә-ягы сазлыклы урман булган. Килеп урнашучылар урманны чистартып йортлар төзегәннәр. Арборның Чепья ягындагы очына килеп утырган удмуртлар соңыннан ислам диненә күчкәннәр. Татарларга кадәр бу тирәдәге Утар елгасы буенда марилар яшәгән. Татарлар мариларны Мещан куаклыгы дип йөртелгән куаклык янына күчереп утырткannar. Марилар анда шактый озак яшәгәннән соң гына, су булмаганлыктан хәзерге Помасьял авылы тирәсенә күчкәннәр. Арбор халкы Лоб авылы барлыгын елга буенча агып килгән йомычканы күреп кенә белгәннәр дип сөйлиләр. Бу мари авылының икенче исеме—Мари-Арбор.

Элек Арбор авылы очларының исеменә нисбәтле рәвештә берничә төрле атап йөртелгән: Арбор, Мөнигәр, Мещан, Бикбулат, һәр очның үз зираты булган. Бер оч зиратына икенче оч кешеләрен күмү гадәте булмаган. Хәзер авылның бер очы булган Мөнигәр элек үзе аерым авыл, аерым колхоз булып йөргән. Ул Арбор авылыннан соң барлыкка килгән.

Мөнигәр Үтәгән кушаматлы алпавытның патшадан бүләккә алынган җир булган. Ул кеше урыс патшасының ниндидер бик кирәкле хаҗәтен үтәгән. Җир сорагач, патша аңа Гоньбадан 500 гектар урман, Малмыждан 500 гектар болын, Мөнигәрдән 500 гектар җир бүләк иткән. Бу җир—урманнар аның варисларына буыннан-буынга күчеп килгән. Үтәгәннең бер кияве Казанда кунакханә хуҗасы—мещан була. Мещанның ятим калган баласы шушы җирләрдә үсә. Хәзер ул җирләр Мещан җире, Мещан куаклыгы дип атала. Соңыннан Мещан җирләренең Карашай нәселенә тиешле бер өлешен сатканнар. Октябрь инкыйлабына кадәр бу 300 гектар җир Йөрек авылының Хәмидуллин Гыйззәтулла дигән кешесе кулында була. Арборда ул тегермән дә тоткан. Арбордагы хуҗалык эшләрен Курамьял авылының Шәмсемөхәммәт исемле кешесе башкарган. Аның Малмыж, Уфа, Төмән һ. б. шәһәрләрдә заводлары булган.

Авылда алпавытлар булмаган, җир дәүләтнеке исәпләнгән. Җирдән файдаланган өчен халык хөкүмәткә имана салымы түләгән. Халык игенчелек белән көн күргән, ә хезмәт кораллары сука белән тырма булган. Авылның 30-35 процент кешесе атсыз крестьяннар булган. Алар хәллерәк авылдашларына ялланып эшләргә мәҗбүр булган. Авылда староста булып Серафим Петрович эшләгән. Чепья авылында хәзер дә аның нәселе яши.

Инкыйлабка кадәр җир ир балаларга гына бирелгән. Үз җирләрен игәргә көчләре җитмәгән ярлы крестьяннар урта һәм бай хәллеләргә хезмәткә ялланганнар.

Авылда, хәзерге Кәтәй урманы буенда, бер хатын салдырган поташ (үсемлек көленнән табыла торган ак селтеле матдә) заводы һәм бәз суга торган фабрика булган. Аларда тирә-як авыллардан һәм шул исәптән Арбордан да килеп эшләгәннәр.

Николай патша заманында армиядә 25 ел хезмәт итүчеләрнең саны авылда өчәү, 1904-05 елларда Япон сугышында катнашучылар унбер булган. 1914-17 еллардагы беренче бөтендөнья сугышында авылның ир-егетләре күп катнашкан.

Инкыйлабка кадәр авылда укый-яза белүчеләр санаулы гына булган, русча белүчеләр бөтенләй булмаган.

Волостька акча алырга яки башка эш белән килүчеләр һәм Арбор халкының күбесе, русча кул куя белүче Габбасов Зәкине 5 әр тиенгә ялдап кул куйдырта торган булганнар.

Элек Арбор авылы волость үзәге булган. Аны Вятка губернасы, Малмыж өязе Арбор волосте дип атаганнар. Волость 33 авылны берләштергән. Хәзерге мари, татар авылларының кайберләре Апаз, Пөшәнгәр, Миржәм яклары Арбор волостена кергән. Волость 1900 елларда оештырылган дип исәпләнә.

1738 елда Арборда мәктәп-мәдрәсә төзелә. Аны Кенә авылыннан Мозафаров дигән бай салдырган. Соңыннан Мөнигәр һәм Чепья очларында да мәктәпләр ачыла. Аларда Садыйк, Зариф, Гәрәй муллалар, Фәләхетдин, Йосыф хәлфәләр укыткан. Авылда китапханә яки хастаханә булмый. Яшьләр мунчаларда җыелып кич утыралар,

олылары кунакка киткән өйләрдә аулак өй ясыйлар. Берничә врач эшли торган хастаханә күрше авыл Чепьядә генә булган.

1893 елны авылда ачлык була һәм шуннан соң Арбор халкы төрле якларга тарала башлый. 1887—1900 еллар арасында авылдагы 300 хуҗалыктан 240 ы гына кала. Халыкның 20 проценты бик ярлы, бары тик тавык һәм казлары гына була, 50 проценты—урта хәлле, 30 проценты тирәсе мул тормышлы була.

Авылда совет хакимияте 1918 елны төзелә. Малмыж өязеннән килеп Арбор волосте идарәсендәге кешеләрне алыштыралар. Авылда старосталар бетә. Аның урынына ярлылар комитеты төзелә.

Авылдагы совет хакимиятенең беренче бурычы халыкка белем бирү, аны агарту була. Концертлар куела, театрлар уйнала башлый, клуб һәм китапханә ачыла. 1933 елда клуб авыл зираты янына салына, 1949 елда гына ул урамга төшерелеп төзелә. Аны Зәкиев Мәгъсүм авыл советы рәисе булып эшләгәндә салалар. Иң беренче клуб мөдире булып Фазлыев Каюм эшли. Авылда мәктәп ачылгач беренче укытучы Хәлиуллин Җәват була. Гражданнар сугышы Вятка буена килеп житсә дә, Арборга килеп житми. Бары продотрядлар гына килеп әйбер җыйнап китәләр. Сугышка бик күп ирләр китә һәм күбесе һәлак була.

Октябрь революциясеннән соң да әле һаман сука белән сөрү, кул белән чәчү була. Ашлык аз күләмдә житештерелә. 1927 елда авылдагы 11 хуҗалык колхозга берләшә һәм алар Өншенәр буена күчеп утыралар. Колхозның 10 аты, 5 сарыгы, эш кораллары һәм шул тирәдә жире дә булган. 1930 елда алар авылга кайталар һәм калган хуҗалыклар белән кушылалар, атларны һәм имана жирләрен берләштерәләр. Колхоз 3 бригадага бүленә, һәр бригаданың 15 аты була. Шулай ук 150-200 баш дуңгыз да асрыйлар.

1924 елда Әкбәров Әкбәр, Гарипов Зариф, Гайсин Йосыф беренчеләрдән булып партиягә керәләр. Авылда партия эше җанланып китә. Ячейканың сәркәтибе булып Әкбәрев Әкбәр эшли. Комсомол оешмасы 1927 елда төзелә. Секретарь Мөхәммәтшин Салих була.

1944 елны колхоз 4 өлешкә бүленә: «Партизан», «Социализм», «Днепр», «Татарстан». 1950 елда алар янадан берләштерелә һәм колхоз «Татарстанның 30 еллыгы» дип йөртелә башлый. 1964 елда колхоз күршедәге «Труд» колхозы белән кушыла.

Бөтен ил халкы белән бергә Арбор халкы өчен дә Ватан сугышы житди сынау була. Сугышның беренче көннәреннән үк ир-атлар фронтка китә. Авыл хуҗалыгындагы тормыш йөген тарту хатын-кыз, бала-чага, картлар жилкәсенә төшә. 1942 елда авылда жидееллык мәктәп ачыла. Сугышта авылның 113 кешесе башын сала. Кире әйләнеп кайтучыларның саны 93 кеше була.

Дәһшәтле сугыш еллары артта кала. Ләкин жимереклек, ачлык-ялангачлык, ятимлек шактый дәвам итә әле.

Югарыда әйтелгәнчә, Арборда төзелгән «Татарстанның 30 еллыгы» исемле колхоз күршедәге «Труд» белән кушыла. «Труд»ка Чепья, Тагашур, Иске Чепья, Янгырчы, Улисьял, Мельничный авыллары кергән. 1964 елда бу исемлеккә Арбор авылы да өстәлә. Авылда бары бригада гына кала. 1972 елда «Труд» рәисе итеп Зәкиев Билсур сайлана. 1979 елның 5 маенда Арбор «Труд»тан аерыла һәм «Ударник» колхозы булып үзбашка яши башлый. Билсур Зәкиев «Ударник» колхозына рәис итеп күчерелә.

Арборда бригада йорты, сигезьеллык мәктәп, кечкенә кибет, клуб биналары гына була. Акрынлап бирелә төзелеш жәелеп китә. Шифалы янгырдан соң барлыкка килгән гөмбәләрдәй берәм-берәм кибет, идарә үзәге, гараж, тегермән, амбарлар, сөт комбинаты, почта, медпункт, урта мәктәп, балалар бакчасы, китапханә биналары калкып чыга. Авыл үсә, яңа йортлар төзелә. Хуҗалыкта укыган яшь белгечләр эшли башлый. «Ударник» колхозы район буенча беренче урыннарны алгаласа да, гомумән, урта сафларда бара.

Хәзерге вакытта авылда халыкка яшәү өчен унай шартлар булдырылган. Юлларга асфальт түшәлгән, өйләрнең барысына да газ кертелгән. Халык сарай тотырып мал-туар асрый.

Биредә бүген 167 хуҗалык исәпләнә, аларда 656 кеше яши. Колхозда эшләүчеләр саны 200 дән артык. Авылда мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният йорты, кибет гөрләп эшли.

Авылның исеме каян барлыкка килгән?

Авыл инкү урында урнашкан. Авылның сул ягыннан тау булса, каршы яктан да үргә күтәрелергә кирәк. Олылар сөйләвенә караганда, шуңа да авыл «үре бар», ягъни Урбар дип атала. Соныннан ул Арбор дип йөртелә башлый. Арбор (Урбар)—саф татар авылы. Драматург Мирхәйдәр Фәйзи күршедәге Шода авылында яшәгәндә язган истәлекләрендә: «...без Урбарның Түнтәр юлыннан пар атларда җилдереп менеп киттек. Гөрләп үскән игеннәр ат дугасын күмәләр иде...»,—дип авылны матур әдәбиятка кертеп калдырган.

Арбор авылы табигатьнең гүзәл бер почмагына утырган. Тирә-ягы калын урманнар. Тау битләреннән, урман аланнарыннан челтер-челтер чишмәләр ага. Һәр урманның, болынның, елга-инешнең, чишмә-кизләүнең, саз-күтәрнең үз исеме бар.

Кәтәй урманы. Авылда борынгыдан яши торган бер нәселне кәтәйнекеләр дип йөртәләр. Күрәсең, бу урман аларның борынгы бабаларыныкы булгандыр. Урманда, ел да сабан туеның икенче көнендә «Урман сабан туе» үткәрелә, һәр гаилә туган-тумачасы, кунаклары белән көне буе табигать кочагында ял итә. Урмандагы челтерәп агучы чишмә дә Кәтәй чишмәсе дип йөртелә.

Фәхри урманы һәм Фәхри чишмәсе. Фәхри исемле кеше чишмә казыган һәм аның тирә-юненә агачлар утырткан. Агачлар үсеп, шактый зур урман барлыкка килгән.

Кара каенлык. Бу каенлык читтән генә түгел, эченә керсәң дә шомлы, караеп тора.

Озын каенлык.

Әкәй каенлыгы. Бик салкын буранлы бер кышкы көндә бу каенлыкта күрше мари авылы хатыны өшеп үлгән дип сөйлиләр. Мари хатын-кызларын татарлар әкәй, ирләрен чирмеш дип йөртәләр.

Мулла куаклыгы. Бу агачларны элек авыл мулласы утырткан.

Садыйк посадкасы. Садыйк Мөхәммәтшин бригадир булып эшләгәндә, аның җитәкчелегендә утыртылган каенлык.

Авыл тирә-юнендә тагын Тазлар чишмәсе, Габит чишмәсе, Кызыл яр чишмәсе, Утар чишмәсе, Чандыралы чишмәсе, Яңгырчы елгасы, Мөнигәр суы, Атау суы, Шәми (Шәмсемөхәммәт исеменнән) суы кебек су-елгалар бар.

Басулар: Тау басу, Аръяк басу, Зират басу, Каенсар як басу, Фәхри елгасы кыры, Пыштып башындагы күл (җир исеме) һ. б. Юллар: Түнтәр юлы, Субашы юлы, Чепья юлы, Куныр юлы һ. б.

Арбор авылы урамы исемнәре үзенчәлекле. Авылда элек 4 мәхәллә булу сәбәпле (Арбор, Мөнигәр, Мещан, Бикбулат), урам исемнәре дә нәкъ шулай атап йөртелгән. Хәзерге вакытта авыл Түбән оч белән Югары очка бүленеп йөри. Аерым урамнары Бүре тыкрыгы, Мөнигәр, Көл тыкрыгы, Озын тыкрыгы, Кыска тыкрык, Яшьләр очы, Комгансызлар тыкрыгы, Зыя тыкрыгы дип йөртелә.

Авылдан милләтебез мәдәниятенә өлеш керткән шәхесләр дә чыккан. Шундыйларның берсе Гарифҗан Садыйк улы Мөхәммәтшин. Ул—район хакимияте башлыгы урынбасары булып эшләде. Гарифҗан Мөхәммәтшин шагыйрь буларак танылды. Аның «Керим әле урманнарга», «Аулак өй», «Унсигез яшем чагы» һ. б. шигырьләренә җырлар язылган һәм алар һәркемгә таныш. Аның иҗат һәм моң чишмәсе Арбор авылында тибеп чыккан. Арбор урманнары, чишмә-кизләүләре, ур-таулары, басу-кырлары, аулак өйләре, кешеләре аның шигырь юлларына күчә. Гарифҗан Мөхәммәтшин шигырьләрен укыганда күз алдына туган як үзенең бөтен яме, матурлыгы белән килеп баса. Хәзерге көндә шагыйрь Балтачта яши һәм эшли. Аның берничә шигырь җыентыгы басылып чыккан. Арбор суына багышлап язган шигырендә мондый юллар бар:

*Син һаман агасың икән,*
*Уйчан, моңсу Урбарым.*
*Син, гүя газиз җаныма*
*Тынгы бирмәс уйларым.*

*Уйларым тынар беркөнне—*
*Йөрәк тынар иң элек.*
*Тик син генә тынма шулай,*
*Син бакый бул—мәңгелек!*

Авылдан яшь талантлар да канатланып китәргә тора. Руфия Билсур кызы Зәкиева Казан дәүләт педагогика университетының татар теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлады. Аның бәхетле балачагы, онытылмас мәктәп еллары Арбор авылы белән бәйле. Ул да шигырьләр укырга һәм язарга ярата. Анын да туган авылы Урбарга багышланган шигыре бар:

*Китәр юлларыма җәймә җәеп,*
*Озатсаң да мине, авылым,*
*Мин ышанам: барыбер алып кайтыр*
*Синнән алып киткән юлларым.*
*Син онытма: өзелеп сөйгән балаң,*
*Еракларда сагынып яшәвен.*
*Авылым ягына искән җилләргә дә*
*Сәлам әйтегез дип дәшәмен.*

*Туган җирдән кадерлерәк җир юк.*
*Бу хакыйкать күптән уйланган.*
*Көт, авылым, барыбер бер кайтырмын,*
*Яшьлегемдә киткән юллардан.*

Руфия киләчәктә, бәлки, коеп куйган шагыйрә булыр һәм туган авылы аның шигырьләре белән горурланыр.

«Безнең авыл» дип тә, «безнең мәктәп» дип тә горурлана Арбор халкы. «Безнең зират» дип тә горурлана торган бу халыкка рәхмәт дими ни диясең?

Арбор халкының житәкчеләренең тагын бер үзенчәлекле ягы—алар эшләгән кешенең, хезмәт әһелләренең кадерен беләләр. Бу авылда лаеклы ялга чыгучы барлык кешене авыл бәйрәме ясап олылаулары күнелне сөендерә. Замана Арбор халкын үзгәртә алмаган. Алар һаман бер йодрык булып дустанә рәвештә дөнья көтәләр.

Быел, ягъни 2007 елда лаеклы ялга китүчеләрне авыл күләмендә бәйрәм ясап, матур итеп кичә оештырып озатуның исеме «Һәр кешедә бер матурлык яши»,—дип аталды. Кичәдә һәр кешенең, тырыш хезмәт куйган алтын йөрәкле эшчәннәрнең уңай яклары, хезмәт сөюдән тәм табып яшәүләре калку итеп күрсәтелде. Лаеклы ялга китүчеләр арасында Тәлгат Низамов, Гөлбостан Гарипова, Гөлзада Юлдашева, Зәнфирә Габделхәева, Мотыйгулла Гатиятуллин, Дамир Низамов, Нурлыгаян Гозәерова, Әкълимә Хәбибуллина бар иде. Яраткан эшеннән, бергә эшләгән иптәшләреннән аерылу кебек монсу вакыйганы авыл хакимияте һәм халкы кешелекле тантанага, онытылмас хатирәгә әверелдерә белә. Чөнки «күнел булмак бер калжа, күнел калмак та бер калжа» бит. Мондый кичәне оештыручыларның, кеше лаеклы ялга чыккач та әле гаиләсенә, авылдашларына, дусларына кирәклекләрен тагын бер тапкыр калку итеп күрсәтә белүләре гажәпләндерә һәм сокландыра. Мондый вәзгыятьтән һәр авылга һәм һәр оешмага үрнәк алу кирәк. Арборлылар менә нинди мәгънәлелек үрнәге!

*Дәвамы киләсе саннарда*

Тәлгат
Нәҗмиев

## БИШ ОЧРАШУ

Истәлек язу ансат түгел, әлбәттә. Бигрәк тә Хәсән Туфан турында—шигъриятебезнең мәңге сүнмәс йолдызы, аксакалы, алтын баганасы, йөз аклыгы, вулканы турында—олы шәхес турында. Чөнки бик күп галимнәрнен, әдәбият-сәнгать әһелләренең аны искә алган язмалары әледән-әле басылып тора һәм алар тагын да дәвам итәчәк. Чөнки әдипнең 110 еллыгы якынлаша. Әлеге юлларның авторы татар халкының беркайчан да онытылмас шагыйренең олы иҗатына, аның сөйләп бетерә алмаслык фаҗигале тормыш юлына тукталуны максат итеп куймый. Бары тик Хәсән абый белән биш тапкыр очрашу истәлекләрен генә укучыларга җиткерергә тели.


*Хәсән абый төрмәдә.*

**Беренчесе.** 60нчы еллар ахырында Бауман урамындагы Матбугат йортына керергә туры килде. Ул вакытта Татарстан Язучылар берлеге идарәсе шундагы икенче катка урнашкан иде. Менә ничектер, баскыч ташлары ашалмасын дигән шикелле йомшак кына, сак кына басып берәү менә. Озын какча йөзле, ак чәчле бу кеше бик таныш иде. Чөнки аның рәсемен әдәбият китапларында күп тапкырлар күргәнем булды. Хәсән Туфан бит бу! Туктап, артыннан карап калдым...

**Икенчесе.** 1973 елда, Армия хезмәтеннән кайтканнан соң, Казан дәүләт университетында читтән торып укый башладым. Сессияләргә барам. Әдәбият курсыннан Ибраһим Нуруллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Зәет Мәҗитов, Марсель Бакиров, Шәйхелислам Садретдинов, Флера Ганиева кебек фән докторлары һәм кандидатлары лекцияләр укый. Мөхәммәт Мәһдиевнең бер лекциясен тыңлау үзе ни тора! Аның «Татар поэзиясендә Туфан—беренче багана» дигән сүзләре бүген дә истә. Шулай итеп, без олы шагыйребезнең иҗаты белән тирәнрәк таныша башладык, һәр шигыренең язылу тарихын ишетеп, бөтен аудитория тынып кала иде. Поэзияне аңлый белергә кирәк икән шул. Якташыбыз Нәфисә Василова башкаруындагы «Киек казлар» җырын гына алыйк. Билгеле булганча, Туфан нахак яла белән 10 ел Сталин төрмәләрендә утыра, 6 ел сөргендә була. «Киек казлар»ны ул әйләнеп кайткач яза:

*Киек казлар кыйгылдаша,*
*Җырлашалар микәнни?*
*—Туган илләр кала бит,—дип*
*Елашалар микәнни?*
*Безнең дә бит шулар сыман*
*Киткән еллар бар иде,*
*—Кыйгак-кыйгак, илем ерак,—*
*дигән чорлар бар иде...*

Тагын бер мисал. Хәсән Туфанның хатыны Луиза Салиәсгарова шул чорның танылган артисткасы була. Туфанны кулга алганда дүрт яшьлек кызчыгы Гөлгенә һәм дүрт айлык улы Идегәй кала (Идегәй 1942 ел башында ук авырып үлә). Луиза иң элек Кремль янындагы төрмәгә ризык ташый. Аннары, ерак сөргендә яшәгән ирен ачлыктан саклап калу өчен, посылкалар җибәреп тора. «Халык дошманы» хатыны буларак, эштән куыла, фатирыннан чыгарыла, юньлерәк әйберләре сатылып беткәч, донор була. Әмма Хәсән ага кайтырга сигез ай калгач, яман шештән үлә. Соңыннан Луизасының фоторәсеме шагыйрьнең гел өстәлендә тора. Хатынын бик яраткан, күрәсең, башка өйләнми дә. Дөрес, Зөфәр абыйсы аңа сөргенгә җибәргән хатында тәкъдим ясап карый. Хәсән Туфан ана болай дип җавап яза: «Син, абый, вакытлыча булса да өйләнсән ничек булыр иде, дисең. Яшәү, билгеле, матди яктан җиңел, яхшы булыр иде, ә мәгънәви яктан—авыр. Нигә дисеңме? Биредә өйләнү—йортка керү дигән сүз. Минем язмыштагы иптәшләрнең байтагы шулай иттеләр—толларга йортка керделәр һәм яхшы тора башладылар: сыер бар, терлек бар, кош-корт бар, тамак тук, өс-баш бөтен. Мина да шулай итәргә мөмкин иде. Ләкин Луиза анда мине көтеп торганда, бу эш килешми инде».

Исән-сау кайткач, шагыйребез болай дип яза:

*...Тәрәзәңә җилләр бәрелгәннәр,*
*«Сагынма!» дип янап киткәннәр...*
*Күнмәгәнсең... Эштән сөрелгәнсең...*
*Еллар сине донор иткәннәр...*
*Посылкалар белән ярдәм иттең:*
*—Без бит илдә... өйдә бит...—дидең.*
*Ә ул ярдәм*
*Каныңа алыштырган*
*Паекларың икән бит синең...*
*Алдарсың дип уйлый идеммени?—*
*Ә син мине алдагансың ич:*
*Өзелер хәлгә җиткән гомеремне син*
*Җаның белән ялгагансың ич!*

Менә шулай итеп без Хәсән Туфан язган һәр шигырьнең мәгънәсен, язылу тарихын белеп укый башладык. Һәркайсыбызда аның үзен күрү теләге уянды. Икенче очрашуны курсташым, запастагы капитан, укырга кергәндә үк дүртенче дистәне ваклаган, офицер вакытта зур фаҗигаләр кичергән Газиз Кашапов оештырды. Алга узып шуны әйтергә кирәк: Газиз, университетны тәмамлаганнан соң, профессиональ язучы булды, шигырьләр, роман-повестьлар язды, күп китаплар чыгарды. Ул Хәсән Туфан турындагы «Киек Каз Юлы» романының беренче кисәген тәмамлап бастырды. Шагыйрьнең «йөргән» эзләре буйлап айлар буе материал туплады. Х. Туфан утырган колония-төрмәләрне күрде, «Дело»лары белән танышып, шуның берсенең «кесә»сеннән фотосын да алып кайтты (рәсемдә), ул сөргендә булган Новосибирск өлкәсендәге авылларга барып җитеп, хәтта Туфан яшәгән землянка урынында төн кунды... Г. Кашапов та Аксубай районыннан, ул—Яңа Үзидән, Х. Туфан Иске Карматтән. Әмма ни кызганыч, Газизнең 49 яшендә кисәк үлеп китүе әлеге романның икенче—Х. Туфан турындагы төп өлешен язарга, дөресрәге, төгәлләргә ирек бирмәде. Барлык җыйналган материал Газиз Кашапов белән мәңгелеккә китте.

...1979 елның гыйнварында без Хәсән Туфанның Вишневский урамындагы фатирына киттек. Ишекне Мөнҗия апа (Х. Туфанның абыйсының кызы—ул шагыйрьне тәрбияләп тора иде, машинистка хезмәтен дә башкарган, секретарьшасы да булган) ачып кертте һәм Хәсән абыйның эш бүлмәсенә озатты. Шагыйрь безне бик җылы каршы алды. Утырдык. Якташлар әңгәмәгә кереште. Ә мин игътибар белән бүлмәне күзәтә башладым. Кечкенә иде ул (чөнки фатиры да ике бүлмәле генә.). Җиһаз да бик гади. Стена кырыенда Хәсән аганың рәссам Рәшит Имашев

ясаган кечкенәрәк портреты тора.

Бер портретка, бер Хәсән абыйга карыйм. Аерма байтак иде, әлбәттә. Туфан кечерәеп калган, чәчләре дә гадирәк. Әмма башка кешеләрдән аерылып торган тышкы кыяфәте һәм йомшак мөлаем йөзе белән җәлеп итте ул. Кыскасы, ап-ак чәчле тарих сыман иде. Әкрен тавыш белән генә сөйли, «тегендә» дигән сүзләр дә куллана. Мөнҗия апа өрек җимеше белән ясаган чәй кертеп чыкты. Гомумән, бу бүлмәдә рухың баеп, күңелең тынычлануын тою рәхәт иде. Әңгәмә дәвам итте. Якташларның туган яклар, нәсел шәҗәрәләре турында да сүз байтак булды. Хәсән ага яшел каралы ручка белән: «Кадерле энебез Тәлгат! Әдәбиятыбызның киләчәк дәвамында уңышларга гына ирешүегезне теләп Х. Туфан. 28. V. 79»,—дип язып, үзенең китабын бүләк итте. Аннары без рәхмәт әйтеп, тирән тәэсирләр белән киттек. Газиз Туфанның теге елларда күргәннәрен кич буе сөйләде...

...Ә мин Хәсән абый култамгасын салып биргән әлеге җыентыкны эчем пошкан саен кулыма алам. Таныш шигырьләрне тагын бер кат укыйм. Чөнки чын поэзия сине үзенә буйсындыра, үзе белән сине әллә кайларга алып китә, тирән уйга сала, күзләреңне дымландыра...

**Өченчесе.** Монысы да шул ук елның маенда булды. Күптәнге танышлар кебек килеп кердек бу юлы. Хәсән аганың чәче тагын да агарган, ул беренче чиста кар кебек тоелды миңа. Өстәлендә—чәчәкләр. Ул аларга гашыйк кеше. Аның чәчәкләр белән бәйле бик күп җырлары, шигырьләре бар. Чәчәкләрне ул Аккош күлендәге бакчасында үстергән.

Менә ул елтырап торган тимер кысалы күзлеген киде, кулына яшел каралы ручкасын (ул фәкать шул төс белән генә язган) тотты. Аннан баш бармак яссуындагы папирос кәгазе алды. Күзлек өстенә лупа куеп, «тегендә» үзе ясаган тамгаларга иелде һәм шигырь укый башлады. Соныннан әкрен генә: «Эшкәртеп бетерә алмам, ахры, шифрын синә өйрәтеп калдырырмын әле, яме, Газизҗан»,—диде.

Ул лагерьда вакытта папирос кәгазен аерып алып, каты карандашны кыл очы сыман очлап, шигырьләрен гарәп хәрефләре белән шунда теркәп барган. Аннары түгәрәкләп төргән дә сохари эченә тыккан, тишекләрне ике яктан да валчык белән ябыштырып, мич янында кыздырып киптергән. Тентүләр бик еш булган, әмма сохарига тимәгәннәр. Шулай да Туфан барлык шигырьләрен дә алып кайта алмаган. Бер лагерьдан икенчесенә кисәк кенә күчергәндә, аларның байтагы яшерелгән урыннарда калган.

**Дүртенчесе.** Монысы да университет белән бәйле. Газиз Кашапов «Хәсән Туфан шигырьләренең вариантлары» дигән диплом темасы алды. Миңа шунысы мәгълүм: нинди олы шагыйрь булса да, Х. Туфан кайбер шигырьләрен дүрт, биш, хәтта алты тапкыр эшкәрткән, гел камилләштергән икән. Диплом эше теләп, аңлап, чын күңелдән язылган иде. Менә яклау көне җитте. Хәсән абый белән Мөнҗия апаны Газиз такси белән алып килде. Чөнки ул вакытта Туфан үзе генә өйдән чыкмый иде инде. Менә үтә ябык юка гәүдәсенә бик пөхтә костюм кигән, ак чәчләрен матур итеп тараган Хәсән ага күренде. Без аларны ихтирам йөзеннән аягүрә каршы алдык. Тагын шуңа игътибар иттек: ул күкрәгенә бер медаль таккан иде. Туфанның 1956 елдан соң бирелгән орден-медальләре бар икәнен беләидек. Әмма ул аларны тагып йөрмәгән. Истәлекле урыннарга барганда монысын—»Чирәм җирләрне үзләштергән өчен» дигәнен калдырмаган. Реабилитацияләгәндә, сөргендә вакытта далада көтү көткән еллары өчен бирелгән булган икән ул. Шагыйрьнең шул чорда нинди хәлдә яшәгәнен сиземләү өчен Зөфәр абыйсына язган хаттан кечкенә генә өзек китерү дә җитәдер:

«Хәзергә мин—матди ярлы. Әкияттәге бәхет эзләүче егетләр кебек үк ярлы. Тезләр чалбардан дөньяга тәрәзә ача, белье исә иясе белән саубуллашып, үзенә алмаш сорый һәм: «Мин чолгауга ярармын әле»,—дип, оекбашларны юата. Ботинка гына ачык авызы кадакланганнан бирле дәшми, дөньяга тел тидерми, болыннарда, кырларда (ферма сыерлары башлыгына, ягъни көтүчегә хас салмак адымнар белән) чәчәкләр арасында гизә бирә...»

Әмма ул төшенкелеккә бирелми:

*Үткән гомер кире кайтмый диләр.*
*Кайгырма син, Хәсән, кайтмаса.*
*Үткән гомер кире кайтмый икән,*
*Үтмәгәне аның бар ласа,*—дип үзен юата.

...Диплом яклаучы, аннан оппонент сөйләде, башка чыгышлар да булды. Соныннан дәүләт комиссиясе рәисе мәрхүм Нил Юзиев:

—Хәсән ага, Сездә сүз юкмы?—дип сорады.

Җавап кыска булды.

—Юк, рәхмәт. Олы хезмәт куелган.

...Бу—Хәсән агага 80 яшь тулырга ярты ел калып барган көннәр иде. Аның юбилее бик олылап үткәрелде. Аннан соң озак тормады, 1981 елның 10 июнь иртәсендә вафат булды.

Ә Газиз Кашапов Хәсән ага бу фани дөньядан бакыйлыкка күчкәч тә, Мөнҗия апа белән бәйләнешын югалтмады. Тылсымлы шигърият остасының фатирына баргалап йөрде, архивын барлады, кыскасы, язылачак романына материал туплавын дәвам итте, истәлекләр бастырды. Шуларның берсен—»Үлем сорап язылган хат» дигәнен миңа да җибәрде һәм ул безнең район газетасында (1989 елның 5 октябрендә) дөнья күрде:



*Хәсән Туфан музеенда.*

«Без, шагыйрьнең туганы Мөнҗия апа белән, инде төнге бер җитүгә карамастан, сөекле Хәсән Туфанның кәгазьләрен барлап утыра идек. Мәрхүмнең архивында әлегәчә укылмаган язулар бик күп. Хәтта «тегe чакта» һәр нәрсәгә тыкшынырга яратучылардан яшереп саклар өчен сохари эчендәге куышка сыярдай итеп эшләнгән, шуның өстәвенә, махсус шифр белән язылган һәм инде беркайчан да укып булмаячак шигырьләр дә бар... Шундый кичерешләрнең берсендә без бөгәрләнеп беткән кәгазь битенә юлыктык. Мөнҗия апаның күзләре дә инде мактанырлык түгел, ә минем гарәпчә хәрефләрне уку осталыгым чамалырак булгангадыр, мөгаен, без әлеге кәгазьне читкәрәк куеп торырга булдык. Әмма нәрсәдер мине дә, Мөнҗия апаны да борчый иде, әллә нинди бер калерле нәрсәне читкә этәргәнбездер кебек тоела башлады. Мондый тойгы монарчы беркайчан да алдамаганга күрә мин аның сәбәбен эзләргә керештем һәм күзем әлеге кәгазьгә төште.

Без аны бергәләп укырга керештек. Укыган саен күзләр яңадан -яңа көч туплаган ялкынлы сүзләргә карады, ә йөрәк илдәге гаделсезлекләргә, рәнҗетүләргә, кыерсытуларга ныграк әрнеде. Бу хат русча язылган һәм Казан төрмәләренең берсеннән, тимер ишекләр, кеше буе җитмәслек тәрәзәләр, салкын таш диварларны ертып чыккан һәм Хәсән Туфанның дусты Муса Җәлилнең фашист төрмәсеннән кайткан дәфтәре кебек үк үлемсезлеккә хаклы.

«Татарстан АССРның 5нче ИТКсында тоткынлыкта утыручы шагыйрь Хәсән Туфаннан СССР Верховный Советы Президиумына Хөкем карарында билгеләнгән вакытның калган өлешен ирекле үлем бәрабәренә аклау һәм кичерү турында үтенеч.

Мин 58нче статьяда күрсәтелгән пунктлар буенча, барысы бергә, атып үтерүгә хөкем ителгән идем.

Дансыз һәм хурлыклы үлememне көтеп утырдым. Ниһаять, миңа чыгарылган хөкем карарын ун еллык төрмәгә алыштырдылар. Бернинди шелтәсез биш ел утырдым. Шушы вакыт эчендә алдынгы бригадир булып эшләдем һәм әле дә эшлим.

Тоткыннарны нәтиҗәле, файдалы итеп эшләргә һәм шунын белән үзләренең гомерләрен дә, сәламәтлекләрен дә сакларга өйрәттем. Мин җитәкләгән бригада күп тапкырлар мактау яулады. Ләкин илбасарларга каршы аяусыз көрәшкә күтәрелгән халкыннан читтә булудан да авыррак җәзаның булуы мөмкин түгел һәм ул юк та. Мине сугышка чаклы булган татар поэзиясенең иң яхшы шагыйрьләренең берсе итеп саныйлар иде. Минем иң якын шагыйрь дусларым Җәлилов, Кутуев, Кәримов һәм Мифтахов сугыш кырларында данлыклы үлем белән һәлак булдылар.

Татар халкының данлыклы уллары мине дә төрмәдә түгел, фронтта күрергә телиләр. Бердәнбер балам һәм артист булып эшләүче хатыным минем исән-сау килеш төрмәдән кайтуыма караганда, сугыш кырында яраланып-имгәнеп кайтуымны артыграк күрәләр.

Халкыбыз һәм партия алдында минем бер бөртек гаебем юк. Ләкин мин бер тапкыр да бу хакта язмадым, чөнки моның болай да билгеле икәнлеге суд даирәләренә ап-ачык дип уйладым. Бәлки сугыш вакытында минем «эш»емне тикшерү белән шөгыльләнергә вакытлары юктыр, бәлки илгә шулай файдалырактыр дип фикерләдем.

Бөек халыкның иң яхшы уллары! Сездән мине сугышның иң канкойгыч урынына җибәрүегезне, яки миңа үлемнән берничек тә котылып булмый торган эш кушуыгызны, гранаталарга уралып самурайларның сугышчан машинасы астына ташлану, я булмаса Торпедоның руль тотучысы булып дошман кораблеңең йөрәгенә барып бәрелеп шартлау, яки шуңа охшаш бүтән берәр максатка юнәлешле бурыч бирүегезне һәм шуның белән күпләрнең тормышын саклап калуны тапшыруыгызны сорыйм.

Сталин чорының мәңгелек дан казанган алдынгы кешеләре—большевиклары, үтенәм Сездән: миңа, элеккеге партиясез шагыйрьгә, үземнең Ватаныма кабатланмас тугрылыгымны исбатлап күрсәтеп, Сезнең кан туганыгыз булып тормыштан китү мөмкинлеген бирсәгез иде. Шагыйрь намусы белән ант итәм: сезгә биргән сүземне һичшиксез үтәрмен.

11 август, 1945 ел.»

Бу хатны Хәсән абый Туфан төрмәдән Луиза апага күчереп язып, Мәскәүгә җибәрер өчен чыгарган. Луиза апа шулай эшләгән, әмма ләкин илнең иң югары органында ул вакытта халыклар җәллады, чын иблис Сталин иярченнәре утырган һәм алар, билгеле ки, илне урап алган лагерьлар һәм таш төрмәләр эченнән, күпвакыт канлы җәзалаулар бәрабәренә ирекка чыгарылган ялкынлы мөрәҗәгатьләрен «алмаганнар», «аңламаганнар», дөресрәге, аңларга да теләмәгәннәр. Әмма аларның, татар халкының бөек шагыйре Хәсән Туфанның, башка халыкларның иң алдынгы улларының иманнары камил булган, алар канлы, гаделсезлеккә күмелгән елларның үтәчәген, илнең иркен сулыш аласын төгәл белгәннәр, шуңа ышанулары чиксез булган.

Хатның төп нөсхәсе шагыйрь архивында саклана.

Газиз Кашапов,

язучы».

Әйе, бу урында классик шагыйрьнең сүзләре үзеннән үзе күңелдә кабат янара:

*Юк, йөрәге аның—чын шагыйрьнең*
*Пенсиягә китми, үлсә дә;*
*Күмелсә дә, илгә эндәшә ул—*
*Архивлары аша эндәшә.*

Хәсән Туфан сабалылар өчен дә бик якын. Ул бездә очрашуларда катнашкан. «Мишә дулкыннары» берләшмәсе утырышларында чыгыш ясаган. Болар турында редакция архивында фотосурәтләр саклана. Әле шушы көннәрдә генә аның Газиз ага Нәбиуллинга бүләк иткән китабын (1958 елда басылган) карап утырдым. Ана яшел кара белән болай дип язылган:

«Кадерле Газиз! Бу Сезгә Сабада беренче очрашуларыбыз истәлеге булсын. Хөрмәт белән Х. Туфан. 2. X. 60».

**Бишенче очрашу.** Еллар үтә тора. Озакламый Хәсән аганың Сабага килгәненә 50 ел була. Узган җәйләрнең берсендә без газетабызның фотохәбәрчесе Нурхан Дәүләтов белән мәшһүр шагыйрьнең туган ягына—Аксубай районының Иске Кармәт авылына сәфәр кылып, бу юлы инде бөек әдипне дөньяга тудырган җирләр белән очрашып-танышып кайтырга булдык.

—Хәсән абыйны хөрмәт итеп күрше-тирә район мәктәпләреннән дә, үзебездән дә бик күп укучылар-укытучылар килә. Казаннан әдәбият-сәнгать эшлеклеләре дә булалар,—дип каршы алды тыйнак кына ханым, музейны оештыручы-энтузиаст Рушания Миннеханова.—Аларның нигезләре шушы урында булган. Музейны һәм һәр экспонатны кадерләп саклыйбыз. Менә монысы—1957 елда язылган «Тамчылар ни диләр» шигырендәге ридикюль. Ул куплетларны хәтерлисездер:

*Сандыгыңда ята*
*Синнән калган*
*Белешмәләр салган ридикюль:*
*Миннән сиңа—гомер юлдашыма*
*Иң беренче бүләк иде ул.*
*Ридикюльдә калган белешмәләр,*
*Алардагы кайбер билгеләр*
*Тормышыңның соңгы хәбәрләрен*
*Бүген миңа сөйләп бирделәр...*

Хәсән абый кулга алынганчы ук, «бу ридикюльне сакларсың» дип әйтеп калдырган була. Безгә аны кызы Гөлгенә апа (ул да фаҗигале төстә үлде бит) бирде. Ридикюль эченнән бик кадерле документлар чыкты. Мәсәлән, Хәсән абый белән Луиза апаның никахлашу турындагы таныклыклары, сугыш вакытында балаларын ялгыз калдырып төнге дежурга чыкмаган өчен Луиза апага салынган штраф квитанциясе, ире «халык дошманы» булган өчен башта эштән, аннан Чистайга сөрелү турында белешмәләр, Луиза апаның Хәсән абый кайтыр алдыннан вафаты турындагы язу...

Гомумән, биредәге һәр экспонатны күз карасыдай саклыйлар. Әнә шкафы белән китаплары, Аккош күлендә утырып язган өстәле белән кәнәфие, документлары салынган шкатулкасы, эш күзлеге, өс киемнәреннән—яшел күлмәкләре, костюмы, бүреге, эшләпәсе, пальтосы. Үзе күп тапкырлар төзәткән стена сәгате дә туктап калган. Музейдагы бөтен әйбер дә күңелгә якын, әлбәттә. Әмма ядкарьләрнең дә ядкаре—Хәсән абыйның әнисеннән калган сөлге. Аны ул: «Үлгәч, Хизбулланың (шагыйрьнең мулла кушкан исеме) битенә ябарсыз»,—дип әйтеп калдырган була. Бу сөлге Мөнҗия апада сакланган иде. Икенче ядкарь—сукно күлмәк. Аның да үз тарихы бар. Хәсән Туфанга сөргеннән кайтырга рөхсәт булгач, ул, кибеткә барып, шушы сукноны сатып ала (өс киеме бик начар була) һәм үзенең кул машинасында шул күлмәкне тегеп, Казанга кайтып төшә,—дип фикерен тәгалләде Рушания ханым.

Әйе, Хәсән Туфанның авылындагы музеенда булып, аның фаҗигале тормышы, иҗат юлы турында тыңлагач, уналты ел буе төрмәләрдә, Себер сөргенендә газап чиккән Хәсән Туфан кабат күз алдына килеп баса, күңел дәрьялары яңадан актарылып, бик күпләргә таныш, романга тиңләрлек шигъри юллары искә төшә:

*Бирде дөнья кирәкне,*
*Еламаска өйрәтте...*
*Кайсыгызның кулы җылы?-*
*Бәйлисе бар йөрәкне.*

## Рөстәм Акъегет

# КҮҢЕЛЕНДӘ ЯШЕРЕН ГАМЬ БАР ИДЕ

«Ана күнеле дә ирешмәслек еракларга китеп барышым».

Бу юллар безнең белән бик иртә хушлашкан шагыйрь Зиннур Насыйбуллинның иң соңгы шигыреннән. «Ана күнеле дә ирешмәслек еракларга»—ул, җиргә әкрен генә сыенган көзге яфрак кебек, тын гына, тып-тын гына китеп барды.



Гомумән, Зиннур Насыйбуллин тормышта да, иҗатта да тыйнак, сабыр булды. Әдәбият мәйданына да чәчрәп чыкмады, дан-шөһрәткә дә омтылмады, кем әйтмешли, тәнкыйтьчеләр тәсбих төймәләре урынына әйләндереп йөрткән исемлектә урын алырга ашыкмады. Кем соң ул шагыйрь Зиннур Насыйбуллин, дигән сорауга без «Совет Татарстаны язучылары» дигән китаптан мондый белешмә таба алабыз:

«Зиннур Сәгыйдулла улы Насыйбуллин 1937 елны Башкортстанның хәзерге Нуриман районы Кече Тенкәш авылында туа. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, колхозда төрле эшләрдә эшли. 1956-58 елларда армиядә хезмәт итә. Аннан кайткач, Бәләбәй киномеханиклар мәктәбен тәмамлап, 1964 елга кадәр Нуриман районында киномеханик хезмәтен башкара, бер үк вакытта төп эшеннән аерылмыйча укып, урта белем ала. 1964-66 елларда ул—Башкорт дәүләт университеты студенты, 1967 елда читтән торып уку бүлегенә күчеп, Зиннур Насыйбуллин хезмәт эшчәнлеген дәвам иттерә. Башта Башкортстанның район газеталарында әдәби хезмәткәр, аннары Башкортстан радиосында мөхәррир вазифасын башкара. 1969 елдан соңгы көненә кадәр Татарстан радиосының әдәби-драматик редакциясендә эшли.

«Тәлгәшләр» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1973 елда басылып чыга».

Белешмәгә Зиннурның «Гамьнәр илендә» дигән икенче җыентыгы керергә өлгермәгән. Аны автор үзе дә кулына тотып карарга өлгермәде шул.

Минем Зиннур белән беренче очрашуым 1974 елның июнь ахырында булды. Әле университет белән бөтенләй үк араны өзеп бетермәгән килеш Татарстан радиосының әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә урнашып йөргән көннәрем. Редакциянең өлкән мөхәррире Рим Шириязданов дәрәҗәлерәк җиргә күчеп, аның урыны бушап калган икән. Җәйнең ямьле чаклары. Редакциянең икенче хезмәткәре әле яңа гына нәүбәттәге ялына киткән. Әдәбият, музыкаль, яшьләр, балалар бүлекләрен үз эченә алган нәфис тапшырулар редакциясенең баш мөхәррире Рим Кәримовның да шулай ук ялга, үзенең туган җире—Оренбург якларына җыенган чагы. Ул июль аенда барачак тапшыруларның планын кулыма тоттырды да: «Кайбер тапшыруларны Рим Шириязданов килеп эшләр, калганнарын үзең оештырырсың, кайткач карарбыз»,—дип, китеп тә барды. Шулай итеп, кулыма айлык план тотып, «кайткач карарбыз»ы нәрсә була икән моның, дигән уй белән, эшкә дә урнашып өлгермәгән килеш редакциядә берүзем калдым. Хәер, редакция бүлмәсендә тагын бер кеше бар, аның белән мине, музыкаль редакциянең әдәби мөхәррире Зиннур Насыйбуллин, дип таныштырдылар. Ишетеп белсәм дә, монарчы аны күргәнем юк иде. Төз гәүдәле, Такташныкыча озын, куе, чалара башлаган кара чәчле, акыллы сабыр караш сирпеп торган зәңгәр күзле урта яшьләрдәге кеше бу.

Вакытлы матбугатта сирәк-мирәк шигырьләре, бер-ике язмасы басылган, ләкин әле шәкертлектән айнып житмәгән тәжрибәсез яшь малайның нинди хәлдә калганын ул анлаган, әлбәттә. Ләкин ачык чырай күрсәтергә дә ашыкмады. Мин үзем дә беренче күргән кеше белән бик үк жинел танышучылардан түгел. Шуна күрә ике-өч көнебез урык-сурык сораулар алмашып кына үтте. Ана дәшеп, сорау бирсәм, ул тәмәкедән саргаеп беткән, музыкантларныкы кебек озын бармаклары белән сигарет көлен пөхтә генә каккалап, жиренә житкереп анлата, үзе миннән берни төпченми. Башта, булса булыр икән бу дөньяда мондый битараф кеше, дип тә уйлап куйган идем. Соныннан белдем, гомумән кешеләр белән мөнәсәбәттә ул бик сак, сөйләшүгә хирыс түгел икән. Ләкин сүзгә кесәгә кереп тормый, шаяртучыларга да тапкыр жавабы һәрвакыт әзер.

Рим Ширияздановның кендеге чыннан да өзелеп бетмәгән икән, ул килеп берике тапшыру әзерләп китте. Шул арада без анын белән танышып, хәтта дуслашып та өлгердек. Тумышы белән шулай ук Башкортстаннан булгангамы, аллә шактый еллар буе бер бүлмәдә бергә утыргангамы, Зиннур белән алар үзара ярты сүздән анлашалар иде. Бу ике чын профессиональнын эшләгәнен күзәтеп тору, аларның ижат мохитында турыдан-туры кайнашу үрнәккә мохтаж яшь малай өчен үзе бер мәктәп булды. Аларга карап үзем дә мөстәкыйль эшкә тартыла башладым. Һәм, озак та үтми, мин әзерләгән тапшырулар да эфирда яңгырады. Әлеге вакыйганы, символик рәвештә генә булса да, без өчәүләп билгеләп тә үттек. Бу Зиннур белән якыннанрак аралаша башлауның беренче адымнары иде.

Кайберәүләр белән гомер буе янәшә яшәп тә, чит-ят кеше булып каласың. Шөкер, безнең Зиннур белән алай булмады, без, ничектер, дәшмичә дә уртак сүз таба алдык һәм бер ай дигәндә безнең мөнәсәбәтләр шактый дустанә иде инде. Шулай булмаса, әлеге үзсүзле, үз-үзенә бикләнгәнрәк кеше: «Син Ширияздан урынына килгәнсен дип ишеттем, ялдагылар чыкканчы таныклыгынны алып куйсаң, хәерлерәк булыр»,—дияр идемени?! Ул аны болай гына, сүз иярә сүз чыгып кына әйткән сымак булды. Ләкин анладым: Рим Шириязданов урынында анын мине күрәсе килгән. Дөресен әйтергә кирәк, ул чакта мине хезмәт вазифасыннан бигрәк, тышлыгы чын күннән эшләнгән шул таныклык кызыктыра иде. Ул вакытларда радионың абруе да зур иде шул. Гап-гади мөхәррир булып раслану өчен генә дә өлкә комитетында әңгәмә үтү кирәк иде бит! Зиннурның сүзләреннән кабынып киттем, ул мәсьәләнең жинел хәл ителә торган юлын өйрәтте. Озак уйлап тормастан, кадрлар бүлеге мөдире—беркадәр ваемсыз, таркаурак, ләкин күндәм һәм киң күнелле маржа түтәй янына кердем, тиешле кәгазьләр тутырттым, һәм күп тә үтмәде, түтәебез житәкчелек утырган икенче катка йөгерде. Мине чын радио кешесе итеп таныткан мөһерле рәсми документ шул көнне үк куен кесәмдә күкрәгемне жылыта иде инде. Димәк, хезмәт вазифам турында житәкчелек күптән инде үзара килешкән. Мин, Зиннурның кайгыртучанлыгы белән, сынау срогын да узмыйча, бүлек мөдире вазифасын башкарырга керештем.

Зиннур белән безнең араны бер вакыйга аеруча якынайтты. Бу болай булды. Атна ахыры, яна торган көндәлек эшләр беткән. Гамьсез генә утырам шулай иякка таянып. Өстәл буш. Алдымда бары тик чип-чиста кәгазь бите һәм каләм. Кул нигәдер ирексездән каләмгә үрелә һәм кәгазь битендә үзеннән-үзе зур хәрефләр белән «Бүген—жомга» дигән язу пәйда була. Шушы «ачыш»тан соң тыныч күнел белән коридорга тәмәке тартырга чыгып китәм. Ул арада безнен яраткан режиссерыбыз, уен-көлке сөюче, һич тиктормас Госман абый Әхмәтжан, минем кәеф дулкынына бирелепме, «Бүген—жомга» дигәннең астына калын хәрефләр белән «Местком» дигән сүзне сырлый. Битарафлык дәрәжәсендә бакый сабыр, гамьсезлек дәрәжәсендә бакый тыныч Зиннурыбызга ул көнне нәрсә булгандыр, Ходай үзе генә белә, ул тота да шул язуны кеше күрмәгән арада боерыклар тактасына элеп куя. Күп тә үтми, кинәт бүлмә ишеге каерылып ачыла да теге кәгазьне селки-селки местком активисты—күрше бүлмәдәге өлкән яшьтәге апа атылып керә. Мине күрү аңа тагын да дәрт-дәрман өстәде булса кирәк, бөтен бүлмәне ярып анын тантаналы зәһәр тавышы яңгырады: «Бу сезнең генә эш, башка беркемнеке түгел, кара син аларны, кара син аларны, совет месткомыннан ничек көләләр, күрсәтермен мин сезгә

ничек күлергә! Фәтхи Фазылҗаныч[1] үзендә микән?.. Хәзер... Хәзер күрсәтәм мин сезгә...». Апабыз минем борын төбендә кәгазьне хәтәр җилфердәтеп, үз сүзләренә буыла-буыла чыгып та китте. Артыннан һава гына суырылып, соңгы сүзләре ишеккә кысылып калды. Җомга көннең икенче яртысы тыныч үтте. Бу начар иде. Димәк, мәсьәләне зурга җибәреп, дүшәмбе көн булачак иртәнге җыелышка калдырганнар...

Дүшәмбе көн «летучка» гадәттәгечә башланды: Фәтхи абый тыныч кына атналык эшкә йомгак ясады. Инде җыелыш бетте, ахрысы, дип җинел сулап куярга әзерләнгәндә генә житәкчебез дәһшәтле житди төс чыгарып, ачулы карашын миңа төбәде:« «Менә яшь специалистка карагыз әле, эшли башлаганына күпме һәм нәрсә белән шөгыльләнә ул, понимашь»,—дип каяндыр теге кәгазьне тартып чыгарды. Аның тавышы көчәйгәннән-көчәя барды: «Ул нәрсә, кайда, нинди оешмада эшләгәнен аңламый мәллә? Баш мөхәррир нәрсә карый, комсомол секретаре?!.» Мин башны аяк арасына тыгардай булып аска караган килеш, Ходайга тапшырган инде, нәрсә булса шул булыр дип тын да алмыйча утыра бирәм. Зал да тып-тын. Теге апаның: «Менә җавап бирсен хәзер»,—дип ысылдаганы гына ишетелә. Әнә шундый гасаби бер мизгелдә аермачык булып Зиннур тавышы яңгырый: «Ул кәгазьне тактага мин элдем». Башымны калкытам. Чалара башлаган чәчләрен сыйпаштырып Зиннур басып тора. Зал өнсез. Фәтхи абзый да өнсез. Мондый хәлне күргәне булмаган, ахрысы. Зиннурга аптырап карап-карап торды да: «Летучка бетте, таралыгыз»,—дип кырт кисте.

Шушы хәлдән соң әле бик озак мин аның алдында үземне ничектер гаепле сизеп йөрдем.

Зиннурны музыкаль редакциянең әдәби хезмәткәре дигән идем бит. Әдәби мөхәррирнең эше беренче карашка әллә ни катлаулы булып тоелмаса да, ул зур әдәби сәләт һәм профессиональ осталык таләп итә торган шактый авыр хезмәт. Гадәти музыкаль программалар, сораулар буенча концертлар, төрле бәйрәмнәргә һәм юбилейларга багышланган тапшырулардан тыш, әле бит аерым язучыларның, композиторларның, һәвәскәр башкаручыларның иҗат эшчәнлеген яктырткан концерт-очерклар, тыңлаучыларның музыкаль белемен күтәрүгә юнәлдерелгән махсус концерт-әңгәмәләр оештырыла иде. Шуның өстенә, музыкаль редакциягә штаттан тыш авторлар да тупланган. Аларның күбесе йә «култык астына скрипка кыстырып туган» халык вәкилләре, йә үзебезнең урыслашкан татар булганга, Зиннурга бик күп кара эш—тәрҗемә белән шөгыльләнергә туры килә иде. Коры академик тел белән язылган, гади кеше аңламаслык үзенчәлекле терминнар белән шыплап тулган никадәр язма узгандыр аның кулыннан. Чиләнсә-чиләнде, ләкин һәрберсенә җан кертте, күңел сулышын өрде һәм аларны саф татарча яңгыратты.

Инде яңа җыр текстларына килсәк, монысы үзе бер тема. Ул заманнарда җыр яздыру студиясенең гөрләп эшләгән чаклары әле. Көне-төне редакция бүлмәсендә, студиядә җырчылар, композиторлар, музыкантлар, шагыйрьләр кайнаша, өзлексез эш бара, иҗат хөкем сөрә. Җыр текстларын карап чыгу, тиешле шигъри камальгә[2] китерү Зиннурга йөкләнгән. Монда Зиннур тагын алыштыргысыз кеше. Эшләсә, ул эшне җиренә җиктереп эшли, текстларына Зиннур кул тидергән авторларның рәхмәт әйтмичә киткәне юк. Җене килсә, беркая ярамаган җыр текстын да өр-яңадан язып бирә. Аның бу йомшак ягыннан оста файдаланучылар да табыла, әлбәттә.

«Нигә болай әллә кемнәр өчен күпме көченне һәм вакытыңны әрәм итәсен?»,—диючеләргә ул: «Көе әйбәт бит, әйдә тусын яңа бер җүнле җыр, миннән булсын яхшылык»,—дия торган иде. Ә белгән кеше белә: әзер көйгә җыр тексты язу бер дә җиңел эш түгел. Аның үз кагыйдәләре бар. Темасы бер хәл, текстны музыкага яткыру, үлчәмнәрне туры китерү, сүзләрнең мантыйкый басымын музыкаль басымга тәңгәлләштерү—болар барсы текст язучыдан зур сәләт тә, тәҗрибә дә сорый.

Ә Зиннурда тегесе дә, бусы да хәттин ашкан иде. Шунадыр, Казан белән Уфа арасында оештырыла торган алмаш концертларны да, аеруча җаваплы

---

[1] Ф. Фазылҗанов—ул елларда Татарстан радиосы башлыгы.

[2] Кәмаль—камиллек

программаларны да гел Зиннурга тапшыра килделәр. Бүтәннәр әзерләгән шундыйрак тапшырулар булса, алар да аның күз уныннан үтмичә калмый. Ул, оста рәссам кебек, бәләкәй генә төзәтмә-үзгәрешләр кертеп җөмләнең аһәңен көчәйтә, әйтәсе фикерне тагы да ачыклап-аныклап фәлсәфи төсмерләр, аны мәгънәви бизәкләр белән баета белә иде.

Зиннурның зур әдәби сәләткә ия кеше булуына ул безнең әдәби редакциядә эшли башлагач тагын бер кат инандым. Нәрсә генә язмасын, коеп кына куя иде. Иң оста каләм иясе дә тел-теш тидерерлек түгел. Әдәби редакциядә эшләгәндә сирәк-мирәк булса да шигырьләр язды, радио өчен әдәби тәрҗемәләр ясады. Ул ара-тирә эшләнгән тәрҗемәләр дә, әгәр бергә тупласаң, күләме белән уртача бер җыентыктан һич ким булмас иде. Әллә тәрҗемәне житди эшкә санамагангамы, әллә гел өелергә торган кәгазь тауларыннан туйгангамы, ул аларны саклауны да, матбугатта бастыруны да кирәк тапмады. Ә алар арасында шактый кызыклылары да бар иде. Мәсәлән, Расул Гамзатның «Минем Дагыстаным» китабыннан кайбер бүлекләр, төрле халык вәкилләренең үз туган телләре хакындагы шигырьләре... Дөрес, кайбер тәрҗемәләре радио фондында әле дә саклана. Киләчәктә бәлки кемгәдер кирәк булыр дип, хәтердә калганнарын искәртеп үтәм. Чыңгыз Айтматовның «Гасырга сузылган көн» әсәреннән өзек, Рөстәм Кутуй хикәяләре һәм шигырьләре, Чиләбедә яшәп иҗат итүче язучы Рөстәм Вәлиевнең «Хәмәт һәм Коромцев» повестеннан өзек, казакъ язучысы Аман Соспаевның «Сары эт» хикәясе...

...Зиннурның 1987 елны басылган «Гамьнәр илендә» дигән китабын янә укып чыктым, һәм өр-яңа китап укыган кебек булдым. Алдагы битләрдә урнашкан берничә шигырен санамаганда, андагы шигырьләр бүген дә заманча яңгырый, бүген дә үзләренең эстетик кыйммәтен югалтмаган. Хәзер инде ышанып әйтергә буладыр— Зиннур вакыт сынавын узган шагыйрьләрдән!

Зиннурның 1973 елда дөнья күргән «Тәлгәш» җыентыгы аның кулына бик сонарып, үз сүзләре белән әйтсәк «шатлыкларга инде күнегеп, иялəшеп беткәч», 36 яшендә керде һәм шагыйрьне «илһам өстәп яңа иҗат үрләрен яуларга рухландыра» алмады. Мин аның белән эшли башлаганда ул инде актив иҗаттан читләшә бара иде. Аннары, шигырь уты сүнеп бетмәсә дә, язу-сызу эше белән шөгыльләнергә аның артык мөмкинлеге дә юк иде. Көн дәвамында—бимазалы радио эше. Кичен—эшчеләр тулай торагындагы дүрт кешелек шау-шулы кысан бүлмә. Түземсезлек белән көтеп алынган ял көннәрендә исә ул Дөбъяз районында укытучылык иткән хатыны һәм сабый кызы янына ашыга. Кызын бик ярата иде Зиннур. Кызы дигәндә аның йөзе җанланып китә, күзләре нурлана, хәрәкәтләренә дәрт керә. Фатир да аңа шулай ук бик соңлап, кырыкның аргы ягына чыккач, дөнья гаме инде битарафлана, шигырьгә күңеле сүрелә башлагач бирелде.

Зиннур бик яшьләй тормыш арбасына жигелә, буындашлары күргән бөтен авырлыкларны, михнәт-нужаларны үз җилкәсендә татый. Йокы хисабына булса да, күңелендә бөреләнгән уй-хисләрен яшереп кенә кәгазь битләренә төшерә һәм аларны кайчан булса да басылган килеш күрергә хыяллана. Ә басыла торган бердәнбер урын—район газетасы. Ул да чәчү һәм урып-җыю турындагы сводкалар, тирес түгү, дуңгызларның көнлек артымы турында язмалар, тәрҗемәләнгән материаллар белән тулган. Ә шигырьгә урын? Бу җирдә Зиннурның каләмдәше һәм күпмедер вакыт хезмәттәше дә булган Әхмәт Рәшит язмасына мөрәҗәгать итик. «Ә шигырьгә урын соңгы чиратта иде. Анда да идеологик нигезе нык булса гына... Тема көн кадагына суга торган булса, матбугатка үтә аласың, булмаса юк. Менә шул хакыйкать тора-бара аңга сеңә дә иҗат кешесенең психологиясен үзгәртеп, аны идеология колына әвереләрдерә иде. Шагыйрь дустым язганнарны кабат-кабат укып карыйм: Ленин һәйкәле, «Интернационал» җыры, Баку комиссарлары, матросовчылар, Армиягә китүче яшьләр турында шигырьләр. Тематик чир Зиннурга да кагылмыйча үтмәде. Ләкин шул әсәрләренең янәшәсендә үк үзәкләрне өзәрдәй «Кара шәле килә сөйрәлеп» дигән шигыре, башка шигырьләр. Тулаем алганда, Зиннур үз шигъриятендә ихлас булырга тырышты, башкалар кебек халтурага бирелмәде, арзанлы дан артыннан кумады...»

Әйе, Әхмәт Рәшит әйткәнчә, Зиннур үз иҗатында ихлас һәм эчкерсез иде. «Хушлашканда», «Үзгәрдең син», «Канаган канатны җилкетеп» кебек шигырьләрне эчке бер тетрәнүсез, әрнүсез язып булмый ул.

Зиннур традицион калыпта һәм шушы калыпның чиксез мөмкинлекләре барлыгына инанып иҗат итте. Үзенең табынган шагыйре Хәсән Туфан кебек, формага караганда, ул күбрәк шигырьнең эчтәлегенә, мәгънәви яңгырашына, аһәңлелегенә игътибар бирде. Туган телнең бөтен нечкәлекләрен яхшы тойган кеше буларак, ул аның чиксез хәзинәсеннән мөмкин кадәр кинрәк файдаланырга тырышты, нәтиҗәдә үзе дә ана телен баетырлык канатлы сүзләр дәрәҗәсендәге шигъри юллар тудырды.

*...Акчарлаклар, әнә, ял итсә дә,*
*Дулкыннарга кунып ял итә.*
(«Уйлый идем...»)

*...Тик яшәми канатлылар,*
*Канатсыз тормыш белән.*
(«Канаган канатны җилкетеп...»)

*...Юксынуы җиңел түгел икән*
*Уз янында булган кешене.*
(«Үзгәрдең син»)

Аз язса да, бер уйлаганда, Зиннур бәхетле шагыйрь иде. Ул халык әле шигъри сүзнең бәясен белгән чорда яшәде. Шагыйрьнең «Гамьнәр илендә» дигән икенче җыентыгы да, беренчесе кебек, чыгуга ук таралып бетте, күтеп алган укучыларын тапты.

Хәзер уйлап утырам, Зиннур белән 12 ел чамасы бергә эшләгәнбез. Шул елларда иң аралашкан кешесе дә мин булганмын. Безнең эш урыны гына түгел, яшәгән җирләребез дә тора-бара бер тирәдәрәк булып чыкты. Ләкин бик озак бергә эшләп тә, кайвакыт хәтта ял вакытларын да бергә үткәрсәк тә, барыбер Зиннурның эчке һәм тышкы дөньясын яхшы белә идем дип әйтә алмыйм.

Авылда туып үскән, шунда тәрбия алган табигать баласының күңеле зур шәһәрнең шартлы тормышына, бигрәк тә кешеләрнең ясалма мөнәсәбәтенә күнегеп тә, ияләшеп тә бетмәгән, күрәсең. Зиннур күбрәк үз эченә бикләнебрәк яшәде, аның ниндидер кешеләргә сиздерергә теләмәгән «күзгә арты дөньясы» бар иде. Ул дөньяга Зиннур беркемне дә, хәтта иң якын кешеләрен дә кертергә теләмәде. Миңа калса, Зиннурда аның күңелен ирексезләп, бимазалап торган бер борчу, гамь бар иде. Ул аны даими сызландырып торды кебек. Нинди борчу икәнлеге сер булып калды. Ни генә булмасын, Зиннур беркайчан да вакланмады, чәбәләнмәде, үз дәрәҗәсен белеп яшәде. Анда тышка бәреп, ташып тормаган эчке бер горурлык бар иде. Зиннурга кайвакыт «синдәге сәләт башкаларга бирелсә, алар нәрсә генә эшләмәс иде»,—диючеләр дә булды. Җавап урынына ул иннәрен җыерып көлемсерәп кенә куяр иде.

Зиннур белән без бергә эшләгән, бергә аралашкан еллар, хәзергечә әйтсәк, торгынлык вакытына, тормыш ашыкмыйча гына үз җаена ага биргән чорга туры килде. Кешеләр дә ул вакытта Ходай биргән юклы-барлы кыска гомерен бүгенгедәй ут капкандай чабып-йөгереп үтми иде. Җәй айлары, кичкырын без Зиннур белән Казансу буенда йөзьяшәр тирәкләрнең дулкын юып шомарткан карт тамырларында утыргалыйбыз. Подлужный урамы әле элеккечә, шул килеш, вакыт гүя ки монда туктап тора—җыйнак йортлар агачлар күләгәсенә ышыкланган, хәрәкәт юк, шәһәр шау-шуы килеп житми. Өстә, зәңгәр күктә каядыр еракта калган балачак иленнән йөзеп килгән ак болыт кисәкләре тирбәлә. Кичке эңгердә ярлары белән хушлашып, тын гына Казансу ага. Кичке шәфәкъ хозурында ашыкмыйча гына суга коелган аксыл-саргылт яфракларның әйлән-бәйлән уйнавын күзәтәбез. Шәраб ачыла, әкрен генә телләр чишелә, сүз иярә сүз чыга. Нәрсә турында гына сөйләшеп

бетермәгәнбездер андый чакларда. Зиннур балачагын искә ала, Башкортстанның табигатен мактый, Сахалинда хезмәт итүләрен, Бүздәк районы газетасында эшләгәндә иптәшләре белән сал ясап, Караидел буйлап сәяхәткә чыгуларын, шәхси тормышы турында сөйләнергә яратмаса да, туган ягында беренче хатыны янында калган малайларын хәтерендә яңарта.

«Их, Сак-Сок темасына бер либретто язарга иде,— дип күрсәнү катыш хыялланып ала.—Бер уйласаң, бу әле аерым кешеләр язмышы гына түгел, гомумән татар халкының, төрки халыкларның уртак язмышы да»,—дип өстәп куя. Әлбәттә инде, агымсулар үткәннәрне дә хәтергә төшерә, узган гомерләрне дә искәртә, яшәеш, фани белән бакыйлык турында да уйландыра. Кайсыдыр бер язучыны җирләгәннән соң шул карт тирәкләр төбендә утырганда: «Ничек кенә авыр, мәшәкатьле булмасын, мин үземне туган туфракта җирләтер идем... Туган туфракта җирләнер идем»,—диде.



*Рәсемдә (сулдан уңга): Рөстәм Акъегет, Равил Кәримов, Зиннур Насыйбуллин, Рәкыйп Гаффаров (арттагы рәт), Нәсимә Әхмәтҗанова һәм Эльза Гобәйдуллина.*

Зиннурның ял йортларында ял итеп ятуын, җылы якларга яки иҗат йортларына баруын хәтерләмим. Һәр елны нәүбәттәге ялын алыр иде дә, шул көнне үк өлкән яшьтәге әти-әнисе янына Башкортстанга кайтып китәр иде. Печән чабып, лапаскураларны карап, капка-коймаларны сипләп, үзенчә ял итеп, җиләсләнеп, күңел күтәренкелеге белән кире Казанга килер иде. 1985 елның җәй башында шушы максат белән ул янә туган ягына юл тотты. Кире кайтуы болай хәтердә калган. Мин дүшәмбе көннәрне була торган җыелышка сонга калмыйм дип эш бүлмәсенә кергәндә Зиннур үз өстәле артында утыра иде инде. «Һәй, Зиннур да эшкә чыккан, яшибез икән болай булгач!»—дип, чын күңелдән сөенеп ана кулларымны суздым.

Зиннур тыйнак кына исәнләште, аннары гаепле кеше сыман елмаеп, кәефсез генә: «Авырыйм әле мин, Рөстәм, авылда да бернәрсә кыралмадым, әти-әнигә бернинди ярдәмем тимәде, гел сырхаулап ятарга туры килде»,—диде. Аннары, минем: «И, андый чаклар була инде ул»,—дигәнрәк сүзләремә игътибар итмичә: «Сине генә көтеп утырам, мин Сәгыйтев[1] янында булдым, рәхмәт ана, нинди дер таныш табибына шылтыратты, хәзер шунын янына барышым. Ярар, әлегә хуш»,—диде дә, чыгып китте. Анын бу чыгып китүе, кызганыч ки, «әлегә» булмады, шул китүдән радиога инде ул кире әйләнеп кайта алмады.

Бер-ике ай 15 нче хастаханәдә ятты. Чыгардылар. Мин хәлен белгәләп йөрдем. Ничә кермә, ул аш бүлмәсенең тәрәзәсеннән урамга карап утыра. Бер кулы белән иягенн учлаган, икенче кулы иң арзанлы һәм иң каты «Астра» сигареты кабын кыпшый (ул чакта барыбыз да шул «Астра»ны көйрәтә идек). Элек кызыл шәрабтан баш тартмаган кеше, аннан тыела төште, ә менә тәмәкедән аерыла алмады, күп тартты, берөзлексез тартты.

Анын янына бер килгәндә, әбиләр чуагы башланган мәл, җылы, матур көзге көн иде. Зиннурның да кәефе күтәренке. Ул мине күрүгә үк: «Рөстәм, бер чыкканда безнең кибеттә коньяк күргән идем, үземнең хәлем юк, бетмәсә, шуны алып кер әле, бәлки, мин дә әзрәк тотып куярмын»,—диде. Өстәл янында шактый сөйләшеп

[1] Сәгыйтев Тәүфикъ Камәр улы—ул чакта Татарстан радиосының яңа җитәкчесе.

утырдык. Шунда ул тәмәке төтененә буылып: «Булдыра алсаң, тәмәкене ташла, мин дә елларны кире кайтарып булса, тартмаган да, тотмаган да булыр идем»,—дип, көрсенеп куйды. Элек юкса үгет-нәсихәт бирә торган кеше түгел иде Зиннур. Адәм баласы үз башына төшмичә, беркайчан да кеше ялгышыннан гыйбрәт алачак түгелен ул яхшы аңлый иде.

Шактый сөйләшеп утырдык. Зиннурның савыгырга өмете бик зур иде әле. Сүз ахырында: «Бу табибларны да әйтер идем инде. Синең бер чирең дә юк, организмың хәлсезләнгән, күбрәк витаминлы азык ашарга, сөт эчәргә кирәк, диләр. Бөтенесен аларча эшлим, инде ничә ай үтте, яхшыга бернинди үзгәреш юк, киресенчә, хәл начарланганнан-начарлана бара, ичмасам, дарулар да бирмиләр»,—дип бераз зарлангандай да итте. Шуннан соң Зиннурның хәле белән даими кызыксынып торган җитәкчесебез Тәүфикъ Сәгыйтев аны РКБга урнаштыру җаен тапты. Күпмедер ятып чыкты, ләкин анда да Зиннурга ярдәм итә алмадылар. Ул сызганнан-сыза барды. Кара көзләр җитеп, декабрь башланды, карлар яуды. Әҗәл аңа хөкем чыгарып яткан көннәр... Мин аның янына болай да еш керәм, ләкин беләм, ул минем тагын да ешрак керүемне тели. Эштән кайтышлый юлым аның тәрәзәсе каршыннан үтә. Башка юл да бар, ләкин болай турырак. Кичә генә хәлен белгән идем, бүген инде кермәсәм дә ярый дип өен узып китәм. Белмим, бу дөньяда чыннан да нәрсәдер бар, ахры. Аның карашы аркамны тишә. Сизәм, бөтен җаным-тәнем белән тоям, Зиннур мине күргән, таныган, инде хәзер өметсез карашы белән кышкы кичнең караңгылыгында югала барган шәүләмне озата. Ниндидер көч мине кире бора. Ишек төбендә сагалап торган диярсең, кыңгырау төймәсенә басу белән Зиннур күренә. Сүзсез генә бер-ике сигарет көйрәтәбез.

Хәлләре авыр булса да, Зиннурның бәләкәй генә юанычы бар—өстеннән бер йөк төште. Тагын ел, ел ярымнан дөнья күрәчәк «Гамьнәр илендә» китабының кульязмасы яңабаштан бер каралып, Равил Фәйзуллинның төпле кереш сүзе белән Татарстан китап нәшриятына тапшырылды. Китап чыгачагына инде хәзер борчылмаска да була.

Зиннурга чын күңелдән сәламәтлек теләп, аның хәлен белешеп торучылар байтак булды. Хәлен белешүчеләр генә түгел, хәленә керүчеләр дә юк түгел иде. Шундыйларның берсе Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире, язучы Фәрваз Миннуллин. Бер көнне ул мине үзенә дәшеп алды да: «Зиннурның бу китабы 1987 елда гына басылып чыгачак. Әгәр дә аңарчы аның белән берәр хәл була калса, гаиләсенә китапка тиешле гонорарның нибары 25 проценты гына эләгәчәк. Ләкин бер хут бар, әгәр дә ул үз кулы белән, «Дәвалану өчен акча кирәк булу сәбәпле, гонорарны тулысынча алдан түләвегезне үтенәм» дигән гариза язса, директор белән сөйләшүне мин үз өстемә алам, озакка сузма»,—диде. Бу сөйләшү декабрьнең урталарында булды. Гаризаны ничек яздырырга? Турыдан-туры, гариза яз, дип әйтеп булмый, Зиннур бик сак акыллы, кеше, дөресен шунда ук төшенәчәк. Бер яхшырак шәраб алдым да, Зиннур янына киттем. Ишектән керү белән: «Зиннур, сөенечле хәбәр бар. Әле яңа гына Фәрваз абыйны күрдем. Нәшриятның быелга бирелгән бераз акчасы файдаланмыйча калган, аны Яңа елга хәтле сарыф итеп бетерергә кирәк икән. Зиннур кебек җүнле кешеләрнең хәленә кереп, китапка тиешле гонорарны алдан ук тулысынча түләп кую мөмкинлеге бар, ди, тиз генә гариза язарга кушты, шуңа ашыгыч килүем»,—дидем. Зиннур уйга калды, бүген каләм тотарлык хәлем юк, дип карады. Мин чын-чынлап ачуландым үзен. Гариза язылмаган хәлдә, безнең ул чактагы хезмәт хакы белән исәпләгәндә, ике ел эшләмичә яшәрлек акча юкка чыга бит. Зиннур ул чакта нәрсә уйлагандыр, әйтүе кыен, ләкин гариза язылды.

Ә күп тә үтми, яңа елга кереп, ябалак-ябалак карлар ява башлаганда без Зиннурны соңгы юлга озаттык. Ул Самосырово зиратында җирләнде. Җәсәден җир куенына иңдергәндә, аның Казансу буенда агымсуларга карап пышылдаган сүзләрен ишеткәндәй булдым: «Юк, мин туган туфракта җирләнер идем!»

Җил исеп куйды.

Ярлары белән хушлашып Казансу сулары ага да ага. Алар ярлары белән генә хушлашмый, безнең белән дә хушлаша икән.

♣

# ЯШӘҮ ТАМЫРЫ... ТИРӘНДӘ

*Бу дөньяда*
*Караңгыдан якты күбрәк.*
Наис Гамбәр

Хәзер инде ул безгә рәсемнән генә елмаеп карап тора. Карашы жылы, ягымлы, күзләрендә нур, иман бар. Шушы көлемсерәп торган моңсу күзләр артында никадәрле гамь, гуманизм, фәлсәфи фикер, тетрәнүләр—барысын берләштереп әйткәндә, тугызынчы дулкын посып ятканын без хәзер генә ныграк аңлыйбыз шикелле...



Сүзем—арабыздан иртә китеп барган талантлы каләм иясе, шагыйрь, әдәби тәнкыйтьче Наис Гамбәр турында. Безнең замандашыбыз «иде» дияргә ничектер тел бармый, чөнки үзенең иҗаты, шәхесенең үзенчәлеге, кылган гамәлләре белән ул безгә бүген дә замандаш һәм иртәгә дә замандашыбыз булып калачак.

Төп сүзгә керешкәнче, бу урында үзеннән-үзе иң әлек бер чигенеш тә ясап аласы килә. Ниндидер мистика, фатализм бар түгелме—соңгы бер ел эчендә кинәт кенә арабыздан зур талант иясе китеп барды: кайнар-романтик рухлы Зөлфәт... исән чагында ук халык шагыйре дип танылган Мөдәррис Әгъләм... сүзен-фикерен өздереп әйтә белгән Нияз Акмал... Шунысын да әйтик, үз буыннары арасыннан бу исемлекне алдан-рак Наис үзе «башлап» җибәргән иде ләбаса. Тормышта да, иҗатта да янып-көеп яшәгән әлеге борчулы җаннарның гамьле кайтавазы безнең тәнебездә-вөҗүдебездә кан тамырыдай тибеп, үзен һаман сиздереп тора түгелмени?!

Барыбыз да шулайдыр: типография, тагын әллә нинди тылсымлы-бихуш исләр аңкып торган яңа китапны һәрвакыт зур дулкынлану белән кулга аласың, ачарга кыймыйчарак иң әүвәле тышлыгына багасың. Менә кулымда яңа китап—Наис Гамбәр «Яшәү тамыры»*.

Шигырьләр, эссе-хикәяләр, мәкаләләр дигән сүзләр белән аның өч тармагы титул битләрдә үк ассызыклап куелган.

Әйе, китап «Шигырьләр» дигән бүлек белән ачыла (җыентыкка кереш сүзне шагыйрь Рәдиф Гаташ язган). Кемнәрнедер күздә тотып, кинаяләп әйтүем түгел: шагыйрьләр, гадәттә, ике төрле була—берәүләр күп яза, күп китаплар бастыра; икенчеләр исә аз яза, өч-дүрт китап белән чикләнә. Наис—соңгылар җөмләсеннән. Шагыйрьнең зурлыгы, иҗатының кыйммәте күләм белән түгел, сыйфат ягы белән дә үлчәнә.

Китапның «түре»нәрәк узган саен өр-яңа дөнья, шигъри табышлар вә ачышлар белән очрашасың. Кошлар, кырурманнар, яфрак, агымсулар, ай-кояш, ел фасыллары... Болар хакында кемнәр күпме генә язмаган да, галәми табигатьне кемнәр генә үзе «күргәнчә» сурәтләмәде икән! Шөкер, Наис иҗатында болар бар да—нәкъ аныңча күрү-тоемлау, үз дөньясын (һәм җисми, һәм рухи яктан) тудыру осталыгы белән, күпләр татып өлгермәгән өр-яңа бер моңсулыкка манып язылган. Аның күп кенә шигырьләре җанның күккә ашуы, күңелнең гади күзләр күреп бетермәгән моңсу матурлык иленә алгысынуы рәвешендәрәк кабул ителә.

---

Наис Гамбәр «Яшәү тамыры». Казан, Татарстан китап нәшрияты. 2007.

*Башлар тулы уйлар – кибән-кибән,*
*«Очты күңел кошы...» Ник җилкенәм? –*
*Хәл җыярга иде бер туктап*
*Шундый дымык, боек иртәләрдә.*

Аның иҗаты лирик-фәлсәфи фикерләр белән сугарылган. Галәм, җир, дөнья һәм яшәеш турында зурдан кубарылып уйлана-яза торгач, ул безне үзе «иҗат» иткән өр-яңа тәэсоратлар дөньясына алып керә, үзенең рухәнә яшәү рәвешен һәм җанын ачып сала. Чагыштыру, метафора, телбизәкләр, көтелмәгәнчә әйтелгән уй-фикерләр шигырьләренең сәнгати дәрәҗәсен югары баскычка күтәрә. Масштаб, кинлек иң яхшы дигән шигырьләрендә күзгә бәрелеп тора. Гап-гадилектән дә зурга күтәрелә шагыйрь:

*Көннәр якты монда.*
*Томаны да*
*Үтә күренмәле, сөт томан;*
*Күпереп тора ястык болытлары*
*Килиманджаро карлары сыман.*

Алдарак моңсулык дигән идек. Ләкин лирик геройның үзгә бу халәтен бары оптимистик моңсулык дип бәяләү дөрес булыр. Елау, зарлану, сыктау түгел, дөнья күргән зирәк, олпат ир-егетләрчә күңелнең эчкәргече белән моңаю. Көтелмәгән яңа төсмер ачыш-образлар кайчак күңелне сискәндереп куя:

*Җирем! Табанымның эзен яшерегез –*
*Тик каплагыз аны яшел чирәм белән.*

Шәрыкъ шагыйрьләре йогынтысын үз иткән Наис еллар агышына, Вакыт мотивларына да еш мөрәҗәгать итә. Иң мөһиме – уйланып үзенең шәхесенә, заман һәм кеше гомеренә бәйләп аңлатырга омтыла:

*Төнге сулар ага, төнге сулар...*
*Килер бер көн, Вакыт чаңы сугар, –*
*Күкрәк елгасыннан аккан еллар*
*Кайтмас, кайтмас... Тынгы бирми шулар.*

Галимә Алсу Шәмсутова хаклы билгеләп үткәнчә, «Вакытны шагыйрь тыштан гына тасвирламый, вакыт аның йөрәге-күңеле аша ага, лирик герой аны үтәли хис итә» («Шәһри Казан», 31 август, 2007).

Шагыйрьнең мәхәббәт дөньясы да шактый үзенчәлекле. Әйтер идем, сәер мәхәббәт: үзе сөя, үзе кача; үзе сагына, үзе ераклаша; үзе кырыс, үзе нечкә җанлы; үзе горур, үзе... Аның күңелендәге тирбәнешләрне, тартыш һәм сөю газапларын тагын әллә ничаклы «үзе»ләр белән билгеләп булыр иде. Хисләр палитрасындагы төсләрнең күплегеннәндер бу, күрәсең. Лирик герой үзенең сагыну-сагыш мотивларын шәрәләндереп, маңгайга бәреп түгел, кинаяле образ-метафораларга төреп әйтә:

*Бушка, бәлкем, сөю-янулар?!*
*Поезд киткән инде... юлларябык, –*
*Алда яңа кызыл семафор.*

Әйтергә яраса, китапта җегәрле шигырьләр урын алган. Афоризм булырдай җөмләләрнең һәр сүзе үз урынында: «Тормышның һәрбер кичәсе – мен дә бер кичә!» Сер түгел ич, кайбер авторларның шигырендәге сүзләрне... юлы белән генә түгел, куплеты белән алып ташлаганда да әсәргә әллә ни зыян килми. Н. Гамбәрнең юлчысы да, сихри атаулар артында «гүзәл балкышлар күреп», моннан мең еллар элек (!) сәфәргә чыккан икән...

Шагыйрь тормышыбыздагы мәңгелек категорияләрдән саналган Яшәү белән Үлем темасын да читләтеп узмый, ләкин тормышта өмет һәм яктылыкның «барыбер күбрәк» икәнлеген раслый, матурлыкка дан җырлый.

Бу шигъриятнең нигезен, ныклыгын, тамырларын кереш сүзендә Рәдиф Гаташ бик тә төгәл әйтеп биргән: «Наис Гамбәр фәлсәфи шагыйрьләр мәктәбен үз күрде... Иң мөһиме – үз классик шагыйрьләребез, милли классикларыбыз йогынтысы: Тукай, Дәрдмәнд, Туфан мәктәбе, замандашлары Зөлфәт, Әгъләм шигърияте ирешкәннәргә таяну, алар замандашы булу шатлыгы...»

Бу юлларга өстәп, шунысын да әйтәсе килә: Зөлфәт белән Әгъләмнең иҗатларына никадәр мөкиббән булса да, шигърияттә Наис аларны кабатламады! Нечкә тоемлы фәлсәфи лирикасы белән ул безнең әдәбиятта үзенчә танылды, үз сукмагыннан атлады.

***

Китапның икенче бүлеге исә язучының эссе-хикәяләре белән ачыла. Наисның әле яхшы прозаик та икәнлеген күпләр күрми-сизми калган булгандыр,

мөгаен. Беренче язмада (аска, җәяләр эчендә, «Әйтелгән васыять» дигән өстәмә сүзләр дә язылган) автор кабык арбада ничек үсүе, тәрбия сәгатьләре бирүче әткәсе турында ничек җылы итеп, яратып, горурланып яза. Әйтерсең, автор туган телебездәге телбизәкләрдән парча чигә, Мөслим ягынчарак сүзләрне дә отышлы итеп әсәр тукымасына кертеп җибәрә.

Ат җигеп гаилә белән печәнгә төшү, беренче покосны чыгулар, әбәд вакытында мәтрүшкәле чәй, чуен казанда пешкән итле шулпа белән сыйланулар дисенме— болар бар да талантлы прозаик кулы белән язылган. Сәнгатьчә оста тасвирлауларга бай булган, яраткан әдипләремнән Г. Ибраһимовның «Табигать балалары», М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү» дигән әсәрләре ирексездән хәтергә килде.

Икәүдән-икәү генә калган вакытларда гади бер җир кешесе—әтисенең әйткән сүзләрен генә кара син:

—...Эшне ярат, намуслы бул, кеше өлешенә кермә, беркайчан да тәкәбберләнмә, иманыңны сатма.

Тормышта, гомеренең яшәп калган өлешендә Наис, миңа калса, әтисенең «әйтелгән васыятен» тулысынча үтәде шикелле. Кыскасы, ул «Лев Николаевич үлгән елны туган һәм нәкъ аның яшендә дөньядан китеп барган» әтисенә үзенә күрә бер шигъри-әдәби һәйкәл салып өлгергән.

Әдәбият сөючеләрдән кем генә Әмирхан ага Еникинең «Матурлык» хикәясен белми-хәтерләми икән! Шаккатмын: кешенең төсе-кыяфәте түгел, күңел матурлыгы мең кат кыйммәтрәк дигән фикри сюжетлары да бер үк; әмма Наис, кабатланудан курыкмыйча, нәкъ менә шушы темага, нәкъ менә шундыйрак өслүбтәге хәлләргә «Ма-ту-у-у!!!» дигән эссе язарга җөрьәт иткән...

Рәссам Илдар Әхмәдиев турындагы язма да кызыклы, үзенчәлекле итеп язылган. Бактың исә, оста рәссам булу өстенә, Илдар—Кремль биләмәсендәге Сөембикә манарасына беренчеләрдән булып Ай куйган егет икән! Моның «серен» белер өчен, иң яхшысы, язманы укучы үзе укып карарга тиештер...

***

Китапның ярты өлешен диярлек биләп торган өченче бүлек, әйткәнебезчә, «Мәкаләләр» дип атала. Дөресрәге—тирән эчтәлекле, шигъри тел-стиль ягыннан аерылып торган фәһемле әдәби тәнкыйть мәкаләләре, иҗат портретлары, китап күзәтүләр.

Кыска гына бу мәкаләдә андагы барлык язмаларны шәрехләү, күздән кичерү мөмкин түгел, билгеле. Шуңа күрә авторның каләменә, җылы һәм таләпчән карашын «эләккән» әдипләр, шәхесләрнең тулы булмаган исемлеген санап китү белән чикләнәм: Р. Даутов, Р. Фәйзуллин, Роб. Әхмәтҗанов, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Ф. Гыйльми, М. Хәсәнов, Т. Галимуллин, М. Вәлиев-Баржылы, Г. Садә, М. Гали, Акъегет, Р. Батулла, Ф. Әмәк, сынчы Ә. Фәтхетдинов, нәфис сүз остасы А. Арсланов, композитор М. Мозаффаров һ. б.

Шулай да... шулай да колачы, язылышы ягыннан иң саллы һәм төпле ике язманы аерым билгеләми мөмкин түгел: болар «Учак җылысы» (Рәис Даутов турында) һәм «Башны салларга салып...» (Равил Фәйзуллин иҗаты турында).

Рәис Даутовның (мәрхүм) кем икәнлеген аңлатып торуның хаҗәте юк. Шәхсән, мин үзем шуңысын гына әйтеп китә алам: ул әдәбиятка, иҗат эшенә бик җаваплы карый иде. Аның менә шушы сыйфатын Наис, хезмәттәше һәм фикердәше буларак, ныклы мисал-уйланулар аша аңлатып бирә белгән. Мәкаләдәге соңгы юллар аеруча истә кала: «Аның учагы һәрвакыт тере, учак урыны һәрвакыт җылы. Чөнки учагын ул кешеләр, халык күңеленнән сирпелгән очкыннардан кабызып җибәргән».

Равил Фәйзуллин дигән шәхесне, аның күпкырлы иҗат дөньясын ачып бетерү мөмкин түгелдер, ахрысы, дигән уй-фикергә килгән идем мин берчакны. Яшь, яңа типтагы тәнкыйтьче Илшат Вәлиуллин үзенең «Һәр шагыйрь—бер дәрья» дигән китабында шушы серле пәрдәнең иң эчкәре почмакларын күтәреп ачкан иде безгә. Бактың исә Наис дигән егетебез бу өлкәдә әллә кайчан «беренче» пионер булган икән! (1993). Сүзенең башында «Шигъри дөньялар эзлим!» дип чаң кага да, рухы һәм каләме белән тәмам тугарылып, ул шагыйрь иҗатына дәлилле, әтрафлы тирән анализ ясый, үзе өчен дә, безнең өчен дә яңа дөньялар ача...

Менә бит ничек: Р. Фәйзуллинның

үзе белән дә, аның иҗат дөньясы белән дә булачак язучыны, әдәбиятчыны 1965 елда ук укытучысы Рәдиф Гаташ таныштырган икән... (Бу кыйссаны сөйләп чыгасым килми, укучы үзе укып танышса иде дигән теләктә калам).

Р. Фәйзуллин иҗатындагы рухи һәм иҗади үсеш-үзгәрешләр юлына, текә борылышлар ясау, кирәк чакта кирәкле ориентирларны сайлау, хәтта мәхәббәт дигән олуг дөньяда эволюцион үзгәреш ясауларны каләмдәшебез Наис, күзәтүчән һәм оста психолог буларак, бик тә үтемле итеп бәя биргән. Сүземне кыскартып, ике генә җөмләне мисалга китереп узам:

«Фәйзуллин шигърияте минем өчен җанга нуклык, иманга нур өсти торган шигърият булды дип әйтер идем».

«Тормышта балалык, иҗатында өйрәнчеклек чоры булды микән аның? Шикләнәм. Чөнки ул егерме яшендә хәзерге илле яшьлек Фәйзуллиннан җитдирәк, хәтта прагматиграк булып тоела мина».

Бу мәкаләдән тагын шунысы да ачыклана төшә: Наис шигърияткә, туган телебезгә изге бер нәрсә итеп караган икән...

Студент елларыннан ук бергә кайнашып яшәгәнгә күрә, мин Марсель Галиевне хәйран яхшы беләм дип йөри идем. Минем өчен Наис аны өр-яңадан «ачты». «Бер бүлмәдә яшәдек...» дигән сүзләре М. Гали, Ф. Гыйльми, Акъегет турындагы мәкаләләрендә юкка гына әйтелмәгәндер. Наис студент чакларында, Татарстан китап нәшрияты һәм «Казан утлары» журналында эшләгән елларында да танылган әдипләр, күркәм шәхесләр, татар халкының зыялы уллары белән һәрвакыт якыннан аралашып яшәде.

Күренекле шагыйрь Роберт Әхмәтҗановка бер генә җөмлә белән минә ничек итеп «үтергеч» характеристика бирә ул: тормышта җәяүле күбәләк булып та, шигъриятта шонкар булу бәхете теләсә кемгә эләкми...

Кыскасы, алып гәүдәле, карап торышка гади бер егеткә охшап торган Наис Гамбәрнең олы гамьнәр белән яшәүче борчулы җан икәнлеген аңлап бетермәдек, ахрысы, дигән тәэсир калды. «Гамбәр—гамьле егет икәнсең...» дип вакытында әйтә белмәгәнбез. Ул трибуналарга чәчрәп чыкмады, орден-медальләр сорап кешене аптыратмады.

Наис Гамбәрнең «Яшәү тамыры» дигән китабы белән танышып чыкканнан соң күкләрем биегәеп, уй-фикерләрем тирәнәеп, күңел күзләрем кинәттән җетеләнеп китте шикелле.

Бу китапның бер дә кимчелеге юкмени соң, дип сорарга мөмкиннһәр. Мин боларны эзләмәдем дә, тапмадым да. Яңа китап белән танышу сөенечен уртаклашасым килде. Бары шул.

«Яшәүдән соң яшәү бармы?»—дип сорый шагыйрь бер шигырендә. «Бардыр...» дип җавап та бирә. Әйе, аның гомере иҗатында, замандашларының хәтерендә кабатлана.

Яшәү тамыры, чыннан да, бар икән ул! Бу—балачакка, туган җиренә, әтиәниенә, туган теленә, кояшка һәм кешеләргә тартылу. Тамыры тирәнгә китмәгән үләннәрне җил аударып, тамыры җиргә нык берекмәгән агачларны өермә куптарып ала. Табигатькә дә, тормышта да тирәнлек кирәк.

Яшәү тамыры—тирәндә.

**Рашат НИЗАМИ**

## Абдулла Алиш

(1908—1944)



Шагыйрь һәм көрәшче Аблулла Алиш 1908 елның 15 сентябрендә Татарстанның Спас районы Көек авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Бабасы—мулла, әтисе хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгән. Әнисе Газизә шигырь һәм бәетләр чыгарырга һәвәс булган. Хөр фикерле хезмәт сөючән гаиләдә кечкенәдән үк зиһенле бала булып үсә, башлангыч (иптидаи) мәктәптә белем ала. Мәдрәсә, совет мәктәбе, педагогия техникумында уку елларыннан соң 1927 елның җәендә Казанга килә, төрле жанрларда актив иҗат итә башлый.

Иҗаты: балалар өчен «Дулкыннар» (1934), «Ант» (1935), «Минем абый» (1940) исемле хикәяләр, «Ана әкиятләре» (1941), «Әкиятләр» («Сказки», 1959) исемле җыентыклар. Шулай да А. Алишны балаларның сөекле язучысы дәрәҗәсенә күтәргән жанр—әкиятләр. Алар кызыклы итеп, музыкаль яңгырашлы, сурәтләү чараларына бай, образлы тел белән язылган.

Муса Җәлилнең көрәштәше. Совет хәрби әсирләренең яшерен оешмасы эшендә катнашканы өчен 1944 елның 25 августында фашист палачлары тарафыннан гильотинада җәзалап үтерелә. 1966 елда ТР Язучылар берлегенең балалар әдәбияты өлкәсендә Алиш исемендәге бүләге булдырылды.

Әдипнең рәсемдәге бюсты туган авылы Көектә урнаштырылган (2001).

## Гариф Ахунов

(1925—2000)



Танылган әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Гариф Ахунов 1925 елның 18 сентябрендә Татарстанның Арча районы Өчиле авылында крестьян гаиләсендә туа.

Җидееллык белем алганнан соң, Арча педагогия училищесына укырга керә. Ватан сугышы башлану сәбәпле, укуы өзелеп, колхозда эшли. 1952 елда Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, биш ел буе «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, җаваплы секретарь вазифаларын башкара. 1957 елны, Әлмәт шәһәренә күченеп, ун елдан артык нефтьчеләр арасында яши, булачак әсәрләре өчен аларның тормыш-көнкүренешен өйрәнә. 1963-68 елларда язучыларның Әлмәт бүлеген җитәкли.

Төп иҗаты: «Хәзинә» (1963, Свердловск киностудиясендә 1977 дә шул исемдә нәфис фильм да төшерелә), «Хуҗалар» (1968) романнары; «Чикләвек төше» (1973) повесте; «Идел кызы» дилогиясе (1978—1986); М. Шолоховның «Тын Дон» романын татарчага тәрҗемә итә.

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире (1971-74), ТАССР Язучылар берлеге рәисе (1974—1984), СССР Язучылар союзы идарәсе сәркатибе (1980-85). Татарстанның халык язучысы, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

**Альфрет ӘБДРӘШИТОВ**

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Г

**ГОБӘЙДИ** (Гобәйдуллин) Даут Гобәйдулла улы (1873, Вятка губ., Алабуга өязе Кыдрылы а. - 1919, шунда ук, Тәбәрле а., туган а. күмелә), шагыйрь, тәрҗемәче. 1885-97 елларда «Буби» мәдрәсәсендә укый. Соңыннан туган авылына кайтып, җәдит мәдрәсәсе ача. 1905 тән Иске Кызыл Яр авылында имам булып тора (хәзерге Әгерҗе р-ны), мәдрәсә оештыра, үзе шунда укыта. Укыту программаларында аеруча зур игътибарны татар матур әдәбиятын укытуга бирә. 1912 дә «Бубилар эше» б-н кулга алына, 4 айга якын төрмәдә утыра. 1917-19 да Сарсак-Омга авылы волость башкарма комитеты рәисе урынбасары (хәзерге Әгерҗе р-ны), бер үк вакытта халык мәгариф бүлеге мөдире булып эшли, укыта. Беренче шигырьләре 20 йөз башында басыла башлый: «Татар кызы» (1904), «Күке» (1905). «Шүрәле каргаган авыл» (1913) исемле шигъри җыентык, «Мөгаллим әл-хуруф» (1909) әлифбасы, балаларга атап язылып гигиена мәсьәләләренә багышланган «Хифзы әс-сыйхәт дәресләре» (1907) китабы авторы. «Җәһәннәм» исемле чәчмә романының кульязмасы югалган. Татар теленә Н.В.Гоголь, А.В.Кольцов, М.Твен әсәрләрен тәрҗемә итә. Н.В.Гогольнең «Өйләнү» («Женитьба») пьесасы Г. тәрҗемәсендә 1919 ның февраленда Казанда куела. Колчакчылар тарафыннан үтерелә.

Әсәр.: Шигырьләр. К., 1959.

Әд.: Ибраһимов Ф. Иж-Буби шәкерте // Казан утлары. 1991. N9.

*А.М.Ахунов.*

**ГОМӘР** (Гомәрев) Абдулла Закир улы (15.7.1906, Оренбург ш. -7.7.1974, Казан), тәрҗемәче. 1925-28 елларда Казан унтында укый. 1928-42 дә «Совет әдәбияты» ж-лы редакциясендә хезмәткәр, 1959-63 тә баш мөхәррир, 1942-59 да Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлеге мөдире. Татар теленә Я.Гашекның «Егет солдат Швейк» («Похождения бравого солдата Швейка во время мировой войны», 1932), Д.А.Фурмановның «Фетнә» («Мятеж», 1934), П.А.Павленконың «Баррикадалар» («Баррикады», 1935) романнарын, А.Г.Голубеваның «Уржум малае» («Мальчик из Уржума», 1939) повестен, М.А.Шолоховның «Нәфрәт гыйлеме» («Наука ненависти», 1942) хикәясен һәм «Алар Ватан өчен сугыштылар» («Они сражались за Родину», 1946) романының аерым бүлекләрен, А.А.Фадеевның «Яшь гвардия» («Молодая гвардия», 1950, Г.Әпсәләмев б-н берлектә) романын, А.С. Яковлевның «Конструктор хикәяләре» («Рассказы конструктора», 1952) китабын, Э.Войничның «Кигәвен» («Овод», 1957) романын, А.Н.Толстой, Л.Н.Толстой, Д.Н.Мамин-Сибиряк һ.б. хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1950-60 еллар әдәби процессына караган мәкаләләр авторы.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ГОМӘР** (Гомәрев) Гариф Мортаза улы (10.12.1891, Уфа губ., Бәләбәй өязе Кыргыз-Миякә а. - 18.8.1974, Уфа ш.), язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1971). «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Укыту программаларына каршы чыккан өчен 1909 елда мәдрәсәдән куыла. 1910-15 тә туган авылында укытучы булып эшли. 1 нче бөтендөнья сугышында катнаша. 1919 да Кызыл Армия сафларына политхезмәткәр булып билгеләнә. 1920-24 тә «Кызыл юл» (Уфа) г-тасында, 1924-33 тә «Һәнәк» ж-лында җаваплы сәркәтип булып эшли. 1934-40 та Башкортстан китап нәшриятында тәрҗемәче, мөхәррир, бүлек мөдире вазифаларын башкара. «Кызыл усмалар» исемле беренче китабы 1925 тә басыла. «Тулкын өстендәге кала» (Уфа, 1954; рус теленә тәрҗемәсе «Городок на волнах», 1955) повесте сал агызучылар тормышыннан алып язылган, реаль картиналар аша тасвирлана. «Тупһанан түргә» (Уфа, 1954; рус теленә тәрҗемәсе «От порога в горницу», 1968), «Жаңыл» (Уфа, 1960; рус теленә тәрҗемәсе «Джаныл», 1975) повестьлары авторы. И.Крылов мәсәлләрен, М.Горькийның «В людях» («Ялсылыкта») повестен, Б.Л.Горбатовның «Непокорённые» («Буйһонмаусылар) романын башкорт теленә тәрҗемә итә. «Почёт Билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Һайланма шигырьзар. Өфө, 1951; Һайланма проза. Өфө, 1961.

**ГОМӘР** Мөхәммәд угылы (19 йөзнең 1нче яртысы), шагыйрь. Оренбург шәһәрендә яши. Татар һәм фарсы телләрендә яза. Оренбург диния Нәзарәте мөфтиенә багышланган «Тәзкирәи мөфти Габдессәлам» (1832) поэмасы авторы. Поэма 2002 елда «Габдессәлам мөфти:

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынан басылып килә.*

Хәтер дәфтәре» исеме б-н кабат басыла. Ул ике телдә язылган: татарча тезмә текст фарсы телендәге чәчмә текст б-н чиратлаша. 1837 дә Оренбургка килгән тәхет варисы Александр II нең свитасында була. Бу вакыйга уңае б-н ул «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1837) исемле мәдхия яза, соңыннан ул аны Александр II нең үзенә тапшыра. Ике поэманың да күчермәсе РФА Шәрекъне өйрәнү ин-тының С.-Петербург бүлегендә һәм Ташкенттагы Бируни исем. Шәрекъне өйрәнү ин-тында саклана. 1783 тә Кавказга, Төркиягә кылган сәяхәте турында чәчмә сәяхәтнамә язган дип фаразлана.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.; Рәхимкулова М. Оренбургта беренче мәчет // Яңа вакыт. 1993. N 23/24.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ГОМӘРЕВ** Мәшгар Фәхретдин улы (11.11.1927, Башкортстан АССР, Әскын р-ны, Кубияз а.), язучы. Казакъ телендә яза. 1948 елдан Алма-Ата шәһәрендә яши. Казакъ ун-тын тәмамлый (1953). 1954-56 да «Казахстан пионери» г-тасында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, 1957-58 дә Казакъстан әдәбият нәшриятында мөхәррир, 1958-75 тә — «Жазушы» нәшриятында, 1975-77 дә — «Жалын» нәшриятында. Беренче хикәяләре 1952 дә басылып чыга. Г. — мәктәп тормышына караган, балаларга һәм яшүсмерләргә әхлаки тәрбия бирүгә, аларда милләтпәрвәрлек хисе тудыруга юнәлтелгән әкиятләр, хикәяләр һәм повестьлар авторы. Аның әсәрләре аңлаешлы, мавыктыргыч һәм кискен сюжетка корылган. «Ана белән бала» («Ана мен бала», 1956), «Тылсымлы дару» («Асыл дәрі», 1960), «Сөяме, сөймиме» («Сүйе ме, сүймей ме», 1967), «Упкын өстендә» («Шыңырау», 1974), «Тугыз киртә» («Тогыз тоскоуыл», 1977), «Ерактан килгән кунак» («Алыстан келген конак», 1985), «Уртанчы ул» («Ортаншы үл», 1990) хикәяләр һәм повестьләр җыентыклары Алма-Атада басылып чыга.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ГОМӘРЕВА** Заһирә Бакир кызы (12.4.1930, Арча р-ны Чума-Елга а. -3.1.2002, Яр Чаллы ш.), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1948-50 елларда Саба р-нының Иләбәр башлангыч, 1950-85 тә Зәмә урта мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Балаларга адресланган «Яшьлек таңы» дип исемләнгән беренче шигырьләр китабы 1964 тә басыла. Аның «Чын герой» (1968), «Нәни врач» (1970), «Әнисенең алмалары» (1980), «Йөгерек елга» (1991) җыентыкларына тупланган хикәяләрендә балаларны кече яшьтән үк тәвәккәл, бербересенә ярдәмчел, туган җирне яратучы кешеләр итеп тәрбияләүнең әһәмияте турында сүз бара. Әсәрләре мавыктыргыч, юмор хисе белән сугарылган.

Әд.: Заһирә Гомәровага - 70 яшь: Кыскача биография // Казан утлары. 2000. N4.

**ГОНЧАРОВ**, Иван Александрович (6.6.1812, Сембер ш. - 15.9.1891, С.-Петербург), язучы, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1860). «Гыйбрәтле язмыш» («Обыкновенная история», 1847), «Обломов» (1859), «Текә яр» («Обрыв», 1869) романнары авторы. 1822-62 елларда үтеп барышлый берничә мәртәбә Казанда була. 1834 тә Буада туктап бер көн уздыруы турында «Ватанда» («На родине», 1887) очеркында яза. 1849 да Казанга килгәндә мәчетләрдә була, Кремльне карап йөри. Татарлар һәм Россиянең бүтән халыклары мәдәнияте һәм көнкүреше б-н кызыксына, шул сәбәпле махсус рәвештә татар, чуаш, мари авылларында булып китә. Казан турындагы истәлекләре «Университетта» («В университете», 1887), «Идел буйлап сәяхәт» («Поездка по Волге», 1873-74), «Иске гасыр хезмәтчеләре» («Слуги старого века», 1887), «Көнчыгыш Себер буйлап» («По Восточной Сибири», 1891) очеркларында очрый.

*Ж.Ф.Хәкимова.*

**ГОРОДЧАНИНОВ** Григорий Николаевич (1772, Түбән Новгород губ. Балахна ш. - 22.12.1852, Казан), әдәбият галиме, шагыйрь, тәрҗемәче. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1797). 1799-1804 елларда С.-Петербургның Баш почта идарәсендә эшли. 1806 дан Казан ун-тында: рус әдәбияты адъюнкты (өзекләкләр б-н), 1810 нан (Казанда беренче булып) экстраординар, 1814 тән ординар проф. Карьерасының чәчәк аткан чоры Л.М.Магницкий эшләгән елларга туры килә: 1816-22 дә Г. - әдәбият бүлеге, 1822-24, 1826-27 дә әхлак-сәясәт бүлеге деканы, 1820-25 тә (өзекләкләр б-н) проректор вазифаларын башкара. 1811-13 тә «Казанские известия» г-тасында, 1821-29 да «Казанский вестник» ж-лында актив языша, 1832 дә «Заволжский муравей» ж-лында, 1843 тә «Маяк» ж-лында хезмәттәшлек итә. 1806 дан Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте әгъзасы, 1926-46 да рәисе. Г. - 18 йөз архаик шигъри формалар тарафдары, Карамзин мәктәбен кабул итми. Тантаналы вакыйгалар уңае б-н язылган мәдхияләр һәм нотыклар авторы. Рус теленә Г.Рейнальнең «Европалыларның ике Һиндстандагы оешмаларының һәм сәүдәсенең фәлсәфи һәм сәяси тарихы»н («Философская и политическая история о заведениях и коммерции европейцев в обеих Индиях», 1805) тәрҗемә итә.

Хезм.: Опыт краткого руководства к эстетическому разбору по части российской словесности. К., 1813; Сочинения в стихах и прозе. Л., 1816.

Әд.: Загоскин Н.П. История Императорского Казанского университета (1804-

1904): В 4 т. К., 1902-04; Русские писатели. 1800-1917; Биогр. словарь. М., 1989. Т. 1.

*М.М.Сидорова.*

**ГОРЬКИЙ** Максим (Пешков Алексей Максимович) (16.3.1868, Түбән Новгород ш. - 18.6.1936, Мәскәү), язучы, җәмәгать эшлеклесе. «Фома Гордеев» (1899), «Ана» («Мать», 1907), «Артамоновлар шөгыле» («Дело Артамоновых», 1925), «Клим Самгин тормышы» («Жизнь Клима Самгина», 1927-36), романнары, «Бала чак» («Детство», 1913-14 ) «Кешелектә йөрү» («В людях», 1916), «Минем университетларым» («Мои университеты», 1923) автобиографик трилогиясе, пьесалар, хикәяләр, шигырьләр, истәлекләр, очерклар, памфлетлар, әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы. Ун-тка керү исәбе б-н 1884 елда Казанга килә, ләкин 2 еллык башлангыч белем б-н бу мөмкин булмый. Елга портында йөк ташучы, генерал Корнэ хатынында бакча караучы һәм ишек алды себерүче, кибетче А.С.Деренковның пекарнясендә ярдәмче булып эшләп йөри. 1887 дә күңел төшенкегә кичерә (Мария Деренкова аның мәхәббәтенә җавап кайтармый, яраткан әбисенең үлгән хәбәре килә) һәм үзе үзен үтерергә тырышып карый. Соңыннан бу хәлне Г. «кабахәтлек һәм тормышның рәхимсезлегә каршында куркып калу» б-н аңлата. 1885 тә ул народниклар түгәрәкләренә йөри, яшерен әдәбият укый башлый. 1888 нең июненнән сентябренә кадәр Иделдәге Красновидово авылында (хәзерге Кама Тамагы р-ны) яши. Казанда узган еллары Г. ның берничә әсәрендә чагыла: «Бервакыт көз көнендә» («Однажды осенью»), «Каптырма мәсьәләсе» («Дело с застёжками»), «Акулина әби» («Бабушка Акулина», барысы да 1895), «Коновалов» (1896), «Элекке кешеләр» («Бывшие люди», 1897), «Егерме алты һәм берәү» («Двадцать шесть и одна», 1899), «Макар тормышыннан бер вакыйга» («Случай из жизни Макара», 1912) «Хуҗа» («Хозяин», 1913), «Җиңел кеше» («Лёгкий человек», 1917), «Минем язарга өйрәнүем» («О том, как я учился писать», 1919) һ.б. Татарлар «аек, пакъ лек яратучы, хезмәт сөюче, максатка ирешү юлында күңел нечкәлеген үҗәтлек б-н берләштерә белүче халык» дип бәяли. Казанда яшәгән елларын соңрак Г. үзенең кеше буларак формалашу чоры дип таныл: «Физик яктан мин Түбән Новгородта тудым, рухи яктан - Казанда. Казан - минем иң яраткан «университетларымның» берсе»,- дип яза. 1928 дә Г. кабат Казанга килә һәм шуннан башлап татар язучылары (К.Нәҗми, Г.Кутуй, Г.Минский, Ш.Усманов, Г.Толымбайский һ.б.) б-н ике арада тыгыз дуслык урнаша. М.Н.Елизаровага язган хатында ул болай ди: «Мин чын күңелдән татар поэзиясе һәм прозасының чәчәк атуын телим. Ләкин бу максатка әдәбият мәсьәләләренә таләпчән караганда гына ирешеп була». Г. әсәрләренең күбесе татар теленә тәрҗемә ителгән. Бу эш б-н күренекле язучылар Г.Камал, Ш.Камал, А.Шамов, И.Гази, М.Әмир, Г.Кутуй шөгыльләнәләр. 1940 тан Казанда А.М.Горькийның Әдәби-мемориаль музее, 1950 дән Красновидово авылындагы музее эшли. Казанда бер урамга, Үзәк мәдәният һәм ял паркына аның исеме бирелә.

Әсәр.: Полн. собр. соч. худож. произведений: 25 т. М., 1968-76.

Әд.: Летопись жизни и творчества А.М. Горького. М., 1958; Музей А.М.Горького в Казани: Путеводитель. К., 1980.

*Ф.Ф.Мирзина.*

**ГОСМАН** Хатип Госман улы (21.5.1908, Пермь губ., Усы өязе Сулмаш а. - 12.1.1992, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1962), проф. (1964), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1968). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1939). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946-51 елларда Казан пед. ин-тында, 1951-91 дә Казан ун-тында (1951-75 елларда татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире). Иҗат юлының башлангыч чорында шигырьләр («Кырлар лирикасы», 1931), хикәяләр һәм повестьлар («Йосыф», 1937, «Ялкынлы йөрәк», 1943; «Ут сызыгында», 1945) яза. Фәнни хезмәтләре урта гасырлар татар әдәбияты һәм 20 йөз татар әдәбияты тарихына, әдәбият һәм шигырь төзелеше теориясенә карый. «Татар поэзиясе антологиясе» (1957), Котб, Х.Кәтиб, С.Сараи, Г.Кандалый, Һ.Такташ әсәрләре җыентыкларын әзерләүдә актив катнаша. Урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты дәреслекләре авторларыннан берсе. Кызыл Йолдыз, «Почёт Билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Такташ поэзиясе. К., 1953; Егерменче елларда татар поэзиясе. К., 1964; Татар шигыре. К., 1964; Шигырь төзелеше. К., 1975; Әдәбият теориясе. К., 1980 (авторлаш); Олы юлга чыкканда. К., 1982; Тюркский стих в средние века. К., 1987.

Әд.: Кашшаф Г. Хатип Госман // Казан утлары. 1968. N5; Мәһдиев М. Яшь йөрәкле аксакал // Ялкын. 1968. N5; Юзиев Н. Җаваплылык // Әдәбият хәзинәләре. К., 1978; Ягъфәров Р. Хатип ага ядкаре // Казан утлары. 1998. N5.

**ГӨЛНАР ХАНЫМ** (Лебедева Ольга Сергеевна) (1854, Казан - ?), җәмәгать эшлеклесе, публицист. Император шәркыять җәмгыятен (1900) төзүдә актив катнаша, аның «мактаулы рәисе» була, Казан уты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы. Халыкара шәркыятьчеләр конгрессларында катнаша. 12 нче конгресста (Рим, 1899) казан татарлары тарихы турында ике доклад б-н чыгыш ясый, алар соңыннан аерым китап булып басылып чыга. Беренче док-

ладта Казан ханлыгының сәяси тарихына, аның Мәскәү б-н булган мөнәсәбәтенә күзәтү ясау б-н беррәттән, татар халкының мәдәнияте торышын, татар хатын-кызының җәмгыятьтә тоткан урынын тәфсилләп яктырта, мөселман халыкларына карата Россия хөкүмәте тарафыннан алып барылган көчләп чукындыру сәясәтен тәнкыйтьләп чыга. Икенче докладта мөселман хатын-кызларының төрле тарихи чорларда җәмгыятьтә тоткан урынын һәм мөселман илләрендә аларның хокукы өчен барган көрәшне яктырта. И.Ф. Готвальд, Н.Ф.Катанов, К.Насрый, И.Н. Березин, В.В.Бартольд, Н.И.Веселовский, В.В.Радлов, И.Ю.Крачковский б-н хезмәттәшлек итә. Төрек теленә А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Л.Н.Толстой әсәрләрен тәрҗемә кыла.

Әсәр.: Об эмансипации мусульманской женщины. СПб., 1900; Abrege de lhistoire de Kazan. Offert aux membres du XII Congres des Orientalistes. Rome, 1899.

Әд.: Каримуллин А.Г. О.С.Лебедева - «Гульнар-ханум» // Народы Азии и Африки. 1977. N3.

*Ә.Г.Кәримуллин.*

**ГРИБОЕДОВ** Александр Сергеевич (4.1.1795, башка мәгълүматлар буенча 1790, Мәскәү - 30.1.1829, Тәһран), язучы, дипломат. 1812 елда Мәскәү гусар полкына корнет хезмәтенә языла. Ул полк 1913 тә Казанда тора. «Студент» (1817, 1889 да басыла) комедиясендә Казан искә алына. 1824 тә язылган танылган «Акыллылык бәласе» («Горе от ума») пьесасы цензура тарафыннан тыела. Декабрист Д.И. Завалишин аның кульязма нөсхәсен Казанга алып килә (Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә саклана). 1834 тә комедия Казан шәһәр театры сәхнәсендә үзешчән актёрлар тарафыннан куела, 1836 да аны Пивато антрепризасының профессиональ труппасы актёрлары уйный, 1853 тә ул Н.Г.Милославский куелышында уйнала һәм 19 йөзнең 2 нче яртысыннан 20 йөз башына кадәр Казан театры сәхнәсеннән төшми.

Әд.: Аристов В.В. Подарок декабриста. К., 1970; Аристов В., Ермолаева Н. Всё началось с путеводителя. К., 1975.

*Ю.А.Благов.*

**ГРИГОРЬЕВА** Лидия Николаевна (12.8.1945, Украина ССР, Луган өлкәсе Новосветловка а.), шагыйрә, тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1972 елдан Мәскәүдә яши. 1988-93 тә Бөтенсоюз радиосында (1991 дән «Радио-1») «Әдәби очрашулар» («Поэтические встречи»), «Шагыйрь остаханәсе» («Мастерская поэта») тапшырулар циклының авторы һәм алып баручысы. 1993 тән Лондонда, Би-Би-Си радиостанциясендә хәзерге рус шигърияте турында тапшырулар алып бара. «Марина Цветаева Лондонда» («Марица Цветаева в Лондоне»), «Н.Гумилёв Лондонда» («Н.Гумилёв в Лондоне»), «Лондонская станицасы» («Станица Лондонская»), «Мөселман Англиясе» («Англия мусульманская»), «Әхмәдия хатын кызлары» («Женщины Ахмадии») һ.б. телефильмнар авторы. «Замана билгеләре» («Приметы века», 1974), «Май ае бакчасы» («Майский сад», 1981), «Виноград яктысы» («Свет виноградный», М., 1984), «Аралашу даирәсе» («Круг общения», М.,1986) шигъри романы, «Мәхәббәткә сусау» («Любовный голод», М., 1993) дүртъюллыклар китабы, «Акылдан язган бакчачы» («Сумасшедший садовник», М., 1999), «Бакча тәрбияләү» («Воспитание сада», СПб., 2001) китаплары авторы. Рус теленә Дәрдемәнд, М.Җәлил, С.Хәким, Ә.Давыдов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Абай шигырьләрен тәрҗемә итә. Аның шигырьләре инглиз, француз, япон, венгр һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ГУЛЯЕВ** Николай Александрович (17.11.1914, Пенза губ., хәзерге Мордовия Респ-касы, Кызыл Бистә өязе, Краснослободск ш. -24.3.1986, Тверь ш.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1957), проф. (1958). Ленинград пед. ин-тын тәмамлый (1938). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947 елдан Томск ун-тында, 1959 дан Казан ун-тында (рус һәм чит илләр әдәбияты каф. мөдире, 1972 дән чит илләр әдәбияты каф. мөдире), 1977 дән Тверь ун-тында (әдәбият теориясе каф. мөдире). 1940-50 дә чит илләр әдәбиятында классицизм һәм мәгърифәтчелек реализмы проблемаларын, 1950 еллар ахырыннан - рус һәм чит илләр әдәбиятлары романтизмының теориясен һәм тарихын, әдәби-тарихи процесста романтизм б-н реализмның үзара бәйләнешен тикшерә (романтизмны «эчке балансы ия булган эстетик система» дип саный һәм аңа карата ике төрле: гносеологик һәм тарихи караш барлыгын дәлилли). Хезмәтләре көнбатыш һәм рус мәгърифәтчеләре иҗаты һәм эстетикасына, Г.Лессинг иҗатының классицизм б-н, В.Г.Белинский эстетикасының 19 йөз чит ил әдәбиятлары эстетикасы б-н бәйләнышларын өйрәнүгә карый. Югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку кулланмалары авторы.

Хезм.: Лессинг и классицизм. Томск, 1955; В.Г.Белинский и зарубежная эстетика его времени. К., 1961; Литературные направления и методы в русской и зарубежной литературе XVII-XIX вв. М., 1983; Теория литературы. М., 1985.

Әд.: Карташова И.В. Концепция романтизма в трудах Н.А.Гуляева // Романтизм: открытия и традиции. Калинин, 1988.

*И.В.Карташова.*

**ГЫЙЗЗӘТ** (Гыйззәтуллин) Баян

(Фәтхелбәян) Нурлыгаян улы (16.7.1918, Башкортстан АССР Кушнаренко р-ны, Талбазы а. -25.5.1991, Казан), әдәбият галиме, әдәбият тәнкыйтьчесе, филол. фән канд. (1951), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1941). 1946 елдан Татар академия театрында әдәби бүлек мөдире. 1953-83 тә СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1968-81 дә сәнгать секторы мөдире). Г.Коләхмәтев, Т.Гыйззәт тормышын һәм иҗатын өйрәнә, Г.Камал, Г.Кариев, К.Тинчурин, М.Фәйзи, Ф.Бурнаш, Х.Әбҗәлилев, Р.Ишморат, Г.Кутуй, Һ.Такташ, Г.Насрый һ.б. иҗат портретларын тудыра. Хезмәтләре татар театры һәм драматургиясе тарихына карый. Г. — «Татар совет әдәбияты тарихы» («История татарской советской литературы», 1965), «Совет драма театры тарихы» («История советского драматического театра», М., 1964-71), «Күпмилләтле совет әдәбият тарихы» («История советской многонациональной литературы», М., 1971-74), «Октябрьгә кадәрге татар театры» (1988) хезмәтләре авторларының берсе. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Драматург Таҗи Гыйззәт. К., 1957; Гафур Кулахметов. К., 1981.

Әд.: Гайнуллин М. Әдәбият һәм сәнгать белгече // Казан утлары. 1968. N7; Ишморат Р., Мәһмүтов Һ. Бәян Гыйззәткә 60 яшь // Казан утлары. 1978. N 7.

**ГЫЙЗЗӘТ** (Гыйззәтуллин) Таҗи Кәлимулла улы (15.9.1895, Вятка губ., Алабуга өязе Барҗы Омга а.- 7.3.1955, Казан), драматург, ТАССР, РСФСРның атказ сәнгать эшлеклесе (1939, 1940). 1910 елга кадәр авыл мәдрәсәсендә укый. 1911-13 тә төрле эшләрдә йөри, 1913-19 да Ижевск корал з-дында эшли. 1919-20 дә Кызыл Армиядә хезмәт итә һәм анда үзешчән сәнгатьтә катнаша, беренче шигырьләрен һәм пьесаларын яза. Самара хәрби округы Сәяси идарәсе каршындагы татар драма студиясенә укырга җибәрелә. Укып бетергәннән соң 1921-29 да - Оренбург, Казан, Ульянов, Алабуга, Мәскәү театрларында һәм труппаларында актёр һәм режиссёр. 1920-50 дә Татар академия театрында эшли, 1930 ның урталарыннан театрның сәнгать советы әгъзасе. 1942-44 тә ТАССР Язучылар берлегенең җаваплы сәкатибе. 30 еллык артистлык эшчәнлеге дәверендә татар театрлары сәхнәләрендә ул татар, рус һәм чит ил классик драматургиясе пьесаларында күп рольләр башкарып, онытылмаслык образлар галереясен иҗат итә.

Татар театры тарихында Г. беренче чиратта драматург буларак билгеле. Ул - Татар академия театры һәм башка театрлар сәхнәләрендә куелган 37 пьеса авторы. Пьесаларының төп үзенчәнлеге - аларның социаль юнәлеше. Г. татар халкының милли һәм социаль изелүгә каршы алып барган көрәшенең әдәби елъязмачысы булып танылды. «Наёмщик» (1928) драмасында 1861 елгы патша Манифестына каршы юнәлтелгән крестьяннар чыгышы чагылдырыла. «Ялкын» пьесасында (1943) 1870 елларда татар авылларында дини изүләргә каршы башланган чуалышлар тасвирлана. «Чаткылар» драмасында (1934) Столыпинның җир реформасына каршы юнәлтелгән крестьяннар чуалышы яктыртыла. «Ташкыннар» (1936-51, «Шомлы көннәр», «Даулы көннәр», «Данлы көннәр») трилогиясендә татар крестьяннарының 1 нче бөтендөнья сугышында, 1917 елның Февраль һәм Октябрь рев-цияләрендә катнашулары сурәтләнә. «Бишбүләк» (1938) музыкаль драмасында Гражданнар сугышы вакыйгалары чагылыш таба. Г. 1920-1930 да илдә барган күмәкләшү б-н бәйле үзгәрешләрне дә читләтеп үтми. Бу еллардагы халыкның тормышын һәм уй-фикерләрен тасвирлаган «Ил үскәндә» (1930), «Бөек борылыш» (1930), «Бөгелеш» (1930), «Көрәш» (1931), «Ударник Мохтар» (1932), «Җиңү бәйрәме» (1933), «Мактаулы заман» (1936) пьесаларын яза. Халыкның Бөек Ватан сугышы елларындагы батырлыгын «Таймасовлар» (1941), «Төнге сигнал» (1941), «Изге әманәт» (1946), «Чын мәхәббәт» (1948) пьесаларында чагылдыра.

Татар драматургиясендә Г. М.Фәйзи һәм К.Тинчурин нигез салган музыкаль драма жанры традицияләрен дәвам итә. Г. либреттосы буенча (башкорт язучысы Х.Ибраһимовның шул ук исемдәге пьесасы нигезендә) «Башмагым» (1942) беренче татар музыкаль комедиясе языла (Җ.Фәйзи музыкасы). Киң таралаган һәм танылган, күп еллар дәвамында Татарстаннан тыш Мәскәү, Киев, Ташкент, Свердловск һ.б. шәһәрләр сәхнәләрендә уңышлы барган «Наёмщик», «Бишбүләк», «Чын мәхәббәт», «Алсу таң» (1949-54) драмаларының музыкасын С.Сәйдәшев яза. Г. - матбугатта күпсанлы публицистик чыгышлар, Г.Камал, Ш.Камал, К.Тинчурин, Н.Сакаев, Х.Такташ, Г.Болгарская һ.б. турындагы истәлекләр авторы. Ике «Почёт Билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Әсәрләр: 4 томда. К., 1975-78.

Әд.: История татарской советской литературы. М., 1965; Абдуллин Я.,Хусаинов А. Классик татарской драматургии / Коммунист Татарии. 1985. N 8; Арсланов Г. Героико-романтические пьесы Т.Гиззата // Татарское режиссёрское искусство. К., 1996; Гыйззәт Б. Драматург Таҗи Гыйззәт. К., 1957; Гыйззәтов К. Таҗи Гыйззәт. К., 2000.

*Ф.М.Мусин.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

***

Хөрмәтле баш редактор Равил әфәнде!

1950-60-елларда Казанда «Совет әдәбияты» журналы чыга иде. Мин ул елларда журналны подписка буенча алдым, аннан да элегрәк чыккан саннарны китапханәдән алып укый идем. Быел июнь аенда «Казан утлары» журналының 5нче санын алып укыдым. Журнал битләрендә минем өчен яңа булган язучылар белән очраштым. Шуларның берсе—Факил Сафин. Аның «Курайчылар» исемле хикәясе мине бик тә дулкынландырды. Шул турыда язучыга әйтәсе сүзем дә бар иде.

*Хөрмәтле Факил әфәнде!*

*Сезнең «Курайчылар» дигән хикәягезне укыганда мин музыка дәресендә дә булдым, тынлы уен коралларының берсе булган курайда уйнау техникасы белән дә таныштым, һәм гомеремдә беренче мәртәбә аның ничек ясалганлыгын белдем. Сүз уңаеннан әйтеп китим инде: балачакта без дә күрше малайлары белән юкә кабыгыннан көпшә чыгарып яхшы гына тавыш бирә торган сыбызгы ясый торган идек, аннары урам буйлап сызгыртып йөри идек...*

*Кызганыч, эшенә җаны тәне белән бирелгән педагог-композитор Гарәф үз баласыдай яраткан талантлы укучысы Айгөлнең зур сәхнәләрдә, телевидениедәге чыгышларын күрә алмаенча бу дөньядан вакытсыз китеп бара. Хикәядә шушы трагедия янының, минемчә, тәфсилләмичә, артык тиз узып кителгән. Хикәядә, бәлкем, автор нияте буенча, бу шулай булырга тиештер дә. Минем сезгә тәкъдимем шул, Факил әфәнде, сез бу әсәрегезне пьесага әйләндереп язсагыз иде. Сәхнәдә ул бик тә уңышлы барыр иде кебек тоела миңа...*

Мин үзем Мирсәй Әмирнең «Агыйдел»ен, «Ялантау кешеләре»н, Габдрахман Әпсәләмовның «Ак төннәр»ен, «Алтын Йолдыз»ын, «Ак чәчәкләр»ен һәм башка күп татар язучыларының әсәрләрен укып үскән буын вәкиле, Казан кешесе буламын. Бу мөмкинчелекне миңа әтинең 1944 елда мине укырга 13нче татар мәктәбенә кертүе бирде. Кызганыч ки, без, хәзерге ата-аналар, бик күпләр, балаларыбызны татар мәктәбендә туган телләрен өйрәнүдән мәхрүм итәбез, шул рәвешле яшь буынның милли горурлыгын югалта баруга дучар итәбез. Шунысы да аяныч, безнең Татарстанда дәүләт әһелләре бу борчулы мәсьәлә буенча берни дә эшләмиләр.

*Сезгә хөрмәт белән, пенсионер, эшем буенча—нефть чыгару белгече*
**Мансур ҖӘЛӘЛИЕВ**
Казан.

## Сәхаб Урайскийның тууына 90 ел

Татар әдәбиятында үзләренең лирик шигырьләре-җырлары белән матур эз калдырган шагыйрьләр байтак. Шуларның берсе—Сәхаб Урайский. Үз чорының җырчы шагыйрен җыр-моң яратучылар «Син кайтмадын», «Өй артында шомыртым», «Яз килде» һ. б. халыкчан җырлары аша танып беләләр иде. Иясенең вафатына инде байтак еллар узса да ул җырлар әле дә яши, яратып җырлана, яратып тыңланыла.

Дөрес, яшьлеге инкыйлап чорларына туры килгән егетнең башлангыч чор иҗатын нигездә комсомол яшьләр темасына язылган язмалар алып тора. «Давыллар аша поэмасы», «Сәрвиназ», «Исемегез җырда яңгырасын» шигырьләре шуның ачык мисалы.

1907 елның 21 декабрендә Самара губернасының Мәләкәс өязе (хәзерге Ульяновск өлкәсенең Иске Майна районы) Иске Кызылсу авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа ул. Яшьли ятим калу, ярлылык сәбәпле башлангыч белемне үз вакытында алырга да мөмкин булмый аңа. Белемгә тартылу С. Урайскийны Самара шәһәрендәге татар-башкорт педагогия техникумына алып килә (1927-30). Аны тәмамлагач, ике ел Урта Идел буе татар совет-партия мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Татар әдәбияты укыту белән берлектә аның үзенең дә күнелендә әдәби эшкә тартылу, тагын да ныграк әдәби мохиттә кайныйсы килү теләге көчәя бара, ул Самара шәһәрендә татар телендә чыгып килүче «Колхозчы» исемле өлкә газетасына әдәби хезмәткәр булып эшкә күчә (1932-38). Әдәбият өлкәсендә белемен арттыру максатыннан СССР Язучылар союзы һәм комсомолның Үзәк Комитеты каршында ачылган әдәби курсларда укып кайта (1934-36).

1938 елда Сәхаб Урайский Казанга килә һәм «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасына эшкә урнаша. Ул чор кешеләренең күбесенеке кебек 1941-45 еллар С. Урайский тормышында да армия, дәһшәтле сугыш афәтләре, орден-медальләр белән бәйле. Армиядән кайткач та С. Урайский әдәби эшчәнлегеннән туктамый, шул газетада озак еллар эшләгәннән соң Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә редактор була.

С. Урайский әдәбиятның башка тармакларында да үзенең каләмен тутыктырмый. Хезмәт кешеләренең фидакарьлеген тасвирлаган очерк-язмалары, иҗатташ дусларының әсәрләренә карата язган мәкалә-рецензияләре, тәрҗемә әсәрләре белән дә матбугатта еш күренә. Шулай ук балалар әдәбияты да аның игътибарыннан читтә калмый. Балалар өчен язылган «Пионерлар җыры» (Х. Вәлиуллин муз.), «Укырга» (С. Сәйдәшев муз.) һ. б. җырлары белән нәниләрне сөендерә.

Үзенең илле еллык гомереннең яртысыннан артыгын әдәбиятка багышлаган Сәхаб Урайский 1957 елның 15 февралендә вафат була. 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

## Сәет Шәкүровның тууына 80 ел

Сәет Шәкүров татар драматургиясенә бай тормыш тәҗрибәсе белән килә. Тумышы белән Балык Бистәсе районыннан булган егетнең беренче әсәрләрендә үк җир, авыл кешеләре тормышы зур урын алып тора. Хәер, туган елы да бит дәһшәтле еллар (1917 елның 14 декабре), аннан соңгы үзгәрешләр аң-белем, тормышка караш формалашуында зур этәргеч булгандыр.

Авылда укытучы гаиләсендә туган Сәет урта белемне Казанда ала. 1934—1938 елларда исә театр техникумында укый. Армиягә алынганчы Сәет Шәкүров, алган белеменә тугры калып, 1942 елга кадәр төрле театрларда актерлык хезмәтен башкара. Аннан армия—1943 елның җәенә кадәр Ленинград хәрби ветеринария училищесында укый. Сугышка җибәрелеп, башыннан ахырына кадәр катнаша, нык кына контузия ала, сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз орденына һәм медальләргә лаек була.

1946 елда сугыштан кайткач та С. Шәкүров актерлык хезмәтен ташламый, төрле театрларда, шул исәптән Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында да уйный. 1959—1964 елларда исә Казан шәһәрендәге Мәдәният сарайларының үзешчән сәнгать коллективларында җитәкче вазифасын башкара, Г. Камал театрының баш администраторы, 1975 елдан алып пенсиягә чыкканчы (1979) Республика күчмә театрының директоры булып эшли.

Сәет Шәкүровның әдәби иҗат эшчәнлеге сугышка кадәр үк башлана. Беренче иҗат тәҗрибәләреннән булган «Орденлы Касыйм» пьесасы 1938 елда күмәк җыентыкта дөнья күрә. Ул шулай ук проза жанрын да читт итми. Ни сәбәпледер, Сәет Шәкүров озак вакытлар иҗат итүдән туктап тора. «Тормыш бусагасында» исемле драмасы бары тик егерме елдан соң гына дөньяга туа һәм 1958 елда Минзәлә театры сәхнәсендә куелып, тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителә.

1960 елларда инде Сәет Шәкүров танылып килүче драматург булып формалаша. Илебезнең төрле театр сәхнәләрендә әсәрләре зур уңыш белән бара. Шулардан бигрәк тә «Зөһрә йолдыз», «Карт гашыйк», «Уракчы кыз», «Мәхәббәт газабы», Татар дәүләт академия театрында куелган «Туган туфрак», «Тол хатыннар, тол кызлар» пьесалары тамашачыларның яратып карый торган спектакльләренә әйләнә.

Сәет Шәкүров аеруча трагедия жанрын үз итә. Үзе дә тәҗрибәле актер һәм театрда күп еллар эшләгән кеше буларак, театрның эчке дөньясын яхшы тоемлый. Аның сәхнә әсәрләрен артистлар теләп, яратып уйныйлар. Ул заман сулышын тирән тоеп, тормышны яхшы белеп иҗат итә. Фашизм алып килгән бәхетсезлекләрне үз күзләре белән күреп, сугышның эчендә үзе булып кайтканга фаҗигаләрне бөтен тулылыгы белән әсәрләрендә яктырта ала. Авторга бигрәк тә «Туган туфрак» пьесасы танылу алып килә. Пьесада кешеләр язмышы, аларның киләчәккә, матурлыкка омтылуы омтимистик рухта сурәтләнгән. Ул татар драматургиясендә туган илгә, туган туфракка мәхәббәт тәрбияләүче җитди әсәр буларак урын ала.

Татар театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен С. Шәкүров 1970 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемгә лаек була.

Ул—1970 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. 1989 елда вафат була.

Рөстәм
Зарипов

# ТУКАЙ КҮЧТӘНӘЧЕ

Ленин бабайның туган көненнән соң ел саен ике-өч көн буе кеше була алмыйча интегәм... Авызны киң ачып исни-исни йокылы-уяулы диванда ята-ауный телевизор карап ятам. Ничек тә урамга чыкмаска һәм башны төзәтми түзәргә кирәк. Кайсыдыр акыллысы экранга чыгып җәелеп утырган да пеләшен ялтырата-ялтырата комнан бау ишә..

Уф... Ниһаять, сөйли торган башның акыл сатуыннан төкәнеп, реклама күрсәтә башладылар, һәм ярты сәгать тә узмады, мин көтеп зарыккан турыдан-туры тере тапшыру вакыты җитте!

Быел, Тукай бүләге билгеләүче комиссияне телестудиягә чакырганнар һәм бүләккә лаеклыларның кемлеге күз алдыбызда хәл ителәчәк! Һолливуд, үз премиясен бөтен дөньяга шәрран ярып тапшыра бит әле, күрәсең безнекеләр дә чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, шул сукмакка каерып маташулары. Афәрин, бирсен Ходай. Ахрысы, социализмга хас «итәк астыннан» озатуларга бу өлкәдә дә нокта куела... Бар да елмая, кайберләренең чырае таныш, араларында үзләре дә әлеге бүләккә тиенүчеләр шактый.

Әлбәттә инде һәркем кайчан, кемнән соң ни әйтәсен белә. Сылу һәм тулы тәнле тынкыш кыз белән теле көрмәкле кәҗә тавышлырак егет, ягъни алып баручылар, алмаш-тилмәш әлеге күнелле матавык хакында сайраша башлый. Иң әвәл утырышта катнашучылар белән таныштыру китә. Боларның фәнни дәрәҗәләре, алган бүләкләре, мактаулы исемнәре шактый икән, шәхесләребез, дан-дәрәҗә берәмлекләрен барлаганда искиткеч тынычлык саклап, елмая төшеп, рәхәтлек кичереп тынлыйлар һәм ялкау гына баш кагып куялар. Белмим, бу идиллия әле күпме дәвам итәр иде, һич көтмәгәндә битләренә маска кигән коралны өч бәндә атылып килеп кереп, студия кунакларын мөшкәгә алды. Битлеклеләрнең Фәнзаман Батталга охшаганрагы:

—Сөйли белмәгән авыздан нәрсә яхшы икәнен әйтеп тормыйм. Шым булыгыз,—дип җикереп микрофоннарын тартып алды.—Ә сез, хөрмәтле хөрмә төшләре,—дип дәвам итте аннары студия кунакларына яңы белән генә борылып,—күлмәгегезне күтәртеп эчләрегезгә типтерәсегез килмәсә, урыннардан кузгалмыйсыз! Кырга сыймас кыланышларыгызга озак түздек. Җитте! Гел сезгә дә гел сезгә, ә кая безгә? Кул кулны жуа, ике кул битне жуа дип байтак узындыгыз! Барыгыз да тотык хәзер. Хаталарыгыз һәм хафалы гамәлләрегез төзәтелми торып, азатлык турында уйламагыз. Хәрам акчаларыгыз эчегезне тишмәсен дисәгез, кесә телефоннарыгызны эшкә җигегез. Сезгә бер тәүлек вакыт, теләсә кайдан табып кайтарыгыз кеше хакына кереп йомганнарыгызны!

Мин башта, ялгыш төймәгә басып, телевизорның каналын үзгәрттем ахры дип торам. Аннары башка китереп сукты, террорчым татарча сөйләшә ләбаса. Ә Русиядә безнең телдә әз-мәз такылдарга рөхсәте бар канал берәү генә... Ни гаҗәп, явызның сөйләм теле ифрат камил. Инде байтактан экранда шәп дикцияле, ятышлы һәм чын ир-атка хас тавышлы кеше күренгән юк иде. Кем булыр бу? Каян? Мондыйны, әйтик, мәдәният яки мәгариф министрлыклары тирәсеннән көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып

булмый... Ленин бабайның «Кем ничек кирәк алай сөйләшә, уйлавы да шул чама» дигән сүзе бар. Татарстанда бар ул, берәү: уе да, сөйләме дә камил зат—авыл хуҗалыгы министры Марат Готуф улы ул. Бу шуның шәкерте мәллә дияр идең, авыл мәнфәгатен алга сөрми... Айдар Хәлимгә шик төшерү дә урынсыз, чөнки ул битлекне үзе кимәү генә түгел, башкаларныкын салдыруга һәвәс. Ә өчәүнең берсе, кунакларның кайсысының пеләшенә чиертеп, бәгъзеләренең сакалын йолкудан яки борыныннан кысып, аска тартудан ямь табучысы тач мина охшаган...

Кинәт экранда ут сүнеп, «тапшыру» өзелде... Аһ мин әйтәм, харап була бит, бахыркайлар. Әле бит араларында халык фәләне, халык төгәне дигән мактаулы исемлеләре дә аталган иде. Менә күрәбез инде хәзер халыкның кемнәре барын... Беркем дә ярдәмгә ашыкмаса ни хәл итәрбез. Әллә үзем торып шунда йөгеримме?..

Әмма изге ниятемне эшкә ашырырга өлгермәдем: ишегемне тибеп ачып фатирыма таныш түгел ир-атлар бәреп керде. Пөхтә киенгән таза муенлы ике әзмәвер бусагадан үтми генә, ишек катында калды, ә битендә карга чукыр ите дә юк, зәһәр карашлысы туфлиләрен дә салып тормый, бөгелә төшеп, түргә үтте. ...

—Кайтып та життек мени ?

—Сез кем? Ни хакыгыз бар?—дидем, тузынмакчы булып авыз ачтым, әмма тавышым кысылып, ысылдап кына чыкты.

—Ни арада телестудиядән кайтып өлгерден дим, композитор? Сорауларны мин бирәм биредә, аңладыңмы?—диде теге һәм күзләрен шундый иттереп акайтты.

—Минем бүген өйдән чыккан да юк бит,—аклана башлавымны сизми дә калдым.

Юка йөзле агай, без күзләрен тагын да очлайтты:

—Турыдан-туры эфир дип алдашканнар булып чыга, димәк?

—Алдашмаганнар.

—Ә синең телевизорга чыгуың нәрсә?

—Мин түгел бит ул.

—Ә кем?

—Анысын сездән сорасаң әйбәт булыр иде ...

—Зарар юк, бар да ачыкланыр. Үзең дә шаккатырсың: синнән менә дигән гаепләнүче цыгып куймагае. Рөстәм Зарипов бит әле. Нәрсәләр яздык инде, Тукай бүләгенә өметләнерлек?

—Андый нәрсәләр язганым юк минем.

—Давай урынсыз тыйнаклык күрсәтмик, яме. Тукайны да беләбез, сине дә.. Генерал булырга омтылмаган солдат начар солдат диләр. Тәк шту, һәр татар иҗатчысы омтылырга тиешле бүләк ул... Тукай балалар өчен язган, тәк. Син дә Кави Нәҗми сүзләрен файдаланып, сөтле танауларга «Алфавит» дигән җыр тәпәләдең, дөресме?

—Аны бит...

—Тукта, тукта. Авторлык агентлыгында, Мәскәүдә көй синеке дип теркәлгән.

—Дөрес...

—Гаяз Исхакыйга багышлап язган «Мөһаҗир җыры»нәрсә? Янә килеп, Зиннур Насыйбуллин сүзләренә турыланган «Туган тел»? Боларны Фердинант Сәләхов Русия буйлап яңгыратып йөри һәм сине дә телгә ала! Ул гына җитмәсә, Салават «Бүре»нне улата! Бик тә милләтчел әсәрләр, әйтергә кирәк. «Бүре» өчен «Алтын барс» премиясе дә алдың бугай ?

—Кәгазьдә шулай язылды, ә фактта кү... кишер тоттырдылар.

—Ә мәкаләләрең! Алар унаеннан бәлкем берәр вакыт иркенләбрәк тә сөйләшергә туры килер әле безгә... Тәк што Тукай премиясенә запрыста

өмет багълый аласың... Мотив бар. Стоп. Әле бит «Юлчы» жыры да синеке ? Ә без яшь чагында «Тамчы гөл»ең, үткне утка ялгагач, аннан да ишетелә иде!

Башны аска иям, ялганчы чокырым йодрык сыярлык булып тирәнәя һәм мин сулкылдап елап җибәрәм.

—Таныйсыңмы гаебеңне?

—Кая кул куясы?

—Ярый-ярый.,—дип аркадан кага тикшерүче.—Ашыкма. Гаебеңне таныганга кадәр берара шаһит буларак күрсәтмә бирерсең. Үзең беләсең, бу программаны караучылар бик юк, шаһит табу да бер бәла. Ярдәмең җиткелекле булса, бәлки кулга да алып торасы булмас, алдан ук сыкма әле балавызыңны, киләчәккә дә калдыр.

—Ярар, гражданин начальник,—дим борынымны лышкылдатып.—Бирегез сорауларыгызны, яшь пионер кебек, әзермен!

—Тапшыруны күрдеңме?

—Әһә. Сез килеп керер алдыннан гына экранда ут сүнде.

—Үзеңне таныдыңмы?

—Миңа охшаган берәү бар иде.

—Бу премия синеңчә нәрсәсе белән үзенчәлекле? Әйтик Нобельнекеннән Тукайныкы ни белән аерыла?

—Нобельнекен бер оядан, ире-хатыны, анасы-атасы, баласы-чагасы, дусы, әшнәсе чират торып ала алмый кебек.

—Террористларның берәрсен танымадыңмы?

—Юлдашларым кем иде дисез инде?—Әңгәмәдәшем миңа гаҗәпсенеп карап куйды, елмайгандай итеп йөзен җыерды:

—Юмор хисегез терелүенә мин шат.

Детективлар укый-укый, криминал турында тапшырулар карый-карый акыл пәкедәй чарланган минем. Тукта, бездән булсын яхшылык, рас кешегә ярдәм кирәк, булышмый ярамас, дип, калтыравыкланып киткән тавышыма әз генә булса да вәкарь кундырырга азапланып, сүзгә башлыйм:

—Рас татарчалары түзәрлек,—минәйтәм,—димәк битлекләләр үзләре дә, Тукай премиясенә өмет багълап, шуннан коры калучылар булырга кирәк.

—Өстенә бастың,—ди теге мыскыллы көлемсерәп.—Ә безне ник килдек дип беләсең синең хозурга?

—Миңа карангы.

—Яхшы. Алайса әйт: синенчә иң лаеклы кемнәр мәхрүм кала бүгенгесе көндә әлеге бүләктән?

Бер кавым маңгайны җыерып уйга талам. Аннары тамакны кырам.

—Гомер бакый әйбәт кешеләр булып уйнаучы артистларны мантыттылар. Исемен дә алдылар, шәп фатирларга да тиенделәр. Ә кызык, мәзәк рольләр уйнап халыкны куандырган Рәшит Шамкай шымытыр тотып калды!

—Да. Рәшит әзи бөек артист. Тагын кемнәрдән шикләнәсез?

Шерлок Холмс сыман йөренә башлыйм һәм үзалдыма такылдавымны дәвам итәм :

—Г. Камал театрының яңа режиссеры да Тукай премиясен артык җәһәт алды кебек...

—Булыштылар димәкчесезме?—ди әңгәмәдәшем сагаеп.

—Мин түгел, моны репертуар әйтә.

—Шуннан ни?...

—Шуннан шул. ...Аларга Тукай да Тукай, ә безгә күү... кишер штоли, ник безгә дә һаман юк, ник гел чират бозыла дип республиканың калган театр әһелләре дуласалар да бик урынлы.

—Бүләккә кандидат итеп күрсәтелгән депутат хакында ни дисең?

—Бер алманы бишкә бүлә белә торган кеше. Җыр текстларына тел-теш

тиерешле түгел. Зөлфәт тә җыр өчен сүзләр язып премия алган иде, бу да юкәдән тукылмаган... Туктале. Бик яхшы сүзләр язып та премия тәтемәгән Әхмәт Саттар бар ...Көен Рөстәм Яхин язган «Серле күзләр»не ишеткәнегез бармы?

—Чып-чын шедевр.

—Димәк, битлек кигәннәрнең берсе Әхмәт әзиен Саттар...

—Композиторлар турында ни әйтә аласың?

—Көйчеләрнең бүләк чиратында иң алда композиторлар берлеге рәисе .

—Нинди рәк кош инде ул?

—Татар сандугачы ук димәс идем. Европага, христиан дөньясы аһәңнәренә ориентлаша, Америка композиторлар берлегендә әгъза...

—Татар өчен бер дә язмыймы?

—«Казан урамына чык әле» дигән җырын ишеткән бар. Тагын шундый бер-ике әйбере бар диләр. Ну, Фирзәр белән моныкылар ике минут та тартыша алмый, әлбәттә...

—Димәк, битлеклеләрнең берсе Мортазин! Үзебезнең Буа шикәре?

—Шул. Әмма минем якташ Фәрит Хатыйповны да исемлектән сызып атмаска кинәш итәм. Гөлшат Зәйнәшеванын «Сакладым сине күнелемдә, сагынуларыма төреп...» дигән юлларын нинди моңга чорнады ул! Ә Зөлфәт сүзләренә язган «Һаман яратам»ы халык бәгыренең түрендә утыра...

Яңа танышым да белә икән ул җырны, шыншырга ук кереште...

Ул арада телеэкранда ут кабынып, Казан янә күрсәтә башлады. Алып баручы гафу сорый. Ниндидер татарча детектив спектакль төшерә башлаган булганнар һәм уенчылар, студияне бутап, Тукай бүләге бүлүче комиссия утырган залга бәреп кереп, ихтыярсыздан репортажны өзгәннәр... Аңлашылмаучылык килеп чыккан...

Хәтәр оешма вәкиле гафу үтенергә керешге. «Әйдә, күнелдә нөктә калмасын, юып төшерик. Үзем оештырам мин сина Тукай премиясен, һәм хәзер үк»—ди.

Монын ымы белән ишек төбендәге әзмәверләрнең берсе аллә каян дипломат тартып чыгара һәм анын эченнән бер шешә килеп чыга.

—Тукай шәрабы бу,—ди яна танышым, кет-кет көлеп. Әйдә чыгар бокалларынны.

—Булмас,—минәйтәм.—Каян андый исемле шәраб ясасыннар,—дим.

—Укы,—ди яна дус. Хактан да шешәнең алъяпкычына ТОКАЙ дип язып куйганнар икән шул.

—Ярар безгә, каткан тезгә,—минәйтәм,—Тукай бүләгенең бүтән төрлесе безнең ишегә, классик әйтмешли, едва ли эләгер һәм бер хәреф өчен генә вакланып тору да егет эше түгел...

Икенче көн иртән хатын ирештерә.

—Бүсеп тә күрсәтәсең йокыны,—ди, «Токай» дигән буш шешәне куенымнан алып.

Аңа ышансаң, безгә бернинди тикшерүчеләр килмәгән, ә гәҗитнең янасы килгән икән инде... Алгы биттә Тукайның зур фотосы. Баксаң бүген апрельнең егерме алтысы җиткән...

Әлеге сурәтле битнең бер читендә быел Тукай бүләге алучыларның исемлеге дә бирелгән. Тиз генә укып чыгам, арага исем-фамилиям тагын кысылмаган. Мин мөкиббән китәрдәй затлар да күренми анда. Ирексездән фотосурәткә текәләм. «Их, Тукай, Тукай... Нәрсә була соң инде бу»,—дим, эчемнән генә һәм шагыйрьнең монсу карашыннан:

—Нобель бит ул үз акчасы белән эш итә, дус кеше...,—дигән җавап саркый кебек...

# Ринат Мәннан

## Бәя

**Китап язучы кайгыра:**
**—Кая бара бу тормыш?**
**Бер китап өчен гонорар—**
**Ике кесә көнбагыш!**

## Җәлләү

**Елына ничәмә тапкыр**
**Йөримен сайлауларга,**
**Ярлылар депутат булып,**
**Әүрелсен дип байларга!**

## Табыла

**Һәрбер бүлмә почмагында**
**Табыла тузан.**
**Министрлык бинасында**
**Почмак саен... зам.**

## Менә шул

**Бәйрәмнәр—**
**Мөбарәк,**
**Түрәләр—**
**Түгәрәк!**

## Үз бизмәне

**«Тәмәке—агу!»—дип күпме**
**Табиблар яза, сөйли.**
**Тәмәкече тарта, чөнки**
**Озак яшәргә теләми—**
**«Матур» яшәргә тели!**

## Рәхәт!

**Математик исәпләү ясагач,**
**Профессорлар калган аптырашка:**
**Коңгыз канатының төзелеше**
**Ярамый икән бер дә очышка!**
**Башын ватмый гына, рәтен белеп,**
**Коңгыз**
**Оча бирә... рәхәтләнеп!**

## Ачы ачыш

Дусларыма кирәк чагым—
Күп алар.
Дусларымның кирәк чагы—
Юк алар.

## Сырганак

Сырганакларның да бар, ди,
Хатыннары, ирләре,
Бергәләп утыртсаң гына
Була ди җимешләре.
Күпме йөрдем, сайлый белми,
Булганмын бит томана.
Базарда аңлатып бирде
Бер абзый серен миңа:
—Алар, энем, кеше кебек,
Белмисең икән әле:
Ире аның—шома гына,
Хатыны—чәнечкеле!

* * *

*Рафаэль Сахабиевкә*

Сәхнәгә чыгар алдыннан
Капшап карый чәчләрен:
—Ахры, хатын, майлы булган
Синең пәрәмәчләрең.

* * *

*Гәрәй Рәхимгә*

Сиңа Гәрәй якынракмы,
Әлләме Григорий?
«Шайтан алгыры!» дисеңме,
Әлләме «чёрт побери!»

* * *

*Марс Макаровка*

«Мәк чәчәге»ң радиодан
Ишетелә еш болай.
Тик кабахәтлек кимеми,
Мәкне өзәләр, малай!

* * *

*Камил Кәримовка*

Юмор ашы кайнап тора,
Актарыла күбекләр,
Симез калҗа кебек кирәк
Безгә Камил кебекләр.

* * *

*Җәвид Шакировка*

Җәвид сөйли: «Җәмәгать!..»
Җәмәгать сөйли: «Җәвид...»
Икесе дә күп сөйлиләр,
Сөйләгәннәре—кәмит!

# Рөстәм Галиуллин

## ШАЯН ХИКӘЯЛӘР

### Әлү, кодагый, исәнме?...

—Әлү, әлү! Кодагый җаным, синме соң бу?

—Мин идем. Хәлләр ничек, әй?

—Бер көе. Яшең җитмешкә җиткәч, юк икән инде ул... Ризыкның тәме, эшемнең рәте юк дигәндәй... Үзең ничек соң?

—Сорама да, кодагый. Аяклар беткән, куллар хәлсез, гәүдә тузган... Көчкә селкенеп йөрим шунда...

—Балалар ничек соң, балалар. Оныкларыбыз үсәме?

—Әй, әйтмә дә инде. Тәгәрәшеп үсеп киләләр. Берсеннән-берсе акыллы, матур. Үзем тәрбиялим шул, үзем.

—Кияүнең эшләре барамы, килененнән ризамы?...

—Ярый инде. Эшләп йөриләр. Алар югында балалар миңа кала, өйдәге тавык чүпләп тә бетерә алмаган бөтен эш минем җилкәгә төшә...

—Шулай инде, шулай. Авылда бит телефоннары да юньләп эшләми. Берәрсенә шылтыратыйм дисәң, әллә кемнәргә эләгеп бетәсең. Бездән өч өй аркылы гына торучы Әлфинур бар бит әле... Беләсең микән син аны?

—Абау, бер дә ишеткән кешем түгел шул...

—...Беркөнне миңа шуңа шылтыраттым. Озак кына сөйләшә торгач, белдем, кодагый җаным, Әлфинур булмаган икән бит ул!

—Китче! Кем белән сөйләштең соң алайса?

—Күрше авыл кешесе булып чыкты!

—Йә, Рабби!

—Менә шулай, кодагый, бөтенләй өзеп бетергәнче шылтыратып калыйм дидем. Әле сезне җыйганчы да бөтен районны «йөреп» чыктым. Аннары, кияү оныкларны бер-ике атнага безгә торырга китереп китмәс микән дигән идем.

—Нинди оныклар? Соң алар болай да churчсездә бит инде! Нәрсә сөйлисең, кодагый?

—Соң, өченче көн элек кенә балаларны килен белән икесе илтеп куйдылар бит!

—Абау, Галиябану кодагый?!

—Ниткән Галиябану? Гөлниса бит мин!

—Йә, Ходам! Нинди хәл бу, ә? Телефонны алырга да куркырсың, билләһи...

### Син инвалид түгелме?

—Туктале, энем, утыр яныма. Син инвалид түгелме? Алай күзеннең агы белән карама. Студент кына әле мин, дисеңме? Яшькә карамый ул, менә минем күрше Маратка нибары егерме биш яшь, ә үзе инвалид. Типсә тимер өзәрлек, сукса, атның билен сындырырлык егет, югыйсә. Тик бер дә авыр күтәрергә ярамый бичарага— эче авырта икән. Ну үзем берничә тапкыр шаккатып карап торганым бар: ашлык тулы ике капчыкны ике култык астына гына кыстырып ташый, вәт «инвалид».

Хәлим абзыеңны беләсеңме? Шул көн саен трактор хәтле ике атын берүзе арканга илтә, кичен алып кайта. Тигез җирдә чокыр ясый торган дуамал-зәһәр атларының урталарына баса да, тегеләргә тирә-якка күз ташларга да ирек бирмичә, йөгерешчә тизлеге белән тотып бара. Баксаң, икенче группа инвалид икән ул, бахыр! Җәлләп туялмассың үзен: ике кулбашы үтереп сызлый, селкеткән саен чатный,

бил каерылган, умыртка баганасы чалшайган икән мескенкәемнен!

Әнә, күрәсенме, Сабира түтән белән Бәшир абыең кайтып килә. Болар кода-кодагыйларына кунакка барганнар. Кыр куяны тизлеге белән алдан сикерә-атлаган Бәшир абзыйның аяклары тәмам беткән—икенче группа инвалид икән. Аннан калышмыйм дип йөгерә-атлый кайткан Сабира түтинең хәлләре бераз ярый—ул өченче группада гына. Хәлләре мөшкел боларның: бер өйдә ике инвалид. Ярый әле район үзәгендәге хастаханәдә табибә булып эшләүче кызлары бар. Нишләп бетәрләр иде алайса ике чирле.

Үзең дә инвалидмы соң, дисеңме? Әй, энем, билне каерып, аякны сындырып, бер кул селкенми башлагач, барган идем районлагы хастаханәгә. Ике көн чират торып, өченче көнне тәки кердем хирург янына. Тегеләй караган булды, болай тикшерде. Үзе күзенең чите белән генә минем урындык аркасында эленеп торган чүпрәк сумкамны күзәтә. Кызларыма дип каймагын-сөтен тутырып килгән сумкам ачылмагач, бу да озак маташмады: «Әй, абзый, синең монда барысы да тәртиптә. Картлык галәмәте генә бу,»—дигәч, әле дә эшләми торган кулымны икенчесе белән кысып тотып, авылга кайтып киттем.

Тукта, озак утырылды, кузгалырга кирәк. Син дә ашыгасыңдыр. Ай-ай, белем! Уф-уф, энем, торгызыш әле. Жирдә яткан таягымны гына алып бир, иелеп булмый. Печән кайтырга тиеш иде бүген. Шуны күрше инвалид Вахит белән бергәләп печәнлеккә кертеп булмас микән, кереп чыгыйм әле үзенә...

---

*Алхәбәр. «Казан утлары»—2008.*

Рәмзис Кадыйров

## ГОМЕР КИЧҮЕ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕКЛӘР

...Арыган, йончыган солдатлар арасында сугышта күпне күргән усал сугышчылар да бар иде, алар ашамыйча беркая да бармаячакларын әйттеләр.

—Вы знаете, что будет за невыполнение приказа?!—дип жикерде лейтенант.

—Знаем, девять граммов свинца,—дип тыныч кына жавап бирде олы гәүдәле урыс егете.—Покормите нас, споров не будет.

Лейтенант акырды-бакырды, тик берни дә кыра алмады. Ярты сәгатьтән комбат килеп, шулай ук жикеренеп наганын болгап торды, әмма солдатлар бирешмәделәр. Бераздан соң атка атланып, ординарецын ияртеп, кып-кызыл битле полковник килеп житте:

—Строиться!—дип кычкырды ул. Солдатлар тиз генә тезелделәр.

—Здравствуйте, товарищи солдаты!

—Здорово,—дип жавап бирде бер солдат, калганнар эндәшмәде...

Полковник наганын чыгарып һавага атты:

—Боерыкны үтәмәгән өчен барыгызны да аттырам!

Тиз генә арткы рәттән алыптай гәүдәле, күкрәгенә медаль таккан солдат чыкты да автоматын полковникка юнәлтте, алан тып-тын калды.

—Куркытма, иптәш полковник, безнең курка торган чаклар узган инде. Нигә ач солдатны һөҗүмгә куасыз, житмеш биш чакрым жәяү атлап, безнең ашарга хакыбыз юкмыни? Безнең автомат та кысыр патрон белән корылмаган, житмеш бер патроны бар.

Полковник пырх-пырх килде, тотлыкты, аннан соң кулын селтәп, атын борып, кирегә чапты. Тәшкә таба старшина ат белән кухня алып килеп, солдат саен колбаса, ипи, махорка, йөз илле грамм аракы таратты...

## Илшат Вәлиуллин



Илшат Әхәт улы Вәлиуллин (Илшат Вәлиулла) 1967 елны Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач Казан университетының филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә.

1985—1988 елларда Тын океан Хәрби Дингез Флотында хезмәт итә.

Армиядән кайткач университетта укуын читтән торып уку бүлегендә дәвам итә һәм тәмамлый.

Бер үк вакытта башка профессияләрне дә үзләштерә һәм төрле эшләрдә (заводларда, сәүдә өлкәсендә, төзелешләрдә һ. б.) эшли.

1984-85 елларда шигырьләре белән сәхнәләрдә, әдәби радиотапшыруда чыгыш ясый. Студентларның «Әллүки» әдәби түгәрәге эшендә актив катнаша. Армия сафларында хезмәт иткәндә әдәби стенгазета эшчәнлегенә үзеннән өлеш кертә.

«Татар декадансы» дигән беренче әдәби мәкаләсе «Татар Иле» газетасында (1994 ел) һәм «Идел» яшьләр журналында (1995 ел) басыла.

Шул чордан башлап Илшат Вәлиуллин (Вәлиулла) үзенең мәкаләләре белән «Яшел Үзән», «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре» газеталарында һәм «Казан утлары», «Идел» журналларында басылып килә.

Аның үз әдәби иҗатына багышланган мәкаләләр «Звезда Поволжья» газетасы, «Казан утлары» журналы битләрендә урын алды.

2004 елны Илшат Вәлиуллинның (Вәлиулланың) эсселәр, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен туплаган «Мәңгелек Бәхет эзләреннән» дигән тәүге китабы дөнья күрде.

2006 елда исә әдәби тәнкыйтьченең «Һәр шагыйрь—бер дәрья» дигән икенче китабы басылып чыкты. Бу китабында автор барыннан да элек татар әдәбиятының бүгенге әйдәп баручы шагыйрьләре Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, Р. Әхмәтҗан, Л. Шагыйрьҗан турында сүз алып бара, алар иҗатына хас әдәби-фәлсәфи үзенчәлекләрне ачарга омтыла.

Кабул итү комиссиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә язучылар—Рәдиф Гаташ, Рифат Сверигин, Газинур Морат) Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Вәлиуллин Илшат Әхәт улын (Илшат Вәлиулла) Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул итте.

# 2008 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

(мөселман ай календаре буенча 1428—1430 һижри еллар)

**10 гыйнвар (пәнҗешәмбе)**— Мөхәррәм ае башланган көн. 1429 ел, яна мөселман елы башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**19 гыйнвар (шимбә)**—Гашура көне. Сөнниләр тарафыннан Аллаһы Тәгалә Үзенең ун пәйгамбәренә күндергән изгелекләре хөрмәтенә, ә шиитләр тарафыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы имам Хөсәенне (626—680) җәзалап үтерү көне хөрмәтенә билгеләп үтелә.

**25 гыйнвар (җомга)**—Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн. (310 нчы һижри, 922 нче милади ел).

**8 февраль (җомга)**—Сәфәр ае башланган көн.

**4 март (сишәмбе)**—Һижри кичәсе көне. Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көн. Шушы көннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни һижри ел исәбе башлана.

**20 март (пәнҗешәмбе)**—Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе—Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**3 июля (пәнҗешәмбе)**—Рәгаиб кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе.

**4 июль (җомга)**—Мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**29 июль (сишәмбе)**—Мигъраҗ бәйрәме. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә—Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**3 август (якшәмбе)**—Дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай—Шәгъбан ае башлану көне.

**16 август (шимбә)**—Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр инә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**1 сентябрь (дүшәмбе)**—чират изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә—Кадер кичәсе.

**30 сентябрь (сишәмбе)**—Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**15 октябрь (чәршәмбе)**—Хәтер көне. Каһарманнарча һәлак булган бабаларыбызны, якыннарыбызны, туганнарыбызны искә алу көне.

**7 декабрь (якшәмбе)**—Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**8 декабрь (дүшәмбе)**—Гайдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Бу ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме һәм ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**9, 10, 11 декабрь (сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе)**—Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**29 декабрь (дүшәмбе)**— 1430 ел, яна мөселман елы башланган көн.

*Төзүче мөхәррир*

**Хаҗи Абдулла ДУБИН.**

Казан.

# 2007 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ**

2007 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №6

«Без бердәм булырга тиешбез...» *(Татарстан Президенты М. Шәймиев тарафыннан төрле елларда әйтелгән кайбер фикерләр).* №1

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Фәйзуллин Р. Юллар текәрәк, еллар җаваплырак. №1

Фәйзуллин Р. Яшәр безнең журналыбыз! («Казан утлары»на 85 ел тулу уңаеннан) №5

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Гыймадиева Л. Үсмерләр өчен хикәяләр. №3

Җамалетдинова Ф. Догалы корт. Повесть. №5

Зәйнуллин З. Мәүлет гусар. Повесть. №3

Ильясов Җ. Еланнар әфсенләүче. Роман. №№2-4

Кәримов К. Уен. Роман. №№6,7

Кәримова Н. Культурный кодагый. Хикәя. №5

Маликова М. Тылсым. Роман. №№8,9

Мирхәйдәров Р. Үзем хөкем итәм. Роман. №1

Мөхәммәтшин Г. Балачакта калачак. Парчалар. №6

Сафин Ф. Курайчылар. Хикәя. №5

Фәттах Н. Аклан. Хыялый роман. №№10-12

Хәлим А. Хикәяләр. №4

Хәсәнов А. Кызлар күрсәм... Хикәя. №12

Якупова Г. Күперләр. Роман. №1

Яруллин Ф. Кыйбласызлар. Повесть. №№1,2

**ХИКӘЯЛӘР КОНКУРСЫНА**

Әмирханов М. Убыр уты. №9

Булатова Д. Туй. №10

Гайнуллин Ф. Күчтәнәч. №2

Зәйдулла Р. Кыз-хатын. №8

Кәримов К. Сунар вакыты. №1

Низами Р. Мәчет бүрәнәсе. №4

Сафиуллин Ә. Көтелмәгән очрашу. №12

Хәбибуллин М. Өч көнлек көтүче. №5

Ширмән Х. Мәхәббәтнең соңгы көне. №3

Шәрифуллин Н. Соңарган сөю. №11

Юнысова А. Мадам Бовари. №4

Яхин Ф. Чишелмәс төен. №7

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Миңнегулова Ф. «Укытучы булулары кыен икән...» Истәлек-хатирә. №11

Сарьян Х. Туган як моңы. №11

**ШИГЪРИЯТ**

Аширов И. Бардамда басу капкасы. Шигырьләр. №8

Әхмәтҗан Роб. Киләчәкнең, шөкер, киләсе бар... Шигырьләр. №8

Әхмәдуллин Г. Йөрәк тагын җыр язды. Шигырьләр. №8

Баян Ә. Без күрмәс еракларга... №12

Бәйрәмова Г. Көзләргә кереп барыш... Шигырьләр. №10

Булатова К. Гомернең кай төше? Шигырьләр. №4

Вәлиева Р. Зәңгәр чәчәк, хәлең беләм... Шигырьләр. №11

Вәлиев Р. «Бер алманы бишкә бүләек» (төрле еллардан җырлар). №1

Вафин М. Җиргә атылган алмадай... Шигырьләр. №11

Гаделша Ш. Туган ягым – Себер уе. Шигырьләр. №7

Гадел Ә. Ватаным. Шигырьләр. №9

Гыйләҗев И. Мәңгелек җирсу. Шигырьләр. №1

Газизова Л. Татарчамы, урысчамы – гамем. Шигырьләр. №6

Диндаров И. Күзгә Күкрәү. Шигырьләр. №10
Зәйдулла Р. Чатырлар. Шигырьләр. №3
Закиров М. Эзләрендә йолдыз кабына. Шигырьләр. №11
Зариф Ч. Төркиядән — илгә, Иделгә. Шигырьләр. №3
Зыятдинов Ф. Кошлар теле дәшә яхшыга. Шигырьләр. №6
Зөлфәт. Борынгы яшен. Шигырьләр. №1
Идиятуллин Р. Күзгә моңнар. Шигырьләр. №9
Исмәгыйлова Ф. Бизмән. Шигырьләр. №3
Кәшфи Л. Ак хисләрем — җырлар канатында. Шигырьләр. №7
Латыйп К. Гомердән — утлы күмерләр. Шигырьләр. №5
Мингалим Р. Елгам сөеп карый күземә. Шигырьләр. №4
Мирза М. Адәм баласына. Шигырьләр. №2
Морат Г. Киңлекләргә дәшә дала җиле. Шигырьләр. №2
Морат Г. Хәтер көне. Шигырьләр. №10
Мәхмүдов Ә. Дим буеның шагыйрьләре. Шигырьләр. №6
Мөхәммәтшин Г. Тансык язлар, тансык назлар. Сигезьюллыклар. №9
Мусин Ч. Көмеш сулар агар учаклардан. Шигырьләр. №5
Миңнуллин Р. Без бу җирдә күпне күрдек. Шигырьләр. №5
Низами Р. Кыяк ярган үлән генә — өр-яңа. Робагыйлар. №7
Рахман Р. Атлар чаба. Шигырьләр. №2
Рәхмәтулла С. Ут эчендә шигырь туачак. Шигырьләр. №4
Рәхим Г. Дусларым аңлар минем бу халәтне... Шигырьләр. №6
Сафина Н. Сабый җаның — тагын бишегендә. Шигырьләр. №7
Ситдикова Ә. Җир өстенә минем хисләр сибелә. Шигырьләр. №3
Суфиров Ф. Оя корыр бәхет кошлары. Шигырьләр. №11
Тарханова Ф. Сагынсак шәрекъ гөлләрен... Шигырьләр. №5
Фазлетдинов И. Мәңгелектән башын алган гомерем... Шигырьләр. №11
Фатыйхов В. Безнең нәсел сынмас, сынатмас. Шигырьләр. №2
Фәйзуллин Р. Соңгы еллар дәфтәреннән. Шигырьләр. №12
Хәсәнов Ә. Әхлакый нур калдырсаң. Шигырьләр. №7
Хөснияр З. Дисбе җебе өзелгәчтен... Шигырьләр. №12
Шагыйрьҗан Л. Туган илкәй бар дөньяда. Шигырьләр. №10
Шәрифуллина Э. Гомер — үтәр, гөлләр — калырлар. Шигырьләр. №6
Шиһапов М. Дөнья кырындагы юлларда мин. Шигырьләр. №10
Юнысова А. Кое күзләреннән су алдым. №9
Юныс Р. Хәтер авазы. Тарихи вокаль цикл өчен текст. №11
Ягъфәров Р. Калган хәтер — янган күперләр. Шигырьләр. №10
Янсуар Л. Кемдер ача күк ишеген. Шигырьләр. №8

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Батулла Р. Мур кырылышы. Фаҗига-хроника. №№10, 11
Мингалим Р., Яһүдин Э. Өч балдызга бер ялгыз. Музыкаль комедия. №8
Миңнуллин Т. Алты кызга бер кияү. Моңсу комедия. №9
Сәгъди Р. Бакчасарай гөлләре. Мелодрама. №7

## ПУБЛИЦИСТИКА

I Бөтендөнья татар галимнәре форумы. №12
Абдуллин М. Малыңмы, җаныңмы? №5
Баттал Ф. Бу дөнья кемгә кала? №11
Гайфуллин В. Фәннилек — милли мәгарифнең нигезе. №4
Галиуллин Т. Гасырлар чатында... №12
Галиева Э. Бай тарихлы гали мәдрәсә. №9
Мирза М. Узып барышлый. №11
Миңнегулов Х. Мөһаҗирлектәге татар әдәбияты. №12
Сабиров И. Фикер бөртекләре. №12
Таһиров И. Тел вә моң — миллилек

чыганаклары. №9

Хәким Р. Татар рухы. №1, 2

Яһүдин Ш. ТР Конституциясендә һәм законнарында милли үзенчәлекләр. №3

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Әдәби тәнкыйтьне ничек җанландырырга? (Түгәрәк өстәл янында сөйләшү). №2

Бәдигый Х. Олы юлның көзгесе. №5

Вәлиулла И. Равил Фәйзуллин шигъриятендә моң һәм сабантуйлык рухы. №8

Заһидуллина Д. Яңа юллар бәхете. №7

Зәйдулла Р. Дулкын биеклеге. №1

Каюмова Г. Сәнгатьчә табышлар. №11

Миңнуллин Р. Дөрес яшисең, Рафис Корбан! №1

Таҗетдинова М. «Яңа» Такташ — ул нинди? №3

Хатипов Ф. Әсәрнең эстетик җегәре. №8

Хәсәнова Ф. Кинаяле сүз уйнату. №10

Юсупова Н. Тылсымлы сүз остасы. №1

**ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ**

Арсланов Г. Еллык драматургия. №6

Әхмәдуллин А. Боз кузгалырга итә. №6

Ибраһимов И. Әдәбият һәм сәнгать елы. №6

Лерон Л. Хәлең ничек, татар прозасы. №6

Морат Г. Караңгылыкны суккәнче шәм кабыз. №6

Рахмани Р. Милләт үсешенең көзгесе. №6

Рәшит Ә. Шигъри хәзинәдә ниләр бар? №6

**ФӘН**

Әхтәмова Г. Борынгы Алабуга. №7

Әмирхан Р. Г. Камалның татар матбугатындагы эшчәнлеге. №3

Беренче татар басма китабына ничә ел? №8

Вәлиев Ф. Татар телен фәннән куалау. №2

Гарипова Ф. Авылларыбыз тарихы. №7, 9, 10, 11, 12

Исламов Ф. Шифалы йогынты. №9

Мәрданов Р. Мәрҗани Фәезханов хезмәттәшлеге: яңа фактлар. №3

Миңнегулов Х. «Яңа япун мөхбире» мәҗмугасы. №2

Сибгатуллина Ә. Гаспралы мирасы кайта. №9

Солтанов Р. XVI—XVII гасырларда Казан тирәсендәге авыллар. №9

Тимергалин А. Миллият сүзлеге. №№1-12

Хуҗин Ф. Алабугага ничә яшь? №2

**ТАРИХ**

Галиев М. Татарны үз иткән немец. №10

Гарифуллин С. Төрки халыклар йолдызлыгы... №1

Макеев С. Барон Мюнхгаузен — чынлыкта. №3

Фукс К. Казан татарлары: статистик һәм этнографик җәһәттән. №№10, 11

**ӘДӘБИ МИРАС**

Галиева Г. Атылган йолдыз кеби. №6

Гамбәр Н. Ачык калган тәрәзәм. Шигырьләр. №8

Мөбарәков Т. Гөл әби. Хикәя. №6

**СӘНГАТЬ**

Арслан Ф. Татар җанлы рус кешесе. №3

Галиуллина М. Төс-бизәкләр — милләт сагында. №4

Мәһдиев Р. Урал-тауның бер кыйтгасы. №3

Хәмидуллин Л. Әй, гармуным, гармуным! Документаль повесть. №8

Хәмидуллин Л. Милли мирасыбыз җәүһәрләре. №2

Сафин Х. Әгәр ул җырчы булмаса. №4

Шакиров Ә. Язмыш һәм узмыш. (Артист язмалары). №2, 3

**ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ ЯШӘҮЧЕ КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ**

**БАШКОРТСТАН**

Вафин М. Җиргә атылган алмадай... Шигырьләр. №11

Закиров М. Эзләрендә йолдыз кабына. Шигырьләр. №11

Суфияров Ф. Оя корыр бәхет кошлары. Шигырьләр. №11

Фазлетдинов И. Мәңгелектән башын алган гомерем. Шигырьләр. №11

УДМУРТИЯ

Батталов Р. Көтү. Шигырьләр. №12

Биектаулы И. Мизгелләр. Шигырьләр. №12

Вәли З. Урланган төн. Хикәя. №12

Исхакова Г. Кабат язлар килә. Шигырьләр. №12

Нигъмәтҗан Э. Дусларыма. Шигырьләр. №12

Сафин Г. Шигырьләр. №12

ТЕЛ ДӘРЬЯСЫ

Абдуллин М. Биздергән дә тел. №10

Диндаров И. Тел байлыгын кем саклар... №10

Сабиров М. «Һәм»нән «хам» ясамыйк! №10

Тимергалин А. Татарга нигә кагыйдә? №7

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Зарифоглу Җ. Йөрәк бабай белән падишаһ. №10

ХӘТЕР

Акъегет Р. Күңелдә яшерен гамь бар иде. №12

Альберт Фәтхи турында истәлекләр. №7

Баттал Ф. Салих абый турында уйланам. №8

Газиз Г. Татар телендәме, рус телендәме? №6

Гарипов М. Мөҗәй батыр. №5

Госманов М. Мөһаҗирлектәге һәвәскәр татар театрлары. №5

Зыятдинов Б. Һәрбер музей – тормыш дәвамы. №2

Литвин А. Күптәнге дуска хат. №4

Мәрданов Р. «Тәрбияви этфаль» журналына йөз ел. №2

Мәрданов Р. Ватан газабы. №5

Мәһдиев М. Көндәлек сәхифәләре. №1

Миргалиев М. Татарның онытылган Ватан сугышы. №5

Нәҗмиев Т. Биш очрашу. №12

Низами Р. Мәңгелектер Сәйдәш моңнары. №3

Низаметдинов З. Җәлил дусты Кашшаф. №4

Табиева З. Хәтерлим. №5

Шамов С. Яшьлекнең ерак таңнары. №3

Шамов С. Мәңгелектер Сәйдәш моңнары. №4, 5

Шәрәфиев Р. Бер авылның күргәннәре. №8

Юсупова Р. Күкләрдән иңгән мәхәббәт. Очерк-хат. №3

ЮБИЛЕЙЛАР

СӘГЫЙТЬ ХӘЛФИННЕН ТУУЫНА 275 ЕЛ

Вәлиди Ә. Сәгыйть Хәлфин. №9

ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙНЫН ТУУЫНА 210 ЕЛ

Габделҗәббар Кандалый. Шигырьләр. №11

ВАСИЛИЙ РАДЛОВНЫН ТУУЫНА 170 ЕЛ

Фәхретдин Р. Василий Васильевич Радлов җәнапләренең илле еллык (1859–1909) бәйрәме. №2

ГАБДЕРӘШИТ ИБРАҺИМОВНЫН ТУУЫНА 150 ЕЛ

Армас-талмас каһарман. №4

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫН ТУУЫНА 120 ЕЛ

Галимҗан Ибраһимов (редакция мәкаләсе). №3

Галимҗан Ибраһимов турында күренекле әдипләр. №3

Байчура Ш. Бергә узган еллар. №3

Галимҗан Ибраһимовның соңгы көннәре турында истәлекләр. №3

ҖАМАЛ ВӘЛИДИНЕН ТУУЫНА 120 ЕЛ

Вәлидев Җ. Кавем һәм кабиләбез арасында. №9

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫН ТУУЫНА 120 ЕЛ

Кәрим Тинчурин. №9

ГАЛИМҖАН НИГЪМӘТИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Әдип. Галим. Мөхәррир. №7

ГАРИФ ГОБӘЙНЕН ТУУЫНА 100 ЕЛ

Гыймадиев А. Бишбалта егете. №8

ГАЙ ТАҺИРОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Низами Р. Яфраклар балет бию башкара. №2

МИРСӘЙ ӘМИРНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Аның «Саф күңел»е, «Агыйдел»е... (Көндәлек сәхифәләре). №2

МӘХМҮТ ХӘСӘНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Галимуллин Ф. Аның сукмагы. №12

КОЯШ ТИМБИКОВАНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Әхмәт Рәшит. Хәтерләрдә калды. №11

МӘХМҮТ ӘХМӘТҖАНОВКА 80 ЯШЬ

Баттал Ф. Милләт җанлы каләмдәшебез. №2

ӘХСӘН БАЯНГА 80 ЯШЬ

Баян Ә. Без күрмәс еракларга... Шигырьләр. №12

МИРГАЗИЯН ЮНЫСКА 80 ЯШЬ

Галиев М. Ә бит... энҗеләр тапкан әдип! №5

МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

Свеpигин Р. Тормыш чоңгыллары һәм тарих төпкелләре аша... №12

ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИНГА 75 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Аксакал әдипләребезнең берсе. №11

ФӘНИС ЯРУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Бәшир Ф. Ачыдыр хакыйкать юлы... №12

РАФАЭЛЬ ГАЗИЗОВКА 60 ЯШЬ

Закир М. Чишмәләр шагыйре. №4

Газизов Р. Шигырьләр. №4

КИТАП КҮЗӘТҮ

Баттал Ф. Күпер аркылы чыкмыйлар. №5

Закирҗанов Ә. «Моңлы ядкарь». №9

Низами Р. Тәнкыйть тә—тирән дәрьядыр. №6

Низами Р. Яшәү тамыры... тирәндә. №12

Рәхимова Б. Халык китабы. №9

Свеpигин Р. Тойгылар сафлыгы. №8

ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Галиев Г. Күңелемдә яңарган хатирә. №8

Зәйнуллин З. Шахматтагы ике ат һәм һәйкәл Салават. Җиде юл чатында. №7

Мөхибуллин Н. «Сөлчә буенда» язылмый калды. №6

Нуриев В. Соңгы йөреш. №10

Фәизов Р. Акча кодрәте. Апаниләр сөйләде. Ахыр заман булмый калды. №4

Фәтхетдинов Ә. Әтине өйләндерү. №5

2007—ХӘЙРИЯ ЕЛЫ

Юнысова А. Ният гамәлнең башы. №8

АККОШ КҮЛЕ—ИЛҺАМ АЛАНЫ

Бәширов З. Сурәтләрдә тарих «күзе». №6

Вәлиев М. «Аккош күле»ндә әдипләр чуагы. №6

Ихсанова Л. Истәлекле җәй. №6

Фәйзуллин Р. Әдипләрнең гамь бишеге. №6

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Әдһәмов К. Телеңне күрсәт... Монолог. №11

Галиуллин Р. Шаян хикәяләр. №12

Галиуллин Р. Хафа. Шаян хикәя. №6

Зарипов Р. Тукай күчтәнәче. №12

Саттаров М. Яшенле елларым. Шигырьләр. №11

Мәннан Р. Шигырьләр. №12

Нәҗмиев Т. Уены-чыны бергә. №4

Хәйруллин И. Шаян хикәяләр. №2

Хәмзин А. Сәхнә монологлары. №5

Лерон Л. Эпиграммалар. №6

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Бикмуллина А. Күзләр байлык белән томаланган... Шигырьләр. №1

Гобәева Р. Тамчыдагы кояш нуры булып. Шигырьләр. №10

Гыйбадуллина Л. Хәтерләрнең хәтәр чигешендә. Шигырьләр. №3

Корбанова Г. Ярым, ярам... Шигырьләр. №5

Куропаткина А. Җан—күк кызы булганга. Шигырьләр. №10

Мөхәммәтҗанова С. Мин—

хыялый җир кызы. Шигырьләр. №1

Сәлах Р. Челлә челтәрендә — кояш. Шигырьләр. №4

Фәтхетдинова Л. Бәхет. Шигырьләр. №1

Шәех Л. Якты шәмнәр. Шигырьләр. №4

Һадиева Э. Зәңгәр таң канаты. Шигырьләр. №3

**БЕРЛЕКНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ**

Кәнәфи Бадыйков. №1

Фәрит Бәширов. №2

Ягъсуф Шәфыйков №3

Камил Тангалычев №3

Марсель Гарипов №4

Гали Арсланов. №5

Рөстәм Зәкуанов №8

Наилә Краева. №9

Гыймран Сафин. №11

Илшат Вәлиуллин. №12

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Миңнеруй. Беренче кар. Шигырьләр. №11

**НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ**

Корбан Р. Куян эз югалта... Шигырьләр. №1

**БЕЗНЕҢ КҮРГӘЗМӘ**

Салих Сәйдәшев. №5

Бакый Урманче. №5

Әмирхан Еники. №6

Фәрит Яруллин. №6

Хәсән Туфан. №8

Җәүдәт Фәйзи. №8

Марсель Сәлимҗанов. №9

Нәҗип Җиһанов. №9

Габдулла Тукай. №10

Фатих Хөсни. №10

Абдулла Алиш. №12

Гариф Ахунов. №12

**АК ҖИЛКӘН**

Габдулхакова А. Тарту көче. Хикәя. №5-7

Галиева А. Кайф. Хикәя. №5

Җамалиев А. Беренче күбәләкләр. Хикәя. №5

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

Сафуан Мулла Галигә 80 яшь. №9

Азат Әхмәдуллинга 75 яшь. №10

Азат Вергазовка 75 яшь. №3

Равил Фәхретдиновка 70 яшь. №3

Юныс Сафиуллинга 60 яшь. №10

Галимҗан Гыйльмановка 50 яшь. №2

**БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ**

Бари Рәхмәтнең тууына 110 ел. №5

Зәкия Туфайлованың тууына 100 ел. №1

Якуб Зәнкиевның тууына 90 ел. №4

Рәйсә Ишморатованың тууына 90 ел. №7

Сәхаб Урайскийның тууына 90 ел. №12

Зәет Мәҗитовның тууына 80 ел. №8

Сәет Шәкүровның тууына 80 ел. №12

Фәрит Гыйльминең тууына 60 ел. №4

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. №№1-12

Бер сорауга — бер җавап. №№1, 6, 10, 11

Укучы сүзе. №№3, 8, 9, 10, 11, 12

Хушлашу сүзе. №№1, 2, 6, 10

«Казан утлары» архивыннан. №№1-12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12

Яңа китаплар. №№1-12



*РСФСР язучылар съездында катнашкан Татарстан язучылары Кремль залында. 1985 ел.*



*Композитор Нәҗип Җиһанов. 1981 ел.*



*«Казан утлары»ның 80 еллык юбилее утырышыннан күренеш. Милли мәдәни үзәк. 2002 ел.*



*Мәшһүр артистлар. Сулдан уңга—баянчы Мохтар Әхмәдиев, җырчы Рәшит Ваһапов, нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов. 50 нче еллар.*



*Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар шагыйре Марис Нәзиров. 1990 ел.*



*Ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу тантанасыннан күренеш. Сулдан уңга—Әнвәр Хәйри, Тәлгат Таҗетдин, Равил Гайнетдин, Туфан Миңнуллин. Мәскәү. 1990 ел.*

## ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ СЪЕЗДЫ

3 ноябрьдә Казанның «Корстон» мәдәни-күңел ачу үзәгендә Татарстан халыкларының II съезды булып узды. Форумга 56 милләт вәкилләре булган 700 делегат, 200 кунак килгән иде. Съезд эшендә ТР Президенты М. Шәймиев, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, РФ төбәкләр үсеше министры урынбасары К. Исхаков, РФ Президентының Идел буе округындагы тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары В. Зорин, Россия халыклары ассамблеясе советы рәисе, РФнең Тажикстан республикасындагы илчесе Р. Абдулатыйпов, Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Р. Моратов, премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Казан шәһәре мэры И. Метшин һ. б. катнашты.

Съездга әдәбият-сәнгать әһелләре дә кунак итеп чакырылган иде. Алар арасында, аерым алганда, Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, драматург Т. Миңнуллин, шагыйрьләр Р. Фәйзуллин, Л. Шагыйрьҗан, Л. Газизова, язучылар Р. Батулла, А. Хәсәнов, Н. Орешина һ. б. бар иде.

Республика съездга ныклап әзерләнде. Форумны каршылап, республиканың барлык районнарында да диярлек «Этномәдәни эстафета» узды. Аның кысаларында «Татарстан—уртак йортыбыз» фестивале, «Без бергә!» республика хәйрия концерты, «Без—төрле, без—бертигез» дигән яшьләр форумы, «Дуслык белән көчле без» дигән республика мәктәпләре фестивале, «Россия этномәдәни киңлеге шартларында милли мәгарифнең тәрбия потенциалы» дигән Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе һ. б. чаралар үткәрелде.

Съезд ачылу уңаеннан да «Корстон» мәдәни-күңел ачу комплексының фойесында делегатлар һәм кунаклар игътибарына берничә күргәзмә тәкъдим ителде.

Съезд тәбрикләүләр белән ачылып китте. Чыгыш ясаучылар съездның көн тәртибенә куелган «Татарстанда милләтара мөнәсәбәтләрнең торышы һәм аны үстерү перспективалары», «Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте концепциясе», "Татарстан халыклары ассамблеясен булдыру турында»гы мәсьәләләргә үз мөнәсәбәтен белдерде.

Президент М. Шәймиев республиканың төрле яклап үсүендә һәм алга китүендә Татарстанда яшәүче барча халыкларның да хезмәте зур булуын билгеләп үтте. "Татарстан һәрвакыт төрле милләт вәкилләре өчен туган йорт булды. Аларның күбесе республикабызны, илебезне үстерүгә зур өлеш кертте. Биредә Украина Республикасының беренче Президенты М. Грушевский, белорус әдәбияты классигы Я. Купала, татар этнографиясен үстерүгә гаять зур өлеш керткән немец галиме К. Фукс яшәде. Безнең республика чуаш И. Яковлев, мари В. Мосолов, башкорт М. Гафури, мордва М. Девятаев һәм башка исемнәр белән тыгыз бәйләнгән»,— диде М. Шәймиев.

Илбашы шулай ук Татарстан халыкларының 1998 елда узган I съезды турында да искә төшереп үтте. Съезд ил өчен катлаулы вакытта—болгавыр чорда узды. Бу форумда милли-мәдәни берләшмәләр ассоциациясе төзелде. Съездда Татарстанда яшәүче халык вәкилләренең милли мәдәниятен саклау һәм үстерү, милләтара һәм конфессияара иминлекне тагын да ныгыту милли эшчәнлекнең төп юнәлешләре итеп билгеләнде. «Бүген инде I съезд тарафыннан куелган бурычлар нигездә үтәлде. Безнең республика төрле диннәр һәм милләтләр арасында, эчке тотрыклылык булдырып, авыр хәлләрдән сакланып кала алды»,— диде М. Шәймиев.

Казанда 1993 елдан Татарстан Халыклар дуслыгы йорты эшләп килә. 2000 елда Чаллыда «Родина» халыклар дуслыгы йорты ачылды. Республикада 100дән артык милли-мәдәни үзәк бар.

Съездда туган тел, милли мәгариф мәсьәләләренә дә җитди игътибар бирелде. Татарстанда 1172 татар, 148 чуаш, 45 удмурт, 22 мари, 5 мордва мәктәбе бар. Керәшен, яһүд, башкорт этномәдәни компонентлары белән берәр, рус этномәдәни компоненты белән 35 уку йорты эшләп тора.

Рус балалары тулысынча, татар балаларының 50,5 проценты үз ана телләрендә белем ала. Моннан тыш, республиканың 34 якшәмбе мәктәбендә украин, әзәрбәйҗан, әрмән, поляк, немец, яһүд, грузин, башкорт һәм башка милли телләр өйрәнелә. Бу уңайдан туган телгә игътибарның кимүенә юл куелырга тиеш түгеллеген Р. Абдулатыйпов та билгеләп үтте. «Әгәр без бер халыкка битараф булсак, иртәгә ул фаҗига икенче халыкка да килеп кагылачак. Милли мәгариф, милли мәдәният, туган тел белән фундаменталь төстә шөгыльләнергә кирәк. Шул

ук вакытта Ватаныбызның гражданнар бердәмлеге дә күз унында тотылырга тиеш»,— диде ул.

Республикада гыйбадәт йортлары төзүгә дә тиешле шартлар тудырылган. Казан Кремлендәге Кол Шәриф мәчете һәм Благовещение соборы халык бердәмлеге һәм диннәрнең янәшә тыныч яшәү символына әверелде.

Съезд игътибарына чыгарылган төп документ Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте концепциясе проекты булды. Делегатлар анда билгеләнгән төп юнәлешләрне, максат-бурычларны тулаем яклап чыктылар. Концепция нигезендә дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру программасы эшләнәчәк. Әлеге документ Татарстан халыклары мәнфәгатьләрен, тигез хокукчылыгын яклау белән бергә, барча татар милләтен кайгырту ягыннан да зур әһәмияткә ия. Әйтик, максат һәм бурычларны билгеләгәндә «Татарстанның дәүләтчелеген ныгыту, республиканың күпкырлы үсешен тәэмин итү, төбәк, гомумроссия һәм халыкара дәрәжәләрдә аның вәкиллекләрен гамәлгә ашыру, Татарстанны бөтен татар халкының тарихи-рухи һәм этномәдәни үзәге буларак күрсәтү, Россиядәге һәм чит илләрдәге татар диаспораларын интеллектуаль, икътисади һәм башкача берләштерү өчен шартлар тудыру; төп юнәлешләрне күрсәткәндә «Татарстан предприятиеләренең ватандашлар күпләп яшәгән регионнар белән үзара файдалы икътисадый хезмәттәшлек куәтен ныгыту, Татарстаннан читтә, ватандашларыбыз күпләп яши торган урыннарда милли-мәдәни үзәкләр төзүгә ярдәм итү», дигән пунктлар милләттәшләребез күңеленә хуш килде.

Шул ук вакытта съезд РФ Президентына, Федераль Җыенына һәм Хөкүмәтенә мөрәҗәгать кабул итеп, РФ дәүләт милли сәясәтенең яңа концепциясен һәм милләтара мөнәсәбәтләрне көйләүче федераль законны кабул итү эшенең сузылуына; милли сәясәт мәсьәләләрендә махсуслашкан федераль орган булмауга, белем бирү стандартларына үзгәрешләр кертеп, милли-төбәк компонентны төшереп калдыру омтылышларына борчылуын белдерде.

Съезд 15 ел элек оешкан ТР Милли-мәдәни оешмалар берләшмәсенең статусын күтәрү максатында аны Татарстан халыклары ассамблеясе итеп үзгәртеп кору турында карар кабул итте.

Съездда Ф. Мөхәммәтшин делегатларга һәм кунакларга РФ Президенты В. Путинның, Премьер-министр В. Зубковның, Дәүләт Думасы Рәисе Б. Грызловның, Федерация Советы Рәисе С. Мироновның котлауларын ирештерде. К. Исхаков РФ төбәкләр үсеше министры Д. Козакның, В. Зорин РФнең Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле А. Коноваловның тәбрикләү сүзләрен тапшырды.

Кичен делегатлар һәм кунаклар өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында зур концерт булды.

### КОНСТИТУЦИЯБЕЗГӘ—15 ЕЛ

Татарстан Конституциясе кабул ителүгә 15 ел тулу уңаеннан Президент Минтимер Шәймиев республика халкына мөрәҗәгать итте.

«Конституция—ул үсеш алган дәүләт, гражданлык, кешенең демократик хокукы һәм ирege синонимы. Мондый мөһим документта хакимият иң югары принципларны чагылдырырга, дәүләт һәм җәмгыять үсешенең иң күркәм максатларын билгеләргә тырыша. 1992 елгы Конституция дә татарстанлылар мәнфәгатьләрен кайгыртып, аларның хокукларын саклар өчен барлыкка килде.

Бүген Татарстан Конституциясе Россиянең бердәм сәяси-хокукый киңлегендә республиканың югары статусын билгеләп, федерализмның асылын ачып бирә», диелә мөрәҗәгатьтә.

### «МӨХӘММӘДИЯ»ГӘ 125 ЕЛ

Казанның «Мөхәммәдия» мөселман мәдрәсәсе үзенең 125 еллык һәм мәдрәсәнең җитәкчесе Галимҗан Барудиның 150 еллык юбилеен билгеләп үтте. Мәдрәсәгә 1882 елда сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Галиев тарафыннан нигез салына һәм аның хөрмәтенә «Мөхәммәдия» дип йөртелә башлый. Юбилей көннәрендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә 125 ел» дип аталган фәнни-гамәли конференция узды. Ф. Әмирхан, Б. Урманче, С. Сәйдәшев, Н. Исәнбәт, К. Тинчурин кебек мәшһүр затларны тәрбияләгән әлеге уку йортында бүген 900 шәкерт белем ала. Мәдрәсәне тәмамлаучылар Россиянең төрле төбәкләрендә эшли.

### «ШҮРӘЛЕ»ГӘ—100 ЯШЬ

Габдулла Тукайның әлеге әкият-поэмасына нигезләнеп, күренекле композитор Фәрит Яруллин 40 нчы елларда балет иҗат иткән иде. Ул безнең илдә генә түгел, күп кенә чит ил сәхнәләрендә дә дан казанды. Танылган рәссамнар Шүрәлене үз картиналарында сурәтләп, әлеге образны күзалларга ярдәм итте.

Әсәрнең язылуына 100 ел тулуга багышланган кичәдә күп кенә авторларның рәсемнәре, картиналары тәкъдим ителде. Б. Әлменов, Ф. Әминов, Ә. Фәтхетдинов, Р. Шәмсетдинов һәм башка рәссамнарның иҗат җимешләре күпләргә яхшы таныш.

Кичәдә профессор Зөфәр Рәмиев, филология фәннәре докторы Фәрит Бәширов, сәнгать белгече Динә Валиева «Шүрәле» әкият-поэмасы хакында тәфсилләп сөйләде. Кичәдә шулай ук «Шүрәле» балетында Сөембикә партиясен башкарган атаклы биюче Ирина Хәкимова да катнашты.

## ДИПЛОМНАР ТАПШЫРЫЛДЫ

Мәгълүм булганча, быел җәй Татарстан Фәннәр академиясенең гомуми җыелышында яңа академиклар һәм мөхбир-әгъзалар сайланды. Алар арасында Татарстан язучылар берлеге әгъзалары да бар иде. 8 ноябрь көнне Татарстан Фәннәр академиясенең зур залында тантаналы шартларда яңа сайланган академикларга һәм мөхбир әгъзаларга фәнни дәрәҗәләре билгеләнгән дипломнар, таныклыклар һәм күкрәк билгесе-значоклар тапшырылды. Дипломнарны ТР Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мәзһаров тапшырды. Академиянең шәрәфле академиклары булып сайланган язучыларыбыз Туфан Миңнуллин һәм Равил Фәйзуллин җавап сүзе белән чыгыш ясадылар. Бу церемониядә, шулай ук, гуманитар фәннәр буенча мөхбир-әгъзалар булып сайланган әдәбият галиме Дания Заһидуллинага һәм театр сәнгате белгече Гали Арслановка да диплом һәм таныклыклар тапшырылды.

## ЖУРФАК ЮБИЛЕЕ

Казан дәүләт университетында журналистика бүлеге оешуга—45 ел. Бу бүлек инде байтак дистә еллар Идел буе төбәкләре өчен кадрлар әзерли. Бүген республика мәгълүмат чараларында эшләүчеләрнең байтагы элеккеге журфак студентлары. Бүген журналистика һәм социология факультетында 900 ләп студент укый. Алар заманча технологияне үзләштерәләр, базар шартларында көндәшлеккә сәләтле белгечләр булып тәрбияләнәләр. Шулай да проблемалар да җитәрлек. Уку стандартларының «өстән», Мәскәүдән төшерелүе милли кадрлар укытып чыгару эшендә киртәләр тудыра. Бу стандартлар нигезендә студентлар рус, чит ил әдәбиятлары, рус теле, рус һәм чит ил журналистикасы тарихлары буенча йөзләрчә сәгать лекция тыңларга тиеш. Ә менә үзебезнең татар әдәбияты һәм журналистикасы тарихы, халкыбыз тарихы, мәдәнияте буенча өстәмә дәресләр бирү өчен мөмкинлекләр бик аз»,— ди журналистика һәм социология факультеты деканы Васил Гарифуллин.

Татар журналистикасы аерым кафедра булып 1990 елдан эшләп килә. Әмма университетның тарих-филология факультетының татар бүлегендә татар журналистикасы белгечләреп оештыру эшен Ш. Хамматов, Х. Госман, М. Гайнуллин, Г. Кашшафлар үткән гасырның 50 нче елларында ук башлап йөргәннәр.

Моннан берничә ел элек, журналистика һәм социология факультеты барлык уңайлыклары булган яңа бинага күчте. Биредә мультимедиа чаралары, интернет-ресурсларны куллану өчен һәр студентка мөмкинлек тудырылган.

## МУЗЫКА БӘЙРӘМЕ

19-22 октябрьдә Казанда Татарстан, Россия, Франция, АКШ, Германия, Кытай, Румыния, Һиндстан, Швейцария, Япония, Таҗикстан композиторлары һәм музыкантлары катнашында VIII халыкара «Европа-Азия» заманча музыка фестивале үтте. Ул С. Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында «Рәшит Кәлимуллин һәм аның дуслары» дигән программа белән башланып китте. Мәгълүм булганча, быел Татарстан Композиторлар берлеге идарәсе рәисе Р. Кәлимуллин үзенең 50 яшьлеген билгеләп үтә. «Үтә дә сизгер ишетү-тоемлау сәләтенә ия булуы белән Р. Кәлимуллин гади тыңлаучыга сихри матур дөньяны ачып бирә. Бик сирәк аһәңсазларга гына бирелә мондый сәләт»,— дигән аның турында дөньякүләм танылган юмпозитор София Гобәйдуллина. Аннары «Европа-Азия» фестивале—«Казан» милли-мәдәният үзәгендә «Стильләр панорамасы» дигән концерт программалары белән дәвам итте. Фестиваль кысаларында композиторлар заманча музыканы пропагандалау чаралары турында да фикер алышты.

## НЕФТЬЧЕЛӘР ПРЕМИЯ ТАПШЫРА

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең теләген истә тотып, нефтьчеләр Сажидә Сөләйманова исемендәге еллык әдәби премия булдырды. Премия бирү «Татнефть»нең «Рухият» рухи яңарыш фонды кысаларында бара.

Нефтьчеләрнең әдәби бүләген тапшыруның инде үз традицияләре дә формалашып килә. Танылган шагыйрәгә багышланган бәйрәм ике елда да Сажидә Сөләйманова урамында, шагыйрә исемендәге китапханә янында аның бюсты каршында әдәби митингтан башланып китте.

Быелгы премияләр Әлмәт шагыйрәсе Клара Булатовага («Әрнү» дигән китабы өчен), Лениногорск язучысы Альберт Хәсәновка («Кан үче» һәм «Полет пчелы» дигән китаплары өчен), Казанда яшәүче шагыйрь Рәниф Шәриповка («Мәңгелек сер» җыентыгы өчен) насыйп булды. Кызыксындыру премияләренә өч шагыйрә ия булды. Алар—Азнакай районыннан Фәйрүзә Исмәгыйлева, Казаннан Фәйрүзә Мөслимова һәм Луиза Янсуар.

Премияләрдән тыш әдәби уңышларга ирешкән студентларга С. Сөләйманова исемендәге стипендияләр дә бирелә.

## ХӘЕРЛЕ ОЧЫШ

«Иделем акчарлагы» бәйгесе 40ка якын яшь язучыны быел җиденче тапкыр җыйды. ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы каршында эшләп килүче «Идел» яшьләр үзәге бу бәйге аша яшь буын арасында талантлы прозаик, шагыйрь, драма-

тургларны ачыклау белән шөгыльләнә.

Жюри рәисе шагыйрь Газинур Морат, жюри әгъзалары Ркаил Зәйдулла, Вакыйф Нуриев, Ләбиб Лерон, Марат Закир, Хәбир Ибраһим, Равил Рахман белән мастер-классларда һәрбер конкурсантның иҗаты тикшерелде, әсәрләренең отышлы һәм кимчелекле якларына анализ ясалды.

Язучы Камил Кәримов белән аның «Уен» романы буенча фикер алыштылар. Буа сатира театры режиссеры Раил Садриев белән әңгәмә дә оештырылды. Г. Тукай музеенда «Ач, шигърият, серләреңне» дип исемләнгән очрашуда яшь каләм тибрәтүчеләр шагыйрьләр Рәмис Аймәт һәм Луиза Янсуар иҗатлары белән таныштылар. Кичен Салих Сәйдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залында Татарстан Республикасының симфоник оркестры чыгышын карадылар.

«Иделем акчарлагы—2007» бәйгесенең Гран-приена шигърияттә Эльвира Һадиева (Балтач), прозада Рөстәм Галиуллин(Арча) лаек булды. Шигърияттә: I урын—Илнур Юнысов (Мамадыш), II урын—Ләйсән Фәтхетдинова (Балык Бистәсе), III урын—Алинә Куропаткина (Питрәч).

Прозада: I урын—Ләйсән Фәтхетдинова (Балык Бистәсе), II урын—Айназ Гайниева (Минзәлә), III урын—Алинә Бикмуллина (Балык Бистәсе).

Әлеге бәйгедә катнашучыларның әсәрләрен туплап, ТР Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы мәдәнияте һәм халыкларының телләре үсеше бүлеге ярдәме белән «Иделем акчарлагы» дип аталган әдәби җыентык нәшер ителергә әзерләнә.

## КАЗАН ЕГЕТЕ—ГРАН-ПРИ ИЯСЕ

Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы оркестр солисты Алмаз Әхмәтҗанов Италиядә узган «Citta di Lanciano» халыкара аккордеончылар бәйгесендә ике номинациядә җиңү яулады. Әлеге бәйгедә Россия, Украина, Беларусь, Молдова, Италия, Польша, Югославия, Румыния, Германия, Франция һәм Чехия сәнгать әһелләре катнашты. Казан егете эстрада көен башкарып, 3 нче урын алды, классик әсәрләр буенча исә Гран-прига лаек булды.

## МУЗЕЙ БУШ ТОРМЫЙ

«Эрмитаж-Казан» үзәгендә Санкт-Петербург шәһәренең Эрмитаж үзәге әзерләгән еллык музей-мәгариф программасы эшли башлады. Айга 2-3 тапкыр Эрмитаж хезмәткарләре казанлыларга сәнгать юнәлешләре, илнең күренекле музейлары турында лекцияләр укыячак. «Беренче елда музейга ике мең ярым кеше килгән, узган елны аларның саны дүрт мең булды. Эрмитажның тамаша залы буш торганы юк»,— ди оештыручылар. Узган елны башкала халкы «XX гасыр сәнгате», «Көнбатыш Европаның бөек музейлары», «Петербургта ачылган Көнчыгыш» циклларын яратып караган. Быел исә Эрмитаж «Рус мәдәнияте. Чор һәм үзенчәлекләр», «Борынгы греклар эзеннән», «Илнең музейлары һәм шәһәрләре буенча» күргәзмәләрен тәкъдим итәчәк.

## ТАНТАНАЛЫ ОЧРАШУЛАР—ДУСЛАРЧА КҮРЕШҮЛӘР

***

9-10 ноябрь көннәрендә Кабарда-Балкар республикасының башкаласы Нальчик шәһәрендә һәм Чечен район үзәгендә Балкар халык шагыйре, СССР һәм РСФСРның дәүләт премияләре лауреаты, шагыйрь Кайсын Кулиевның тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналар булып узды. Нальчик каласының республика музыка театрында үткән тантаналы җыелышта Кабарда-Балкар республикасы Президенты Арсен Бәшир улы Каноков доклад белән чыкты. Мәскәү, Татарстан, Карачай-Черкес, Дагыстан, Осетия, Ингушетия, Чечня, Ставрополь, Әстерханнан килгән делегация вәкилләре катнашты. Юбилейда Татарстан республикасы исеменнән Татарстан язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Россия дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харис чыгыш ясадылар...

***

Шушы елның сентябрендә Җәләлетдин Руминың тууына 800 ел тулуга багышланган халыкара конференция Таҗикстан башкаласы Дүшәмбе шәһәрендә уздырылды. Бу форумны ЮНЕСКОның «Диалог Евразия» («ВА») журналы, Таҗикстан Фәннәр академиясе бергәләп оештырган иде. Монда дөньяның 28 иленнән килгән галимнәр, әдипләр, җәмәгать эшлеклеләре, шул җөмләдән Татарстан язучылары Разил Валиев, Марсель Галиев, «ВА» журналының Казандагы вәкиле Рәсим Хөснетдиновлар делегат буларак катнаштылар.

Шәрыкнең бөек акыл иясе, суфи-философ, шагыйрь Мәүлана Җәләлетдин Руми иҗаты бүген дә бик күп телләргә тәрҗемә ителә, югары уку йортларында укытыла; бүгенге чорда Җир шары экологик катастрофа алдында торганда Руми иҗатыннан бик күп сорауларга җавап табып була. Күп гасырлар элек илләр, диннәр арадашчылыгы турында бөек акыл иясенең әйтеп калдырганнары—бүген дә актуаль. Конференциядә Таҗикстан Президенты Эмомали Рахмон докладында да, бүтән илләрдән калган вәкилләр чыгышында да Шәрыкнең бөек шәхесе—Руминың иҗат һәм тормыш юлына югары бәя бирелде.

Кунаклар Курган Төбе шәһәренең зур мәйданында Румига һәйкәл ачу, шунда ук төрек лицее ишегалдында бюст ачу тантанасында катнаштылар.

Таҗикстанның азатлык алу көнен бәйрәм

иту тантанасында делегатларны Президент Эмомали Рахмон үзенең резиденциясендә кабул итте.

### ТАТАР КИТАБЫ КИБЕТЕ АЧЫЛДЫ

Соңгы 15-20 еллар эчендә, бүтәнчәрәк әйткәндә базар мөнәсәбәтләре чорында, Республикада гомер бакый яшәп килгән байтак китап кибетләре ябылды. Шулай да, рухи тормышыбызда күңелгә хуш килә торган вакыйгалар да булып тора. Октябрь аенда башкалабыз үзәгендә (Бауман урамы, 29/11 йорт, Татар халык ашлары, Чәй йорты янәшәсендә) татар китаплары сатыла торган кибет ачылды. Анда, нигездә, Татарстан китап нәшрияты чыгарган китаплар тәкъдим ителә. Кибет ачылу язучылар, гомумән, зыялылар, китап сөючеләр өчен бәйрәм төсен алды. Андый очракларда була торган рәсми ачылышта язучылар—Т. Миннуллин, Р. Фәйзуллин, Р. Вәлиев, И. Ибраһимов, Т. Галиуллин, Ф. Гыйззәтуллина, Ф. Тарханова, шулай ук, «Татмедиа» агентлыгының генераль директоры урынбасары Ф. Шаһиәхмәтов һ. б. чыгыш ясады. Татар китап кибете ачылуда Татарстан китап нәшрияты директоры Д. Шакиров эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. Татар китабы кибетенә рәхим итегез!

### ЖУРНАЛИСТ-ЯЗУЧЫ ҖИҢҮ ЯУЛЫЙ

Быел җәй Пермьда журналистларның «Балалар һәм яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү» дигән темага конкурсы узган иде. Анда «Татарстан» радиосының балалар өчен тапшырулар редакциясе мөхәррире Дания Гайнетдинова катнашып, диплом һәм «Ника» сыны алып кайтты.

Күптән түгел Екатеринбургта «Россия патриотлары» дигән VI Бөтенроссия конкурсы үтте. Анда Россиянең 67 төбәгеннән матбугат һәм радио-телевидение хезмәткәрләре катнашты. Бу юлы да Дания ханым «Ватан кайдан башлана?» дигән радио тапшырулары циклы өчен Россия Мәгариф министрлыгының махсус бүләгенә лаек булды.

* * *


Балалар әдәбиятындагы казанышлары өчен язучы **Гыймадиев Алмаз Марс улы** Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе белән бүләкләнде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Кышкы урман».

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Рәмис Аймәт**.

# Яңа китаплар




**Зиннур Мансуров.** Көнгә шөкөр кылыу: шигырьләр һәм поэмалар. —Уфа: Башкортстан «Китап» нәшр., 2007. —296 б. Тиражы—1500 данә.


Татарстан китап нәшрияты белән Башкортстан «Китап» нәшрияты 1994 елда «Каләмнәр туганлыгы»—«Кардәшлек киштәсе» дип исемләнгән серия булдырган иде. Әлеге уртак килешүнең максаты танылган татар һәм башкорт шагыйрьләренең Казан һәм Уфада аерым җыентыкларын чыгарудан гыйбарәт. Шушы 13 еллап вакыт дәвамында татар һәм башкорт телләрендә дистәләрчә китап дөнья күрде.

«Көнгә шөкөр кылыу»—күренекле шагыйрь Зиннур Мансуровның әлеге килешү нигезендә Уфада чыккан китабы. Анда авторның әдәби җәмәгатьчелектә унай бәя алган шигырьләре һәм поэмалары туплап бирелгән. Әсәрләрне башкортчага шагыйрь Габделхак Игебаев тәрҗемә иткән. Бизәлеш рәссамы—Салават Гыйләҗетдинов.




**Рәдиф Сәгъди.** Ирдәүкәләр: романнар. —Казан: Тат. кит. нәшр., 2007. —384 б. Тиражы—3000 данә.

Рәдиф Сәгъди киң катлау тамашачыларга драма әсәрләре авторы буларак билгеле. Бу китапта ул прозаик буларак тәкъдим ителә. Китап ике романнан тора. «Ике кояшлы дөнья» романы фантастик жанрда язылган. Бередә параллель дөньялар аша Россия белән бүгенге Татарстан тормышы чагылдырылган. «Ирдәүкәләр» романы «Тарих атасы» исеменә лаек булган, безнең эрага кадәр 490-425 елларда яшәгән Геродот язмаларына таянып иҗат ителгән.



Рәмис Аймәт

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**QAZAN UTLARI**
**ОГНИ КАЗАНИ**

**Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)**